# Казан утлары

3

МАРТ-1976

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**3**

МАРТ
1976

## Бу санда

С. ХӘКИМ. Акты бозлар. Шигырьләр . . . . . 3
А. РАСИХ. Айлы төннәр. Роман . . . . . . . . 12
С. ГӘРӘЕВА. Әнкәм көлмәге. Шигырьләр . . . 91
В. РӘХМӘТУЛЛИНА. Хәтта хыяллардан ялгыз кайтма. Шигырьләр . . . . . . . . . . 92
Л. ИХСАНОВА. Үкенү. Хикәя . . . . . . . . . 94

ОЧЕРКЛАР

КамАЗ елъязмасы . . . . . . . . . . . . . . 120
М. МАЛИКОВА. БАМ башланган җирләрдә . . . 123
М. ЗАРИПОВ. Уракчы егетләр . . . . . . . . 134

ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ 90 ЕЛЛЫГЫНА

Р. ЯКУПОВ. Архивтагы язулар ни сөйли . . . . 145
И. НУРУЛЛИН. Тукай . . . . . . . . . . . . 153

ТӨРЛЕСЕННӘН

Й. ГӘРӘЙ. «Каләм», «Нур», «Ашкадар» . . . . 164

КИТАП КҮЗӘТҮ

Б. КАМАЛОВ. Егетлек хакында . . . . . . . . 172
Г. ЗӘЙНАШЕВА. Туган якка мәхәббәт белән . . 174

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

С. ШАКИР. Сез әпе дә уң флангта . . . . . . 176

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

К. ТИМБИКОВА. Дарулы сөт. Хикәя . . . . . 178
Г. АФЗАЛ. Иртә килгән көз. Шигырьләр . . . . 182
К. ЗАДӘ. Бер шагыйрьнең зары. Шигырь . . . 183
Бервакыт шулай була... . . . . . . . . . . 184

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов, Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**

Производствога бирелде 1/XII-1975 ел. Басарга кул куелды 10/II-1976 ел. ПФ 07046. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 91 544 экз. Заказ Я-480. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе, Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1976 ел.

## Сибгат Хәким

# АКТЫ БОЗЛАР...

•

Сугышның мөмкинлеге күп,
Төрлечә сугыш сынар...
Яшь, таза, кайнар иделәр
Мин күргән сугышчылар.
Беркетте күңелем гомергә
Шул яшь чагын сугышның.
Карт чагы буламы аның?
Була, кысыла сулыш-тын.
Берни эшләтә алмыйлар
Врачлар, зур табиблар:
Утыз ел узгач, очрашкач,
Елыйлар фронтовиклар.

•

Зур җиңүнең 30 еллыгында,
Торып сугышып алган үрләрдән,
Чыгышлары [1] белән яктырттылар
Докладымны минем үлгәннәр.

•

Суд үлемгә хөкем иткән, үлем...
Муса үзенең калган һәр көнен
Санап яши, яши, әсәрләрен
Ул соратып ала Дантеның.
Ничә тапкыр булып чыкты икән
Өтелеп җан утта, тән утта?
Керү аңа, юк, куркыныч түгел
Бер тәмугтан тагын «Тәмуг»ка.

•

Минага безнең солдатлар
Ялгыш басмасын өчен,
Алар үз вакытыннан элек
Күккә ашмасын өчен,

[1] Сугышта үлгән шагыйрьләрнең пластинкадагы тавышлары-чыгышлары.

Куялар иде саперлар
Кайчакта чыбык тертеп.
Күрмәдем, бастым берсенә
Хәтердән чыгып китеп.
Без өчәү, өчәү янәшә:
Үлем, мин һәм талчыбык,
Селкенми, мин дә селкенмим,
Торам өнсез, талчыгып.
Кем башлап дәшәр, тынлыкта
Кушар сүз алдан улмы?
Кузгалмый, мин дә кузгалмыйм,
Көтә кузгалганымны.
Һавага чөйгән ракета
Көзге бер кара төндә
Тикшерә: торамы кеше
Һаман шул халәтендә?
Тикшерә: туры киләме
Дигән кебек чынлыкка?
Сүнә аягым очында
Күрсәтеп шул чыбыкка.
Әйләнәм кебек урынымда,
Болганам утта-суда,
Без өчәү: үлем, чыбык, мин
Бу галәм уртасында.

## Ржев шигырьләре

●

Яз, март башы. Тагын мин Ржевта.
Тынгы белми һаман карт башым,
Килдем сагынып нәкъ утыз ел элек
Безне каршылаган март башын.
Идел өсте. Күзгә бәрә якты.
Сугыш минем чыкмый хәтердән,
Ә яшь кызлар берни булмагандай
Иделдә су ала бәкедән.
Әйтерсең җир яңа яратылган.
Үз бәхетен яңа татыган.
Яз, март башы, бар дөньясын онытып,
Кер чайкыйлар тып-тын хатыннар.

●

Карга бата-бата мин Ржевның
Урманына кердем. Я, шуннан?
Мин сугышкан урман... Танып булмый,
Каплап киткән аны яшь урман.
Бик кадерле төсләр... ул төсләрне
Югалтмаска күпме тырышма,
Һәр яңа чор катлау-катлау итеп
Үз төсләрен сала тормышка.
Авыр булды, кыен булды, беләм,
Ватылганмын, атлыйм көчкә мин,
Барыбер эзлим, карлар ерып эзлим
Бөек Ватан сугышы төсләрен.

●

Керде чорларның түренә
Текә Чаллы ярлары...
Бәрелеп-сугылып шунда
Үтәр кебек арбалы,
Моргунок үтәр шикелле,
Колак кагып йөгәннән,
Йөгәне белән урлатып
Атын юлда чегәннән,
Бәйләп ыңгырчаксыз гына
Аркалык аркасына,
Җигелеп үткән гасырның
Какшаган арбасына,
Аты урынына җигелеп,
Урап билгә дилбегә,
Моргунок узар шикелле
«Муравия иле»нә [1].
Сугышта аны очраттым,
Сугыш... юлга — барлык ут...
Булыштым «пробка»ларда,
Якын миңа Моргунок.
Ул еллар, сугышлар артта,
Күп герой үлгән менә,
Ул исән, үрләр төшә дә,
Яңадан үрләр менә.
Тукталып борылыш-чатларда,
Майлап арба күчәрен,
Минем хыялда гел шулай
Чордан чорга күчә ул.

## Өч тал

Кайтам да төшәм болынга,
Төшәмен «Шомыртлы»га,
Элекке елга төбендә
Су ага шыпырт кына.
Кайчандыр тирән иде ул,
Без үстек читтә коенып,
Ә хәзер йөри уртада,
Күмелми сиртмә койрык.
Бара ул нәрсәдер эзләп,
Саегып калган судан,
Койрыгы уйный, каләмне
Карага манган сыман.
Йөзәсе иде яшьлеккә
Бу ярдан колач салып,
Иске тегермән урынында —
Бары тик иске чарык.
Уйларым елга төбендә,
Уйларымнан гарыкмын,
Ишетә башлыйм бер вакыт
Шаулаганын чарыкның,
Ишетәм, ыргыла кинәт

[1] А. Твардовский. «Страна Муравия».

Чарыкның өстенә су,
Дерелди башлый бер вакыт
Тегермән стенасы.
Ишетәм, кемдер кычкыра
Сал, дип, тизрәк мөшкәгә...
Хисләрем гүя тегермән
Ташларында нечкәрә.
Иске бер тегермән урыны,
Яшьлек шунда буталган,
Бөкрәеп капчык күтәргән
Апалар күк бу таллар.
Иске тегермән, елганың
Буылган урыны монда...
Утырам зәңгәр тынлыкта,
Буыннар тынлыгында.
Бу ара... Татар да мари...
Бу ерак чик, бу ара
Гасырлар, Иделләр аша
Тоташа күк Болгарга.
Сәлам, Болын марилары!
Финн-угор, угор-финнәр,
Тарихта безнең язмышлар
Гел бергә туры килгән.
Бу ара... Җыела җилләр,
Куркыныч ае, төне,
Иске тегермән урынында
Төн буе мари түе...
Бу ара... ява яңгыры,
Ява аралаш кары,
Шушында табыла иртән
Югалган, адашканы...
Бу ара... Тәгәрәп үстем
Шушы җир туфрагында,
Киләм шатлыгым сөйләргә,
Я бергә уфтанырга.
Бу өч тал... легендаларның
Ниндиләре юк монда,
Язын чарыкның астында,
Кайнап торган упкында
Тегермәнченең өч кызы
Баткан, ышан-ышанма,
Сөйлиләр, чыккан ди алар
Әйләнеп шул өч талга...
Төрлечә күрдем аларны:
Моңсу, уйчан, көр, дәртле,
Берсе ак, берсе зәп-зәңгәр,
Берсе сары күлмәкле.
Иске тегермән урынында
Язы шаулый елларның,
Җыела яшьләр уенга,
Кыза уен, җыр, гармун...
Бу өч кыз читтә, уртага
Чакыра «Сарман» көе,
Иң күңелсезе аларга —
Таралгач сабан туе.
Җырны җыр йота, көйне көй,
Тыңлап ярда тал кала,

Ярда шул өч тал каршында
Тагын ике пар кала.
Бәхетле, тыныч көннәрне
Хәбәр итә таң алдан,
Күптәнге йөрәк серләрен
Яшергән күк таллардан,
Утыра ярда ике пар,
Аралары өч адым,
Саргая кебек йөзләре
Мәхәббәттән өч талның.
Шаулаган шулай ничә яз,
Җәе кыска, көз, яңгыр...
Картайды таллар, яшьлеге
Артта калды кызларның.
Төшәм тегермән урынына
Авылга кайту белән.
Сугышта кайсы хәбәрсез
Югалган, кайсы үлгән.
Башымны кая куярга
Белми эчем пошканда,
Төшәм дә сөйлим кайгымны
Замандашым өч талга.

●

Габделнасыйр Сабитов (1745—1840), каллиграф. 223 том кулъязма күчереп язган.

Кышкы озын кичләр. Салкын өйдә
Калган кайчак куллар күшегеп.
Төннәр, еллар буе ул утырган,
Ул утырган томнар күчереп.
Кузгалмаган, тәрәзәдән генә
Күз төшереп алган ул язга.
Һәр яшәгән елга икешәр том,
Ике йөз том китап-кулъязма.
Яндырылган, күмелгәннәр алар,
Тузаннарда аунап чормада,
Канашевич [1] күзләреннән качып,
Килеп җиткән безнең чорларга.
Габделнасыйр... Үзенең яше белән
Тиң кеше ул зур бер гасырга,
Китаплардан һәйкәл өяр идем
Әрдәнәләп Габделнасыйрга.

●

Кар дими, суык, җил дими,
Өстендә кайры туны.
Алып үз өстенә бөтен
Агарту-кайгыртуны,

[1] Канашевич — миссионер.

Йөрде авылдан-авылга
Кечкенә чана тартып,
Кай көнне күбрәк, кай көнне
Өч кенә данә сатып.
Йөрде китап сатып. Кайдан?
Исеме ничек, ни атлы?
Бары тик чанасы истә,
Тунлы кеше, китаплы...
Ямь керде өйгә, ә тышта
Җиһанның тоташ кары,
Эштән соң китап тыңларга
Әтинең чордашлары
Җыелды кичен. Җан керде.
Шунда бер читтә посып
Тыңладым, кайда Зөләйха?
Кайда, дип, хәзер Йосыф?
Ишек төбендә бозлы су,
Берәм-берәм чүмечләп
Эчтеләр — янган йөрәккә
Торды алар су өстәп.
Кызсалар, кисәтте әти:
Укыйм, имеш, кем өчен?
Куйды Хәзрәти Галинең
Ялтыратып кылычын...
Тышта кар теге кешенең
Әйтерсең кайры туны...
Адашса буранда? Кинәт
Күңелгә кайгы тулды.
Китаплы, диләр, адашмас,
Кетмәстән авылларны
Уятып таңда, кар баскан,
Көрт баскан авылларны
Урыйдыр... Арса, түбәнгә
Шуар чанасы белән,
Гасырлар эченә шуар
Чуар чанасы белән.
Юктыр газаплы, кыен юл
Китапның юлы кадәр,
Үлмиләр, яшиләр озак
Йосыфлар, Зөләйхалар.

●

Китә авылыннан, өйләнә,
Эшен эшли казнаның,
Читтә, еракта каршылый
Ул гомеренең азагын.
Картая бервакыт, йончый,
Туймый башлый саулыкка...
Исенә төшә бала чак:
Туган җирдә, таллыкта
Онытылып беткән чишмә бар,
Улагы яшел мүкле,
Сагына шул иске чишмәне,
Таллыкны-яшеллекне.
Итсә дә хезмәт бик озак

Еракта үз авылыннан,
Ә гомер дигәнең аккан
Шул чишмә улагыннан.
Кайтасы иде, күрәсе,
Тезләнеп чүгәләсе...
Шунда рух. Кайдадыр йөргән
Гәүдәсе, күләгәсе.
Рух шунда, шунда аерылып
Калганга ул тын икән,
Баса сусауны, ә үзе
Бер генә йотым икән.

●

Карт кеше, борчу уңайсыз,
Эш төшә, эзләп керәм,
Яшьләр шигырьдер, Туфаннан
Мин сәгать төзәттерәм.
Тазарта төрле вак-төяк
Кәгазьдән эш өстәлен,
Кия күзлеген, өстәлгә
Куя лупа, эскәген.
Янтая бераз, иелә,
Ул сөйли башлый, көтәм,
Актара, мактый сәгатем:
Унсигез ташлы икән...
Шагыйрь — сәгатьче, күзәтәм,
Сиздерми эчтән көләм,
Каптыра кылын, шигырьнең
Рифмасын эскәк белән
Ләктерә төсле... Уйланып
Өемә атлыйм сүлпән,
Туфан сәгатем сүткән күк
Язганым кире сүтәм.

●

Килергә ярый дөньяга
Ташлап читкә бар эшне,
Тик укыр өчен генә дә
Шәехзадә Бабичны...

## Суд дәфтәреннән

Шулай язган. Өйдә утырышчы,
Судта утырышчы.
Гомер буе утырышчы... Судья
Чыгар, укыр эшне...
Мин күз салдым алда каралачак
Төрле язуларга,
Урамда яз, яшьләр, бала-чага,
Шаулый яз урамда.
Сагынырлык олы булсын яшьлек,
Якты булсын узган...

Акты бозлар Казан елгасында,
Зәңгәр-моңсу бозлар.
Иделдә яз, калын, көр тавышы
Барлык елгаларның,
Шундый чакта тыңлап утыр судта
Бала елаганын...
Керде кеше судья булмасена,
Ямьсез, кара кеше,
Бу эштән соң әрнеп минем йөрәк
Һаман канар төсле.
Больницада яткан хатынының
Үлемен ашыктырып,
Керде монда, ә бер читтә торды
Яңа гашыйк көлеп.
Хатыныннан котылырга, безне
Каравыллый, кереп,
Шушы кеше басты минем алга
Кара үлем булып.
Больницадан судка язу: «Кыен
Әгәр аерым булсаң,
Көтмәгез, мин бәхил, мин мәңгегә
Үзем аерылышам...»
Үлемнең мин таныш идем элек
Эскизлары белән,
Бүген аны суд залында күрдем
Үз күзләрем белән.
Сагынырлык олы булсын яшьлек,
Якты булсын узган,
Акты бозлар, саубуллашып акты
Соңгы моңсу бозлар...

●

Чыга бер, чыга серләр дә
Тирән су төбендәге,
Һәр авыл саен бар иде
Элек су тегермәне.
Бикләсә берсе буасын,
Куйса ябып улагын,
Икенче тегермәнчегә
Дошман иде ул авыл.
Әмер шул: кара, тотылма,
Бирелмә тере килеш...
Яшермим, җибәрә идек
Буага терекөмеш.
Күзәтә идек уйнаклап
Иң төпкә йөгергәнен...
Келтерәп тартып утырган
Иҗатым тегермәнен...
Туктатса кемдер, хәзер мин
Болынга төшеп, эзләп
Китәмен шунда хисләрнең
Буылган төшен эзләп.
Табамын эзләп җыелган,
Бөялгән күлләр суын,
Бала чактагы шикелле

Саламын Күнә суын,
Саламын малайлар кебек
Шук, шаян терекөмеш...
Ташыту хисләр елгасын
Һаман да минем төп эш...

●

Төрлесе булды тормышта,
Иҗат бит ул — чынбарлык,
Әйткән чакларым аз түгел,
Ярый, авылым, син бар дип.
Төрлесе булды тормышта,
Сугышып җаным арса,
Кыйналып яки хаксызга,
Нахакка җәберләнсә,
Егылдым сиңа, һич түгел
Өстемдә түбәм юктан,
Иҗаттан түгел, һәртөрле
Ваклыктан-түбәнлектән
Качып мин сиңа егылдым,
Кайттым, синдә савыктым,
Шатландым һәр чак эчемнән,
Йөрәгемдә сау утым.
Тыкрыкка кергәндә һәр тал
Кул бирде, дәште танып.
Барсы да синдә дәвалый,
Барсы да синдә табиб.

●

Күреп азагы гомернең
Якынлашып килгәнен,
Ашыкмый, түгәрәк итеп,
Очлап аның кибәнен,
Һәр вакыт олы, зур булып
Аталарча киңәштә,
Сәламең алып ерактан,
Бата барган кояшта
Елмаеп, елынып утырган
Хөрмәтле картларына,
Яшен яшәгән, картлыгын
Хезмәте акларына
Ышанып горур утырган
Шул авыл картларына
Сокландым, кешенең йөзе,
Паспорты капка монда.

●

Көз. Аккош күле, аерылып
Күп мәләкләр кала,
Шигырьләр, өстәлдә үлгән
Күбәләкләр кала.
Китәләр.... Аккош урманы,
Өйләр шәрә кала,
Гомернең кыскалыгына
Ишарәләр кала.

1975

**Атилла Расих**

# АЙЛЫ ТӨННӘР

РОМАН

## 19



Урал» газетасы белән бер үк вакытта дип әйтерлек Оренбурда чыга башлаган үтә кадим «Дин вә мәгыйшәт» журналының яңа сул газетаны ни дәрәҗәдә яратмаячагын һәм булдыра алган начарлыкларны эшләячәген Хөсәен журналның беренче санын карап чыккач та сизенгән иде. Ләкин көрәшнең мондый формада башланачагын башта күз алдына да китермәде.

Һәрхәлдә, корректор белән булган хәлдән соң икенче көнне ул, иптәшләре белән киңәшкәч, мондый эшләргә катгый рәвештә чик кую өчен клерикаль журналның башында торучы Вәли мулла белән очрашырга кирәк дип тапты. Шулай кирәк иде. Көрәш икән — ул ачыктан-ачык, намуслы рәвештә алып барылырга тиеш. Әгәр алар матбугат әһелләре икән — бәхәс өч кадаклы гер белән түгел, нигезле исбатлау ысулы белән газета-журнал битләрендә башкарылырга тиеш. Шуның турында тәкъсир белән бер моназара кылышып утырмыйча ярамый.

Ләкин бу эшнең җайсызлыгы да бар иде. Ул да булса, Хөсәеннең асылда рәсми мөхәррир түгеллеге Вәли мулла белән бәхәс алып барырга комачаулый. Хөсәеннең «Урал» исеменнән сүз кузгатуы да, ахыр чиктә, үз-үзенне фаш итү булачак. Ул, шуларның барысын да уйлап, «Дин вә мәгыйшәт» идарәсенә Хәдичә белән бергә барырга булды. Сүзне, әлбәттә, Хәдичә алып барачак, ә кирәк икән, аңа ярдәмгә Хөсәен һәр вакыт әзер булып торыр. Хөсәен хәл-әхвәлне Хәдичәгә аңлатты.

— Мин бара алмам, ахры, — диде Хәдичә.

— Син анда барырга тиеш, Хәдичәкәй, чөнки мин ялгыз гына барсам, уңайсыз булачак. Хәлне аңлыйсың бит.

— Хөсәен, син бит миңа җибәрелгән аноним хатны укыдың...

— Менә шундый нәрсәләр булмасын өчен, без бергә барып, аларга протест белдерергә тиеш. Юкса, дәшми калуны алар куркаклыкка санаячаклар.

---

[1] Ахыры. Башы 2 нче санда.

— Мин, Хөсәен, битемә төкереп, хәкарәтләп чыгаруларын теләмим. Минемчә, аларга барып йөрү үзе бер түбәнлек, ялынып, алардан шәфкать көтү.

— Әбез үзебезне тиешенчә тотарбыз, мескенләнмәбез.

— Юк, юк.

Хөсәеннең йөзенә кызыллык йөгерде. Ул ачуын басып, мөмкин кадәр тыныч булырга тырышты:

— Җанкисәгем, бу бит бер минем генә теләгем түгел. Без, һәрьяклап уйлашып, шундый карарга килдек,— диде.

— Нәрсә, партия йомышы дип әйтмәкче буласыңмы?

— Әйе, — диде Хөсәен, чәчләрен артка сыпырып. — Шулай дип аңларга кирәк!

Хәдичә ап-ак эскәтер ябылган өстәл янында кулларын алъяпкычына төргән хәлдә утыра иде. Ул башын тагы да аскарак иде, кашларын җыерып, тынып торды.

— Хөсәен, карачы, канатым, нигә син мине бер дә җәлләмисең? Мин бит синең хезмәтчең түгел ләбаса, ә, әйтүеңә караганда, сөекле хатының. Миңа әллә башка хатыннарча яшәргә язмаганмы? Иртә таңнан торып китәсең, төн уртасында кайтып керәсең. Әле ул гына җитмәгән, син мине күрәләтә янган учакка тыгасың. Син партия йомышы дисең. Син минем партия әгъзасы түгеллегемне онытасың, ахры. Аңла, Хөсәен, аңла, кадерлем. Мин сине бик яратам. Ләкин син мине болай җәберләп яхшы эшләмисең.

Хөсәен бу кадәресен көтмәгән иде. Ул, тетрәнеп, бераз вакыт өнсез торды.

— Безнең бит, Хәдичәкәй, хәзергә шундый чорыбыз.

— Мин белеп торам: ул мәңге шулай булачак.

Хөсәен утырган урыныннан торып, бүлмә буенча әрле-бирле йөренә башлады.

— Син беренче авырлыклардан соң ук сыгылып төштең, Хәдичәкәй. Тик хәтерлә әле. Мин Казаннан чыгып киткәндә барысын да синең үз иркеңә куймадыммы? Теләсәң, минем арттан бар, ләкин мин сиңа беркайчан да җиңел тормыш вәгъдә итмим, дидем. Рәхмәт, син Уфада миңа әйбәт булыштың, беркайчан сыкрану, авырсыну сүзләре ишеттермәдең. Ни булды сиңа?

— Мин арыдым, Хөсәен.

— Юк, син арымадың. Мин сиңа арымасын өчен барысын да эшлим. Эш башкада, минемчә, Хәдичәкәй. Син просто безнең эшнең уңышлы чыгачагына ышанмыйсың.

Хәдичә дәшмичә башын игән килеш утыруында булды. Аның күзләре яшьләнеп китүен күргәч, Хөсәен йөрәгенең авырттырып кысылганын тойды. Ул ашыгып Хәдичә янына килде.

— Ярар, Хәдичә, кирәкми, ташла,— диде.— Синнән бары бер нәрсә генә үтенәм. Син мине «Дин вә мәгыйшәт»кә үз исемеңнән сөйләшү өчен вәкил сыйфатында җибәр.

— Ничек инде?

— Менә шуны Вәли хәзрәткә хат рәвешендә язып бир.

Хәдичә Хөсәеннең эш өстәле янына барып утырды да кулына каләм алды.

— Әйтеп тор.

«Мөхтәрәм Вәли әфәнде җәнаблары! Сезнең илә бик мөһим мәсьәләләр тугрысында үзем сөйләшергә теләсәм дә, имкяният булмау сәбәпле, вәкил сыйфатында шушы хатны Сезгә тапшыручы әфәндене җибәрәм. Аңа мин барысын да аңлаттым. Ул әйткәннәрне минем сүзләрем дип кабул итегез.

Хөрмәт илә «Урал» газетасының мөхәррирәсе: Хәдичә Ямашева».

Хәдичә язуны конвертка салды, конвертның тышына «Дин вә мәгыйшәт» нашире имам Вәли Хөсәенов җәнабларына» дип язып куйды.

Хөсәен конвертны кулына алгач:

— Ярар, рәхмәт, хәзер мин аның белән сөйләшеп багыйм инде,— диде.

Хәдичә, каерылып, иренә тәнбиһле караш ташлады. Моны, кара аны, син минем исемнән сөйләшәсең, алай-болай булса, аның авырлыгы миңа төшәчәк, дип аңлады Хөсәен.

— Хафаланма,— диде,— мин карагруһлар башлыгы алдында сынатмам! Ә синең арып китүең турындагы сүзне кәефең әйбәт чагында дәвам иттерербез.

Хөсәен сәгатенә карап вакытны белде дә ашыгып киенә башлады.

— Аннан соң мин идарәгә барам, Хәдичәкәй, озакласам, борчылма, — диде. — Миңа капкаларга бирәр әйбер әзерләп куярсың, суынса да ярар.

Хөсәен киенде дә папирос кабызып чыгып китте.

— Йа хода,— дип куйды Хәдичә,— бернинди рәхәт күрми бит бичаракаем.

Хәлбуки, Хөсәен җил-җил атлап, җиңеләчәк дошман белән якалашуның ләззәтен алдан ук тойган хәлдә, бик дәртләнеп бара иде.

Вәли хәзрәтне ул «Дин вә мәгыйшәт» журналы редакциясендә очратты. Хөсәеннең әле кадимчелекне эзлекле һәм сугышчан рәвештә гамәлгә ашырырга тырышучы бу фанатик мулланы беренче тапкыр күрүе иде. Шактый чибәр, хәтта мөлаем диярлек, башына кара кәләпүш, өстенә утырма якалы озын казаки кигән кеше каршы алды аны. Нашир мулланың кап-кара мыегы һәм сакалы нәкъ Мөхәммәт пәйгамбәр кушканча үстерелгән. Мыек төкләре кыскартылган, ә сакал иякта генә түгәрәкләндерелеп калдырылган иде. Гомумән, Хөсәен, бу усал хәзрәтне күреп, башта аптырабрак калды. Данлыклы Гани бай Хөсәеновның улы, Бохарада укып кайтып, атасының юлыннан китмичә, карагруһ динчеләр лагеренең җитәкчеләреннән берсенә әверелгән бу кешене мондый итеп күз алдына китермәгән иде ул.

Хәзрәт Хөсәеннең сәламен алып:

— Вәгаләйкем әссәлам,— диде. Хөсәен шулай да хәзрәтнең беренче мимика һәм интонациясеннән үк шуны аңлады: әйе, бу үзен шактый югары бәяли торган кеше, ахры. Тәгаен бик көчле натура булырга охшый.

— Мин сезгә «Урал» газетасының мөхәррирәсеннән вәкил сыйфатында килдем,— диде Хөсәен.

— Аңлыйм, аңлыйм,— диде Вәли хәзрәт көлемсерәп.— Хәдичә ханымда шәригать кануннарына хөрмәт ул кадәр бетеп җитмәгән икән әле, ирләргә йөзен күрсәтергә батырчылык итми, намәхрәм икәнлеген аңлый. Утырыгыз.

Хөсәен, эчтән генә ачуы килеп, зур өстәлнең уң ягындагы венский утыргычка чүкте.

— Ул кадәресенә керешә алмыйм, ихтимал, шулайдыр, ихтимал, башка сәбәпләре дә бардыр. Менә ул сезгә хат тапшырырга боерды миңа.

— Бирегез, укып карыйк,— диде Вәли, хатка үрелеп. Өстәлдә яткан озын кайчы белән кисеп ул конвертны ачты, хат юллары буйлап күзләрен йөгертә башлады. Аннан авызын чалышайта төшеп, уң азау тешен суырып куйды. Тагы бераз вакыт хатка карап торды. Хөсәен шунысына игътибар итте: хәзрәтнең йөзендә бер генә тамыры да тибрәнмәде, бары күзләре генә ныграк ялтырый башлады. Аның йөзендә әле һаман беренче күргәндәге ярым елмаю чалымы сизелә иде.

— Хуш,— диде ул, ниһаять.— Кем дип белик сезне, вәкил әфәнде? Хөсәен үзенең исем-фамилиясен әйтте.

Хәзрәтнең елмаюы ачыктан-ачык бөтен битенә җәелде. Ләкин бу елмаю ягымлы, дустанә елмаю түгел иде.

— Барысы да аңлашыла хәзер, Хөсәен әфәнде,— диде ул. — Сез минем тарафка килеп сүз башларга ниятләгәнсез икән, башта ук, берсен дә яшермәскә, ачыктан-ачык сөйләшергә, дип сүз куешыйк. Ачыктан-ачык, алдашмыйча, пәйгамбәребез Мөхәммәтел саллаһыл вәсәллигалә кушканча. Ризамы?

— Мин каршы түгел. Сез моңа әңгәмә барышында бик тиз ышанырсыз да.

— Менә, алайса, әфәндем, шундый сорау. Рәсмиян сезнең газитәнең мөхәррирәсе сезнең хәләл җефет исәпләнсә дә, хакыйкатән газитнең мөхәррире сез бит?— Хәзрәт, пистолет төзәгәндәй төбәп, Хөсәенгә имән бармагын сузды. — Дөресен әйтегез. Шулай сүз куештык.

— Әйе,— диде Хөсәен.

— Бәс, шулай булгач, сез минем вәгаземне бераз тыңлап утырыгыз. Кичерегез, без муллаларның һөнәре шул инде: вәгазь сөйләү.

Хөсәен мыек астыннан гына елмаеп, «агитация башлана» дип уйланды.

— Мин сезгә, әфәндем,— дип тезеп китте хәзрәт,— аятьләр укымам, безнең динебез, аннан килеп шәригатебез турында да сөйләмәм. Мин бары сезгә үземнең мәсләгем, тоткан юлым турында гына кайбер төп мәсьәләләрне изһар итмәкче булам. Сез, җәдитчеләр вә социалистлар, бик ялгыш юлда торасыз. Сезнең гамәлегез, әфәндем, исламга, шәригатькә каршы гына юнәлмәгән, агяһ булыгыз, ул иң әүвәл безнең милләтебезгә инкыйраз[1] әзерләү, аның нәселен-нәсәбен бетерү. Инзар итәм, хакыйкатән бу шулай. Сез инде бу ысулы кадимчеләргә карыйсыз да, җаһилләр болар, наданлыклары аркасында дингә ябышып яталар, дисез. Хәлбуки, гаять ялгышасыз. Әлбәттә ки, безнең мәсләктәшләр арасында җаһилләр дә бар. Ә сездә юкмыни ул? Шул ук мин социалист дип йөрүчеләр арасында әлифне таяк дип уйлаучылар юкмыни?

Минем әтием, мәрхүм Гани бай, урыны җәннәттә булсын, гомере буена үзе дә хатадан хали була алмады. Халыкны укытырга кирәк, исәп-хисапны шәп белүче, башлы управляющийлар кирәк безгә дип, мал-мөлкәтен аз исраф итмәде. Эш шуңа барып җитте ки, хәтта мәрхүм әтиебез Каргалыда кызлар мәктәбе ачу кебек ахмаклыклар эшләп ташлады.

Вәхаләнки, бу гаять дәрәҗәдә зур ялгышу. Мин моның хата юл икәнлеген бик күп күзәтүләр вә уйланулар аша белдем.

— Бик кызык, нинди күзәтүләрегез булды соң сезнең?— диде Хөсәен.

— Сабыр. Барысы да үз нәүбәте белән әйтелер. Мин атамның гамәлен бизмәнгә салып үлчәү өчен бер төнемне түгел, мең төнемне йокысыз уздырганмындыр. Ахырда мин аның юлыннан ваз кичәргә мәҗбүр булдым. Чөнки халыкны агарту, яурупалаштыру ул — гамәлдә руслаштыру, бетерү дигән сүз. Сезнең игътибар иткәнегез юкмыни, әфәндем, берәр байбәтчә урыс телен үзләштерсә, мотлакан үз денендә генә түгел, теленә дә төкереп, нәфрәт белән карый башлый.

— Мин, мәсәлән, рус телен әйбәт беләм, әмма үз телемне элеккечә тәкъдир итәм.

— Сез... Сез ул меңгә бер, Хөсәен әфәнде. Анда да, әгәр ул тел, сезнең нинди дер шәхси мәнфәгатегез өчен кирәк булмаса, күптән оныттылыр иде.

— Әгәр дә мин гади бер тофәйли булсам, әлбәттә, шулай. Ләкин

[1] Инкыйраз — бетү.

миллэтне тэрэккый иттерүчелэр алар иҗтимагый мэнфэгатьлэр белэн яшэүчелэр бит!

— Менэ без, мэсэлэн, дин эһелләре — миллэт терэклэре. Эгэр дэ мэхэллэдэге барлык сез эйткэн тофэйли[1] динен дэ, телен дэ онытса, мэсҗетнең вэ имамның кирэге калыр идеме соң?

— Миңа барысы да ачык, тэкъсир,— диде Хөсэен,— ахыр чиктэ сезнең тырышлыкларыгыз бары үзегезнең имамлык вазифасы өчен икэн. Инде мин, рөхсэт итсэгез, сезгэ килүемнең төп максатын эйтмэкче булам.

Хэзрэт күңелсезлэнэ төшеп:

— Эйтеп карагыз,— диде.

Хөсэен дэ нэкъ хэзрэт кебек иттереп аңа имэн бармагын төзэде.

— Тэкъсир, турысын эйтегез, шулай сүз куештык, — диде. — «Урал» мосаххихы[2] Басыйр эфэндегэ сезнең боерык белэн һөҗүм ясалдымы?

Хэзрэт кинэт сискэнеп артка чигенде.

— Ни сөйлисез сез?! Нинди мосаххих? Андый сүз эйтеп, кешегэ яла ягу гөнаһысыннан ничек курыкмыйсыз сез, Хөсэен эфэнде?!

— Менэ, күрэсезме, сез эңгэмэнең башында ук шартны боздыгыз. Чөнки мин бит эшнең ничек булганын бик анык белэм, тэкъсир.

— Шарт бозылмады, Хөсэен эфэнде. Эгэр дэ андый вакыйга булган икэн — ул минем кушуым буенча түгел. Ул кемнеңдер мине ялгыш аңлавы аркасында.

— Сез, димэк, ишан үз мөритлэренең гамэле өчен җавап бирми дип уйлыйсыз?

— Юк, юк, алла сакласын, миңа бернинди дэ гаеп такмагыз. Бу эш бөтенлэй минем катнашымнан башка эшлэнгэн. Мин битараф.

— Ярар, мин төпченеп тормыйм, хэзрэт. Тик «урал»чылар исеменнэн шуны талэп итэм: эгэр моннан соң да шундый берэр эш кабатланса, без дэ саклану чараларын күрергэ тиеш булырбыз. Онытмагыз, гади халык, хезмэт халкы — безнең яклы, алар «урал»чыларны яклый алырлар.

— Моннан соң андый эшкэ юл куймабыз, үрнэкне сездэн алмабыз,— дип куйды Вэли көлемсерэп.

Хөсэен гаҗэпсенеп аңа текэлде:

— Нинди үрнэк ул?

— Ничек эле, «террор» дисезме аны?

— Юк, тэкъсир, сез безне социал-революционерлар белэн бутыйсыз.

— Барыгыз да бериш инде,— диде хэзрэт.— Шуңа күрэ без сезнең белэн беркайчан да тату яши алмабыз.

— Аңысы бик табигый. Без ике сыйныф вэкиле...

— Куегыз эле шул сыйныф дигэн сафсатагызны! Безгэ менэ хэзер бердэм булып динебезне, телебезне сакларга кирэк. Халык тэмам бозылды. Олыларга хөрмэт бетте. Угрылык, зина, ялган сүз бөтен мөселман дөньясын черетэ. Вэ сез шундый аяныч ы бэрвакытта, дэҗҗал кебек, халыкларны, миллэтлэрне, дин вэ йолаларны таркатып, ниндидер мэгънэсез сыйныфлар турында сөйлэнеп, Мөхэммэт өммэтенең күңелене вэсвэсэ саласыз. Мин сезнең гэзитегез дингэ вэ миллэткэ хезмэт итэр дип өметлэнгэн идем. Гакысе[3] килеп чыкты.

— Без, хэзрэт, сезнең белэн беркайчан да уртак тел таба алмаячакбыз шул,— диде Хөсэен. — Тик сүз көрэшне нинди рэвештэ алып бару турында гына бара.

---

[1] Тофэйли — обыватель.
[2] Мосаххих — корректор.
[3] Гакысе — киресе.

— Көрәш сез теләгән рәвештә булыр. Тик упкәләштән булмасын, без денебез өчен вә телебез өчен жаныбызны кызганмабыз.

— Андый бирелгәнлек вә фидакарьлек ифрат мактауга лаек, тәкъсир, тик мин гамәлегез үзегез бәян иткән декларациягездән аерылыр дип куркам. Сез дә, сукыр эсерлар кебек, террор юлына басарсыз кебек.

— Нидән чыгып әйтәсез сез аны?

— Нигә, сезгә безнең газетаның икенче саны килмәдемени әле? Безнең хәбәрчебез анда сезнең әле әйткән сүзләрегез коры сүз генә булып калганын исбат итә. Укып күрсәтимме?

Нашир «укы» дигәнне аңлатып ияк какты.

— Менә ул: «Җиденче гыйнвар, кич сәгать биштә Мәхмүт Хәсәнов йортында мөселманнарның хосуси җәмгыятьләре улды. Бу мәҗлестә киңәш итәргә чакырылуга сәбәп: Уфа мөфтисенең Петербург шәһәренә киңәшергә чакырылу хәбәредер», — дип укыды Хөсәен. Газетада мөфти, моңарчы эшләгәнчә, Петербург бюрократиясенең һәр эшенә кул куеп утырмасын өчен аның белән бергә ике вәкил сайлап җибәрергә булулары турында язылган иде. Ләкин вәкил итеп сайланган кешеләрнең берсе булган Вәли мулла вәкиллектән баш тарткан. Мондый эшләр өчен вакыт әрәм итеп йөрү тиеш түгел, дип әйткән, имеш...

Хөсәен укып бетерде дә сорау белән хәзрәткә текәлде.

— Мәкаләгездә җавап биргәнсез бит инде,— диде хәзрәт.

— Ни дип?

— Мондый эшләр өчен вакыт әрәм итеп йөрү тиеш түгел дип. Шуңа күрә мин барырга теләмәдем.

— Яхшы,— диде Хөсәен, мыек астыннан гына елмаеп. — Ә ни өчен соң утыз җиде кеше арасында сез дә кеше сайларга кирәк дип кул күтәрдегез?

Вәли мулла, күрәсең, үзен артык тыныч тотарлык хәлдә түгел иде.

— Аңысын мин, әфәндем, үзем беләм инде. Сезнең алда хисап биреп тормам. Ә менә сез, әфәндем, шул ломовой извозчиклар телендә чыгара торган газитегез өчен бүген булмаса иртәгә җавап бирерсез.

Хөсәен урыныннан торды.

— Без бит сезнең белән намуслы рәвештә, үзара, ир-егетләрчә көрәшергә булдык, хәзрәт. Әле сезнең донос ясарга да исәп бармыни?

— Аңысы турында мин сезгә, әфәндем, хисап бирергә уйламыйм.

— Юк, сез безнең өстән доноослар яза башласагыз, аннан башка да юк дәрәҗәсендәге абруегызны бөтенләй бетерәчәксез. Шулай, хәзрәт. Киләчәк күрсәтер. Хушыгыз...

Хөсәен торды да нашир бүлмәсеннән чыгып китте. «Ярый», дип уйланды ул, юлда кайтканда канәгатьләнеп. Чөнки эшләнәсе эш эшләнгән иде.

## 20

Хөсәен Гафурга язган хатында «Урал»ның Казан эшчеләрендә тудырган тәэсире белән кызыксынган иде. Ул шулай ук газета укучыларның «Урал»ны ниндирәк итеп күрергә теләүләрен, ниндирәк кимчелекләрен абайлауларын сорап та язды. Шул ук хатында газетаны тарату мәсьәләсенә кагылып, Хөсәен шәһәрдә генә түгел, бу эшне мөмкин булганча авыл җирендә дә оештырып булмас микән? дигән сорау белдергән. «Әлбәттә, бу якта да авыллар бар, андагы кешеләрнең фикере белән мин кызыксындым вә бик мәмнүн булып калдым,— дип язган иде ул хатында. — Ләкин, ни генә әйтсәң дә, мондагы крестьянның хәле белән безнең як крестьянының хәлен чагыштырып булмый. Оренбур, Бозаулык ягындагы крестьянны безнең яклар дәрәҗәсендә җир кытлы-

гы борчымый, мондагы крестьян безнең як крестьяны кэбек ук хәерчелектә яшәми, монда җир саталар алар, монда чирәм җирләрне арендага биреп сөрдерәләр, монда татар казаклары да аз түгел, үзең беләсең, алар инде Минзәлә яхут Әлмәт крестьяннары түгел».

Гафур беренче санны укып бик шатланган хәлдә, аны Пороховой эшчеләренә дә, Алафузов заводларында эшләүчеләргә дә, хәтта Гыйльфан ярдәмендә Крестовников заводы эшчеләренә дә җиткерергә тырышты. Нәтиҗә көтелгәннән дә яхшырак булып чыкты. Һәр җирдән афәрин һәм рәхмәт сүзләре генә ишетелде. Хәзер инде яшерен татар түгәрәкләре өчен рәхәтләнеп файдаланырлык кулланма бар иде. Галиәсгар Камалның «Мәгариф» көтепханәсенә килгән «Урал» газетасы һәм аңа кушымта булып чыккан брошюра бик тиз сатылып бетте. Дөресен генә әйткәндә, шул дәрәҗәдә тиз таралды, охранка аңына килеп тентү ясарга керешкәндә ни газетаның, ни китапчыкның бер генә нөсхәсе дә калмаган иде.

Бу көннәрдә Пороховойдагы Гафур укыткан мәктәптә кышкы каникул көннәре башланды. Гафурда, дустыннан килгән хатны укып чыкканнан соң, дуамал бер теләк туды. Ничек булыр, әгәр дә ул, берәр якын дус табып, шул каникул көннәрен сәяхәттә уздырса? Ул, гадәттә, һәр җәйне авыл тирәсендә, күбрәк үзе үскән Кузнецк якларында уздыра иде. Ләкин, кызганычка каршы, аның быелгы җәйге ял вакыты Казанда гына узды. Ул үзенең беренче елда ук башланган пьесаларын язу белән шөгыльләнде. Хәзер исә авыл җиреннән көн саен берсеннән-берсе күңелсезрәк, хәтта дәһшәтле хәбәрләр ишетелеп тора. Халык ач, тиф чиреннән кырыла. Бу хәлне Гафур бик авыр кичерде, аның авылдагы хәлләрне үз күзе белән күреп, нинди дә булса ярдәм күрсәтәсе килә иде. Кем белән генә юлга чыгарга соң? дип байтак вакыт баш ватканнан соң, ул Галиәсгар Камалга тукталды. Бу — күптәнге дус, мәсләктәш. Бишенче ел вакыйгаларында Камал да, Гафур кебек үк, патша сатрапларына каршы көрәшкән кеше. Алай гына да түгел, аның революцион һәм мәгърифәтчелек эше көннән-көн күтәрелә, көчәя бара. Әгәр эшне гаиләсе белән җайлый алса, ул Гафурның тәкъдимен хуплап каршы алырга тиеш.

Гафур эшне озакка сузмыйча, Галиәсгар өенә китте. Бәхеткә каршы, Гафурның юлы уңды. Галиәсгар китап сәүдәсендәге борчуларына да, «Шәрык клубы» бинасында даими театр оештыру мәшәкатьләренә дә һәм, ниһаять, үзенең яңа пьеса язарга керешүенә дә карамастан, дустының тәкъдимен шундук кабул итте.

— Ә җәмәгатең? — дип сорады Гафур, «ул рөхсәт бирерме соң?» дигәнне күздә тотып. Галиәсгар хәтфә-кара матур күзләрен җемелдәтеп елмайды.

— Күндерәбез аны, ходай насыйп итсә!

Алар маршрут билгеләргә керештеләр.

— Иң муафигы Әлмәткә юл тоту, — диде Гафур (ул алдан ук бу мәсьәлә турында уйланган иде), — чөнки анда бару фиргавеннәр күзенә төтен җибәрәчәк.

Ул, «аңладыңмы» дигәндәй, Галиәсгарга карап торды.

— Бераз төшенәм, — диде Камал. — Анда кунакчыл либерал Якуп әфәнде яши.

— Әйе, әйе. Анда кунак булып ятучылар өзелми. Атласые да, Гаяз Исхакые да, әлхасил, барысы да — татарның бөтен күпчелек милли зыялылары. Өстәвенә, шунысы да бар: Хөсәен Ямашев Якуп әфәндегә кияүгә чыккан сеңелесе өчен бик борчылып яза. Ни әйтсәң дә...

— Анысын да аңлыйм, — диде Галиәсгар.

— Мәсьәләнең өченче уңай ягы бар, ул да булса, Якуп әфәнде

аргамагына утырып, без андагы тирә-юнь авылларга чыгып йөри алачакбыз. Бу исә хәвефсез бер эшкә әйләнәчәк. Бәлки әле бай әфәнде безне үзенең атларында Казанга да озатып куяр.

— Кайтканда Минзәлә якларына сугылырга кирәк, — диде Галиәсгар. — Халык анда ачлыктан интегә икән.

— Ә хөкүмәт бернинди дә чара күрми. Аның тарафыннан җибәрелгән ризык ачлар авызына барып җиткәнче, земский начальство чинушалары кулында сеңеп кала. Әйткәнең дөрес, бу башбаштаклык турында матбугатта язып чыгарырга кирәк, имеш-мимешләр белән коралланып түгел, ә үз күзебез белән күреп, халыкның аһ-зарын үз колакларыбыз белән ишетеп язарга кирәк.

— Мәслихәт!

— Барганда, әлбәттә, Чистайга тукталырбыз, — диде Гафур. — Шулай ук, фиргавеннәрнең борыннары томалансын өчен, Зариф Бадамшиннарга төшәрбез.

Әлбәттә, Гафур Бадамшиннарга эзне югалту өчен генә төшүне күздә тотмый иде. Ул Зариф Бадамшин белән Хәдичәнең арасын яхшыртып, бернидәр бу мәсьәләдә дә Хөсәеннәргә ярдәм күрсәтеп булмасмы дип уйлый иде. Узган җәйне, Хөсәен яшерен рәвештә Казанга килеп чыккач, Хәдичәнең ата-анасы белән үзе арасындагы суыклыкны бик авыр кичергәнлеген сөйләгән иде. Дусның теләген үтәми булмый.

Хәзерлек эшен бик тиз тоттылар. Алып куясы әйберләрне бүген кичтән үк җыеп, саквояжларга салып куярга, ямщик белешергә һәм иртәгә иртә белән үк сәфәр чыгарга!

Кышкы юлны дусларның икесе дә сагынган иде.

Лаеш тракты буйлап Казаннан чыгышлый, Архиерей дачаларына җитәрәк, Галиәсгар кәефләнеп җырлап та җибәрде. Гафур ул җырны белми иде. Ул элмайган килеш, шулай ук иркенлек рәхәтен кичереп, җыр тыңлап барды. Ә Галиәсгар бик шаян, халыкка хас үткен, тапкыр телле такмакларны күп белә иде. Ул җанекп-җанашның кыйгач кашлары турында, бичара шәкертнең кәкре аяклары турында да, хәзрәтнең мутлыгы турында да, остабикәнең шәкерт белән булган шаярулары турында да җырлап күрсәтте. Аннан кинәт җитдиләнде дә ат тотып баручыга ымлап:

— Башы тишек түгелме моның? — дип сорады.

— Башы да, авызы да тишек түгел, борчылма.

— Алайса, мин сиңа бер вакыйга сөйлим. Ул без алып бара торган әйберләргә бәйләнгән. Әйе, «Мәгариф»та тентү булды бит, ничек саклап кала алдың син аларны? дип нигә сорамыйсың?

— Мин синең тапкырлыгыңа күптән ышана идем. Шуңа күрә мин аны табигый бер хәл дип уйладым.

— Аһа! Бик ансат кына! Миңа аның өчен, беләсеңме, нишләргә туры килде?

— Я?

Галиәсгар Гафурның вакыйга белән кызыксына башлавын аның ялтыр күзләреннән тойды.

— Тыңла, алайса, — диде. — Узган атнада булды ул хәл. Мин көтепханәдә утыра идем. Бер заман атылып-бәрелеп бутышник Гайнулла абзый килеп керде. «Галиәсгар энекәш, дигән була, мин әйтмәдем, син ишетмәдең, ярты сәгатьтән тентү ясау өчен синең кибетеңә килеп җитәчәкләр». Шулай диде дә бу, ай күрде, кояш алды, атылып чыгып та китте. Нишләргә, ярты сәгатьтә кая яшереп өлгерәсең шул кадәр әйберне. Шуннан нишләдем дисеңме? Беткән баш беткән, мин әйтәм, рискка бармыйча булмый. Үземдә эшләүче Галәвине чакырдым да, син хуҗа урынына каласың, әйдә, миңа булыш, мин әйтәм. Без ашык-пошык барлык тыелган китап-газеталарны зур бер капчыкка тутырдык. Мин башыма ертык колакчын бүрек киеп алдым, өскә бишмәтнең дә иң искесен

элдем. Әйдә, аркага сал капчыкны, мин әйтәм. Аның капчыкны җилкәгә салуы булды, мин ашыгып урамга чыктым. Чыксам, урамнан бер хөрти генә извозчик узып бара. Йөгереп бардым да шуның чанасына капчыкны ташладым. Аннан капчык өстенә үзем менеп утырдым.

— Әйдә, — мин әйтәм, — атыңны җан-фәрманга ку. Яртысы синеке. Шулай дип әйтүем булды, теге капчыктагы әйбер урланган дип уйлады булса кирәк, атын чыбыркылый башламасынмы! Кая, кайсы якка? ди. Әйдә, мин әйтәм, Яңа бистәгә таба. Барып та җиттек, бәхеткә каршы, минем таныш кешенең капкасы шәрран яра ачык икән. Әйдә, мин әйтәм, туп-туры шунда алып керик...

Галиәсгар үз сүзенә үзе кәефләнеп кеткелдәп көлә башлады.

— Шуннан, шуннан? — диде Гафур, вакыйганың бик кызык булып бетәсен сизенеп.

— Шуннан болай булды. Капчыкны икәүләшеп минем дус кешенең өенә алып кердек тә мин аны идәнгә бушатып, китап-газетларны икегә бүлә башладым. Менә,— мин әйтәм, теге мине алып килгән извозчикка,— син мине коткардың, шуның өчен бу өемнәрнең теләсә кайсын сайлап ал. Нәрсә соң бу, ди, надан икән. Мин әйтәм, мөэмин мөселманнар өчен чыгарылган китаплар бу. Бу акаеп бер миңа карый, бер өй хуҗасына. Нигә кирәк миңа сезнең басурманский китапларыгыз, ди. Алайса, мин әйтәм, акчалата ал инде. Монда барлыгы биш сумлык товар, яртысы, ягъни синә тиешлесе, ике сум да илле тиен көмеш була, дим. Дурак, ди бу миңа, биш сумлык товарны урлыйм дип вакытымны да әрәм итеп йөрмим инде мин! Шулай диде дә сүгенеп чыгып китте.

— Ә ике сум илле тиенне алдымы соң?

— Алды, алды, — диде Галиәсгар, янә күңелле кеткелдәп.

Гафур да тыела алмый көлә башлады.

— Ләкин шулай да артык риск булган бу. Извозчик сине товарыннең белән частька илтсә, нишләр идең? Я булмаса, нидер сизенеп, теге дус кеше өстеннән донос яздырса?

— Мин болай дип уйладым инде, Гафур. Хәзер бит, үзең беләсең, караклык гөнаһка саналмый башлады. Иң зур җинаять — ул политический эш. Шуңа күрә мин извозчикның шул җимгә кабасын күңелем белән сизендем.

— Шулай да син молодец, — диде Гафур көлә-көлә. — Минем андый эшкә башым җитмәс иде, валлаһи.

Чыгып киткән шәпкә көн ул кадәр салкын тоелмаса да, бара торгач, суык үзенең сузан бармакларын җиң һәм изү эчләренә кертә башлады. Толыпларга ныграк төренеп утырдылар, бер берсенә ныграк сыендылар. Инде алай да булмагач, төшеп чана артыннан җәяүләп киттеләр. Авыр киемнәрдән кар ерып бару җиңел түгел иде. Тиз арада мышкылдап чыктылар. Яңадан чанага утырышып сүз башладылар. Монда гаилә дә, ачлык та, Дума да, революцион хәрәкәт тә калмады. Ләкин барыннан да күбрәк сөйләнгән сүз патша хөкүмәте тарафыннан прогрессив хәрәкәткә каршы булган реакциянең көннән-көн көчәюе турында иде. Бик күп кешеләр, дуслар, якыннар, мәсләктәшләр хәзер төрмәләрдә, сөргеннәрдә интегә.

Юлны кыскарту өчен Казан гайбәтләре дә сөйләнде. Егетләр туңа башлаган саен төшеп җылыналар һәм тагы утырып гәп коралар. Ә тирә-юньдә аклы-каралы чакрым баганалары, салам маяклар һәм ачлык газабы кичергәнлекләре бөтен торыш-кыяфәтләреннән күренгән фәкыйрь авыллар кала иде.

Юлда бер тапкыр атларны алыштырып, көн тәмам караңгыланганда Чистайга барып керделәр.

Гафур Чистайдан чыгып киткәндә бер нәрсәне ачык аңлады: ата белән кыз арасында төзәтелмәслек киеренке бер мөнәсәбәт туган икән. Әлбәттә, Зариф Бадамшин эшнең асылын кунаклар каршында ачыктан-ачык сөйләмәде, ләкин шулай да аның кинаяләреннән һәм ярым чын, ярым шаяртып сөйләшүеннән күңелендә кызына карата һич төзәлмәслек үпкә сакланганлыгы сизелеп тора иде. Бердәнбер кызы, алар фикеренчә, ата-ана ризалыгыннан тыш, кырын эшләр юлына баскан эшлексез Хөсәен артыннан киткән.

— Зариф әфәнде, сез юкка Хөсәенне эшсезлектә гаеплисез, — диде Гафур, һич тыела алмыйча, — әгәр дөресен генә әйтергә рөхсәт икән, ул арабызда иң изге эш белән шөгыльләнүче тырыш кеше.

— Һай, барлык кеше безнең кияү башкарган шундый изге эш артыннан йөрсә, кем икмәк үстерер дә, кем мал белән сату итәр икән? — диде Зариф.

— Сез аның бөтен Россия мөселманнары өчен ифрат файдалы газета чыгара башлавын беләсезме?

— Нинди газета булсын тагы, прокламация ич ул!

— Ул газетаның чыгуы безнең халкыбыз тарихында сөенечле бер хәл, ул, маякчы маякларга ут кабызып, көймәләргә юл күрсәткән кебек, безнең халыкка дөрес юл күрсәтә торган газета. Сез аны менә укып карагыз башта.

— Нигә, мин аны укып карамаган булсам, бу сүзләрне сезгә әйтер идеммени?

Зариф көннәрдән бер көнне «Урал»ны бер приказчигы кулыннан тартып алганлыгын һәм «Мөхәррирә Хәдичә Ямашева» дигән сүзләрне укыганнан соң, өч көн тамактан калганлыгын, йөрәге бик каты авырта башлаганлыгын сөйләде.

— Тиле яшьләр аңламыйлар, — диде ул, — бишенче ел да, алтынчы ел да узды инде. Уен бетте, тырышып, җиң сызганып эшли торган чаклар җитте хәзер. Менә икесен дә якаларыннан тотып алып острокка ябарлар әле!

Гафур ул көнне, булдыра алган барлык дәлилләрен эшкә җигеп, Зариф Бадамшинның кызына, киявенә карата карашын үзгәртергә тырышты. Ләкин бу файдасыз эш, кирәксезгә вакыт уздыру гына булып чыкты. Алар арасында буй җитмәслек кирмән-коймa үсеп чыккан инде. Шуңа күрә Гафур, моңа кул селтәп, Галиәсгар белән үзенең төп бурычын башкарырга ашыкты. Газета, брошюра таратты, җирле комитет әгъзалары ярдәме белән газетага Чистай һәм аның тирәсендәге авыллар турында «Урал»га хәбәр язып торучы тапты.

Чистайдан Бадамшиннарның пар атына утырып чыгып киткәндә Гафур шулар турында уйланып, Хөсәенгә язылачак хатны күңеленнән төзеп барды.

Әлмәткә алар шулай ук көн караңгылангач кына барып керделәр. Гаҗәпсенүләренә каршы, Ильясовларда бу юлы кунаклар юк иде. Бу гадәти хәл түгел иде. Гафур аларда булмады түгел, Хөсәен белән килгән чаклары да булды, аннан соң да ике тапкыр узышлый кунак булып китте, ләкин һәр вакыт аларда өй тулы кунак, шау-шулы, уен-көлкеле яки җитди бәхәсле мәҗлесләр була иде. Бу юлы исә Якуп бай Гафурларны ялгыз үзе генә каршы алды, якты чырай күрсәтеп, өйгә алып керде, ләкин Гафурның сизгер күңеле яшь байның мөгамәләсендә хәзер элекке үз итүчәнлек һәм ачыклык юклыгын абайлап өлгерде.

Өй эчендә аларны Хөсәеннең сеңелесе Хәдичәбикә каршы алды. Яшь бикә дә үзгәргән кебек тоелды. Гафур аның артык ябыкканлыгын ирексездән күңеленә теркәп куйды. Хәдичәбикәнең электән дә моңсурак карый торган күзләрендә хәзер авыр кичереш, хәтта хәсрәт дип әйтерлек

тойгылар ачык чагыла иде. Мәгәр Якуп та, Хәдичәбикә дә тыштан гына булса да сер сынатмыйча, якты чырай, кунакчыллык күрсәттеләр. Тиз арада асраулар, пешекчеләр эшкә җигелде, инде соң булуына карамастан, табын әзерләнде. Кунаклар, чишенеп, юынып, үзләрен рәткә китереп өлгермәделәр, өстәлгә кайнар ризык, тәмле камыр ашлары һәм гөжләп торган ак зур самавар да менеп утырды.

Якуп хас үзе утыргычка басып асылмалы кырыклы зур лампаны кабызды. Матур итеп җиһазланган иркен бүлмәгә бәйрәм төсе керде, кинәт өйнең генә түгел, күңелнең дә караңгы почмаклары яктырып киткән кебек булды.

— Әйдәгез әле, кунаклар, рәхим итегез, — диде Якуп. — Хосусан, мин Галиәсгар әфәндене үз өемдә күрүемә бик шатмын, аны безгә алып килүегез өчен рәхмәт сезгә, Гафур әфәнде. Икегезгә дә рәхмәт сезнең, ераклыктан, юл азаплары кичерүдән курыкмыйча, безнең кара, фәкыйрь якларыбызга килергә батырчылык кылуыгыз өчен рәхмәт.

Галиәсгар, иң зур кунак буларак, түр башыннан урын алды, өстәлнең уң ягына Гафур утырды. Якуп белән Хәдичәбикә аның каршысына урнаштылар. Юл маҗаралары, Казан хәлләре сорашылды, сәламнәр тапшырылды, туган-тумача, дус-иш, таныш-белеш турында сүз барды. Ниһаять, чират хуҗаларга житте. Алар гаилә һәм авыл хәбәрләрен сөйләргә җыендылар.

— Сезнең тормышлар һәм кәсеп бер көе матур гына барадыр инде? — диде Гафур. Хәдичәбикә кинәт самавар астына куелган подноска текәлде, ә Якуп исә җиңелчә кызарынып өстәл өстендә бармакларын тыпырдатып алды. «Нидер булган», дип уйлап алды Гафур шомланып.

— Кәсепләр әкрен бара, — диде Якуп, ниһаять. — Беләсез бит, ел бик коры килде, иген уңмады...

Ул кунакларны шактый озак көттерде, нидер эзләгәндәй, тирә-юненә карангалап, иреннәрен чәйнәп куйды.

— Менә болай инде, кадерле кунаклар. Сез безнең никах мәҗлесендә була алмадыгыз, талак мәҗлесенә генә килергә насыйп булган икән сезгә.

Кунаклар аптырап калдылар.

— Ничек «талак»? — диде Гафур, зур күзләрен Якупка текәп.

— Шулай. Без Хәдичәбикә белән аерылышырга булдык.

— Сәбәп? — диде Гафур тәмам югалып.

— Сәбәбе аның мәгълүм инде, — диде Якуп, күңелсез генә елмайган хәлдә. — Безнең яшь араларыбыз артык зур. Мин бу аерманы өйләнгәннән бирле рухи яктан авыр кичереп яшәдем. Вөҗданым өзлексез газапланды. Менә икебез дә, ниһаять, бер фикергә килдек: мондый гаделсезлеккә чик куярга булдык. Кемгә кирәк бу газаплар?

Галиәсгар тыела алмады:

— Гафу итегез, ә өйләнешкәндә соң... ул чакны да шул ук яшь аермасы булгандыр бит?

— Адәм хатадан хали түгел икән шул, Галиәсгар әфәнде.

«Әйе, бик күңелсез бер вакытка туры килгәнбез икән», дип уйланды Гафур. Ләкин, никадәр генә авыр булмасын, бирешергә ярамый иде. Мәҗлес бозылырга тиеш түгел. Шул ук вакытта бу четерекле мәсьәләдә казынырга, төпченергә мөмкинлек юк. Чөнки артык интим мәсьәлә. Һәрхәлдә, бу эшнең серләрен Гафур иртәгә, ничектер җаен туры китереп, Хәдичәбикәдән сорашачак. Ул аннан яшермәс. Чөнки бу мөмкин түгел. Ул бит кадерле абыйсының иң якын дусты Гафур икәнлеген яхшы белә. Алар Хөсәен белән тәрәзәләрне томалап прокламацияләр баскanda, Хәдичәбикә бик күп тапкыр ышанычлы сакчы булды. Ул абыйсы белән Гафурның барлык яшерен, революцион эшләреннән хәбәрдар иде бит.

Иртәгесен уянып, ашап-эчкәннән соң, чыннан да, Хәдичәбикә белән сөйләшергә мөмкинлек туды. Якуп Галиәсгарны ияртеп хуҗалыгын, икмәк складларын күрсәтергә алып чыгып китте, Гафур исә Хәдичәбикә бүлмәсендә, алып килгән басма материалны аерым өемнәргә бүлә-бүлә, сүз башлады. Хәдичәбикә аңа булыша, һәр төргәкне җеп белән бәйләп тора иде.

Артык зур игътибар бирмәгәндәй, Гафур әйтеп куйды:

— Синең сәфәр кайчан инде, Хәдичә?

— Менә җыенам әле, аның көнен әйтә алмыйм.

— Һәм кая китмәк буласың инде?

Хәдичәбикә уйга калды.

— Бөтен хикмәт тә шунда шул, Гафур абый. Уфага китәргәме, әллә Хөсәен абыйларгамы? Үзем дә аныклаганым юк әле.

Гафур тынычлыгын артык саклый алмады. Тойгылары ташып, йөрәгенә кан саугандай булды.

— Эш нидә, зинһар өчен аңлат, Хәдичәкәй? Ни өчен ул бүген, ни өчен ул кичә булмады. Ни өчен, ни өчен?

— И Гафур абый, — диде Хәдичәбикә, — нишлим, мин үзем дә аның белән ни чарадан бичара гына яшәдем бит. Беләсеңдер, мин зур максатлар куеп абыйга ярдәм күрсәтәм дип ясадым бу адымны. Ә менә хәзер аның ахмак рәвештә үз-үзеңне корбан итү икәнлеген, абыйның теге чакта ук хаклы булуын яхшы аңладым.

— Димәк, бу эшне дәгъва итүче син?

— Минем дәгъваларым гына мәсьәләне хәл итәрдәй булса, күптән инде төен чишелгән булыр иде. Эш катлаулырак, Гафур абый.

— Аңламыйм. Син аны яратмаган хәлдә дә аңа кияүгә чыктың. Ул сине яратып алды. Димәк, ул хәзер үзенең хатасын аңлады, сиңа яхшылык эшләргә булды. Ярый әле, балаң юк, ә балаң да булса тагы?

— Монда минем дәгъваларымнан тыш башка кайбер сәбәпләр дә бар. Монда минем абый дусларына ярдәм итүем дә, бу җәһәттән шактый кыю эш итүем дә тәэсир ясады.

— Ничек инде? Ул үзе дә безнең эшкә ярдәм итеп торучы иде бит. Хөсәен миңа барын да сөйләде. Якуп әфәнде бит инде, уездный начальствоны майлап, Хөсәенгә, Казаннан киткәч, ялган паспорт алып биргән кеше.

— Әйе, Гафур абый, болар барысы да дөрес. Ләкин алар узган эшләр. Әлмәттә соңгы вакытта бик күп кешене кулга алдылар, Якупның әйтүенчә, минем арттан да күзәтү куйганнар. Җитмәсә, маэмурлар [1] яңадан хөкем сөрә башлаган бер вакытта абыйның Оренбурда большевиклар рухындагы газета чыгарып ятуы...

— Аны өркетте, шулаймы?

— Юк, мин алай дип тә әйтә алмыйм. Белмим, мин аңламыйм. Кыскасы, хәзер барысы да хәл ителде инде. Озакламый мин китәргә тиеш.

Хәдичәбикә тирән итеп көрсенеп куйды. Гафур гүзәл яшьлеген үзе сөймәгән кешегә биреп, соңыннан хатасын аңлаган хатынның хәлен төшенә иде. Ул Хәдичәнең яшьле күзләренә карап уйланып утырды.

— Гомумән, бу адымың синең дөрес адым,— диде ул.— Якуп, әлбәттә, моны куркудан эшли, мәхәббәттән җан тынычлыгын артыграк күрүчеләр аз түгел. Ләкин, әйтәм ич, бу эшкә эткән сәбәпләрнең нинди булуына карамастан, бу синең киләчәгең өчен файдалы адым, Хәдичәбикә сеңелем.

— Белмим, минемчә, барысы да җимерелде, Гафур абый.

---

[1] Маэмурлар — чиновниклар.

— Юк, юк, алай димә, син бит әле бик яшь, синең әле киләчәгең алда, акыллым.

Газета һәм брошюраларны төргәкләргә бүлеп чыкканнан соң, Хәдичәбикә сорап куйды:

— Ничек таратырга уйлыйсыз боларны?

— Менә монысы сиңа, — диде Гафур, бер төргәкне аңа сузып. — Газетаның икенче санында Ленин мәкаләсе дә бар.

— Рәхмәт, мин аны аулакта берүзем генә калганда укып чыгармын. Сезне күргәч, абыемны күргәндәй булган идем, инде ул чыгарган газетаны укыганда, аның белән сөйләшкән кебек булыр.

Хәдичәбикә төргәкне кулына алды да елмаеп куйды.

— Ирешкән Хөсәен абый! Бик, бик тели иде ул үзебезнең телдә шундый газета чыгарырга!

— Калганнарын Әлмәттә генә түгел, аның тирә-ягындагы авылларда да таратасы иде, Хәдичә.

— Эшлибез аны.

— Монда синең якын-танышларың, ышанычлы кешеләрең бардыр?

— Әйтәм ич, берәм-сәрәм генә калды алар дип. Әйе, — диде кинәт Хәдичәбикә, нидер хәтерләп, — абый соңгы хатында Нәдердә яшәүче Фәрхетдин исемле егетнең гаиләсе турында язарга куша. Ул егет кайчандыр бездә ялчылыкта торган икән, хәзер Оренбурга барып чыккан.

— Фәрхетдин, Фәрхетдин, — дип уйланып торды Гафур. — Мин бит аны беләм. Ул иске клиникада ятты. Аны рус карагруһчылары кыйнап ташлаганнар иде.

— Менә шул инде. Мин әллә кайчаннан бирле шунда барырга җыенам, һич вакыт таба алмыйм.

— Әйдә, мөмкин булса бүген үк барыйк шунда... Синең анда боларны таратуда булышырлык кешең юкмы?

— Бар, әгәр кулга алынмаган булса.

## 22

Хөсәен идарәдә Ильяс Кудашев белән сөйләшеп утырганда кемдер кыймыйча гына ишек шакыды. Вакыт шактый соң иде инде. Гадәттә, бу сәгатьләрдә чит-ятлардан беркем дә идарәгә керми, беркем дә борчымый. Хөсәен бары шуның өчен генә, Пименев заводы эшчесенең улы, учительскаяны Хөсәеннән соңрак тәмамлаган бу яңа дус белән булачак яшерен сходка турында тынычлап сөйләшергә дип бүген идарәдә калган иде. Ул, ризасызлыгын яшерә алмыйча, шактый коры итеп:

— Кем анда? Керегез, — диде.

Ишектән бишмәт якасын күтәргән, яка өстеннән дөя йонынnan бәйләнгән шарф чорнаган бер кеше керде. Хөсәен ирексездән сагая төште. Ләкин, дикъкатен җигебрәк караганнан соң, бу кешенең шәкерт икәнлегенә ышанды. Чөнки аның кырпулы иске бүреге, ямаулы бикасап бишмәте, аягындагы читек өстеннән кигән ак киез каталары моңа дәлил иде. Шәкерт керү белән бәсләнеп каткан шарфын чиште, якасын төшерде һәм, салкыннан күшеккән кулларын уа-уа, куркып карый торган күзләрен Хөсәенгә, аннан Ильяска текәде.

— Сезгә кем кирәк? — диде Хөсәен.

— «Урал» газетасының идарәсе шушы буламы, әфәндем?

— Әйе, шушы, эчкәрәк узыгыз, нинди йомышыгыз бар иде?

Шәкерт, һаман әле туңган кулларын уа-уа, Хөсәен өстәле янына кыюсыз гына килеп, бермәл таптанып торды.

— Мине Вәли хәзрәт мәдрәсәсеннән шәрикләрем җибәргән иде.

— Бик әйбәт. Димәк, вәкил сыйфатында икән. Сез утырыгыз, шәкерт әфәнде.

Шәкерт утырды да кинәт ачынып, күкле-яшелле тавышлар чыгарып сөйли башлады:

— Ислах, ислах таләп итәбез без, заманга муафыйк фәннәр укытылсын, туйдык без беркемгә дә кирәкмәгән мантыйк укып ятудан. Мәдрәсәне бетергән кеше шул корьән укудан башка ни белә?! Ярдәм итегез зинһар, әфәндем, сезнең гәзит тәрәккыять ягында бит. Ә менә Заһидулла хәлфәгә шул сүзләрне әйткән идек, сез кабихлар, сез денсезләр, сез зиндыйклар [1], ди, мин Кашгар ысулы белән укытам, сезне кеше итәм. Чын мөэмин мөселманнар оерлык имам итәм, ди.

— Туктагыз, тынычрак сөйләгез, — диде Хөсәен. — Сез, димәк, Вәли мулла мәдрәсәсеннән. Сез безнең идарәдән нинди ярдәм эстисез соң?

Шәкерт кулларын өметсез рәвештә җәеп җибәрде.

— Белмим инде, аптыраганнан җибәрделәр инде шәрикләрем. Булмаса үзегез әйтегез, нинди ярдәм күрсәтә аласыз соң сез?

Шәкертнең күзләрендә ялвару чагыла иде. Хөсәен ирексездән үзенең дә кайчандыр шундый мескен, кызганыч шәкертләр арасында булган чакларын хәтерләде. Аларның күпчелеге тынчу мәдрәсәләрдә, атнага бер-ике тапкыр аш ашап, калган вакытын каткан икмәк һәм чәй белән уздыралар. Өсләренә кигән киемнәре сәләмә, я булмаса берәр үлгән кеше калдыгы, аякларында иске читек, кәвеш. Бердәнбер керем — ул да булса сәдака. Мескен шәкерт хәерче кебек өметләнеп сәдака көтә, сәдака аның төшләренә керә, сәдака күбрәк төшәрлек җеназа аның өчен бер бәйрәм...

Һәм менә шундый кимлек-хурлыкларны күтәрергә тиеш татар интеллигенциясе! Әйе, башлыча шулай, ә Хөсәен кебекләр дөньяви фәннәрне уку бәхетенә ирешкәннәр — андыйлар диңгездән бер тамчы, бер генә тамчы.

Хөсәен, тагы нидер әйтүен көтеп, үзенә текәлгән шәкерткә карап торды. Егет чибәр генә иде үзе, аның кара зур күзләрендә акыл шәүләсе чагыла, үзе, йөз чалымнарының житезлегенә, сизгерлегенә караганда, зирәк шәкертләрдән булырга тиеш.

— Сез көрәшегезне дәвам иттерегез, — диде Хөсәен. — Көрәшсез генә Вәли мулла кебек кадим хәзрәтләрне дөрес юлга бастырып булмый.

— Без әйтеп карадык инде, тик аның файдасы юк. Әгәр сүз тыңламасагыз, мин сезне мәдрәсәдән куам, ди. Аннан нишләрбез без? Кулда һөнәр юк. Хәер эстәргә генә кала безгә.

— Курыкмагыз, — диде Хөсәен, — инде бик авыр хәлгә каласыз икән, без ничек булса да ярдәм итәрбез. Һич югында, газета аша җәмәгатьчелеккә мөрәҗәгать итәрбез, иганә җыюны оештырырбыз.

— Рәхмәт алайса, әфәндем.

— Ләкин сезгә бер үтенеч бар. Сез безнең газетага ислах өчен барган көрәшегезнең ни хәлдә булуын даими рәвештә хәбәр итеп торыгыз.

— Яхшы, әфәндем.

— Курыкмагыз, — диде Хөсәен, йодрыгын өстәлгә куеп, — арыслан кебек яшь, матур егетләр сез. Кыюрак булырга кирәк. Сөйләштекме шулай?

— Сөйләштек. Рәхмәт.

— Сезнең исем-фамилиягез кем инде? Анысын да әйтегез зинһар. Мин үзем Хөсәен исемле кеше булам.

— Минем исемем — Галимҗан, фамилиям — Ибраһимов.

Хөсәен, шәкертне аптырашка калдырып, пырхылдап көлеп җибәрде. Егетнең уңайсызлануын күргәч:

— Сездән көлә дип уйлый күрмәгез, — диде. — Минем исемә бер Уфа шәкерте килеп төште. Аның да исеме Галимҗан иде, фамилиясе дә нәкъ сезнеке кебек — Ибраһимов. Ләкин ул бик кыю егет иде.

[1] Зиндыйк — дуңгыз.

Узган ел ул революцион эшләре аркасында кулга да алынды, утырып та чыкты, ахрысы. Шул кадәресен дә хәтерлим, сезнең икеләтә адашыгыз кайчандыр үзе дә сез укыган Вәли хәзрәт мәдрәсәсен ташлап киткән кеше.

Егет инде аягүрә басып тыңлады бу сүзләрне. Ул Хөсәеннең әйткәннәреннән әллә ни тәэсирләнмәде. Аның йөзендәге каушау билгеләре әле һаман шул килеш калган иде. Ул ярым елмаеп Хөсәенне тыңлады да мөхәррирнең үзенә таба сузылган кулын, күрәсең, шул ук кыюсызлык аркасында бармак очларыннан гына кысып, тиз арада идарәдән чыгып та китте.

«Ике Галимҗан», икесе ике төрле», дип уйланды Хөсәен. Уфада чакны ул «Галия» мәдрәсәсендә уздырыла торган җыелышларга, концертларга, кичәләргә еш бара торган иде. Андагы Галимҗан үзенең кыюлыгы, белеме һәм фидакарьлеге белән Хөсәеннең күзләренә беренче көнне үк чалынган иде.

Кайдандыр Хөсәен турында ишетеп, ул үзе беренче булып Ямашев янына килде һәм үзен әз генә дә менә бүгенге Галимҗан шикелле месскен итеп тотмады. Бер вакыт Хөсәенгә «Галия» мәдрәсәсендә лекциягә охшаш бер әңгәмә уздырырга туры килде. Шул чак Галимҗан Хөсәен белән бәхәскә керүдән дә курыкмады. Әлбәттә, аның Хөсәен тезислары белән килешмәве, ахыр чиктә барлык социаль мәсьәләләрне аерым шәхесләрнең карашы, мәсләге хәл итә дип баруы авылда туып үскән күпчелек татар егетләренә хас, крестьянга хас вак буржуа карашы иде. Хөсәен тыныч кына аңа аңлата башлады. Мәгәр уфалы Галимҗан бик тиз генә күнмәде, тагы бер очрашып бу темага сөйләшүне кирәк тапты. Әмма, кызганычка каршы, Галимҗан тиздән кулга алынды, ә ул төрмәдән котылгач, күп тә узмады, Хөсәен үзе газета эшләре белән Чиләбе якларына сәяхәткә чыгып китте...

Хөсәеннең уйларын Ильяс бүлдерде. Бу Пименев заводы эшчеләре белән элемтәче вазифасын үзе теләп алган дус егет Хөсәеннең шәкерт белән сөйләшүен игътибар биреп тыңлап утырган иде. Хәзер һич уйламаганда ул яшүсмерләрчә шукланып:

— Хөсәен абый! Шәкерт булып кыланып күрсәтимме? — диде.

Хөсәен, җитди уйларыннан аерылып, сәерсенә төште:

— Ничек инде?

— Менә артистларча, шул шәкерт булып уйныймы?

Хөсәен Ильясның теләген аңлап, яктырып китте:

— Я, я, булдыра алсаң...

Ильяс тиз генә ишек янына барды да шундук, әлеге шәкертнең хәрәкәтләрен кабатлап, шарфын чишкәндәй кыланды, кулларын уа-уа, борынын тарткалап куйды. Аннан куркынган кыяфәттә күзләрен төрле якка йөгертеп алды.

— «Урал» газетасының идарәсе шушы буламы, әфәндем,— диде.

Егет шул кадәр охшата иде — Хөсәен тыела алмастан өстәлгә иелеп көлә башлады. Ильяс үзе дә көлеп җибәрде.

— Чын шайтан икәнсең син, Ильяс. Синдә артист кына булырлык, — диде Хөсәен, яшьле күзләрен кулы белән сөртеп.

— Ә без Оренбурда беренче спектакль куячакбыз, — диде егет, — син әле менә безнең Сакаев дигән егетнең осталыгын күрсәң! Сине, Хөсәен абый, таныштырам әле шуның белән.

— Бик рәхәтләнеп танышам, алып кил.

Аларның үзара иң мөһим сүзләре беткән иде инде. Пименев заводындагы татар эшчеләре башлыча Сакмардан бүрәнә тарттыручылар. Шуларның алдынгылары белән уздырыласы чираттагы җыелышның кайчан һәм кайда булачагы сөйләшенгән, бары сәгате генә анык билгеләнмәгән иде.

Ильяс үзенең мәзәген күрсәткәннән соң, сүз шул турыда башланды. Барысы да хәл ителгәч, Хөсәен:

— Вакыт соң, кайт инде, — диде, — сиңа бит иртәгә эшкәдер?

— Шулай инде, Хөсәен абый, әле дәфтәрләр карыйсы да бар.

— Алайса бар, кайт та ял ит. Мин дә бүген артык озак эшли алмам, ахры, арыта төште.

Ильяс саубуллашып чыгып китте.

Елдам һәм сәләтле егет иде бу. Ничектер Казанда чакны игътибар итмәде аңа Хөсәен. Эшчеләр арасында бик тырышып газета таратты, үзе укытучылык эшендә булса да, хәтта типографиядә яшерен бастырылган листовкаларны да эшчеләргә өләшкәләде. Авыр, хәтәр эштән тартынмый. Ни әйтсәң дә эшче гаиләсендә үскән шул.

Хөсәен, Ильясны озаткач, шулай бераз уйланып утырды. Артык күп уку һәм язу аркасында күзләр әчетә башлаган иде. Ләкин ничек тә мәкаләне язып бетерергә кирәк. Хөсәен, алдындагы лампаның филтәсен күтәрә төшеп, кулына каләм алды, мәкаләсен дәвам иттерде: «Мөселман иттифакы» тугрысында газетабызның өченче номерында бу «партия» байлар партиясе диеп язган идек. Тагын милләткә хезмәт итмәкче булалар, тагын дин, милләт диеп кычкыра башладылар. Ләкин ни өчен соң бу милләтчеләр бары да байлар партиясенә керделәр, ник бу милләтчеләр бөтен җирнең халык кулына күчүен теләмиләр? Ник бу милләтчеләр бөтен власть халык кулында булырга тиешлеге белән разый булмыйлар?»

Хөсәен, каләмен кара савытына куеп, бераз уйланып утырды. Бераздан тагын җиңелчә каләм кыштырдаганы ишетелде. Әледән-әле күңелендә оешкан җөмләләрне ул тигез гарәп хәрефләре белән кәгазьгә төшерә барды. Мәкалә төгәлләнгәндә сәгать төнге уникенче иде инде. Ул кинәт бүген көндезге аштан соң бернинди ризык капмаганлыгын хәтерләде. Эче авыртып киткәнен сизде. Үпкә дә, йөрәк тә үзләрен сиздергәндәй булдылар.

«Зарар юк», — диде Хөсәен, — барысы да җайланыр, бары газета гына вакытында һәм теләгәнчә булып чыксын». Ул папирос алып лампадан гына кабызды да, шуны авызында тоткан килеш, бераз вакыт утыргыч аркасына сөялеп, башын артка ташлап ял итеп алды. Язылачак мәкаләләр әле бик күп иде. Дума турында зур бер мәкалә эшләргә кирәк. Думаның кулыннан берни дә килмәячәген аңласын халык, иллюзияләр корып саташмасын, алданмасын. Аннан шәкертләр хәрәкәте турында, аннан социализм турында, аннан...

Һай, һай, һай, дөнья кадәр! Рәхмәт Галимҗан Сәйфетдиневкә, армый-талмый ат кебек эшли.

Тик шунысы начар: халык арасында үзләре теләгән кадәр була алмыйлар алар. Уфада, ичмасам, Хөсәен нинди генә кәсеп ияләре белән аралашмады! Кораллы отрядлар оештыру, татар-башкорт эшчеләре арасында революцион пропаганда алып бару, шәкертләр, кул һөнәрчеләре, приказчиклар арасында булу... Ә Казанда соң? Дүрт ел диярлек армый-талмый халык арасында йөрде ич ул. Ә менә хәзер күзләренне әчеттереп утыр, туктаусыз яз да яз. Әле хәзергә тәҗрибә азрак, тора-бара, әлбәттә, эш шактый җиңеләячәк, шуннан соң вакыт булыр — Хөсәен Оренбурның һәрбер почмагын айкар, эшчеләр арасында йөрер, авылларга да чыгар.

Ул папиросын тартып бетерде дә киенә башлады.

Өйгә кайтып җитеп, капка шакыды. Ни өчендер аны бүген хуҗа хатыны Анфиса Петровна үзе каршы алды.

— Җәмәгатегез кәефсезләнеп тора, — диде ул. — Суык тидергән, ахры.

Хөсәен ашыгып өйгә керде. Чыннан да, Хәдичә йокламый, кызышып, ыңгырашып ята иде. Хөсәен өс киемнәрен салып утыргычка ташлады

да ашыгып өстәлдә яткан термометрны карады. Терекөмеш утыз тугыз билгесендә тукталган иде.

— Аппагым, ни булды сиңа?

— Минә иртән керләр уган идем. Күрәсең, әләргә чыкканда җиңелрәк киенгәнмен.

— Әй, Хәдичәкәй, ничек инде шулай... сакланмадың?

Хөсәен салкын учын Хәдичәнең кайнар маңгаена куйды.

— Мин сиңа ашарга да әзерли алмадым инде, — диде Хәдичә. — Үзең берәр нәрсә эмәллә, әнә калган аш та бар.

— Ә, андамыни эш! Берәр дару эчтеңме соң?

Хәдичәнең гомумән дару эчәргә яратмаганлыгын һәм бу юлы да чирнең үзлегеннән узуын көтеп ятканлыгын төшенә иде Хөсәен. Шуңа күрә, җавап көтмичә үк, комод өстендәге катыргы тартманы ашык-пошык актарырга тотынды, ниһаять, солицилка табып, аны көчләп диярлек Хәдичәгә эчертте.

— Күрмәдеңмени, сиңа Казаннан хат килгән... комод өстендә, — диде Хәдичә. — Гафурдан булса кирәк.

Хөсәен, Хәдичәне иплэп кенә урынына яткырды, өстенә җылы юрганың япты да, конвертны кулына тотып, ашыга-ашыга кухня якка чыгып китте.

Кәстрүлдәге аш тимер плитәдә җылынган арада, Хөсәен бик бирелеп хат укып утырды. Хатның идарәгә түгел, ә өйгә килүе табигый иде. Саклану өчен Гафур аны башка кеше адресына җибәрә. Ул кеше исә хат килгән көнне үк Хөсәеннәргә тапшыра иде.

«Хөсәен дус, — дип язган иде Гафур, — бу хатны сиңа, артык озынга китмәсен өчен, мөмкин кадәр кыска итеп, телеграф теле белән язам. Каникул вакытыннан файдаланып, мин һәм Галиәсгар әфәнде дөнья күреп кайттык. Чистайда, Әлмәттә, Минзәләдә һәм, табигый ки, шул өязләрнең байтак карьяләрендә булдык. Алып кайткан гомуми тәэссорат бик яман. Аерата Минзәлә өязендә коточкыч ачлык, хәерчелек мине ифрат дәрәҗәдә тетрәтте. Ярар, газетаңда файдаланырлык андый нәрсәләрне хатымның азагында баян итәрмен, хәзер исә шәхсән сиңа һәм синең гаиләңә кагылышлы вакыйгаларны язып узыйм.

Башта сине шатландырыйм. Үзебез белән «Мәгариф» көтепханәсеннән «Урал» һәм аның приложениеләрен алып бардык. Максат — аларны халыкка тарату иде. Җитмәде дә. Халыкта зур ышаныч, бетмәс-төкәнмәс өмет уята синең хезмәтең. Ул татар халкының күзен ача. Без Галиәсгар әфәнде белән кәррә-кәррә сиңа рәхмәтләр укыдык. Кайбер авылларда (һәм шәһәрләрдә дә, мәсәлән, Чистайда, Минзәләдә) махсус җыелган мәҗлесләрдә дә укылды« Урал». Тыңлап утыручылар бик кызыксындылар, газетадагы кайбер мәкаләләр халыкны йокысыннан уяткандай булды.

Инде әйткәнемчә, шәхси эшләр турында. Узган җәй синең миңа сөйләгәннәреңне искә алып, мин ата кешенең кызына һәм киявенә карата булган мөнәсәбәтен белергә, ә мөмкин булса, хәтта җайларга тырыштым. Ләкин, Маркс бабаң әйтмешли, сыйнфый мәнфәгатьләр барысыннан да көчлерәк икән шул. Әфәндекәем, дилемма алдында калгач, үзе өчен файдалысын сайлаган. Күрәсең, ул элек барлык революцион хәрәкәтне бер уен дип кенә караган, бу уенга катнашудан да тартынмаган. Ләкин уеннан уймак чыга башлагач, «тәүбә, тәүбә» дип тирә-ягына төкеренергә керешкән. Әлбәттә, ул кадерле кызының зинданда череячәк кешеләр арасына эләгүен бик авыр кичерә, ә сине ул... ачуланма, гаепле саный. Мин шуны аңладым, дустым, ул сине бер вакытта да гафу итмәячәк.

Инде тагы синең өчен икенче яңалык. Бусы бәлки ул кадәр авыр тоелмас. Сеңелеңнең әйтүенә караганда, сине шатландырачак кына

(ай-һай ла?). Хәл шулай тора: Якуп бай Хәдичәбикәне аера. Ул үзе бәлки сиңа тулырак итеп язар. Ләкин мин бу хәбәрне бик авыр кабул иттем. Галиәсгар әфәнде Якупка бик усал сорау бирде. Теге яшь аермасы, фәлән-төгән, вөждан газабы дип сөйләнә башлагач, яшь аермасы сез өйләнгәндә үк мәгълүм түгел идемени? диде. Хикмәт, әлбәттә, Хөсәен дус, минем аңлавымча, ахыр чиктә тагы синең хәзерге деятельностьңа барып тоташа. Син «бәләкәй» чакны түзеп була иде, хәтта сиңа ярдәм итүе дә бер мәртәбә, рыцарьлык иде. Ә менә хәзер син кинәт бөтен мәмләкәт масштабындагы аренага чыктың. Син аларга куркыныч бер фигурага әйләнә башладың. Шуның аркасында кичә дус булып уйнаган бик күпләр, шул җөмләдән синең кайбер якыннарың да, синнән йөз чөерде. Хәер, бу сүзләрне язуның хаҗәте бар микән?! Син боларны миннән яхшырак беләсең. Алдан ук барысын да белеп эш итүеңне аңлыйм. Инде хәзер мин сиңа газетта файдалану өчен кайбер хәбәрләр язам.

Казан университетында узган атнада тентү булган, бер әйбер дә табылмаган. Кызыгы шунда: ректор урынында булган Ивановский тентү вакытында чакырылса да, кабинетыннан чыкмаган.

Казанда Яңа клуб бинасында мөселманнарның Думага сайлауда кадетлар белән бергә хәрәкәт итүләренә багышланган җыелышы булган. Шунда Бат дигән берәү мөселман мәктәпләренә рус хәрефен кертү турындагы указны тәнкыйтьли башлагач, полиция җыелышны тараткан.

Казан губернаторы шушы араларда авылларга чыгып йөргән. Ул Алексеевскида «Бу Думага үткән Думадагы кебек разбойниклар сайламагыз, «чын рус халкы» союзының членнарын гына сайлагыз» дип лыгырдаган...»

Хөсәен шул җирдә укудан тукталырга мәҗбүр булды. Кайный башлаган ашны тәлинкәгә салгач кына хатны тагын кулына алды. Андагы хәбәрләр Хөсәен өчен үтә кызыклы иде. Ул ашый-ашый хат укып утырды. Монда Думага сайлау кампаниясенең барышы, Казанда һәм аның тирә-ягындагы кулга алу, тентүләр һәм авыллардагы ачлык, тиф, зәңгелә чирләренең таралу хәбәрләре язылган иде. Гафур Тәтеш өязендә коточкыч ачлык булган хәлдә дә он юктан Кызыл хач җәмгыятенең йөз кырык җиде ашханәсе ябылуын хәбәр иткән. Минзәләдә ачлык шул дәрәҗәгә җиткән ки, өяз начальствосының мәгълүматларына караганда, мең семьяның өчесе генә икмәкле...

Хөсәен хатның соңгы юлларын аерата зур игътибар белән укыды. Анда Гафур түбәндәгеләрне язган иде:

«Әлмәттә чакны, сеңелеңнең үтенече буенча, Нәдер дигән авылда да булдык. Монда теге Фәрхетдиннең өенә дә кереп чыктык. Ул Нәдердә бераз яшәгәннән соң тагын бәхет эзләп чыгып киткән икән. Мескеннең әтисе үпкә чиреннән бер ай элек кенә вафат булган. Ул гына җитмәгән — хатыны да үлеп киткән. Яңа туган баласы калган...»

Хөсәен бу юлларны укыгач, ашавын онытып, дулкынланып һәм Фәрхетдин хәсрәтен авыр кичереп күзләрен йомып торды. Хәбәр Фәрхетдингә килеп җиткәнме икән? Ничек кичерә ул аны, түзәрме, канатлары сынмасмы егетнең?

Хөсәен, байтак вакыт хәрәкәтсез утырганнан соң, урыныннан торды, Хәдичә янына чыкты.

## 23

Төнне йокысыз диярлек уздырды ул. Бары көн яктыра башлаганда гына Хәдичәнең температурасы төшә башлады, шунда гына Хөсәенгә бераз черем итеп алырга мөмкинлек туды.

Иртәгесен врач килде. Хәдичәгә бер атнасыз урыннан тормаска кушып, дарута рецептлар язып, нинди ризыклар белән тукландырырга кирәклеген әйтеп, китеп барды.

Барлык ышаныч хәзер квартира хуҗасы Анфиса Петровнада иде. Әгәр дә ул Хәдичәне карарга авырсынса, эш куркыныч төс алачак.

Хөсәен шул турыда сөйләшү өчен кухня якка чыкты. Тик хуҗа хатын анда юк иде. Мич янындагы самаварның куелганлыгын, әле яна гына җылына башлавын белгәч, Хөсәен күрше ишекне әкрен генә шакыды. Анфиса Петровна, янәшә олы бүлмәләрен фатирчыларга биреп, үзе кухня аша керә торган тар гына бүлмәдә яши иде. Хөсәен, бүлмәгә керергә рөхсәт булу белән, хуҗабикә дә авырып китмәдеме тагы дип сөйләнә-сөйләнә, борчылып эчкә узды. Бәхеткә каршы, Анфиса Петровна сау-сәламәт икән. Ул тәрәзә янына утырып үзенә кофта көкли. Хатынның ябык йөзеннән куркыну катыш аптырау узды. Хөсәеннең беркайчан да хуҗабикәнең бүлмәсенә кергәне булмады әле. Аларга кухняда гына очрашып сөйләшергә туры килә иде. Олыгая башлаган, чәчләре агара төшкән, соргылт күзле, яңак сөякләре шактый калку бу хатын үзенең сабырлыгы һәм игътибарлылыгы белән, бер күреп сөйләшкәннән соң ук, кешедә әйбәт тәэсир калдыра иде.

— Хәдичә Зарифовнаның хәле ничек? — диде ул шомланып.

— Ярыйсы хәзергә, дарулар эчкәч, бераз җиңеләйгән кебек.

— Шөкер ходага, — диде хатын. — Мин ишетеп яттым. Сез төне буе аны карадыгыз.

— Карамыйча булмый, аңа доктор берәр атна ятарга кушты, үпкәсенә суык тидергән.

— И ходаем, әйттем мин аңа, тирләгән көе бик җиңел чыгасың диеп. Яшь кеше үзенә артыграк ышанучан була шул...

— Анфиса Петровна, мин сезгә үтенеч белән бит...

Хуҗабикә җиңелчә генә елмайды.

— Хатыныгызны каравымны үтенәсездер?

— Әйе, зинһар өчен, эшем бик күп чак, үзем генә булдыра алмыйм. Мин сезне буш итмәм...

— Юкны сөйләмәгез, Хөсәен Минһаҗетдинович. Әйтмәсәгез дә минем Хәдичәне ташласым юк.

Кинәт ул ике күзен дә йомып алды һәм, тәгаен берәр сер әйтергә теләптер: — Мондарак килеп утырыгыз әле, — диде.

Хөсәен өстәл янындагы артсыз утыргычка барып утырды.

— Мин сезне бик хөрмәт итәм, — диде хатын. — Сез бик намуслы, тугры кешеләр. Шуңа күрә мин сезнең белән ачыктан-ачык сөйләшергә телим. Өченче көн минем янга околодочный керде һәм сезнең турыда сораштыра башлады. Алар ниндирәк эшләр белән шөгыльләнәләр, янәсе, кемнәр килә, теге сөргенгә җибәрелгән Сәйфетдинев буламы сездә, янәсе.

— Сез ничегрәк дип җавап бирдегез соң, Анфиса Петровна?

Хуҗабикә, сынаган кебек, бермәл Хөсәеннең йөзенә карап торды.

— Минем улым да сезнең юлдан йөри торган кеше булды. Аңлыйсызмы?

— Аңлыйм, — диде Хөсәен катгый рәвештә. — Сез, андый иснәнеп йөрүчеләргә нинди җавап кайтарырга кирәклеген беләм, диярга телисез.

— Дөрес аңлагансыз. Ләкин үзегезне дә, мине дә сатарга теләмәсәгез, алла хакына дип әйтәм, сак булa күрегез...

Хөсәен урыныннан торды.

— Рәхмәт кисәтүегез өчен.

— Ә теге эш турында борчылмагыз, күгәрченкәем. Мин инде Хәдичәне сезгә караганда яхшырак багармын дип уйлыйм.

Хөсәен, рәхмәт әйтеп, Хәдичә янына чыкты. Аның йөзе бер төн эчендә суырылып, агарып калган, коңгырт күзләре зураеп эчкә баткан, үзе артык күңелсез иде.

— Кәефләр ничегрәк? — диде Хөсәен, Хәдичәнең кулын сыйпап:
— Тын алуы авыр, күкрәгем авырта.
— Хәзер Анфиса Петровна белән без сиңа банка куярбыз.
— Син бүген дә мине кара төнгә кадәр калдырып китәсеңме инде? Хөсәеннең бик каты авыртып йөрәгә кысылды. Ул дәшмәде, сораулы караш белән Хәдичәгә карап торды.
— Бар, бар, — диде Хәдичә, — газетаны туктатып булмый.
Хөсәен авыр сулап Хәдичәнең аяк очына утырды.
— Юк бит, юк. Ярдәмчеләр җитми. Синең яныңнан бер генә минутка да китмәс идем. Ә газетаны чыгарырга кирәк!
Хөсәен бик азга гына эшеннән аерылса да, номер соңга калып чыгачак. Ә бит әле газета чыга гына башлады. Ул шулай беренче көннәрендә үк соңгара башласа, ни әйтер укучы? Ах, Хәдичә, Хәдичә, син бит, җанкисәгем, моны беләсең, нигә соң минем йөрәгемне телгәләп шундый сорау бирәсең?
Хөсәен тиешле даруларны аптекадан алып кайткан иде инде. Алар бераздан хуҗабикә белән Хәдичәнең матур, тыгыз аркасын кызыл таплар белән чуарлап, банкалар куйдылар. Барысы да булды шикелле. Хөсәен Хәдичәнең уң яңагыннан үпте дә, тизрәк терелүен теләп, бүген, һичшиксез, иртәрәк кайтам, дип өйдән чыгып китте.
Әлбәттә, газета эше бик матавыклы һәм бер генә сәгать тукталып торуны да кичерми. Ләкин шуның белән бергә Фәрхетдин кайгысы да һич кичектермәстән нииндидер чаралар күрүне сорый иде. Хатта язылганнар турында Хөсәен Хәдичәгә бер сүз дә әйтмәде, мондый вакытта аны күңелсез хәбәрләр белән борчу әдәпсезлек булыр иде.
Хөсәен туп-туры группа әгъзасы Леонтьевка юнәлде. Хәзер Фәрхетдинне бары шуның аша гына чакыртырга мөмкин. Чөнки Хөсәенгә тимер юл мастерскойларына барып йөрү катгый рәвештә тыелды.
— Нинди йомыш, газета эше буенчамы? — диде Николай.
— Юк, бу юлы башка мәсьәлә, — диде Хөсәен, күңелсезләнеп, вакыйганы сөйләп бирде.
— Ала-ай икән! — дип куйды Леонтьев.— Егетнең эшләре, алайса, шәптән түгел. Без бит аңа зур өметләр баглаган идек. Бу кайгы аны сындырмас микән?
— Авыр булыр инде, әлбәттә. Ләкин сынмас дип уйлыйм. Беләсезме нәрсә... аңа ничектер авылына кайтып әнисен, баланы алып килүне оештырасы иде.
— Комитетның кесәсендә сукыр бер тиен дә акча калмады, — диде «Җирән».— Күптән бернинди керем юк.
— Анысы начар икән, — диде Хөсәен. — Үз кесәмнән эһ тә итмичә чыгарып бирер идем, әмма үзем дә минимумда яшим.
— Бәлки берәр бай либерал ярдәм итәр?
— Ышанмыйм, газетаның беренче саннары ук аларны өркетте.
— Өркетте дигәннән, сезнең газета белән фиргавеннәр артык кызыксына башладылар. Төгәл мәгълүматлар буенча әйтүем, чабуларыгызны җыебрак йөрегез. Компроментация ясарлык бөтен язу-сызу бүген үк көлгә әйләндерелергә тиеш. Бүген булмаса иртәгә, редакциядә дә, квартирагызга да тентү булуын көтегез. Мин үзем сезне эзләп тапмакчы идем әле. Ә Фәрхетдин бүген кичке сигезләргә редакциягә килеп җитәр.
Хөсәен эчтән генә: «Газетага язылган барлык материал патша сатраплары өчен хәнҗәр ул», дип уйлады. Ләкин шулай да аңлады: Николай кораллы көрәшкә өндәгән конкрет материалны һәм явка адресларын күздә тота. Анысын инде Хөсәен үзе дә белә һәм шуңа охшаш әйберләрне газетага эзоп телендә кертеп җибәрә иде.
Фәрхетдин нәкъ әйтелгән вакытка килеп керде. Ул бик көр, күтәренке күңелле, елмайган хәлдә, Хөсәен белән дә, Басыйр белән дә ике

кыллап исәнләште. Әлбәттә, ул ерактагы Нәдердә булган хәлләрне бөтенләй белми иде.

— Я, ничек соң, теге көнне эштән соңга калуың өчен мастерыңнан эләкмәдеме? — дип сорады Хөсәен.

— Яшәсен Егорыч, ул мине моңарчы ким-хур итмәде. Эш тукталмаган, минем урынга башка берәү чукеч сугып торган.

Фәрхетдиннең, кирәксә, Хөсәен кушкан эшне тагын башкарырга әзер икәнлеге күренеп тора. Хөсәенгә бик авыр булып китте. Шундый күтәренке күңел белән дәртләнеп килгән үзе яраткан кешесенә, якын егеткә бик авыр хәбәр әйтү аның йөзенә сугып, битенә төкерүдән дә хәтәррәк тоелды. Ләкин моны Хөсәен эшләргә тиеш иде. Ул сүзне ерактанрак башлап китте.

— Әйдәле, Фәрхетдин, утыр әле. Бер сөйләшик әле. Синең тормышлар ничегрәк соң?

— Эш ярыйсы бара, Хөсәен абый, әйткән идем бугай: Егорычка тап булып бик уңдым. Ул әйткән сүзендә тора, мине келәшчә тотарга да өйрәтә, хәзер инде җиңелрәк әйберләрне тимерче кебек үзем дә әтмәлли алам. Бик әйбәт мачтыр, «Фархутдин якши» дип кенә тора. Үзем дә инде кырыкка ярылсам ярылам, барысын да ул кушканча итеп эшлим. Шәп кеше бит. Ул яхшылык иткәндә ничек сүзен тыңламыйсың?! Аннан инде минә миңа яңа юаныч табылды, мин татар-башкорт агай-эне арасында сез чыгарган «Урал»ны укыйм. Күзләре ачыла томаналарның. Ну, үземнеке дә, әлбәттә. — Фәрхетдин көлеп җибәрде. — Рәхмәт, Хөсәен абый!

Хөсәен авыр сүзне ничек әйтергә гаҗизлектән тирән итеп көрсенеп куйды. Күрәсең, бу Фәрхетдингә тәэсир итте, ул җитдиләнеп, нидер эзләгәндәй, игътибар белән Хөсәеннең йөзенә карап алды.

— Үзегезнең хәлләр ничек соң, Хөсәен абый? Хәдичә апа исән-саутына йөриме? — диде.

— Хәдичә апаң авырып китте әле...

— Ту-ты, бик өшәнгәнсең, гүпчи бетерешкәнсең. Шулай инде, авыру бактың ни, авырып яттың ни, дип дөрес әйткәннәр. Бик каты чирлимени?

— Суык тидергән. Үпкәдә.

— Минә суык тидерүдән башлана инде ул барысы да. Минем әти дә минә лашман тарттырганда бозлы суга чумып суык алдырган да хәзер үпкә чиреннән гомерлек хаста булып калды. Чахот чире.

Хөсәен әңгәмәнең чишелеше якынлашканын тойды.

— Өйдән хәбәр алып торасыңмы соң, Фәрхетдин?

— Монда килгәч тә, көзлектә бер хат алган идем. Шуннан бирле ул-бу юк.

—Ниләр бар соң? Нинди хәбәрләр?

— Авылга килеп прокламация таратып киткәннәр. Аннан соң атлы казаклар килеп авыл халкын бик каты өркеткән.

— Шулай икән. Ә семья турында ни язалар соң?

— Шәп түгел инде, Хөсәен абый. Әти карт уларга ята, Хафаза әле баладан котылмаган. Акча җыям, җибәрермен дип торам. Хәлләр шәп түгел авылда. Безнең якта бик каты ачлык бит.

— Фәрхетдин, өйдә әйбәт түгел дисең инде син?

— Әйе, Хөсәен абый.

Хөсәен нидер сизенеп каушап калган Фәрхетдингә кискен бер караш белән текәлде.

— Ә син, Фәрхетдин, тагын да начаррагына да әзер бул.

— Ни язса, шуны күрербез инде, Хөсәен абый.

— Шушы көннәрдә мин бер ышанычлы кешедән хат алдым. Ул синең авылда — Нәдердә булган.

Фәрхетдиннең күзләре зураеп китте, үзе алгарак иелеп, сулышын ешайта төште. Хөсәен сүзен дәвам иттерде:

— Ул кеше синең әтиеңнең узган айда гүр иясе булып китүе турында яза.

Фәрхетдиннең йөзе күзгә күренеп агарынды.

— Булмас!

— Булган инде, Фәрхетдин дус, әмма үзеңне нык тот.

— И алла, — дип куйды Фәрхетдин, үз-үзен кая куярга белмәгәндәй, тәкатьсез калып тирә-юненә карап алды, күзләреннән яшь бөртекләре атылып чыкты.

— Җирләгәннәрме инде? Нигә моның турында Хафаза миңа берни дә язмый икән соң?

Хөсәен Хафаза турында дөреслекне әйтергә җөрьәт итмәде.

— Ул авырый икән, каты авыру, ди.

Фәрхетдин урыныннан сикереп торды. Кулларын алга сузып ярдәм эзләгәндәй, Хөсәенгә таба атлады.

— Хөсәен абый, нишләргә соң инде миңа?.. Хөсәен абый!

Аның күз яшьләре хәзер битен мул итеп чылаталар, үзе исә калтыранып елый иде. Хөсәен дә өстәл яныннан торды, аннан килеп Фәрхетдиннең иңбашына кулын салды.

— Хөсәен абый, — диде Фәрхетдин, әкрен генә сулкылдап елый-елый. — Күңелем сизенә: Хафазам үлгәндер кебек. Ул бит йөкле иде. Ничек ул болай... Ул бит миңа: «Малай табып бирәм, сиңа памушник булыр», дип әйтә торган иде.

— Тынычлан, тынычлан, Фәрхетдин, бирешмә, — диде Хөсәен. — Мин сиңа менә нинди киңәш бирәм.

Фәрхетдин керле кулъяулыгын кесәсеннән чыгарып күз яшьләрен сөртте, борынын сеңгерде.

— Менә нинди киңәш, — диде Хөсәен. — Син, озакка сузмыйча, тиз генә авылга кайтып кил. Хәл-әхвәлне үз күзең белән күреп белерсең. Ә юлга акча мәсьәләсендә мин үзем сиңа булышырмын, бүген үк мастерскойдагы начальствоң белән сөйләш, хәлне аңлат һәм мөмкин булса иртәгә үк кит. Ләкин, Фәрхетдин, ишетсен колагың: ни генә булса да, анда калма, аңладыңмы? Китәр алдыннан миңа кер, мин сиңа юллык акча әзерләп куярмын.

Фәрхетдин юллык акчаны Хөсәеннең үз кесәсеннән, көндәлек чыгымнар өчен билгеләнгән сумадан бирәчәген аңлый иде. Шуңа күрә андый акчаны аласы килмәде. Хөсәен моны тойды, аңлата башлады: егеткә Хөсәен ярдәм итмичә кем итсен тагы? Якын кешегә мондый вакытта да булышмаса, кем була ул Хөсәен!?

Иртәгесен үк Фәрхетдин көн яктырыр-яктырмас вакытта Хөсәеннәр капкасын какты. Өйдәгеләрнең барысы да чәчрәп аякка бастылар: полиция килгән дип уйладылар. Капка ачарга чыккан Хөсәен Фәрхетдинне күргәч кенә тынычланып көлеп җибәрде.

Ул Фәрхетдин белән кухня якта гына сөйләште, аңа акча бирде, хәерле юл теләп озатып калды.

Ләкин Хөсәен тентергә килүләрен көтеп ялгышмаган иде. Бусы да шул ук көнне булды, ләкин полиция төн уртасында килде. Өйдә авыру бар дип тормадылар, бөтен нәрсәнең астын-өскә китерделәр, шик кузгатырлык берни тапмыйча сукранып китеп бардылар. Шул ук төндә тентү Сәйфетдинев квартирында да булган. Артык ягымлы Анфиса Петровна өендә калырга ярамый иде хәзер. Хәдичә аякка басу белән Хөсәеннәр идарә урнашкан «Американская гостиница»га күчеп киттеләр.

— Әфәнделәр, мин үзебезнең Уральскида куелачак беренче татар спектаклендә катнашырга шатланып риза булам. Хәтта шул кадәресен дә әйтим ки: мин спектакль башланганчы кыска гына бер концерт та бирә алам.

— Бик хуп, — диде Хәйруллин. — Рәхмәт сезгә, Камил әфәнде.

— Тик шунысы үкенечле, — диде Камил Мотыйгый, — Россиядә беренче публичный татар спектаклен миңа куярга туры килмәде. Югыйсә, минем шөһрәт икеләтә артыр иде. Кем Россиядә татар матбугатына беренче булып юл ачты, ә?

Камил ак тешләрен ялтыратып, түшен киереп, кәефләнеп көлеп куйды.

— Ә Гаспринский әфәнденең газетасын сез санга сукмыйсызмыни?— диде Тукаев.

— Һо-һо, әйттегез сүз! Сез үзегез үк аны безнең телдә чыга торган газета түгел бу димәдегезмени?!

— Әйттем, әмма ул газетаны татар укый бит, ярым-йорты аңлап булса да...

— Ягез әле, бәхәсләшмик, — диде Хәйруллин, — барысы да хәл кылына дигәндә генә сез сүзне бөтенләй икенче якка бора башлыйсыз.

— Барысы да, минемчә, сөйләшенде инде, «Гыйшык бәласе»н куябыз. Рольләр дә бүленде. Сезгә, Миңлебай әфәнде, хатын-кыз рольләрен бирәбез, ә Тукаев безнең койган да куйган Габдессамат хәлфә инде.

Камил Мотыйгый үзенең яңгыравыклы калын тавышы белән тагы көлә башлады.

— Бик ул кадәр бүленеп бетмәгән шул әле, әфәндем, без яңадан ике кеше табарга тиеш. Берсе — суфлер, икенчесе — Сәхиб ролен башкаручы.

— Әйе, анысы бар икән әле. Безнең шәкертләрдән мәгъкуль кеше табылмас инде.

— Юк шул, Камил әфәнде. Беришесе теләми, теләгәннәре — рольгә яраклы түгел.

— Миндә бер фикер бар, — диде Тукаев. — Әйдәгез, егетләр, татар приказчикларын да тартыйк бу эшкә. Алар профсоюзлар оештырып мәш киләләр. Араларында бик тәрәкъкый пәрвәрләре дә бар. Аннан соң алар безнең мескен шәкерт кебек һәфтияк кимереп ятучы күселәр түгел, башларын югары тотып сөйләшә беләләр. — Шуннан соң ул Миңлебайга мөрәҗәгать итеп сөйли башлады: — Хәтерлисеңме, бер чибәр генә егет безнең номерга керә иде, мин аңа «Урал»ның беренче санын күрсәтеп тора идем син кайтып кергәндә.

— Хәтерлим, шуннан нәрсә булган?

— Шул егетне мин бер кызыл мал магазинында очраттым. Ул приказчик булып алган. Уральскига килү белән эшкә урнашкан. — Тукай башын өскә калкытып алды.— У-у, аның ни дәрәҗәдә белемле икәнен күрсәгез! Ул Маркларны яттан, карый корьән укыган кебек, су урынына эчә.

— Безнең компаниягә керерме соң? — диде Камил.

— Сөйләшеп карарга кирәк.

— Алайса, сез бүген үк аны күндерергә тырышыгыз, әфәнделәр. Ә суфлер табуны мин үз өстемә алам.

— Булды, мәслихәт, — диештеләр.

Китәргә җыенып аягүрә бастылар.

— Онытмагыз, — дип калды Камил. — Иртәгә Народный домда репетицияләр башланырлык булсын.

Урамга чыккач, Хәйруллин:

— Әйттемме мин сиңа,— диде Тукайга.— Камил Мотыйгыйны һәр яңалыкка тартып була. Ул кая барып сугылса да, тәнкә чәчелә башлый.

— Яратам мин аның шундый дәртле, ялкынлы кеше булуын. Һавалырак, аумакайрак та булмаса, милләтебезнең беренче каһарманы булыр иде...

Алар кунакханәгә кереп тормадылар, туп-туры Җәгъфәрне эзләп кызыл мал кибетенә киттеләр.

Народный дом дип аталган, бишенче елны ачылган клубта иртәгесен репетицияләр башланды. Көндезләрен күпчелек кеше эштә булу сәбәпле, алар кичләрен генә җыелалар һәм репетиция төнге берләргә кадәр дәвам итә иде. Бу эштә алар барысы да ялкынланып янып йөрделәр. Тукай үзенең шагыйрьлеген, Камил наширлеген, Җәгъфәр приказчиклыгын оныткан иде. Алар өчен бу мавыктыргыч бер уен иде. Бары Миңлебай Хәйруллин өчен генә бу уен түгел, бик, бик җитди эш. Ул үзенең хыялын тормышка ашырган бәхетле кешедәй йөрде. Дустының бу минутлардагы нурланган шадраРак йөзен күреп шагыйрь ихлас күңелдән сөенә, Хәйруллинның омтылышы нигезле җирлеккә корылганлыгын аңлый, аңарда искитмәле артистлык сәләте күрә. Хәер, Тукай үзе дә начар артист түгел иде. Ул бик матур, бик моңлы итеп татар, башкорт көйләренең бөтен борылыш-нюансларын җиренә җиткереп, күңелләрне җилкендерерлек итеп җырлый белә, теләсә кем булып кыланып күрсәтә ала. Ләкин шулай да ул Миңлебайдан уздыра алмый. Хәйруллин кыз ролен башкарырга хәзерләнә иде. Әле хатын-кызча киенмәвенә, парик, грим булмавына карамастан, ул хатын-кыз табигатенең беркем дә игътибар итмәгән үзенчәлекләрен шаккатырлык дөрес итеп күрсәтә белә иде.

Егетләр беренче репетициядән соң өйләренә төннең икенче яртысында гына кайттылар. Дәртләнеп, ару-талуны тоймыйча, бер-берен бүләбүлә сөйләшеп бардылар. Барысы да үзләрен бер дәрәҗәдәге, берберенә тиң кешеләр итеп тойдылар, барысы да шат, бәхетле иде. Бераздан берәм-берәм тарала башладылар. Соңыннан Җәгъфәр, Габдулла һәм Миңлебай гына калдылар. Аяз күктә, егетләр белән бер тарафка баргандай, тулган ай ага. Тып-тын. Буп-буш урам аерата иркен тоела. Һава салкын булса да, җил исмәгәнгә суык ул кадәр борчымый, сөйләшергә комачауламый иде.

Өч шәкерт белән Камил Мотыйгый аерылып тыкрыкка кереп киткәннән соң, моңа кадәр урамны тутырып шаулашкан төркем беравык сүзсез барды. Ике катлы, асты таш, өсте агач зур өй турысына җиткәч, сүзне Тукай башлады:

— Сезнең хәлләр турында сорашырга да вакыт тимәде,— диде Җәгъфәргә.— Сез беренче очрашуда ук исемегезне әйтмичә качып киттегез. Ярый ла, мин сезне магазинда теге көнне иттифакый[1] рәвештә очраттым. Бары шунда гына Җәгъфәр икәнлегегезне белү шәрәфенә ирештем. Ничек урнаштыгыз соң?

— Минем бәхеткә каршы, Уральскида бер авылдаш очрады,— диде Җәгъфәр,— әгәр ул булмаса, миңа, әлбәттә, өй борынча йөреп хәер эстәргә генә калыр иде.

— Сөйләмәгез юкны, сез Уральск халкы турында бик начар фикердә икәнсез. Аннан соң, минем аңлавымча, сезнең белемегез дә бик тирән. Сез мәдрәсәдә генә укымагансыздыр?

— Мин Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыдым, аннан, аны ташлап, русча укып маташтым бераз.

— Гимназия бетердегезме?

— Һе, мин гимназия бетергән булсам!

Җәгъфәр бераз уйланып торды.

[1] Иттифакый — очраклы.

— Әти рөхсәт бирмәде. Инде мин, аның сүзен тыңламыйча, бер учительдән дәрес алып укуымны дәвам иттергәч, ул миңа бәддога кылды. Үлде ул узган җәй. Бик бай мөлкәтле, ләкин ифрат иске фикерле кеше иде, мәрхүм, миңа мирас итеп сукыр бер тиен дә акча калдырмады.

— Алайса, минем хәл ул яктан сезнекеннән шәбрәк икән, — диде Тукай көлемсерәп. — Мин күптән түгел үзем туган Кушлавычтан хат алдым. Хатта язганнары дөрескә чыкса, миңа моннан егерме ел элек үлгән әтиемнән йөз сумга якын мирас калган булырга тиеш.

— Чыннан да, сез бәхетле икәнсез шул, Тукаев әфәнде,— диде Җәгъфәр, күңелсез генә елмаеп.

— Сезгә, Җәгъфәр дус, күңел төшерергә урын юк, — диде Хәйруллин.— Сезнең авылдаш ул кибеттә кем булып эшли? Управляющиймы? Бетте. Бераз тырышсагыз, бер елдан сез — старший приказчик.

Җәгъфәрнең йөзе кинәт җитдиләнеп китте.

— Нәрсә хакына ул мине шулай күтәрергә тиеш дип уйлыйсыз?

— Авылдаш булганыгыз өчен, тырышлыгыгыз өчен, Җәгъфәр әфәнде.

— Эх, егетләр,— диде Җәгъфәр тирән сулап.— Сез шаяртасыз. Вәхаләнки хәзер, сыйнфый көрәш зилзиләсе җирне тетрәткән бер чакны, тырышып эшләүнең дә, авылдашлыкның да бер тиенлек тә әһәмияте юк.

— Ничек инде юк? — диде аптырый төшеп Хәйруллин.

— Мин дә аңламыйм,— диде Тукай.

— Хәзер, егетләр, карьераңны бирелгәнлек я сатылганлык кына хәл итә!

— Куегыз әле! Сез бигрәк!

— Артык утрировать итәсез.

— Ашыкмагыз, хәзер мин сезгә барысын да аңлатам. Авылдаш очрап мине бәладән коткарды, дидем бит. Миңа кулай эш табылды, ятак бирелде, айлык акча белән тәэмин итеп башлады. Ә менә эшкә керешүемә ун көн узмады, мине авылдашым үзенең канторасына чакырып кертте дә, безнең приказчиклар арасында бик юньсез адәмнәр бар, алар белән зинһар сак бул, әгәр инде берәр кабахәтлек эшләгәннәрен күрсәң, миңа әйтми калма, диде. Мин түзмәдем: Хафиз абый, мин бит сезгә доносчик булып ялланмадым, приказчик булып кына эшлисем килә, дидем. Кул кулны юа ул, ди. Бу инде байның әмере, ди. Бай кушканны мин үтәргә тиеш, инде авыр чакта сиңа ярдәм итеп тә сиңа таянып эш итә алмам микәнни? — ди. Инде тагы болай ди әле: приказчиклар арасында байга каршы котыртучы юньсезләрнең кем икәнлеген алдан белеп торсам, бай алдында минем абруем күтәрелә бит, энем. Ә минем абруй ул — синең абруй, ди. Мин картаепмы, я булмаса баепмы моннан китәрмен бер көн, шул чакны минем урынга син кереп утырырсын. Аңладыңмы? Тормыш ул! — ди.

— Тормыш муеныңны бормыш,— дип куйды Тукай.— Ләкин мин ул Хафизга туп-туры: «Мин сезгә шпион була алмыйм!» дияр идем.

— Мин дә аңа шулайрак әйттем. Әгәр мин сезгә приказчиклар өстеннән доносплар ясамасам, нишләрсез? — дидем. Бу бик тиз арада мәгълүм булачак, диде. Булса соң? дидем. Булгач, якташлык бетте инде, бигайбә, калганын үзең аңла, диде. Күрдегезме, инде мине якташ булганга күрә түгел, ә шпион итеп булмасмы дип, канат астына керткән. Менә сезгә сәләткә хөрмәт, менә сезгә инсаният!

Алар чатта тукталып тордылар.

— Хушыгыз. Рәхмәт арагызга кертүегез өчен,— диде Җәгъфәр.— Бу көн кебек бәхетле көнне күптән күргәнем юк иде.

Алар саубуллашып аерылыштылар. Тукай белән Хәйруллин байтак вакыт аяк астындагы кар шыгырдавын тыңлап, сүзсез уйланып бардылар.

— Казанга, Казанга! — диде Тукай ачыргаланып.— Сәгыйтьләр, Галиәсгар, Фатих әфәнделәр янында буласым килә. Сәгыйть белән ярышып шигырьләр язасым килә. Бу кабахәт, гадаләттән ерак, караңгы тормышны фаш итеп, усал, яшен кебек үткен, бар золмәтне бер оруда зир-зәбәр итәрлек шигырьләр язасым килә. Аңлыйсыңмы, дус кеше?

Хәйруллин әле сүзнең бетмәгәнлеген тоя иде. Ул, кайнар йөрәкле дустының күңеленә сыймаудан ургылып тышка чыккан хисләре йогынтысында үзе дә ярсыган хәлдә, сүзнең дәвамын көтте. Тукай бераз вакыт уйланып барды да шактый тынычланып:

— Мин быел туган якларга солдатка каралырга кайтасы кеше бит, Миңлебай, — диде. — Белеп торам: мине солдат хезмәтенә алмаячаклар. Ләкин мин, шул форсаттан файдаланып, барысы белән дә танышачакмын. Һәм...— Тукайның ап-ак тешләре ай яктысында чагылып китте.— Һәм синең Тукай дустың Казанда җиң сызганып, шигырь дигән кылычын зур колач белән кынысыннан суырып чыгарачак. Аһа! Рөстәм, Галиләрең торсын шул чак бер якта!

Алар «Казан» кунакханәсенә барып җиттеләр. Җылы бүлмә, кайнар чәй ләззәтен алдан ук тоеп, киң агач баскычтан өске катка йөгерә-атлый менеп киттеләр.

Җәгъфәр дә бу вакыт үзенең торагына кайтып җиткән иде. Капка бикле булганлыктан, койма аркылы төште. Ишегалды түрендәге бәләкәй генә өйнең ишегенә барып кагылуы булды, урта тәрәзәне балкыткан ут кинәт сүнеп китте. Ләкин шулай да озак көттермәделәр. Бу яңа приказчикны сукранып, мыгырданып каршы алдылар. Җәгъфәр сүзгә каршы сүз кайтармады. Тавышсыз-тынсыз чишенде дә шыгырдавык тар караватына ауды. Күңеле белән тойды: аның тизрәк йоклап китүен телиләр иде. Ул одеялын баштан ук бөркәнде. Байтак вакыт өй эчендә сәгать текелдәвен тыңлап ятты. Кемдер күрше бүлмә ишеген сак кына ачып, күрәсең, Җәгъфәрнедер күзәтеп торды. Аннан ишек шыпырт кына тагы ябылды.

— Йоклады. Әйдәгез укыгыз, бетерик,— диде берсе ярым пышылдап. Җәгъфәр ихтыярсыздан игътибарын ныграк туплады. Ул соң дәрәҗәдә кызыксынып, приказчикларның ни эшләүләрен белергә тели иде.

— Сез иртәдән кичкә чаклы прилавка артында вакыт уздырасыз, — диде бер приказчик.— Сез үзегезнең хезмәтегез белән хуҗаларыгызга дәүләт җыясыз. Ләкин бу көн буе эштән соң сез балаларыгыз берлән чүкердәшеп сөйләшеп утырырга, ул балаларыгызны тәрбияләргә, карарга, аларның киләчәктә кеше икәнлекләрен дә аңлаган гражданнар булуларына инә очы кадәр дә вакыт сарыф кыла алмыйсыз.

«Урал» газетасы укыйлар, дип уйланды Җәгъфәр. — Валлаһи, шулай!»

Ул ирексездән башын калкытты.— «Урал» газетасы, Хөсәен,— дип куйды. — Әйдә укысыннар!»

Җәгъфәр тоныккына ишетелгән тавышка колак салды.

— Шуңар күрә сезгә ялланып эшләүчеләрнең барысы өчен дә сигез сәгатьлек эш көне, айлыкның[1] иң ким көн берлән тәгаен кылынуы, картлыктан һәм авырудан эшчеләрнең мәмләкәт хисабыннан страховать ителүләрен булдырырга тырышучыларны выборщиклар итеп сайларга кирәк...

«Бәхетле кеше Хөсәен», диде Җәгъфәр йокы аралаш.

## 25

— Карале, Галимҗан! Мин Әбелмамбетовтан килгән хатны редакцияләп чыктым. — Тыңлале, бәлки синең дә замечаниеләр булыр. Безгә аны 10 нчы саннан да калдырмаска кирәк, — диде Хөсәен.

[1] Айлык — хезмәт хакы.

Галимҗан, урындыгын күчереп, аның янына килеп утыргач, Хөсәен казакъ егете оештырган «Русия халкына ачык хат»ны укырга тотынды.

«Русия гражданнары! Без, кыргызлар [1], хөкүмәт, безнең җиребезгә Русия эченнән җирсез крестьяннарны күчереп безне талатма, бу эшең безгә зарарлы, диеп үтенеп карадык. Бу эшебез турысында без самодержавие хөкүмәтеннән үтенә-үтенә бик күп акчаларыбызны да, бик күп көн вакытыбызны да бетердек. Безнең ихтыяҗыбызга хөкүмәт бер дә илтифат итмәде. Безнең хөкүмәт тарафыннан җиңеллек көтүебез файдасыз булып чыкты. Инде без, хөкүмәткә ышанмаенча, бөтен Русия халкына ялварабыз. Туганнар! Хөкүмәт, безнең наданлык берлән, безнең укымаганлык берлән файдаланып, безнең бөтен областьлардагы яхшы җирләребезне талап алып, көчеп килгән адәмнәргә биреп тора. Безгә комнан һәм чагыр, әрем үсә торган җирләрдән башка бер нәрсә дә калмайды. Хөкүмәтнең эшләгәне болар гына түгел әле. Хөкүмәт, безгә бер дә мәгълүм кылмаенча, безнең арабызга үзенең чиновник агентларын җибәреп тора. Болар безгә килеп, халыкны алдап, куркытып, халыкның арасына гауга салып йөриләр. Халык бу чиновникларның ниндәен сәбәп берлән килгәнен белмәенчә, бәгъзеләре подать, ягъни өй акчасы, җыйнарга, безнең малыбызны язып алып китәргә килгәннәр дип уйлыйлар. Халык малыбызны язарга килгән икән диеп куркып йөдәгәннән чиновникларга мал хисапларын киметеп яздыра. Әмма безгә җирне мал хисабына бүлеп биргән сәбәпле безнең мал асрарга җиребез бик аз кала. Безгә калдырган җирләре чагырдан башка чүп үсми торган җирләр. Безнең тары, бодай, солы чәчә торган яхшы җирләребезне чиновниклар, байлар белән бер авызда булып, фәкыйрь әдәмнәргә зарар китереп, куркытып алып, күчеп килгән адәмнәргә бирәләр. Безнең тора торган зимләнкәләребездән куалап чыгарып, икенче җиргә күчәргә кушалар».

Шул җиргә җиткәч, Галимҗан Хөсәенне туктатты. Аңа кайбер казакъча атамалар аңлашылмый иде. Алар, бераз киңәшкәч, мәкаләнең стиленә һәм кайбер милли үзенчәлекләренә кул тидермәскә булдылар. Чөнки бу хат бит бөтен Россия халкына мөрәҗәгать, анда кемнәрнең аһ-зары язылганлыгы беленеп торсын дигән фикергә килделәр. Хөсәен укуын дәвам иттерде. Ул озын хатның ахырына җитә башлады:

«Туганнар! Әгәр дә сез гаепсез халыкның каны түгелмәвен чын күңелегез белән теләсәгез, хөкүмәтнең бу эшен туктатырга тырышыгыз. Җирсез йөдәгән крестьяннарга безнең җирләребезне талап алып бирмәенчә, Русия эчендәге үзенең кенәз һәм монастырь җирләрен бирсен. Без дә үзебезнең кулдан килгән кадәрле иҗтиһад итәрбез».

Хөсәен, «ничегрәк бара?» дигәнне аңлатып, Галимҗанга карап алды. Теге хуплап аяк каккач, укуын дәвам иттерде. Мөрәҗәгать-хатның азаккы юлларын Хөсәен һәр сүзенә аерата басым ясап, вәзенләп укыды.

«Без югарыда язылган сүзләрне рус халкына дошманлыктан әйтмайбыз. Рус халкы безгә дошман имәс. Безнең барыбызның да дошманыбыз бер, ул — самодержавный правительстводыр.

Безнең бүлерлек җиребез булса, рус халкы белән бүлешер идек. Иң әүвәл Русия эчендәге алпавыт, монастырь һәм удельный җирләрне җирсез крестьяннарга бүлеп бирергә кирәк.

Бөтен җир бөтен халык кулына керсен. Ләкин бу эш бары мәмләкәттәге власть халыкның үз кулына күчкәч кенә булыр. Шуның өчен без бар халык белән бергә көрәшергә уйлыйбыз.

Кыргызларның уполномоченныйлары».

Хөсәен шактый зур исемлекне укып чыкты.

---

[1] Революциягә чаклы рус рәсми документларында казакъларны кыргызлар дип атаганнар.

— Я, ничек, шулай барыр кебекме?

— Әйбәт, әйбәт, акыллы һәм казакъка хас оста әйтелгән. Тик анда, Хөсәен, тагы «власть» дигән сүз кабатлана. Аны цензор җибәрмәс дип куркам.

— Кай турыда киткән соң ул сүз?

— Соңгы җөмләдән алдагысын укы әле.

— Чыннан да, шулай икән шул, — Хөсәен әлеге сүзне төзәтеп куйды. — Менә, алайса: «...эш бары мәмләкәттәге көч халыкның үз кулына күчкәч кенә булыр». Шулай барамы?

— Шәт, иншалла,— диде Галимҗан көлемсерәп.

Алар берара тынып тордылар. Һәркем үз эше белән генә мәшгуль иде. Хөсәен шушы хатны җибәрүче казакъ егете Әбелхәер турында уйланды. Әйе, аңа рәхмәт әйтеп, җылы гына хат язасы бар әле. Бәлки ул казакъ далаларында барган ыруг талашлары турында, бу ахмак нәрсәнең ахыр чиктә социаль азатлык өчен барган көрәштән казакъ халкын читкә тартуы, аның уй-фикерләренә, аңына кирәкмәс юнәлеш бирүе турында язар. Һай, шәп булыр иде дә соң әгәр ул егет халкы арасындагы сыйнфый көрәшне чагылдырган материал җибәрсә.

Хөсәен шул ук арада, газетаны башкорт халкы турындагы материаллар белән дә баетасы иде бит, дип уйлап алды. Исенә Чынбулат төште, аңа бәйләнеп Фәрхетдин күзалдына килеп басты. Тәгаен, бәхетсез егет үзенең Нәдеренә кайтып җиткәндер инде. Күз яшьләрен агызып үксеп елый торгандыр. Аерата Хафаза өчен, баласы өчен ачыргаланып елыйдыр. Хәер, ни өчен Гафур бала турында берни дә язмый. Исәнме ул, кем кулында тәрбияләнә? Хөсәеннең күңеленнән җитез, шаян коштай: «Һай, минем дә балам булса иде», дигән уй уйнаклап узды. Аннан ул, бәлки Фәрхетдиннең ятим баласын, ул исән булса, тәрбияләп үстерергәдер, дип уйланды. Ләкин бу теләкнең һич нигезсез татлы бер хыял гына икәнлеген ул яхшы белә иде. Хәдичә аякка яңа басты. Әле дә бу ике бүлмәле номерны ятсынып, Анфиса Петровнаны сагынып яши. Өзлексез күзәтү астында яшәү. Төнге тентүләр. Аннары соңгы көннәрдә Хәдичә белән Хөсәен арасында ниндидер, моңарчы һич тоелмаган, күренмәгән аңлашмаучылык. Арыдым, ди Хәдичә. Юк, бу гади ару гына түгел, моның тамырлары бик тирән яшерелгән.

— Карале, әйтергә онытканмын, — диде Галимҗан. — «Бәянелхак»-тан мәктүб килде бит!

Хөсәеннең уйлары бүленде. Казанда сәүдәгәр Сәйдәшевләр тарафыннан чыгарыла торган иң реакцион татар газетасының исемен ишетү белән аның чыраена усаллык йөгерде.

— Нием калган аларга?

— Газеталары турында игъланнамә басуларын үтенәләр.

— Инде шул гына калган иде «Уралга». Нигә кирәк ул безгә көфер почмагы каһарманнары органын пропагандалау?!

— Кара инде, үзең беләсең, — дип куйды Галимҗан. — Әмма алар яхшы түлиләр, бәдбәхетләр. Черегән байлар бит наширлары.

Хөсәен кашларын җыерып читкә карап торды.

— Ярар, алайса, дүртенче битнең иң астына бир игъланнарын, — диде күңелсезләнеп.

Галимҗан көлеп куйды.

— Эш аларның акчаларында гына да түгел,— диде Хөсәен өстәп,— хикмәт кайберәүләргә объектив булып күренергә тырышуда. Партиясез газета...

— Әйе, әйе, мин килешәм, — диде Галимҗан. — Язылучы кеше безнең игъланга гына карап тормый инде ул, языла бирә.

— Юк, без аны, ул газетаның сафсаталарын дип әйтүем, «Урал»дагы мәкаләләр белән өзлексез туарып торырбыз. Безне төп укучы аңлар...

Алар тагы эшкә чумдылар.
— Әйе, — диде Хөсәен, кинәт нидер хәтерләп, — ничегрәк тора икән Вәли хәзрәт мәдрәсәсендәге хәлләр?..
— «Урал»да басылган ачык хат нәтиҗәсез калмаган. Минем адаш тагы килә. Заһидулла хәлфә белән бик каты дәгъвага кергәннәр. Егерме бишләп шәкерт мәдрәсәне ташлап чыгарга җыеналар, ди.
Хөсәен җанланып китте. Урыннан торып тәрәзә янына килде.
— Әгәр егетләрнең андый эшкә батырлыклары җитсә, аларга ничек тә ярдәм оештырырга кирәк.
— Газета аша иганә җыю...
— Иганә җыю, аннан җәмәгатьчелек фикерен тудыру...
Хөсәен тагы өстәле янына килде. Утырып, аның тартмасын ачты да Галимҗанга кульязма сузды.
— Карап чык әле, зинһар. Шәкертләргә тагы бер ачык хат язуны кирәк таптым мин, — диде.
Галимҗан баш тартмады, шунда ук укый башлады.
— Оһо! — дип куйды ул бераздан. Кычкырып укый башлады: «Шәкертләр! Бәлки сезгә милләтчеләр: «Юк, безгә, мөселманнарга, махсус гимназияләр, университетлар һәм башка мәктәпләр ачып, хәзерге заманга муафыйк фәннәрне шәкертләргә татар телендә укытырга кирәк, мәмләкәтнең мәктәп вә мәдрәсәләренә кереп фәннәр уку — бу фәннәрне рус телендә алу дигән сүз бит. Бу ниткән эш? Ул чакта безнең телебез югалачак, телебез югалгач, татар милләте дә бер милләт булып яшәмәячәк бит», диярләр. Шәкертләр! Сез аларга: без Русиядә торабыз, без сезнең кебек үзебез Русиядә торып та, «төрек булып» йөрмибез дип җавап бирергә тиеш... Сез милләтчеләргә, дөньяга чыкмаслык бер хыялларга чумып, башыгызны ватканчы, әгәр кулыгыздан килсә, хәзерге мәдрәсәләргә фәннәр кертегез дип җавап бирергә тиеш».
Галимҗан укуыннан туктады да әсәрләнеп башын чайкап торды.
— Алай да! Бу юлларны Садри Максуди укыса, һушыннан язар иде.
— Ул гына һушыннан язмаячак, кара йөрәк Пурешкевич укыса да, һуштан язарга тиеш. Чөнки алар икесе дә ахыр чиктә бер үк җыр җырлаучылар...
Типографиядән гранкалар күтәреп Басыйр кайтып керде. Ул кәгазь төргәкләрен өстәлгә ташлады да, суыктан күшеккән кулларына өрә-өрә, кием элгеченә таба китте.
— Я, ниләр бар, Басыйр? — диде Хөсәен. — Сине борчымыйлармы?
Басыйр бишмәтен чөйгә элгән арада әйтеп куйды:
— Минем, Хөсәен туган, эшләр хәзер ярыйсы, куркытучы юк. Тик бит безнең әлеге Фәрхетдиннең эшләре бик начар, ахры.
— Нигә, кайтканмыни, күрдеңмени?
— Әнә ул безнең идарә ишек төбендә ята. Лаякыл исерек.
Хөсәен гасабиланып аякка басты.
— Әйдәгез әле! — диде, өстәл артыннан чыгып.
Өчәүләшеп ашыга-ашыга ишеккә ташландылар.
Фәрхетдин урамда «Американская гостиница»ның парадный ишегенә җитәрәк, тротуар читендә сул ягы белән бөгәрләнеп җирдә ята иде. Күрәсең, ул вокзалдан туп-туры «Урал» редакциясенә юл тоткан: аркасында биштәрләп таккан капчыгы, уң кулында такта сандык. Башын карга төртеп йоклый иде.
Фәрхетдиннең кесәсеннән чыгып торган буш шешә күргәч, Хөсәен егетнең Оренбурга килеп җиткәч кенә казенкага сугылганлыгын аңлады.
— Өйгә алып керик әле башта, — диде Хөсәен.
— Андый-мондый сүз булмасмы соң? — диде куркынып Басыйр. — Теге «мәгыйшәт айгырлары» күреп калмагае.
— Соң, аны урамда калдырып булмый бит инде. Ягез әле.

Хөсәен белән Галимҗан Фәрхетдинне култык асларыннан эләктереп аякка бастырдылар. Басыйр аның агач сандыгын тотты. Фәрхетдинне идарәгә алып керделәр.

— Бер-бер җирен өшетмәгәнме? — дип сорады Хөсәен.

Галимҗан Фәрхетдиннең йөзен, кулларын игътибар белән карап, капшап чыкты.

— Юк, минемчә, ул әле генә егылган булырга тиеш.

Фәрхетдин исә һаман әле гамьсез рәвештә йоклый иде. Ара-тирә авыр сулап ыңгырашуын һәм кашларын җыергалавын исәпкә алмасаң, ул хәтта типтереп яшәүче бәхетле бер кешене хәтерләтә иде.

Галимҗан аның бишмәт кесәсеннән аракы шешәсен тартып чыгарды.

— Оһо, бер бутылканы бетерә язган.

— Тинтәк, — дип куйды Хөсәен ачусыз гына.

Хәдичәнең өйдә булмавыннан файдаланып, Фәрхетдинне бүлмәгә кертеп салдылар. Шулай да егетне барагына илтеп куярга кирәк. Извозчик турында сөйләшә башладылар. Фәрхетдин бүген барыбер берни дә сөйли алмаячак, анда бүген мәгънә юк иде. Басыйр извозчик ялларга дип урамга чыгып китте. Ул әйләнеп кайткач, Галимҗан Фәрхетдинне атка утыртып барагына илтә китте. Чөнки ул гына егетнең торган җирен белә иде.

Хөсәен эш арасында өзлексез Фәрхетдин турында, аның язмышы турында уйланды.

— Баласы исән микән бичараның? — диде ул, кинәт үз-үзеннән сорагандай.

— Нинди бала?..

## 26

Казанда приказчиклар клубында каралган беренче публичный спектакль, аның тамашачыга ясаган тәэсире, инде өйгә кайтканда эшче яшьләр белән булган дәртле әңгәмә Гафурны, якасыннан тотып селкеп, тирән йокыдан уяткан сыман булды.

«Синең халыкка җиткерәсе сүзеңне тиешенчә матур итеп әйтә белү сәләтең бар, ни өчен син, Гафур, башлаган драмаларыңны дөньяга чыгару турында кайгыртмыйсың?» — Бу сүзләрне Хөсәен әйткән иде.

Өстәл тартмасында, өйдә, аның ике пьесасы ята. Берсе — «Ике фикер», икенчесе — «Яшь гомер» исемле. Хәер, беренчесе аның язылып беткән әсәр инде. Ул аны, дөресен генә әйткәндә, җитлеккәнлегенә шикләнеп, ничектер оялып, моңарчы кешегә күрсәтмичә тотты. Гафур яраткан, тәкъдир иткән Максим Горький йогынтысында язылды ул. Әле дә хәтерендә: әсәрне язу фикере аның башына беренче тапкыр бишенче елның революция давыллары күтәрелгән көзендә, төрмәдә килде. Ул аның сюжетын чыккач төзеде, тиздән күңелдә образлар туды.

Узган ел июнь азакларында яшерен рәвештә Хөсәен Казанга кайтып китте. Шул чак бер төнен ул дусты янында уздырды. Гафур аңа «Ике фикер»не күрсәтте. Ләкин, кызганычка каршы, Хөсәен укый алмый калды. Чөнки төн уртасында аңа эз югалту өчен Гафурлар квартирыннан чыгып китәргә туры килде. Шулай да китәр алдыннан Хөсәен кульъязманы Гафурга биреп:

— Котлыйм мин сине уңышың белән, — диде.

Гафур бераз ирония белән сорады:

— Ничек, укымаган хәлдә дәме?

— Әйе, чөнки мин сиңа ышанам,— диде Хөсәен.— Мин бит синең язучы булырга тиешлегеңне күптән әйтеп килә идем.

Ләкин шул көннән бирле әзер пьеса өстәл тартмасында ятты. Хәер, Гафур «Яшь гомер»не язды. Анысы хәзер яртылаш әзер хәлдә, шулай ук илһам, вакыт көтеп ята иде.

Әмма, ни әйтсәң дә, Гафур иҗат эшенә салкынрак карый иде, ахры. Хөсәен сүзләренең хаклы икәнлегенә Гафур Галиәсгар куйган спектакльне караганнан соң бөтен тирәнлеге белән ышанды. Спектакль идеалларыңны татар халкына җиткерү өчен иң якын, иң көчле сәнгать төре икән ләбаса. Гафур Дворянское собрание бинасы янындагы рус театрында еш булгалый. Ул анда куелган әсәрләрнең дә тамашачыга тәэсирен күреп, еш кына уйлана иде. Ләкин гади татар хезмәт иясенең үз телендә куелган спектакльләрне ничек каршы алачагын ул күз алдына китерә алмый иде әле. Приказчиклар клубындагы спектакль аның күзен ачты, язу дәртен кузгатты. Ул ашкынып, илһамланып, икенче көнне үк, мәктәптән кайту белән, иҗат итү өчен үзенең бүлмәсенә кереп бикләнде. Әйе, әйе, өстәл янына утыртмыйча булмый. Эшләргә кирәк. Бүген булмаса иртәгә дистәләп һәвәскәр труппалар спектакльләр куя башлаячак. Татар театры иң прогрессив идеяләрне, олы дөреслекне, туу белән үк, халык арасында таратырга тиеш.

Гафур атна буена тырышып үзенең «Ике фикер»ен төзәтте. Ул анда илдә бара торган фикерләр көрәшен образлар аша булдыра алганча чагылдырырга тырышты. Тамашачы, спектакльне карагач, «кызыл» фикернең «кара» фикерне җиңәчәгенә һәм кеше бары «кызыл фикер» тантана иткәндә генә бәхеткә, тигезлеккә, хөрлеккә ирешәчәк икәнлегенә ышанырга тиеш. Менә шул!

Гафур барлык көчен биреп эшләде. Һәм пьеса барып чыкты да булса кирәк. Ләкин «булса кирәк» кенә шул әле. Әсәренә нокта куйгач та, Гафур үзе белән бер мәктәптә укытучы булып эшләүче Гыйматулла Мостафинга укып чыкты аны. Гыйматулла Гафурның коллегасы гына түгел, фикердәше дә иде. Ул да, заманында мәдрәсәне ташлап, Гафур укыган рус-татар учительскаясын бетергән иде. Соңгы елларда, күрәсең, Гафурның да йогынтысы аз булмады, ул үзенең карашлары белән аерата суллар ягында торып, еш-еш кына фиргәвеннәрнең ачуын да китергәли башлады, Гафурга ул ихластан хөрмәт белән карый. Әсәрне яратты, ләкин ышаныч нык булсын өчен, аны бу эшнең әһелләренә укып карарга киңәш итте.

Гафур, атнакич мәктәптән укытып кайткач, ашык-пошык кына ашады да, үз бүлмәсенә кереп, Галиәсгарләргә барырга җыена башлады.

Кемдер ишек шакыды.

— Синме, Суфия? Мин хәзер...

— Абый, ниндидер авыл кешесе килгән, — диде Суфия, ишекне ача төшеп.

— Пенза ягымы?

— Юк, түгел, ахры.

— Хәзер, Суфия.

Гафур алгы якка чыкты һәм Фәрхетдинне күреп аптырап калды.

— Фәрхетди-ин! Исәнме? Әйдә уз. Нәдердәнме?

— Исәнме, абый. Нәдердән. Мин сезгә Хөсәен абыйдан хат алып кайткан идем.

— Хат?

Гафур тагы бер тапкыр аптырауга төште. Ләкин сүз әйтергә өлгермәде, Фәрхетдин үзе башлап:

— Син мине, Гафур абый, артык табалама инде. Мин бу хатны сиңа Оренбурдан кайтышлый ук тапшырырга тиеш идем дә, тик эшләрем бик тә ашыгыч булды шул.

Гадәттә, сөйләшкәндә кыюсыз гына елмая торган Фәрхетдиннең йөзендә караңгы бер рәнҗү күләгәсе ята иде. Гафур моның сәбәбен тиз аңлады.

Фәрхетдин исә, үзенең агач сандыгын һәм капчыгын караңгы коридорда калдырып, Гафур белән бергә эчке бүлмәгә узды. Идәннән тү-

шәмгә кадәр менгән киштәләрдәге китаплар ирексездән аның игътибарын тартты.

Әйе, Гафур егетнең авыр кичерешләрен аңлый иде. Ләкин аның Хөсәеннән хат китерүе гаҗәп тоелды. Гафур ашыгып конвертны ачты һәм күзләрен хат юллары буенча йөгертә башлады. Хәзер барысы да аңлашылды. Хөсәен хатында Фәрхетдин турында язган, Гафурның аңа ярдәм күрсәтүен үтенгән һәм булган корреспонденцияне шуның аша җибәрергә кушкан иде. Гафур бераз уйланып торды, аннары кунакны хәтерләп:

— Өстеңне сал, Фәрхетдин, утыр, кунак булырсың. Әле бүген китмисеңдер ич? — диде.

Фәрхетдин ашыга иде, ул бүгеннән дә калмыйча китәргә тиешлеген әйтте.

«Алай икән,— дип уйланды Гафур, димәк, бүген пьеса мәсьәләсе иртәнге көнгә калдырыла».

— Ашыгычрак килеп чыкты. Хөсәенгә җибәрәсе язуларымны ул арада гына тиешенчә әзерләп өлгерә алмам дип уйлыйм, — диде ул Фәрхетдингә.

— Ачуланма, абый. Оренбургдан кайтышлый ук керә алмадым шул. Нәдергә ашыктым. Күземә ак-кара күренмәде.

— Төшенәм,— диде Гафур,— төшенәм, туган. Батыр бул, түз, дөньядән башка ни әйтә алыйм?!

Фәрхетдин тирән итеп сулап куйды:

— Бер ай эчендә бер ишектән ике мәет алып чыкканнар. Әнинең дә хәле, ташка үлчим, Оренбурга алып китәрлек түгел.

— Кайда калдырдың соң әле әниеңне?

— Әнине хәзергә апада калдырдым. Тик ул анда да артык тамак инде, бичара.

Алар икесе дә беразга тынып, көрсенеп утырдылар.

«Туктале, ул «ике мәет» ди, — дип уйланды Гафур, Фәрхетдиннең әле генә әйткәннәрен хәтерләп. — Әтисе, хатыны. Димәк, бала исән. Гафур кызыксынуын һич яшерә алмыйча:

— Фәрхетдин, син ике мәет дидең. Бала исән дигән сүз. Шулаймы?

Фәрхетдиннең күзләре яшьләнеп китте.

— Бала исән, Гафур абый, атын Гыйззәтулла дип кушканнар. Шулай сөйләшенгән иде. Малай туса, әле дә күз алдымнан китми торган Гыйззәтулла исемен кушарсың дигән идем.

Фәрхетдиннең эшләре тәмам буталган иде шул. Ул Гафурга Хәдичәбикә ярдәме белән баланың Әлмәттәге Нурҗиһан атлы бер хатынга асрамага калдырылганлыгын әйтте. Ул хатынның баласы тугач та гүр иясе булган икән.

— Ярар, Фәрхетдин, үзеңне бетереп ут йотма, аларны кире кайтарып булмас инде. Ә балаң үсәр, үзеңә бер юаныч булыр, — диде Гафур, Фәрхетдин тынгач. — Мин Хөсәенгә җибәрәсе әйберләрне булганча әзерлим, син ял ит.

Гафур алгы бүлмәгә чыгып керде.

— Ичмасам, баламны үзем тәрбияләп үстерә алсам иде, — диде Фәрхетдин ачыргаланып. — Нинди тормыш инде бу, Гафур абый, я, әйт. Дөрес эшлисез сез, Гафур абый, Хөсәен абый белән. Үзем дә Нәдердә өй борынча йөрдем. «Әйләндереп салырга кирәк, егетләр, бу влачны!» дип кычкырып сөйләп йөрдем. Минем хәзер куркырлык бернием дә юк, миңа ат та, сыер да кирәкми. Хәтта ки гармун да кирәкми. Төкерәм мин хәзер барысына да.

— Шулай да сак булырга кирәк, — дип куйды Гафур.

— Юк, сак булмыйм, җитте, битләренә бәреп әйтәчәкмен, Гафур абый.

— Төрмәгә ябып куярлар үзеңне, шул булыр!..

— Япсыннар! Үлемнән дә курыкмыйм!

Фәрхетдиннең ярсуы артык көчле иде. Шуңа күрә Гафур бу турыдагы сүзне куертмаска кирәк дип уйлады.

— Фәрхетдин, теге бүлмәгә чыгыйк әле, — диде ул. Кунагын табын янына утыртып, туйганчы ашап-эчәргә кушкач, Хөсәенгә хат язар өчен үз бүлмәсенә кире керде.

Әгәр кеше бик кадерле якынын югалтса, әллә нинди дуамаллыклар эшләп ташлардай була, бернидән дә курыкмый башлый, берни белән дә исәпләшми. Моны Гафур үзе дә кичереп белә иде. Фәрхетдин дә шундый бер халәттә иде хәзер. Ләкин бу батырлыкның бер куркыныч ягы да бар. Ул саклыкны югалтуга китерә, сизгерлекне киметә, һәм, ахыр чиктә, төзәтелмәслек бәлаләргә дучар булуның сәбәбенә әйләнә. «Ничек моның турында уйламаган Хөсәен?» Хатында җибәрелергә тиешле язуларның нидән гыйбарәт икәнлеген дә төшендергән. Әлбәттә, алар Казан хәбәрләре генә түгел, беренче чиратта, төрле юллар белән Гафур бәйләнешкә кергән «Урал» агентларының яшерен яңа адреслары иде. Хөсәен узган ел беренче җай чыгу белән ышанычлы кеше аша шул адресларны җибәрерсең, дип әйткән иде. Хәзер исә Фәрхетдинне шул килеп чыккан җай дип өметләнгән, ахры.

Ләкин, Гафур уенча, Хөсәен барысын да дөрес исәпләп бетермәгән, Фәрхетдиннең саксызлык аркасында кулга эләгүе мөмкин, адресларның жандармерия кулына төшүе бар иде. Гафур үзе генә белгән шифрлы язуларны өстәлгә ачып салгач, уйга калды. Ниһаять, катгый бер карарга килде. Юк, ярамый, бөтен эшне җимереп ташлавың ихтимал. Башка берәр әмәле табылыр әле. Адресларны шул чак җибәрермен, ә хәзергә ул агентлар белән эшне минем аша гына йөртсен! Гафур Хөсәенгә шуларның барысын да аңлатып хат язарга кереште. Хат тәгәлләнгәч, ул аны аерым конвертка салды. «Урал» өчен кирәк булачак, ләкин югалса да куркынычсыз хәбәрләрне аерым кәгазьгә күчереп язарга кереште.

Фәрхетдин ул арада тамагын туйдырган иде инде. Ул, Гафур янына чыгып, бераз вакыт аның җиңел һәм күңелле итеп язуына сокланып утырды.

— Ятып ял ит, булмаса, — диде Гафур, — әле минем берәр сәгатьлек эшем бар.

— И, йокы керәме соң минем күзгә, Гафур абый. Булмаса, сез язу язган арада мин танышларыма барып килим.

— Ихтыярың, — диде Гафур.

Фәрхетдин кайтып кергәндә хәбәрләр сайланып күчерелгән, аерым конвертка салынган иде.

— Менә бусы Хөсәен абыеңа дигән хат. Менә монысы ул сораган язулар. Икесен ике урынга яшер, аңладыңмы?..

## 27

Тукай үзенең сиртмәле караватында, кәефләнеп, төрек шагыйре Габделхак Хәмиднең шигырьләрен укып ята иде. Ургылып искән җилгә чыдамагандай, каерылып ишек ачылып китте, бүлмәгә Хәйруллин килеп керде.

Тукай күз кырые белән аңа карап алды, ирексездән башын күтәрде. Аннары китабын читкә куйды да, караватында тезләрен кочып утырган килеш, тирбәлә-тирбәлә көйләп укырга кереште:

Оҗмах, тәмуг өкешер,
Өкешмәктә мәгънә бар;
Тәмуг әйтер: мән баймын...
Мәндә фиргавен һаман бар...

Адәм углы үлгүче,
Кем яхшыдыр, кем яман,—
Шунда мәгълүм булгучы.
Нә кылырсың мескен адәм,
Тотса Газраил якаң?
Ничек җавап бирерсең,
Тотса Газраил якаң?

Тукай сорау белән Миңлебайга текәлде. Гадәттә, кәеф әйбәт чакларда Габдулла балаларча шукланып «Бакырган» китабын җырлый башласа, Миңлебай да үзенең көр тавышы белән җырга кушыла иде. Хәзер исә, гаҗәпкә каршы, аска карап тын гына өстәл янында утыра бирде. Йөзе төксе, чырае качкан иде.

— Ни булды, менля Карый? — диде Габдулла.

Хәйруллин Тукай караватына килеп утырды.

— Барысы да җимерелде, — диде өметсезләнеп.

Габдулла китабын карават янындагы өстәлгә куйды.

— Я?

— Камил Мотыйгыйны әле генә частька алып киттеләр. Газетлары туктатылачак, матбага ябылачак. Спектакль әзерләнеп беткән иде бит. Ах, ах, менә күрәчәгең булса, билләһи!

Тукай караваттан аякларын салындырып Миңлебай белән янәшә утырды.

— Ни сәбәптән инде бу? Әллә, юкса, Камилнең без белмәгән яшерен эшләре дә фаш ителгәнме?

— Без белмәгән берни дә юк, минемчә. Син үзең дә хәл-әхвәлне күреп торасың бит. Шул газетадагы кайбер хөр фикерлелек өчен.

— Бу хәбәр сине спектакль тукталу сәбәпле тетрәткән. Әмма ул мине бөтенләй үтереп ташлый бит, малай!

— Ачтан үлмәбез үлүен. Минем корьән укып җыйган бераз акчам бар.

Тукай кыза төште:

— Акчасын китереп кыстыра! Эш акчадамыни!..

— Анысы шулай, — диде Хәйруллин, килешеп, — акчада түгел, журналларның чыгуында. Көрәш мәйданың булуда...

— Кайтыр идем туган-үскән якларга,— дип куйды Тукай, бер ноктага текәлеп. — И Казан, нурлы Казан! Туйдым, билләһи, мондагы бертөрлелектән. Син дә мин, Мөхәммәтдәмин...

Тукай Миңлебайча һич урынсызга шаркылдап көлеп җибәрде.

— Синнән дә туйдым, менля кем. Акчаң булса да туйдым. Уральскидан туйдым, Камил Мотыйгыйдан туйдым. Хәерче шәкертләрдән туйдым. Талчукчылардан, мотагассыйп муллалардан, хәлфәләрдән туйдым. Валлаһи, туйдым. Минем бик шәп, үземнән белемлерәк, үземнән акыллырак кешеләр белән аралашасым килә. Минем, җан фида дип, мәҗнүн кебек үлеп гашыйк буласым килә. Миңлебашка! Я скрывать не стану, безумно я люблю Татьяну! Ай-вай-вай, алла үзе ярдәм итсен.

— Син Уральскига рәхмәт әйт, өтек мәҗнүн, ул сине кеше иткән! — диде ачулана төшеп Хәйруллин.

— Анысы шулай. Рәхмәт сиңа, Уральск, үксез Апушны шагыйрь дәрәҗәсенә җиткердең!

Хәйруллин ачы елмаеп әйтте:

— Чын шагыйрь булырга сиңа күп кирәк әле, җаным.

— Әкрен-әкрен тауга табан үрләп барам, Пушкин илә Лермонтовтан үрнәк алам.

— Авызыңа шайтан төкергән синең! Әйдә якланып утырма. Сөйләшик әле телең ачылган чакны, бәлки берәр чарасына керербез. Бәлки Камилсез дә спектакльне очлап чыга алырбыз.

Тукай тел шартлатып куйды.

Хәйруллин аңа, телең ачылган чак, дип дөресен әйтә иде. Чөнки Тукай күпчелек вакытта тавышсыз-тынсыз, үз эченә бикләнеп яшәргә яратучан. Караватына менеп утырыр, тезләрен кочаклар һәм аңардан тешең-тырнагың белән тартсаң да, бер кәлимә сүз йолкып ала алмассың. Тукай бу минутларда үз дөньясына чумган, шигърият дөньясына.

Көннәрдән бер көнне алар, ике дус, тынчу мәдрәсәне ташлап, шушы Уральск татарлары ачкан «Казан» кунакханәсенә күчтеләр. Шунда алар бер-берсен ныклап белә башладылар. Тукай өнсез калган чакларда артык кырыс, андый вакытта аңа дәшмәү, аңа якын бармау яхшырак. Ирек бир, барысын да үзе генә кичерсен, борчыма. Аның иң гүзәл бәхетле минутлары бәлки шулдыр. Бу кагыйдәне Хәйруллин тиз үзләштерде. Карый зирәк, бик гадел, ләкин кайчак кирәгеннән артык кискен дустының үтә катлаулы эчке дөньясын аңлады. Аның сәер гадәтләренә күнекте. Ике дусның берсе бөек артист булырга, икенчесе бөек шагыйрь булырга хыяллана иде. Бөек шагыйрь булырга теләгәне инде шактый кыю адымнар белән үз максатына таба атлап китте, ә менә бөек артист булырга теләүчесенең әле бер генә публичный спектакльдә дә чыгыш ясаганы юк. Бу хәл, әлбәттә, Хәйруллин өчен фаҗига иде. Мәдрәсә чаршаулары эчендә яки аерым бүлмәләрдә генә тамаша күрсәтү — ул бит әле үзеңне чын эштә сынау түгел. Аның рус театрындагы кебек зур тамаша залларында Шекспирның, Шиллерның тетрәткеч трагедия каһарманнарын, Мольерның, Гогольнең комедия шәхесләрен уйнап, залны хәйран калдырасы килә!

Казан губернасының икесе ике почмагында дөньяга килеп, рәхимсез язмыш кушуы буенча, казакъ далаларында адашып калган бер шәһәрчектә яшьлек елларын уздыручы бу егетләр зур дәрт, хыяллар белән гомер сөрәләр иде әле. Ләкин бүгенге вакыйга исә бер дә хәерле фал түгел. Әгәр Камил Мотыйгый газеталары туктатылып, аның типографиясе ябылса, — димәк, Габдулла Тукаев эшсез калды дигән сүз, аңа иҗат мәйданы бетте дигән сүз. Икенчедән, шундый зур өметләр баглап беренче публичный спектакльгә әзерләнгән Хәйруллинның канатлары ук каерылмаса да, дәрте шактый сүнәчәк.

— Син берәр чарасын күрик дисең, — диде Тукай җитдиләнеп. — Синең белән миңа клубны бирмәячәкләр бит, әфәндем. Без бит синең белән бай, ышанычлы Камил Мотыйгый түгел. Аның бөтен җирдә дус-ише. Ул бит маллы, абруйлы гына түгел, ул бит, каһәр суккыры, чебен кебек әрсез, теләсә кай җиреңә үтеп керә белә. Юк, әфәндем, без бары аның белән генә, аның химаясендә генә Уральскида беренче татар спектаклен куя алабыз.

— Димәк, барысы да җимерелде? — диде Хәйруллин, куркынып.

— Барысы да җимерелде, — диде Тукай, Миңлебайны иңеннән кочаклап. — Төенчекләреңне әзерли башла, оек-чабата киеп илгә кайтып китәргә вакыт.

Хәйруллин утырган урыныннан кисәк кенә торды да өс киемнәрен сала башлады.

— Мине үзем тормыйча уятма! — дип боерды ул. Эчке күлмәктән һәм ыштаннан гына калып, юрган астына кереп ятты. Гадәте шундый аның. Моны Габдулла яхшы белә иде.

Тукай кулына яңадан китабын алды. Беренче туры килгән шигырьне укый башлады.

Хәйруллин озак кына вакыт ухылдап, борсаланып ятты, ниһаять, тигез сулыш алып йокыга китте. Хәзер шыксыз бүлмә эчендә тирән тынлык урнашкан, бары ара-тирә, Тукай яңа бит ачканда гына, кәгазь кыштырдавы ишетелә иде.

Шундый тынлыкта Габдулла байтак вакыт тирән шигърияте бакчасында гизде. Караңгылана башлагач, торып лампа кабызды, кәгазь-каләм алып өстәл янына утырды.

Ишек шакыдылар. Керүче Җәгъфәр иде.

— Бу нинди хәл бу, әфәнделәр? Мин сезне көтә-көтә көт булдым,— диде ул.

Җәгъфәрнең күзе Хәйруллинга төште.

— Авырып киттеме әллә?

— Безнең кораб һәлакәткә очрады, — диде Тукай. — Миңлебай хәсрәтеннән ауды.

Җәгъфәр чишенеп өстәл янына утыргач, Тукай вакыйганы сөйләп бирде.

— Мин дә һәлакәт алдында торам, — диде Җәгъфәр, Тукай тынгач. — Авылдашым кичә чакырып алып соңгы сүзен әйтте. Мин я чыгып китәргә тиеш, яисә итәгатьле рәвештә приказчиклар арасында филер вазифасын үтәргә...

Тукай зур күзләрен тутырып аңа карап торды.

— Җавап ниндирәк булды соң, Җәгъфәр әфәнде?

— Мин өзеп бер сүз дә әйтмәдем. Берничә көн уйланырга рөхсәт бирегез, дидем.

— Алай икән, — дип куйды Тукай. Аннан гадәтенчә бераз ирония белән (ул дулкынланса, шулай һөҗүмгә күчә иде) сорады:

— Ә уйларыгыз ниндирәк юнәлеш алырга исәп итә соң?

Җәгъфәр Тукайның каны кыза башлавын төшенде.

— Сез минем шундый дипломатичный җавап бирүемә аптырамагыз. Мин, әлбәттә, нәкъ сез теләгәнчә итеп авылдашның битенә төкереп чыгып китәргә дә батырчылык итәр идем. Ләкин биредә мәсьәлә катлаулырак. Минем кайберәүләр алдында үземне аклыйсым килә...

Тукай аңламады.

— Әйе, аклыйсым, — дип кабатлады Җәгъфәр. — Элекке дусларымнан кайберәүләр мине революция талашларыннан курыкты, хаинләр өеренә качты, дип исәплиләр. Ләкин мин моның гаксен исбат итмәкче булам.

Тукай бу юлы да аңламады булса кирәк.

— Ничек инде ул алай, әфәндем? — диде. — Минемчә, сез моны җөрьәт итеп кыю эш башкарсагыз гына исбатлый аласыз.

— Юк, алай түгел, — диде Җәгъфәр, — мин барысы турында да бик каты уйландым. Минем, Габдулла әфәнде, моны приказчиклар арасында эшләп исбат итәсем килә. Мин монда бу эшкә тиешле зәмин күрдем.

Тукай һаман әле ышанычсыз бер караш белән Җәгъфәрне күзәтә иде.

— Габдулла әфәнде, — диде Җәгъфәр, кинәт урыныннан кубып,— әйдәгез, зинһар өчен, йөреп керик, һава ифрат әйбәт, җылымса. Мин сезгә барысын да сөйләрмен. Сез минем хәлемне аңларсыз. Сез аңларга тиеш.

Тукай язарга утырган иде. Аның уйланган, үзен дәртләндергән шигырь оеткысы бар чак. Язылачак шигырьнең гомуми калыбы, кысалары да төсмерләнгән, хәтта берничә строфасы дә әзер иде. Ләкин ул Җәгъфәрнең сүзен тыңламый булдыра алмады, чөнки монда Тукай белергә тиешле әйбер — кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр фаҗигасе сизелә. Аннан, гомумән, аның сүзен тыңламау кешелексезлек булыр иде...

Алар киенеп урамга чыктылар. Һава, чыннан да, шактый җылы иде. Тукай матбагадан кайтканда әле буран котыра, кар себерә, ияк асларын, бит очларын суык чеметтерә иде. Хәзер исә хозур тынлык һәм җылымса яз сулышы сизелә.

Алар ялтырап яткан тап-такыр ат юлыннан урам буйлап ашыкмыйча гына алга киттеләр.

— Минем киңәшер, уртаклашыр бер кешем дә юк, Габдулла, — дип

сүзен башлады Җәгъфәр. — Мин сезне беренче күрүдә үк яраттым. Мин сезгә бөтен яшерен газапларымны ачып салмакчы булам. Чөнки ялгызлыктан туйдым. Зинһар өчен, әлләниләр уйламагыз, сабыр гына тыңлагыз.

Алар салмак адымнар белән баралар. Җәгъфәр, үз алдына сөйләгәндәй, Тукайга һич карамастан, тыныч кына тезеп китте.

Күренеп тора: ул үзенең моңарчы булган эш-гамәлләрен бик күп тапкырлар бизмәнгә салган, үзен бер генә тапкыр табаламаган, бер генә тапкыр үкенеп тә моннан соң алай итмәскә антлар эчмәгән иде.

— Сез сөйлисез, — диде Тукай, бер урында аны туктатып, — нәтиҗәдә минем алдымда Кар бабайдай эреп югала барасыз, ә менә Хөсәен әфәнде үсә, ныгый бара кебек. Аңа булган мәхәббәтем минем арткан-нан-арта бара кебек. Сөйләгез, минем өчен гыйбрәтле вакыйга бу.

Күрәсең, хәзер Җәгъфәр өчен Тукайның сөйләгәннәргә булган мөнәсәбәте әһәмиятсез иде. Ул Тукайның әйткәннәренә әз генә дә үпкәләмәде, сүзен дәвам иттерде. Алар чатка җиттеләр. Аркылы узган олы урамда фонарьлар кабынды. Кире борылдылар.

— Хөсәен Казаннан киткәннән соң мине вөҗдан газабы талый башлады, — диде Җәгъфәр. — Туктале, ни өчен соң мин шундый түбәнлекләргә төштем дип, мин еш-еш уйландым. Халкыма булган мәхәббәт, аның аһ-зарына чиксез көенү китермәдемени мине Хөсәеннәр катына! Ярый, баштагы эзләнүләремне, адашуларымны үземә кыйбла табарга тырышу, яшьлек чорым өчен зарури бер нәрсә дип кабул итим, кичерим ди. Ә менә хәзер бит инде барысы да күрелгән, барысы турында да мин үзем, Җәгъфәр Батырҗанов үзем күреп, бәя бирә алам. Халкын синең милли изелүгә дучар. Һәм аны бернинди Гаспринскийләр дә, Садри Максудилар да бу язмыштан коткара алмый. Чөнки аның язмышы әллә ничә йөз ел буена шундый катлаулы, хәйләкәр, мәкерле җепләр, богаулар белән чорналып беткән ки, халыкны коткарам дип, аны аяксыз-кулсыз, хәтта башсыз калдыруың да бик-бик ихтимал. Димәк, бердәнбер юл — башта халыкны иҗтимагый азатлыкка алып чыгу. Ә милли азатлык ул шул чакны, өстендәге күлмәктәй, тән белән бергә азатлык бакчасына барып керәчәк. Менә мин бу фәлсәфәмне, дөресрәге, карашымны, үзем эзләп таптым. Моңа мин үзем ирештем. Юк, мин бу турыда Хөсәеннән дә, башкалардан да ишетмәдем түгел. Хикмәт шунда икән: кешедән нинди генә акыллы сүзләр, хакыйкатьнең нәкъ үзен ишетмә, барыбер ул караш синең үзеңнекенә әверелми торып, әле бары тик җансыз курчак кебек кенә икән. Менә шуңа күрә, мин ирештем, дим дә инде. Әйе, ирештем һәм миңа Хөсәеннәр каршында ифрат дәрәҗәдә оят булып китте. Мин вөҗдан газабы кичерә башладым. Мин бу хәлне җиңеләйтү өчен яңадан элекке дуслар янына, алар сафына басарга теләдем. Ләкин алар миңа ышанмадылар, мине, җасус дип, бернинди революцион эшләргә якын җибәрмәделәр. Алар миңа шикләнеп, чирканып карады. Мин милләтчеләр, байгуралар арасына, әлбәттә, кире кайта алмадым. Бу инде минем өчен үлемнән дә катырак җәза булып тоелды. Шулай итеп, мин, Габдулла әфәнде, дәһшәтле урталыкта калдым. Фаҗигале көннәремне җиңеләйтү өчен аракы эчә башладым. Бай кәләшемнең үзәгенә үттем. Бер тапкыр асылынган җиремнән бауны кисеп коткарып калдылар. Ниһаять, түзмәдем, өйдән чыгып качтым. Көз иде инде, ләкин әле Иделдә пароходлар тукталмаган чак. Мин Устьега юнәлдем. Анда крючник булып эшләүче Кәче егетләре янына бардым. Тезләнеп үтендем, үзегезнең артилгә мине алыгыз, егетләр, дидем. Гади халык әйбәт бит ул, рәхимле, шәфкатьле. Мине үз араларына керттеләр, артык төпченмәделәр дә, сорашмадылар да. Крючник булып эшли башладым. Беренче көннәрдә үләмме дип уйлаган минутларым күп булды. Менә бу синең хаинлегең,

түбәнлегең өчен җәза, түз, кабахәт җан, дия идем үземә-үзем. Минем сәләтсезлегемнән, булдыксызлыгымнан көләләр иде егетләр. Ләкин әкрен-әкрен өйрәнә, рәткә керә башладым. Мускулларым ныгыды, тәнем тыгызланды, үземне бик бәхетле сизә башлаган чакларым да булгалады. Тик бер айдан Иделдә боз катты. Устьегә баржалар килмәс булды. Егетләр Кәчегә кайтып киттеләр, мин исә Алафузов заводына иң авыр, кара эшкә урнаштым. Минем эш хәзер яңадан эретелеп коелырга тиешле металлны кувалда белән яньчү, вату. Көнозын кулда авыр чүкеч, көнозын металл күгәрегеннән чыккан сап-сары тузан. Ләкин минем максатым бер: мин эшчеләр арасындагы революцион эшкә керешергә телим, Хөсәеннәр кебек ышаныч казанырга, үз кеше булып, максатына таба бара торган бәхетле кеше булып яшисем килә. Тик бу миңа насыйп булмады. Миннән тагы шикләнделәр, күрәсең, минем маңгаема сугылган мөһер барлык кешегә күренеп тора иде. Минем аерым дуамаллыкларымны, начальство белән бәхәсләшүләремне, эшчеләр арасында агитация алып барырга тырышуымны алар оста оештырылган бер хәйләй шаргыйя, маска дип кабул иттеләр. Ниһаять, мин түзмәдем, Казанны ташлап чыгып киттем...

Җәгъфәрнең шушы урында сүзе өзелде.

Алар, икесе дә тын калып, байтак вакыт этләр өргәнен, соңга калган юлчыларның атларын ашыктырып кычкырганнарын ара-тирә тыңлый-тыңлый, уйланып бардылар.

Җәгъфәр яңадан сүз башларга җыенып тамак кыргалап алды.

— Сез мин сөйләгәннәрнең ихлас күңелдән икәнлегенә ышанырга тиеш. Мин үземне аклау өчен бер генә кәлимә сүз дә өстәмәдем.

— Мин сезгә ышанам, Җәгъфәр әфәнде, — диде Тукай, ничектер йомшак итеп. — Ихластан булмаса, сез миңа җаныгызны корттай кимереп торган ачы хакыйкатьне сөйләмәс идегез. Аннан соң мин бит революционер да түгел. Бу сүзләрегезнең дөреслек икәнлегенә ышандым мин. Аңлыйм мин сезне, Җәгъфәр әфәнде, сезнең үзегезне аңлардай кеше табасыгыз килә. Ә мин сезне аңлыйм. Күрәсең, революция ул байлар белән ярлылар мөнәсәбәтенең кискенләшүе, кылычка-кылыч килүе генә түгел, ә ике якта да карашларның сират күпере аша кичүе. Мин сезне аңлыйм, ләкин гафу итүче ул мин түгел бит, Җәгъфәр әфәнде. Андый хокук миндә юк.

Чатка җиткәч, Җәгъфәр Тукайның кечкенә, матур кулын кысты.

— Рәхмәт сезгә, Габдулла әфәнде, тыңлавыгыз өчен генә булса да рәхмәт.

## 28

— Һай, Фәрхетдин, Фәрхетдин, — диде Хөсәен, шелтә белән башын чайкый төшеп. — Шулай итәләрмени!? Синең бит алай каш ясыйм дип күз чыгаруың бар.

— Җанымдай якын кешеләрем үлгәндә дә түздем, Хөсәен абый, әчмәдем, ә менә сиңа җибәрелгән сикритный кәгазьләрне урлаткач, түзмәдем.

Хөсәен телен шартлатып, «ай-яй-яй» дип куйды.

Аның кулында әле генә укыган Гафур хаты иде. Хөсәен аны укып чыккач та бермәл каефләнеп елмаеп торды. Каршысында гаепле кеше сыман башын түбән иеп утырган Фәрхетдингә хәйләкәр бер караш ташлады.

— Менә синең турыда нәрсә яза Гафур абыең. — Хөсәен хатка текәлеп, кирәкле юлларны эзләде. — «Фәрхетдиннең авыр хәсрәт кичерә торган чагы. Андый минутларда кеше әллә нинди дуамаллыклар эшләп ташлаучан була, саксызлана. Шуңа күрә, Хөсәен, мин бу юлы егетләр-

нең адресын җибәрмәскә булдым. Җае чыгар әле, җибәрермен. Ә Фәрхетдин аша сиңа гадәти корреспонденция генә юллыйм».

Фәрхетдин, йокысыннан уянгандай, кинәт башын күтәрде.

— Ничек инде ул гадәти кор... кор... — Фәрхетдин әлеге сүзне әйтә белмичә тукталып калды.

Хөсәен җиңелчә генә көлеп куйды да:

— Ул инде югалса да, полиция кулына эләксә дә, әллә ни куркыныч язулар түгел дигән сүз, — диде. — Ул инде язу югалттым дип җүләрләнеп йөрү һич ярамый торган эш дигән сүз.

— Аллага шөкер, — дип куйды Фәрхетдин җиңеләеп. — Рәхмәт төшкерләре, юкса менә, билләһи, кара кайгыга баткан идем, Хөсәен абый.

— Ә әчәргә ярамый! — диде Хөсәен, җитди тонга күчеп. — Нинди генә хәлгә калсаң да! Аңладыңмы? Безнең эшкә булышыйм дисәң, әчмисең!

— Аңладым, — диде Фәрхетдин тынычланып.

— Аңласаң, бар өеңә кайт, эшеңә кереш. Ә кичен Народный домга килми калма, анда әдәбият кичәсе.

Алар икесе дә аягүрә бастылар.

Фәрхетдин моннан ярты сәгать кенә элек идарәгә килгән иде. Кичә аны барагына илтеп салганнан соң ул үлгән кебек йоклаган һәм уянгач барын да хәтерләп, әле битен-күзен юмас борын ук, үзенең зур казалы булуын, ачык авызлылык аркасында әманәткә хыянәт итүен —Гафур биргән язуларны урлатуын әйтергә Хөсәен янына килгән иде. Күрәсең, һәр эшнең бер җае бар. Фәрхетдин Казанда чакны Гафур биргән язуларны ныграк саклансын өчен чалбар балагына эчке яктан чүпрәккә төреп тегеп куйган иде. Нәгаләт караклар, акча дип уйлаганнар булса кирәк, пәке белән уеп кына алганнар шуны. Анысы да әле бөтенләй Оренбурга якынлашкач...

Фәрхетдин саубуллашып чыгып китте. Җилкәсеннән тау төшкәндәй булды, җиңел, хәтта рәхәт тә иде аңа бу минутларда. Кунагын озаткач, Хөсәен, ирексездән егетнең Нәдер хәлләре турында сөйләгәннәрен хәтерләп утырды. Фәрхетдиннең ятим калган баласы турында уйлаганда кинәт күңеле җилкенеп куйды. Гыйззәтулланы үзебездә тәрбияләргә иде, дигән теләк тагы узды аның башыннан. Ләкин бу — реаль мөмкинлектән бик ерак торган татлы теләк кенә иде шул! Хөсәен көрсенеп яңадан эшкә кереште.

Сәгать ярым бирелеп мәкалә язганнан соң, ул торак бүлмәгә керде, киенә башлады.

Хәдичә яңа мөгаллиме Сәйфетдинев биргән дәресләрен әзерләп утыра иде. Хөсәеннең каядыр җыенганын күреп:

— Озаккамы? — дип сорады.

— Бүген Петербурга Дума депутатлары озатылачак. Вокзалга барам.

Хәдичә дәшмәде, яңадан китабына текәлде.

Хөсәен урамга чыккач, тизрәк барып җитү өчен, извозчикка утырды. Ул вокзалга җиткәндә халык перронга чыгып тулган иде инде. Монда кемнәр генә юк! Думага зур өметләр баглаучы беркатлы шәһәр мещаннары, вак һөнәрчеләр, вак сәүдәгәрләр, интеллигенция... Алар чын күңелдән ышанып Думадан ниндидер үзгәрешләр көтәләр. Хөсәен халык арасында эшчеләр төркемен тиз абайлады. Аның таныш-белешләре дә бар иде. Партия членнарыннан да берничә кешене күреп алды. Комитет белән газета арасында элемтәче хезмәтен башкаручы Леонтьев күренде. Ләкин аларга якын барырга ярамый иде. Хөсәен битараф бер кеше кебек читтән генә күзәтеп тора башлады.

— Әнә депутатлар!.. — диде кемдер. Вокзал ишеге ачылып китте.

Халык уртасында тар юл калдырып тезелешкән полицейскийлар бер-берсенең кулларыннан тотыштылар. Башта бай киенгән, мех якалы кыйммәтле туннардан, шәп эшләпәләрдән монархистлар, октябристлар күренде. Халык бермәл кызыксынып тынып калды. Ләкин беренче тәэсир түгәрәкләнү белән халык арасында кемдер ачы итеп сызгырып җибәрде. Кемдер: «Бетсен бюрократия!» — дип кычкырды.

— Җир крестьяннарга!..

— Сигез сәгатьлек эш көне!..

Бөтен перрон гүли, халык дәрьясы дулкынлана иде. Ул арада ишектән гадирәк киемле суллар күренделәр. Аларның күкрәкләрендәге кызыл бантлардан халык кем икәнлекләрен тиз аңлады, алкышлап гүли башлады.

— Безнекеләр, — диде кемдер.

Эшчеләр арасыннан берәү түзмәде:

— Яшәсен халык вәкилләре! — дип кычкырды.

Гүләү көчәйгәннән-көчәя барды. Сул депутатларның йөзләрендә елмаю чагыла иде.

— Үз сүзегездә нык торыгыз, иптәшләр, хезмәт халкы сезнең белән! — диде берсе әче тавыш белән.

Сул депутатлар бер генә минутка тукталдылар. Алар араларыннан берсен күтәреп алып ниндидер әрҗә өстенә менгерделәр. Өскә калыккан депутат:

— Иптәшләр! Без нинди максатлар белән Думага баруыбызны беләбез. Безгә ышана аласыз. Бергә оешыгыз. Бары нык оешкан пролетариат байрагын үз байрагыгыз итсәгез генә җиңүләргә ирешербез! Үрра! — дип кычкырды.

Бөтен вокзал тирәсен «ура» тавышлары күмеп китте. Хөсәеннең күңеле җилкенә иде. Аның хәтеренә Казан, 1905 елның утлы көзе килде. Авыр иде Хөсәенгә шундый шау-шулы тормыштан читтәрәк яшәү. Иртәгә икмәк пешерүчеләрнең шәһәр күләмендәге җыелышы була. Ул шунда барачак һәм сүз әйтми калмаячак. Әйдә, ни булса — шул!

Депутатлар вагоннарга урнаштылар. Чаң суктылар. Паровоз ачы итеп сызгыртты да, парларын бөрки-бөрки, авыр пошкырып кузгалып та китте. Ишек, тәрәзәләрдән депутатлар яулык селки, кул болгыйлар иде.

— Хәерле юл, уңыш телибез! — дип кычкырып калды кемдер. Хөсәен дә: «Уңышлы булсын сәфәр», дип уйланды. Беренче Думага суллар, хосусан, социал-демократлар бөтенләй катнашмады. Думага байкот игълан ителде. Хәзер исә илдәге хәл үзгәргән һәм ул башка тактика таләп итә иде. Һич югында, большевиклар Дума трибунасы аша реакцияне фаш итә алалар, большевистик пропаганда алып бара алалар иде. Хөсәен күңеленнән сул депутатларга шул эштә уңышлар теләде.

Халык тарала башлады. Хөсәен вокзал мәйданына чыкты.

Февраль үзенекен итә: карына, буранына юмарт кылана. Әле дә күк йөзен саргылт кара болыт пәрдәсе каплап алган иде, ишелеп кар яварга тотынды. Хөсәен извозчиклар туктала торган җиргә җиткәнче тәмам ап-ак булды. Инде извозчикка утырам дигәндә генә, кемдер аның иңбашына кулын салды. Нашир Тимерша Соловьев иде бу. Базык гәүдәле, нык каратутлы йөзле.

— Мине дә алып кайт,— диде ул.

Дөресен генә әйткәндә, Хөсәеннең нашир белән соңгы көннәрдә бик очрашасы килеп тормый иде. Башта дуслык, шәриклек хакына (бәлки шөһрәтенә дә кызыгыптыр) үзенең кайнагасы типографиясендә «Урал»ны бастырырга алынган бу нашир, соңгы вакытларда газетада басылган материалларның артык хәтәр булуын күреп, шүрли калган иде.

Хәер, ул чыгара торган «Чүкеч» журналында да шактый усал нәрсәләр булып куйгалый. Ләкин һаваларның үзгәрүен, реакциянең көннән-көн элекке позицияләренә кайта башлавын сизәрлек зиһен бар иде нашир-да. Шуңа күрә ул соңгы көннәрдә Хөсәенне, чама белеп эш итәргә кирәк, дип үгетли башлаган иде.

Хөсәеннең юраганы юш килде.

Тимерша кашовкага, аякларын тире каплагыч астына әйбәтләп тыгып, Хөсәен белән янәшә утыргач та, әле генә өзелгән әңгәмәне дәвам иттергәндәй, керешсез-нисез сүз башлады:

— Соңгы номерны тагы бер тапкыр җентекләп укып чыктым, Хөсәен Сез, Сәйфетдинев белән, минем башны, туган, ит бүкәне өстенә саласыз. Чама кирәк, сез бит турыдан-туры хәзерге властьны бәреп төшерергә өндисез. Моның өчен баштан сыйпамаслар.

— Алай ук түгел инде,— диде Хөсәен, сүзне уенга әйләндерергә тырышып.— Без бит синең белән бу турыда бер генә тапкыр сөйләш-мәдек.

— Сөйләштек, әмма һәркем үз позициясендә кала барды.

— Газетаның беренче санында ук без үз кредобызны ачык язып чыктык бит.

— Нәрсә анда, патшаны бәреп төшерергә, властьны эшче белән крестьяннарга бирергә өндәячәкбез дип язылган идемени? Юк, юк, туганкаем, сез рус газеталарының бары подпольеда, я чит мәмләкәттә чыга торганнарында гына язылырлык нәрсәләрне Россиянең үзендә ташка басып чыгара башладыгыз. Ә минә аяк-кулга богау салып Себер җибәрсәләр, нишләрсез?

— Нишләрбез? Китәрбез.

— Ә минә минем китәсем килми,— диде Тимерша, кыза башлап.

— Юкка син шул кадәр ут йотасың, Тимерша дус,— диде Хөсәен, наширны тынычландырырга тырышып.— Газетаның редакторы да, нашиpы да фиркасезләр. Газета үзе легаль. Дөрес, туры юл белән губернатор хәзрәтләре тарафыннан рөхсәт ителгән. Һәрбер санын цензор җентекләп укып бара, рөхсәтен бирә. Шулай булгач, нигә сиңа шул кадәр ут йотып яшәргә?!

— Цензор,— дип куйды Тимерша, үзалдына мыгырданып.— Юк, юк,— диде ул, кискен рәвештә баш чайкап,— сезнең газетага кушып чыгара торган брошюрагыз үзе ни тора! Әле, минемчә, тегеләр аңлап бетермиләр. Ләкин, җәмәгать, алар һаман шулай йоклап ятмаслар бит!

— Борчылма, алар йокламый. Идарәне берничә тапкыр тентеп чыкканнарын беләсең бит. Хәлбуки, без әле дә исән-аманбыз.

— Аннан мин төшенеп җитә алмыйм, Хөсәен дус: Уфа өчен, Казан өчен матбагада русча прокламацияләр басу кайчан тукталачак?

— Алар бит бушлай бастырылмый. Бәлки, син акча азрак түләнә дип борчыласыңдыр? Инде рәсми яктан килгәндә, син алар өчен җаваплы түгел.

— Акча! Акча кирәк булса, мин Мәкәрҗәгә барып миһманханә-ресторан ачам. Эш акчадамыни! Монда инде, агай-эне, баш кайгысы туды, акча табу кайгысы түгел.

— Без, минемчә, договорны бик ачык итеп төзедек, Тимерша дус. Безнең як төзеп бирә, сез бастырып бирәсез. Без эчтәлек өчен, юнәлеш өчен җаваплы. Ә сез газетаның басылуы, сыйфаты өчен. Шулай бул-гач нигә аңа ул кадәр борчылырга?!

— Син, Хөсәен, минемчә, юри күз буяу өчен беркатлыланасың. Син бит әгәр эш суд мәхкәмәсенә кадәр җитсә, мөхәррир дә, нашир да читтә калмаячагын бик яхшы беләсең!

— Мин алай дип уйламыйм. Сине тагы бер тапкыр тынычланды-

рырга җөрьәт итәм,— диде Хөсәен.— Әгәр инде килере җитәрлек түгел дисең икән, ул вакытта уйлашырбыз.

Хөсәен Тимершаның, байлык сөйсә дә, бу үзенчәлеген бик нык яшерергә тырышканлыгын, либерал һәм демократ булып уйнарга яратканлыгын әйбәт белә иде. Хәлбуки, эш акча мәсьәләсендә, чыннан да, шәптән түгел иде. Хөсәен хәтта наширның килере аз дип әйтүеннән аерата нык курка иде. Хөсәеннең әйткән сүзләре нәкъ төзәгән җиргә барып тиде. Тимерша бөтенләй тузына башлады.

— Син мине, Хөсәен, җитди сүзгә меркантельный ваклыклар кертеп, бик-бик хәкарәтлисең. Яратмыйм мин синең ул гадәтеңне.

— Гафу ит, туган, әгәр абайсызлык күрсәткән булсам, кичер.

— Менә сиңа соңгы сүз шул, Хөсәен, әгәр минем наширлыкта калуымны теләсәң, газетага материалларыңны әзерләгәндә бик җитди уйлан.

Кинәт ул кучерның янтыгына төртеп алды:

— Туктат!

Хөсәен аңгарып та өлгермәде, Тимерша саубуллашуны, күрәсең, кирәксенмичә, чанадан төшеп калды. Наширның кыйланышы көлке иде. Ләкин шул ук вакытны бу эшнең ахыры бик күңелсез бетүе дә мөмкин бит. Тимершаның, җитди эшкә җиңел генә алынган кебек, өянәге килсә, шундый ук җиңеллек белән ул эшне ташлавы да ихтимал иде.

Хөсәен, уйларына батып, чак кына квартирын узып китмәде.

Хәдичә өйдә ялгызы гына иде.

Хөсәен үзе белән өйгә дымсу салкын һава алып керде. Ул өс киемнәрен тиз генә салды да хатыны янына узды. Каефен сорашты. Хәдичә хәзер аякка баскан, хәлсезрәк булса да, өй эшләрен эшли ала, дәресен укый инде.

Авырудан терелә башлаган көннәрдә ул артык көйсез иде. Хәзер тынычлана төште.

— Бүгенгә эшләрең беттеме инде? Бөтенләйгәме? — дип сорады ул. Хөсәен әйтер сүзен әйтә алмыйча икеләнеп торды.

— Бүген Народный домда, Хәдичәкәй, әдәбият кичәсе. Репертуарны Шакир әфәнде белән без төзегән идек. Бәлки...

Ул: «Бәлки син дә бара алырсың»? — димәкче иде, ләкин шунда ук, бу бит аның өзлегеп китүенә сәбәп булуы бар, дип кире чигенде. Хәдичә Хөсәенгә шелтә белән тулы рәнҗүле матур күзләрен текәп торды.

— Хәер, сиңа өйдән чыгарга иртә әле,— диде Хөсәен.

— Син ачмы? — дип сорады Хәдичә.

— Ач.

Хәдичә урыныннан тора башлады.

— Юк, юк, үзем, эшендә бул. Нишләсен миңа әйт кенә.

Кухня якта аш ашаганда Хөсәен Хәдичәгә наширның бүгенге ультиматумы турында әйтергәме, юкмы, дип уйланып утырды. Әйтмәскә булды. Болай да һәр кагуны-сугуны артык авыр кичерә башлады, тыныч кына савыксын.

Хөсәен җылынган итле, токмачлы шулпа ашап өлгермәде, кухня ишегендә Хәдичә күренде. Искерә төшкән ак күлмәктән, чәчләре тиешенчә таралмаган, йөзе сулып, агарып киткән. Кулында «Урал» газетасы. Ул, Хөсәен каршысына утырып, газетаны өстәлгә куйды.

— Минем сиңа бер соравым бар. Син шәкертләргә хитабән мәкаләңдә фәннәрне нинди телдә укыту турында язасың һәм милләтчеләрнең татар телендә укытырга кирәк дигәнен дөньяга чыкмаслык бер хыял дип хурлыйсың.

— Ә шулай түгелмени, Хәдичәкәй? Бездә дөньяви фәннәрне укытырлык мөгаллимнәр бармы соң? Бездә урта һәм югары белем алу өчен дәреслекләр үз телебездә чыгамы соң?

— Шулай булган хәлдә дә мин синең белән килешмим, Хөсәен.
Хөсәен ашавыннан туктады:
— Сәбәп?
— Сәбәбе мәгълүм. Синең юлдан бару ул телне югалту дигән сүз.
— Ә синең юлдан бару гомумән халыкны югалту дигән сүз. Син Россиядән аерылып чыгуны алга сөрмисеңдер ич?
— Мин халкымның милли изелүдән азат булуын телим. Мин аның теле дә, мәдәнияте дә алдынгы халыклар дәрәҗәсенә җитсен дим. Мин халкымның, Хөсәенкәем, инсаниятькә үзе булдыра алган барлык матди, рухи байлыкларыннан лаеклы өлеш кертүен телим.
— Менә мин дә нәкъ шуны телим, Хәдичәкәй. Ләкин теләк бер, ә аңа ирешү юлларын сайлау икенче. Синең юл ул милләтне физический бетерүгә илтәчәк, ә минем юл — яшәүгә, тәрәккыяткә. Әгәр мин барлык көчемне куеп тырышам икән, иң әүвәл мин үз халкым өчен тырышам бит!
— Ләкин ул юлың синең татарны телсез, илсез һәм исемсез калдырачак. Мин синең карашларың белән бу мәсьәләдә килешә алмыйм.
— Юк, алай түгел,— диде Хөсәен гасабиланып.
Ул ашавын онытты. Хәдичәгә үз карашының дөреслеген исбатларга кереште. Хәзер ул шактый йончыган, арыган иде, артык ярсып китүен үзе дә тойды. Бераз вакыт авыр сулап читкә карап торды. Тагы сүзгә кереште. Бу юлы шактый тыныч акты аның сүзләре.

## 29

Хөсәен төн уртасында тирләп, ютәлгә буылып уянып китте.
— Тәмәкене күп тартасың,— диде Хәдичә.
— Юк, аннан түгел ул.
Хөсәен үпкәләренең авыртуын күптән сизеп йөри иде. Инде Оренбурга килгәч башланган катлаулы тормыш, төннәр буе туктаусыз эшләп утырулар үпкә авыруын аерата көчәйтте.
Узган елда да язга таба хәле начарлана башлавын тойган иде ул. Быел исә чир үзен аерата кискен рәвештә сиздерде. «Туберкулез булмагае тагы», дип уйлады Хөсәен. Ул үзенең авыруыннан да бигрәк, бу яман чирне хатынына йоктырудан курка иде.
Хөсәен, аякларын караваттан салындырып утырган килеш, бераз вакыт ютәлнең тагы кабатлануын көтте. Исәбе әгәр тагы ютәл буа башласа, тәмәке тартырга кухня якка чыгу иде, ютәл артык борчымады, Хөсәен, яңадан караватына ятып, юрганын ябынды.
Ләкин йокы инде әллә кая качкан иде. Кичә йокларга ятар алдыннан сүз Хөсәеннең ирдән аерылырга тиешле сеңелесе Хәдичәбикә турында булды. Ниләр кичерә икән ул? Ни өчен бер дә хаты юк? Әллә булмаса берәр фаҗигагә юлыктымы? Ни Уфадан, ни Әлмәттән бернинди хәбәр юк. Оныттылармы, әллә үзләренчә саклык күрсәтүләреме? Хөсәен әле сеңелесенең язмышы турында юрап ятты. Бер дә булмаса, аны бирегә алдырырга кирәк, дигән фикергә килде. Шунда бу мәсьәләгә нокта куеп, тынычлана төште. Аны соңгы вакытларда борчыган мәсьәлә хатыны белән араның ераклаша баруы иде. Белмәссең, калырсың бер көн Галимҗан көненә! Үзе большевик, хатыны меньшевичка. Мөмкинме соң мондый хәл? Ха, юрган астындагы оппозиция көрәше.
Хөсәен, түшәмгә текәлгән килеш, мыегын сыпырып елмаеп куйды. Бер карасаң көлке, ә бер карасаң иң авыр хәл түгелмени бу? Эшлисе эш үтә авыр, моңа бердәмлек, ышану һәм җан тынычлыгы кирәк. Җан тынычлыгын иң беренчеләй гаилә тормышы бирмимени ир кешегә?!
Ул кинәт Тимерша Соловьевның кичәге сүзләрен хәтерләде дә алданрак аяк киенергә кирәк, алай-болай була калса, зилзилә купканчы ук хәстәренә керешми булмый, дип уйланды. Хөсәен иртәгә ук

Шакир Мөхәммәдов белән бу турыда киңәш-табыш итәчәк. Шуннан соң катгый карар кабул кылыныр.

Ул инде менә-менә йоклап китәм дигәндә тагы ютәлли башлады. Кара син аны мәгънәсез ютәлне?! Каян килеп чыкты әле монысы? Хөсәен кухня якка чыкты да самавардан агызып кайнаган су эчте. Тәмәке көйрәтеп җибәрде. Кинәт үзенең хәлсезләнеп китүен тойды. Маңгайга, күкрәккә салкын тир бәреп чыккан иде. Ул ирексездән өчен-че ел үзләрендә авырып яткан Заводскийны хәтерләде. Ул да көрәш-нең кайнар көннәрендә үпкә чире белән азап чигеп ятты. Аның — ялкынлы, фидакарь революционерның — шул көннәрдә ачыргаланып чирен каргаганы Хөсәеннең әле дә исендә. Хәер, юләрләнмә әле, Хөсәен, синең хәлең андый түгел бит! Әлбәттә, бу бер очраклы хәл генә. Суык тигән, шул, узар!

Чыннан да, икенче көнне ул үзен ярыйсы хис итте. Иртәрәк торып, язасы мәкаләсен бетерде, вакытында идарәгә чыгып көндәлек эшләрен башкарды, матбагага барып, наборщиклар белән сөйләште, башка бик күп йомышларын үтәде һәм Шакир Мөхәммәдовларга юнәлде.

Шакир бик җитди кыяфәттә, күзлеген борын очына төшереп кигән килеш, корректура төзәтеп утыра иде. Ул, Хөсәеннең үзләренә килүенә ихлас күңелдән шатлык белгертеп, урыныннан торды, эшеннән аеры-лып, Хөсәенне аулак, тыныч бүлмәгә алып кереп китте.

— Чәй эчәбезме, Хөсәен?

— Бер стакан гына.

Алар, үзара көлешеп, чәйне бер сылтау итеп, кара-каршы утырды-лар да җитди сүз башладылар. Башта хуҗа сөйләде. Ул Хөсәенгә үзе ишеткән Дума утырышлары турындагы яңалыкларны, аннан Уфа, Казан, Әстерхан, соңыннан килеп Оренбур хәбәрләрен җиткерде. Әле матбугатка чыкмаган, өр-яңа нәрсәләр сөйләп чыкты. Хөсәеннән ул берни дә яшерми, үз карашларын ачыктан-ачык ярып сала иде. Ниһа-ять, ул сүзен бетерде дип, Хөсәен үзенең үтенечен әйтергә җыенганда гына ничектер серлерәк итеп яңадан сүзгә керешге:

— Әле синең килеп чыгуың бик әйбәт булды, Хөсәен туган. Юкса, үзем барырга тора идем.

Хөсәен сагая төште.

— Хуш, әллә берәр үтенечегез бар идеме, Шакир абый?

— Үтенеч түгел ул. Синең чалмалы «дустың» газетага каршы тәре походы оештырырга җыена.

— Ул күптән җыена инде,— диде Хөсәен көлемсерәп.

— Үткән җомгадагы вәгазен «Урал»га багышлаган. Синең газетаңа каршы мәхәллә халкын котырткан. Ә мәхәллә халкы арасында төрлесе бар. Көтеп тор: синең өстән жандарм идарәсенә шикаятьләр ява баш-лаячак.

— Минем ул Вәли муллага каршы көрәштә бер, ләкин берәгәйле юлым бар, Шакир абый. Газетаны тагы да үткенрәк телле һәм усалрак телле итү юлы. Ә пропагандага хәзер ул мохтаҗ түгел, тиражлар көннән-көн арта. Ул инде хәзер үзен-үзе пропагандалый башлады.

— Донос начар әйбер ул, Хөсәен. Ул маэмурларга нигез булып хезмәт итә ала.

— Рәхмәт кисәтүең өчен,— диде Хөсәен,— рәхмәт, Шакир абый. Без һәр вакыт уртак тел һәм фикер табып яшәдек моңарчы. Моннан соң да шулай булсын. Мин, әлбәттә, сез әйткәннәрне исәпкә алырмын.— Ул алгарак иелде.— Минем сезнең янга килүем киңәш-табыш итү өчен иде. Тимерша әфәнде шүрли башлады, ахры, наширлектән баш тартырга чамалый.

— Алай икән. Бу күңелсез фал.

— Нишләргә киңәш итәсез?

— Тимершаны беләм мин, ул гомумән тотрыклы адәм түгел. Ул

бүген болай уйлаган кебек, иртәгә бөтенләй башкача уйлавы да бар. Ашыкмыйк. Әйбәтләп сөйләштеңме соң?

— Ул стадиядән узган инде хәл. Минем Себер китәсем килми, ди. Шакир кеткелдәп көлеп куйды.

— Себер китәсем килми диме?

— Китәсем килми, ди, әгәр газета үз тонын үзгәртми икән, мин наширлектән баш тартам, ди.

— Ә договор?

— Договор гына тота алмас дип уйлыйм. Мондый ут астында яшәгән газетаны суд органнары якламас, дип уйлыйм. Вакыйгага политик төс биреп, процессны шул юнәлештә җибәрүләре мөмкин.

— Хәзергә без ашыкмыйк, ләкин шулай да бер кеше белән сөйләшеп куйыйк. Ул бик кулай булыр дип уйлыйм.— Шакир эре ак тешләрен күрсәтеп елмаеп куйды.— Потомственный дворянин!..

— Аһа! Кем соң ул?

— Менә таныштырырмын, белерсең. Ул бу эшкә алыначак.

Хөсәен дә мыек астыннан гына көлемсерәп куйды.

— Мин башта сөйләшеп кылларын тартып карармын аның,— диде Шакир,— аннан уйлашырбыз. Уйлашырбыз дим, чөнки бу Тимерша, ни әйтсәң дә, бик җайлы кеше синең өчен.

— Җайлылыгын күрсәтте инде.

— Юк, алай димә, Хөсәен. Беренчедән, бик абруйлы, мәгълүм мөхәррир Фатих Кәрими әфәнденең кияве, матбага аның үз кулында дип әйтерлек, аннан, үзең белгәнчә, елдам, житез, тапкыр. Әлхасил [1], без Тимершаны наширлектә калдыру өчен барлык көчебезне куярга тиеш. Беренче атакадан соң ук кулларны күтәреп бирелмик.

Әлбәттә, «Карчыга» мөхәррире хаклы иде.

Иртәгесен ул әйткән кешесе белән сөйләшкәнлеген, газета наширсез калса, бу эшне үз кулына алырга риза булганлыгын әйтте. Ләкин аның бер генә шарты бар икән: ул да булса тәкъдимне Тимерша Соловьев ясасын. Димәк, аның белән ныклап, барлык вак-төякләренә кадәр ачыклап сөйләшергә кирәк. Кем белә, мәсьәләне кабыргасы белән куйсаң, наширлекне ташларга телисез икән, әйдәгез, сөйләшик, алайса, дисәң, бәлки әйткән сүзләрен кире алыр. Чөнки гади хезмәт халкы арасында «Урал» аркасында ул кешенең абруе үсмәдемени?! Шул газета өчен эшчеләр, приказчиклар, шәкертләр аны үз итеп, якын күреп тормыйлармыни?!

Хөсәен катгый карарга килеп, аяк астыннан чыккан бу бәлагә каршы ташланырга торганда, аның уйларын чуалдырып, ике хат килеп төште. Хатның беренчесе күптән көтелгән хат, Әлмәттән, Хәдичәбикәдән иде. Ул Уфага апасы, әнисе янына китәр алдыннан язган. Тәгаен, бу хат монда килеп төшкәндә, ул Уфага барып җиткәндер дә инде. Хөсәен хаттагы юлларны укып уйга калды. Кеше үзенең яшьлек дуамаллыгы аркасында күңеленә гомерлек авыр яра алды. Кинәт Хөсәен сеңелесенең «әгәр мине бәхетле итәргә теләсәң, менә бу акчаны аласың» дигән сүзләрен хәтерләде. Хәтерләде һәм ачык итеп ишетте.

Бу минутта Хәдичәбикәнең күзләрендә дәһшәт билгеләре чагылган иде. Күрәсең, абый акчаны алмас, мин ясаган корбаннар бушка китәр, дип уйлагандыр. Акчаны алгач, аның йөзе яктырып, күзләре нурланып китте. Әйе, ул әле дә аңа матди ярдәм күрсәтә алыр иде. Әле дә, әгәр үзенең кеше икәнлеген, гади кеше бәхетенә мохтаҗ һәм ул бәхеткә лаеклы икәнлеген кинәт тоймаса! Күрәсең, аңарда бу тойгы уянганлыкны бай да сизенгәндер һәм Хөсәеннең исемен сылтау иткәндер. Нинди катлаулы бер хәл! Юк, кеше беркайчан да мәхәббәт кебек олы, саф бәхетне сату бәрабәренә нииндидер эш, хәтта файдалы эш башка-

---

[1] Кыскасы.

рырга хаклы түгел! Ул инде шул олы бәхетне инкарь итүе белән үзе дә ваклана, зур эшләр башкару сәләтен югалта.

Хөсәенне уйлары ерак-еракларга алып китте. Ул Уфаны, шунда яшәүче туганнарын күз алдына китерергә тырышты. Ничегрәк каршы алырлар бит әле ирдән кайткан хатынны?! Артык кашык булмасмы? Хәер, аның сеңелесе адәм арасында ким-хур була торганнардан түгел. Юаш юашын, ләкин ялкау түгел. Әйбәтләп киңәшләр биреп җылы бер хат язарга кирәк.

Хөсәенне уйланырга мәҗбүр иткән икенче хат Уральск шәһәреннән, Җәгъфәрдән иде. Конвертны кулына алу белән язудан Җәгъфәр кулын танып, Хөсәен, ниндидер җирәнгеч бер нәрсәгә ялгыш орынгандай, чирканып йөзен чытты. Ачаргамы, юкмы, дигәндәй, бермәл икеләнеп торды.

Җәгъфәр хатында Уральск кибетләрендә эшләүче татар приказчикларының хәле, андагы революция хәрәкәте турында, деспотизм һәм эксплуатациягә каршы каты көрәш башланганлыгын, байларның, аларга тәлинкә тотучы кешеләрнең исем-фамилияләрен атап, ачык итеп язган. Ул редакторга атап җибәргән кыска гына хатында моннан соң «Урал» өчен кулдан килгәннең барын да эшләргә сүз бирә. Хәбәрнең азагына исемен куймауны, я куелса да, ялган исем куелуын үтенгән. Башка ләм-мим сүз юк. Үкенү дә, гафу үтенү дә юк.

Нәрсә бу? Шундый начарлыклар эшләгән кешене яңадан үз арбаңа утыртырга ярармы? Хәзергә акылына килгән кешенең иртәгә үк яңадан, беренче авырлыклардан өркеп, тәртәне сындырмавына ышанырга мөмкинме? Аннан, каян килеп әле ул Уральскига барып чыккан, приказчиклар арасына ничек барып эләккән. Нәрсә бу?

## 30

Фәрхетдиннең бер кайгыдан котылуы икенче кайгысын көчәйтеп җибәрде. Гафур язуларының ул кадәр куркыныч нәрсә түгеллеген белеп тынычлана төшүе булды,— үзенең барлык дәһшәте белән аның алдына якын кешеләрен югалту кайгысы килеп басты. Фәрхетдин хәзер төн урталарында уянып, хатыны, әтисе, ятим калган сабые өчен сыкрана, күрше тапчаннарда йоклаучы иптәшләрен уятмаска тырышып, мендәренә капланган килеш шыпырт кына елый, көндезләрен дә, кайчак хәтта эш вакытында да каядыр текәлеп уйга бата иде. Ул кинәт өшәнеп калды. Моңарчы шактый тазарып, кызган металлга зәһәр генә кундыра башлаган бу чүкеч сугучының чүкече хәзер сандалда йомшаграк дөпелди иде. Егорыч барын да күреп, күзәтеп торды. Хәзер тимерченең эше сүлпәнәя төште, мәгәр Фәрхетдингә авыр сүз әйтмәде, каты кагылмады, түзде оста.

Фәрхетдин телдән дә калды. Элегрәк тәмәке тарткан арада түгәрәкнең уртасында үзенең рус телен бозып әкәмәт сөйләшүе белән иптәшләрен көлдереп бетерә торган Фәрхетдин хәзер караңгырак почмакта дәшми-тынмый гына авыр хәсрәте белән ялгыз калырга ярата. Ләкин аның тышкы тынлыгы әз генә дә эчке ярсуларына тәңгәл түгел. Ул ниндидер шашкын бер эш эшли башласа гына үзенең тынычлыгын табар иде кебек.

Көннәрдән бер көнне алар тимерчелектә Егорыч белән икәү генә калдылар. Фәрхетдин шул чак:

— Син әйбәт кеше, Егорыч, — диде, — мине кызганасың, әгәр башка оста белән эшләсәм, ул мине әллә кайчан артыма тибеп куып чыгарган булыр иде инде.

— Синең ниндидер үтенечең бар, ахры? — диде Егорыч.

— Әйе, Егорыч, бик зур үтенечем бар, син миңа нинди дә булса берәр хәтәр йомыш куш.

— Бар, алайса, бер шкалик аракы алып кайт.

— Юк, Егорыч, син шаяртма. Син миңа үзең башкара торган яшерен йомышларыңның берәрсен тапшыр. Мин бит синең тыелган газеталар укуыңны, эшчеләр арасында тыелган кәгазьләр таратуыңны сизенәм. Димәк, син үзең дә яшерен оешмада торасың. Менә шул. Курыкма, мин сине сатмам. Андый кеше түгел мин.

Егорыч тыныч кына көлемсерәде.

— Юкны сөйлисең син, Фәрхетдин, нишләп тыелган газеталар укыйм ди мин. Саташма. Син дә бит газетаны бик күп укый идең.

Фәрхетдин күңелсезләнеп:

— Алайса, сүзем бетте, — дип куйды. Ул: «Хөсәен абыйның йомышын тиешенчә үти алмадым. Кадерле кешенең ышанычын югалттым. Инде хәзер Егорыч та мине санга сукмый, миңа ышанмый. Барысы да җимерелде», дип уйланды.

Егорыч аның янына килде, корымлы маңгаен җыерып торды, ниһаять:

— Мин сиңа йомыш куша алмыйм, — диде, — анысы минем эшем түгел, тик мин синең урында булсам, әлеге якташың чыгара торган газетаны иптәшләремә укыр идем. Бар ич бездә алар, татарлар...

— Кайда?

— Табарсың инде урын. Һич югында — баракта.

Фәрхетдин йөзен чытты.

— Андый гына эш ул...

«Ул эшмени» дип төгәлләмәкче иде, тик Егорыч шунда ук аны бүлдерде:

— Эш ул, Фәрхетдин, эш! Эшнең дә әле беренче сортлысы. Син әллә сәнәк күтәреп атлы казакларга ташланырга җыенасыңмы? Ул көннәрнең үткәнен үзең дә беләсең ич. Укырга кирәк, газетада язганнарны аңлатырга кирәк.

Тимерчелек цехына көндезге аш вакытында таралышкан эшчеләр кайта башлады.

— Яле, Фархутдинушка, өрдер әле бераз күрекләрне, эшкә керешергә вакыт, — диде Егорыч.

Фәрхетдин учакка таба атлады. Аның колагында останың «эш ул, эш!» дигән сүзләре яңгырагандай булды. Шул турыда ул эш арасында да, өйгә кайткач та уйланды. Юк, шулай да Фәрхетдин теләгән эш түгел иде бу. Фәрхетдин тимерчелектә чүкеч сугып тору кебек авыр, ләкин хәтәр, хәвефле эш тели иде. Утлар чәчрәсен тирә-юньгә, ул Фәрхетдинне бәхетсез итүче йөзе кара дошманнарда дәһшәт уятсын, котларын алсын!

Ләкин Фәрхетдин берни дә уйлап чыгара алмады, ә тиктомалга, бары шашкын хисләрне басу өчен генә, ниндидер җәнҗал, сугыш кузгатырга теләми иде. Шулай ук ул эчеп исерергә дә теләмәде. Юк, юк, андый ахмаклыклар белән генә йөрәк ярсуын баса торган кеше түгел Фәрхетдин.

Шул көнне эштән баракка кайтышлый ул Чынбулатны очратып үзенә дәште.

— Күптән сөйләшеп утырган юк, кил, — диде. — Хөсәен абый гәзитен укыганга да байтак вакыт узды. Менә мин югында чыкканнарын алып кил. Сөйләшербез дә, укырбыз да.

Баракта татар, башкорт бер яккарак урнашкан иде. Бу унбишләп кешенең барысы да диярлек Фәрхетдин ишләре — авыл егетләре. Моңарчы тимер юл мастерскойларының төрле урынында һәм төрле сменаларда эшләгәнгә күрә, алар бергә сирәк очрашалар һәм һаман үзара әшнәләшеп китә алмыйлар иде. Әле дә Чынбулат килеп кергәндә Фәрхетдин үзенең такта тапчанында утырып баракта берүзе күлмәк ямый иде.

— Утыр,— диде ул Чынбулатка, ятак каршындагы артсыз утыргычка ымлап.
Чынбулат газеталарын Фәрхетдиннең сандыгы өстенә ташлады да урындыкка тез чәнчеп менеп утырды.
— Я, эшләр кай тирәлә, яның тынычланмыймы бераз? — диде ул, ниһаять.
— Башны ташка орып буламыни, дөньясын җиде бабасы белән салып еккыры!
Чынбулат, юкка моның яраларын кузгаттым дигәндәй, ни әйтергә белмичә өнсез калды. Фәрхетдин гасабиланып җепне тешләре белән шырт иттереп өздә дә шактый кыю рәвештә:
— Карыйк әле гәзитне, укып җибәрик әле бер кычкырып, — диде. Чынбулат тын гына утыруында булды.
Әйе, ул да укырга тырышып карады. Шуның өчен саклап тотты да ул аларны. Ләкин барып чыкмады, хәрефләрне җыеп сүз оештыру җиңел эш түгел иде шул.
Фәрхетдин бик җитди кыяфәт белән газеталар актара башлады.
— Башлыйк әле менә моннан, мать якасына, Садыйк абый әйтмешли.
— Кем анысы?
— Улмы? Ул — шәп кеше! Мин генә ул чакны тинтәк, бер хайван булганмын, хәтерен калдырдым аның. Хәзер ул әллә кайда, сөргендә, җәһәннәмдә.
Фәрхетдин газетаны иләп яктыга тотты.
— Без бит синең белән эшчеләр, — диде, — шуңа күрә «Эшчеләргә ни кирәк» дигәннән башлыйк.
Казарма эченә бер төркем эшче килеп керде. Аларның шау-шуын басар өчен, Фәрхетдин төртелә-төртелә булса да, бик каты кычкырып укый башлады. Башта аларга беркем дә игътибар итмәде, Фәрхетдиннең әледән-әле китап-газета тотып укып утыруы гадәти хәл иде. Ләкин бу юлы тамак киереп каршындагы башкорт егетенә кычкыра-кычкыра газета укуы кайберәүләрне кызыксындырды.
Болар янына тәбәнәк буйлы, шадра бер кеше килде.
— Син, нәрсә, шул кадәр акырасың, теплашка! Каля-маля!..
Фәрхетдин шадра кешегә ачулы караш ташлады. Аңа инде бу карсактан сакланырга кирәклеген, тәгаен аның ялланган бер әләкче икәнлеген әйткәннәр иде. Ачуы эченә сыймады Фәрхетдиннең, ул көчкә тыелып:
— Мин бик кызык нәрсә укыйм, аны әкрен укырга ярамый, — диде.
— Нәрсә язган соң анда?
— Анда синең кебек сатлык җаннарны бәреп үтерергә кирәк дигән.
Карсак зәһәрләнеп йодрыкларын төйнәде:
— Син саграк кыйлан, гололобый, юкса, мин сине!..
— Монда ул гына язылмаган әле, — диде Фәрхетдин. — Монда патшаны төшерегез, байларны юк итегез, җирне керәстиянгә, заводны эшчегә бирегез дигән. Ярыймы шундый газета укырга? Шадра, татар теленд‍ә андый язуның булуы мөмкин түгел, бу юрамалый аны ирештерәдер, дип уйлады булса кирәк.
— Кала-маля, шайтан теле, — дип сүгенеп китеп барды.
— Билләһи, тагы бер сүз әйтсә, торып муен тамырына укмаштыра идем, — диде Фәрхетдин.
— Диваналанма, — диде Чынбулат. — Әйдә, укый бир.
Фәрхетдин тагы да кычкырыбрак укырга кереште. Кешеләр берәмберәм «татар почмагына» җыела башлады. Араларында әле генә эштән кайтып кергән ике татар эшчесе дә бар иде. Аларның берсе — иләмсез таза, каратутлы, тупасрак йөзле егет. Ул, бераз тыңлап торганнан соң, якынрак килергә батырчылык итте. Әле генә өйалдыннан

юынып кергән, күрәсең. Муенына киндер сөлге аскан килеш тукталып торды.

— Әт-тә-тә,— дип куйды егет бераз тыңлагач, кысык күзләрен җемелдәтеп.— Шулай дип язганмы?

— Шулай дип язмаса, мин үземнән чыгарып укыйм штоли аны?! — диде Фәрхетдин, укуыннан аерылып.

— Давай, укы укы, — диде эшче.

Арттарак торганы да якынлашты. Монысы бөтенләй бала сымак яшь-җилбәзәк иде әле. Аның да сөлгесе муенына чолганган иде.

— Утырыгыз минем көрпәгә, — диде Фәрхетдин.

Казармага бер исерек килеп керде. Ул тапчаннарга орынып-сугылып Фәрхетдиннәргә таба килә башлады. Исерек тамагы ертылганчы акырып «Баламишкин» көенә татарча җырлый иде.

— Безнең Гаяз тагы печтек кенә чирттергән, — диде таза бәдәнле эшче.

Гаяз исә, Фәрхетдиннәр турысына җиткәч, тукталып, егылмас өчен аякларын аерып баскан хәлдә, сөзәргә җыенган үгез кебек, башын ия төшеп егетләргә текәлде.

— Син, Фәрхетдин, бик грамотный булып чыктың әле, анаңны үләт себергере,— диде ул, көрмәләнгән телен көчкә әйләндереп.

— Давай, ят син, Гаяз,— диде таза эшче.

— Ә син атбакат булма, Фәтхелбаян. Яратмыйм мин грамотныйларны.

— Син бит безгә гәзит укырга бирмисең, ә анда синең тормышың язылган, — диде Фәрхетдин.

— Минем тормыш юк. Кеше тормышы юк миндә, миндә эт көне. Белдеңме?

— Хатыны үзен ташлап качкан, — диде Фәтхелбаян.

Фәрхетдин уйланып исереккә карап торды... «Ташлаган, ташласа да, үлмәгән бит әле» дигән уй узды аның башыннан. Исерек тагы тамак төбе белән акырып җырлый башлады.

— Яткырырга туры килә инде бу шалапутны, — диде Фәтхелбаян көлемсерәп. — Син туктап тор, укыма. Бик тамаша әйберләр язып бетергәннәр икән бу юлы гәҗиткә. Аһ итәрлек!

Ул исерекне култык астына кыстырып күтәрде дә, тегенең ай-ваена карамастан, дөбердәтеп үз урынына илтеп яткырды. Гаяз шуны гына теләгән дә иде, ахры. Өстен чишендереп, итекләрен салдырып, якасын чишүгә, гырлап йокыга да китте.

Фәтхелбаян Фәрхетдиннәр янына килгәндә төркемгә тагы ике кеше өстәлгән иде. Берсе типтәр егете Исмәгыйл, икенчесе, картрагы, татар агае Борһан. Икесе дә этрәк-эләмнәр.

— Компания монда шәп икән,— диде Борһан,— бер акбаш кына җитми.

— Фәрхетдин анау көннән һоң авызыма алмаем тип ант итте,— диде Чынбулат кеткелдәп.

— Тыңлыйсызмы, юкмы, егетләр? Тыңлар булсагыз гына укыйм, — диде Фәрхетдин кырку гына.

Тыңлаучыларның берсе дә укый-яза белми. Алар өчен үз телләрендәге газета сүзен ишетү кызык иде. Фәрхетдин укуын дәвам иттерде.

Ул бер хата җибәргәнен соңыннан гына аңлады. Иптәшләрен, монда ишеткәннәрегезне һәр очраган кешегә сөйләп йөрмәгез, дип кисәтмәгән иде ул. Шунда иде аның хатасы. Хәлбуки, әлеге шадра чыннан да махсус куелган кеше булып чыкты. Ул, җаен туры китереп, яшь эшче егеттән барын да сорашып белде, өстәвенә, хас тимерчелеккә барып Фәрхетдин турында сорашып та йөрде.

Март урталарында «Урал»га полициянең һөҗүме шул дәрәҗәдә көчәйде — охранканың якын арада газетаны туктатачагы Хөсәен өчен хәзер көн кебек ачык иде. Берничә тапкыр группа членнары белән очрашу булды. «Урал»ның татар-башкорт арасында гына түгел, гомумән барлык төрки халыклар арасында большевистик идеалларны таратучы зур бер көчкә әйләнүе, аның әһәмияте турында сөйләшенде. Инде хәзер максат шул органның гомерен озайту, ничек кенә булса да, һич югында, янә берничә айга озайту иде. Озак баш ватканнан соң, уртак бер фикергә килделәр. Бу мәсьәлә бары акча булганда гына чишелә алачак иде.

— Акча, акча, нинди генә юллар белән булса да акча табарга кирәк безгә. Ул вакытта цензорны да юашландыра алабыз, губернатор канцеляриясенә дә, хәтта жандармериягә дә йогынты ясап булачак,— диде Сәйфетдинев.

Тик, кызганычка каршы, РСДРПның җирле группасы кесәсендә акча бик аз иде шул.

Соңгы тапкыр очрашудан соң ике көн узгач, Леонтьев аркылы Хөсәенне яшерен квартирага тагын чакырттылар. Гадәттә группа членнары белән очраша торган бу урын иң ыгы-зыгылы Николаевский урамында, ишегалдындагы бер аулак флигельдә иде.

Хөсәен халык төркеменә ияреп шул ишегалдына кереп китте. Койма шикелле булып күтәрелгән акация агачлары арасыннан узып флигельгә җитте.

Аны группа членнарыннан ачык чырайлы, кискен хәрәкәтле, каратутлы, моңарчы Хөсәенгә артык таныш булмаган бер кеше каршылады.

— Сүз кыска булачак, Хөсәен Минһаҗетдинович,— диде ул.— Без күп уйланганнан соң акча табу өчен экспроприациягә барырга булдык. Шушы араларда банкка тузган ассигнацияләр урынына яңа гына чыгарылган акчалар киләчәк. Шуны басып алырга кирәк. Барысы да уйланган, тик безгә бик интеллигент кыяфәтле күркәм бер ярдәмче генә кирәк. Ул чиновник формасында булырга тиеш, менә шундый кеше эзлибез.

Хөсәен катгый рәвештә баш тартты.

— Юк, мондый эшкә барып булмый!..

Каратутлы төксе кешенең йөзенә ризасызлык билгесе чыкты.

— Партия дисциплинасын онытасыз, иптәш Ямашев!

Хөсәен тирән итеп бер көрсенде дә:

— Мондый эш безнең фракция принципларына туры килми,— диде,— мин башка ысул табып булыр дип уйлыйм.— Һәм Хөсәен кинәт нидер хәтерләп:

— Күрсәтегез әле шул турыдагы карарны. Бармы ул, иптәш Воинов? — диде. Воинов йомшара төште, ничектер күзләрен читкә алды.

— Мин аны сезгә күрсәтә алмыйм, конспирация,— диде ул.

— Булмый,— диде Хөсәен, катгый бер фикергә килеп, урыныннан торып, ишеккә таба юнәлде.

— Моның ахыры хәерле булмас,— дип калды Воинов. Хөсәен дәшмәде, бары тик: «Ни өчен Леонтьев үзе килмәгән?» дип кенә уйлады.

Урамга чыккач, идарәгә таба юнәлеп, бик озак баш ватып атлады ул. Группа җитәкчеләре, аныңча, меньшевиклар йогынтысына бирелгән иде. «Бәлки башка чарасын табу мөмкин булмагандыр?» Ул Леонтьев белән очрашырга булды. Аннары бераздан, бу бик җитди мәсьәләне Тамаровның үзе белән сөйләшергә кирәк, дигән нәтиҗәгә килде.

Хөсәен, әнә шундый икеләнүле уйлар белән, кичке дүртенче яртыда идарәгә кайтып керде.

Идарәдә Басыйрдан башка кеше юк иде. Галимҗанның менә хәзер шунда булмавы әйбәт түгел, әлбәттә, чөнки Хөсәеннең аның белән Воинов тәкъдиме турында киңәшәсе килгән иде. Басыйр белән исә, хәтта Хәдичә белән дә бу турыда сүз кузгатып булмый.

Хөсәен, күңелендә кайнаган тойгыларны тыярга тырышып, чираттагы санга әзерләнгән материалларны карап утырды. Көн тәмам караңгыланды. Басыйр бүгенге эшен тәмамлап өенә кайтып китте. Хәдичә ашарга чакыргач кына Хөсәен эшеннән аерылып башын күтәрде.

Табын янында ул борчылып:

— Ни өчендер Галимҗан көне буе күренмәде,— диде.— Һәр адымны сагалап тора башладылар дип зарланган иде....

— Бик мөмкин, Хөсәен,— диде Хәдичә.— Александра Михайловна да миңа шул хакта әйтте.

— Нәрсә дип?

— Кулга алынуы ихтимал дип.

Хөсәен нидер әйтмәкче иде дә тыелып калды. Бары кашларын җыерып куюы гына аның башка уйлар белән булашуын сиздерә иде.

Галимҗан иртәгесен дә газета идарәсендә күренмәде. Хөсәен борчуга төште. Бу көннәрдә, җитмәсә, Николай белән дә бәйләнеш өзелде, билгеләнгән вакытка явка урынына килмәде ул. Күрәсең, аны да бик нык эзәрлекли башлаганнар.

Хөсәен моңарчы бу тирәдә бер дә күренмәгән егетне, Кудашев алып килгән Сакаевны, Галимҗаннарга җибәрергә җыенганда, ике көн буе югалып торган Галимҗан үзе идарәгә килеп чыкты. Хөсәен шатланып аның иңеннән кочып алды, сораулы караш белән дустына текәлде. Галимҗанның кыяфәте исә киеренке һәм бик дәртле күренә иде.

Ул Хөсәеннең кочагыннан ычкынды да, ым кагып Басыйрны сәламләгәч:

— Хәдичәң өйдә юк, ахры, әйдә керик әле бүлмәңә,— диде.

Хөсәен бу сүзгә гаҗәпсенә төшеп:

— Әйе, ул базарга китте бугай,— диде.

— Сүз бар сиңа,— диде Галимҗан бик мәгънәле итеп һәм Хөсәеннәр бүлмәсенең ишегенә таба атлады.

Бүлмәгә керделәр. Галимҗан нык итеп ишекне япты.

— Я? — диде Хөсәен, гаҗәпсенү катыш шикле караш ташлап.

— Мәсьәлә хәл кылынды, кичә кич мин ризалык бирдем,— диде Галимҗан. Хөсәеннең күңеле нидер сизенеп «жу» итеп китте.

— Нинди ризалык? — диде ул шомланып.

Галимҗан Хөсәен янына ук килде дә, аның йөзенә кайнар сулышын бөркеп, шыпырт кына сөйләргә кереште:

— Кичә караңгы төшкәч Воинов янында булдым. Экспроприациягә ул җитәкчелек итә. Акча капчыгы поездан алынган вакытта сакчыларга һөҗүм ясалачак. Акчалы капчык шул минутта ук тартып алына да узып барган паровозның тендерына ыргытыла. Һөҗүм ясаучы кешеләр составлар астына кереп югала, аларга качып котылу өчен алдан ук урын уйланган. Ә маневр паровозы Сакмарга якынлашу белән каенлык яныннан кире Оренбурга таба китә башлый. Шул вакыт, ул тукталган арада, акчаны җиргә ташлыйлар. Тендердагы кеше үзе дә төшеп кала. Ул капчыкны күтәреп каенлыкка таба йөгерә, анда аны атлы кеше көтеп тора. Капчык чанага салына, аннары Сакмар ягыннан шәһәргә алып кайтыла.

— Мин бу операциягә каршы,— диде Хөсәен кисәк кенә.

— Миңа әйттеләр. Воинов сине курыкты ди. Мин аңа синең катнаша алмавыңны аңлатырга тырыштым.

Хөсәен йөзен чытты.
— Эш андамыни! Сиңа группаның карарын күрсәтteләрме соң, ичмаса?
— Карар... Син аңла, минем баш тартуым ул иптәшләрне сату булыр иде.
— Ничек инде?
— Чөнки барысы да әзер, эш безгә генә терәлеп калган. Ике кеше җитми икән аларга, берсе — паровоз тендерында барырга тиешле, ә икенчесе — кучер хезмәтен оста башкарырлык кеше...
Хөсәен тәкатьсез калып төкереп куйды. Ашыгып папирос кабызды. Төтенне бик күп итеп суырып читкә өрде дә ачуланып:
— Бик зур ахмаклык эшләгәнсең,— диде.— Гомумән безнең эш ысулы түгел бу.
— Алай димә. Барысы да «Урал» өчен эшләнә бит. Бездән беркем дә катнашмаса, ничек группадан акча таләп итә алабыз соң без?!
— Ах, акча гына барысын да хәл итә алса икән! — дип куйды Хөсәен ачынып.
— Хәзер соң инде. Мин ризалык бирдем. Бу эшкә Фәрхетдинне дә тарттым. Ул мине урманда ат белән каршы алачак.
Хөсәен күзгә күренеп агарынды. Аның соң дәрәҗәдә ярсыганын бары бит мускулларының тартышып куюыннан гына белерлек иде.
— Кайчанга билгеләнгән операция? — диде ул, ниндидер ят, тоньк тавыш белән.
— Акча Оренбурга бүген бер тулар-тулмаста килергә тиеш. Тагы шуны әйтим, мин инде өйгә кайтып тормам, шушында кабыкны алыштырып, туп-туры вокзалга китәчәкмен.
— Ә Александра Михайловна? — диде Хөсәен. Галимҗан ул берни дә белми дигәнне аңлатып баш селкеде.
Хөсәен аның кулындагы күн тышлы чемоданга әле генә игътибар итте. Сәйфетдинев чемоданны ачып, аннан өс киемнәре чыгара башлады.
— Мин аларга булышам, ә син миңа булышырга тиеш, Хөсәен,— диде ул, ни эшләргә кирәген аңлатырга керешеп.

## 32

Галимҗанның хатыны Александра Михайловна кунакханәдәге үз бүлмәләрендә көндезге ашка табын әзерләп йөргәндә ишек шакыдылар. Тәгаен, Галимҗан үзе кайткан иде, чөнки ишеккә бармак сырты өч тапкыр бәрелде. Саша ашыгып ишеккә таба атлады. Келәне ычкындырды, инде ирен муеныннан кочып үбәргә әзерләнгәндә генә куркынып кире чигенде. Хатынның каршында Галимҗан киемнәрен кигән Хөсәен басып тора иде. Ул бармагын иренәнә тиз генә тидереп, тавыш чыгарма дип ымлады. Саша, ни диярргә дә белмичә, тәмам аптырап Хөсәеннең күзләренә текәлде. Хөсәен күтәреп куйган пальто якасын төшерде, изүләрен чишеп җибәрде.
— И аллам, бу ни хәл? Галимҗан кайда? — диде, ниһаять, хатын, куркуга төшеп.
— Хәзер барысы да аңлашылыр,— диде Хөсәен.— Әз генә сабыр итегез, Александра Михайловна.— Киемен салып чөйгә элде дә:— Ачуланмагыз, бүген миңа көндезге ашны сездә ашарга туры килер,— диде.
— Аңлатыгыз әле, алла хакы өчен, нинди комедия бу?
— Барысы да аңлашылыр,— диде Хөсәен кабатлап. Кулын юып, өстәл янына урнашкач:— Без, Александра Михайловна, сезне борчырга теләмәдек инде,— дип хәлне аңлатырга кереште.— Кыскасы, шул,

Галимҗан хәзер партия йомышын үти. Ләкин бу эшне күзәтүчеләр сизмәскә тиеш. Шуңа күрә, гафу итегез, үзенең үтенүе буенча, мин сезнең иргегезнең киемнәрен киеп кердем.— Шулай дигәч, Хөсәен көлемсерәп куйды.— Ә бит охшашлык зур безнең, без яшьтәш булу өстенә, тагы бер үк үлчәүдәге кием киябез.

— Нинди йомыш ул? — диде Саша шомланып.— Нинди йомыш үти Галимҗан?

— Менә анысын инде хәзергә әйтми торырга рөхсәт итегез...

— Һич югында, шунысын әйтегез: бик хәвефле эшме?

Хөсәен кашларын җыерып Александра Михайловнаның матур ак чыраена, зур зәңгәр күзләренә карап торды.

— Ничек булып бетәр бит, Саша. Минемчә, куркырлык урын юк.

Хөсәен шулай диде, ләкин эченнән: «Бик тә куркырлык, гомумән ахмак эш», дип уйланды. Бу яшь хатынга ялган сөйләвен ул ничек тә сиздермәскә тырыша, үз-үзен өзлексез табалый иде.

Саша өстәлгә миски белән шулпа китереп куйды, тәлинкәләргә аш салды. Хөсәеннең тамагыннан аш үтми, аның әз генә дә ашыйсы килми иде. Ләкин сер сынатырга, эчтәге борчуларны тышка чыгарырга ярамый. Хөсәен теләмәсә дә, бик ачыккан кеше кебек ашарга тотынды.

Күзе стенадагы түгәрәк сәгатькә төште. Әгәр бу сәгать дөрес булса, тагы ун минуттан поезд килергә, янә бер биш минутлар узгач, һөҗүм ясалырга, капчык Сәйфетдиневкә тапшырылырга тиеш.

— Ашагыз, нигә туктаддыгыз? — диде Саша, нидер сизенеп.

— Әйе, әйе,— диде Хөсәен көлемсерәп,— менә Хәдичә турында уйланып алдым әле. Һич рәтләнеп китә алмый бит. Хәлем юк дип зарлана.

— Һавада йөрергә, җимерттереп ашарга кирәк.

Хөсәен ирексездән соңгы көннәрне үзен бик нык сиздерә башлаган акча кытлыгы турында уйланып алды. Килгән шәпкә арзанчылык оясы булып күренгән Оренбурда хәзер бары да артык кыйммәт булып тоела башлады. Теләгән ризыгыңны теләгән кадәр алып булмый.

— Мин шулай да сезнең миннән яшереп эш кылуыгызны аңламыйм. Аңламыйм да, кичерә дә алмыйм. Нинди задание башкара Галимҗан? — диде кинәт Саша.

Хөсәен җавап кайтармады, яңадан бер-ике кашык шулпа капты да, рәхмәт әйтеп, урыныннан торды.

— Икенче блюдо да бар.

Хөсәен кире урынына утырды.

Саша өстәлгә таба белән куырдак китереп куйды.

— Сез шулай да минем соравыма җавап бирмәдегез.

Хөсәен башта стенадагы, аннары кулындагы сәгатькә карап алды. «Боларның сәгате биш минутка артта икән. Хәзер һөҗүм ясалган булырга тиеш», дип уйланды ул.

— Әйтегезче, Саша, Галимҗан гадәттә өйдән сәгать ничәдә чыгып китә иде?

— Төрлечә, сез аны, Хөсәен Минһаҗетдинович, миннән яхшырак беләсез.

— Ярый, алайса, мин китим,— диде ул, бу юлы катгый рәвештә урыныннан торып.

Күрәсең, Хөсәен авыр кичерешләр эчендә януын яшерергә никадәр тырышмасын, Сашага бик ачык сизелә иде. Ул кием элгеченә таба атлаган Хөсәеннең юлын бүлде, агарынып, еш-еш сулап:

— Әгәр эләкмәсә, ничәдә кайтып керергә тиеш ул? — дип сорады.

— Анысын өзеп әйтә алмыйм. Ләкин караңгы төшү белән кайтып керер дип уйлыйм. Уңыш телик, Саша, батыр бул.

Хөсәен пальто якасын күтәреп куйды. Чыннан да, ул хәзер бик игътибар белән карамаганда Галимҗаннан һич аергысыз иде. Хөсәен,

коридорны кара, кеше-кара юкмы, дигәнне аңлатып, Сашага ишарә ясады. Анда беркем дә юклыгы беленгәч, кызу адымнар белән коридор буйлап ишеккә таба китте.

Нәкъ шул минутта исә Фәрхетдин, җигүле атын каенга бәйләп, агачлыктан тимер юлга таба чыгып килә иде. Паровоз озакламый килеп җитәргә тиеш. Фәрхетдин тирә-ягына караштыргалап юлга якынрак килде, корыган бер карт каен артына посты. Шул вакытны гына ул йөрәгенең атылып чыгардай булып тибүен тойды. Тирә-юньдә күгелҗем кар юрганы, арырак — каенлык. Паровоз менә шушы турыда, тимер юл үренең иң биек урынына җиткәч, кычкыртырга һәм әкрен генә шәһәргә таба чигенә башларга тиеш. Шул вакыт капчык җиргә ташланачак, аның артыннан Галимҗан сикереп төшә...

Фәрхетдин шәһәр ягына карады. Көн болытлы, җитмәсә, буранларга да чамалый, ахры. Кичә көн чалт аяз иде, кояш җылысы кар юрганының өстен эреткән, көртләр юка боз элпәсе белән капланган, аякны алыштырып баскан саен боз чатнаганы ишетелә. Җилнең җинелчә генә сызгыртып исүеннән башка бернинди тавыш та юк.

Кинәт шәһәр ягыннан сискәндереп ниндидер ят бер гөрелте ишетелгән кебек булды. Шулай шул, поезд килә. Фәрхетдиннең йөрәге «дөрт» итеп куйды. Ул башын күтәреп бүрегенең уң колакчынын өскә тартты. Бераздан паровоз килгәне күренде. Фәрхетдин аңышып та өлгермәде, ул нәкъ корыган каен турысына җиткәч туктады. Машинист, ишектән күкрәк тиңентен чыгып, тирә-якка каранды һәм тендерга борылып нидер әйтте. Фәрхетдин андагы кешенең Галимҗан икәнен да абайларга өлгермәде, нәкъ үзенең турысына шапылдап кечкенә, ләкин авыр бер капчык килеп төште.

— Ал, күтәр, йөгер каенлыкка! — дигән тавыш ишетте Фәрхетдин. Ул капчыкка ташланып, аны җилкәсенә салганда Галимҗан да килеп җитте. Фәрхетдиннең күзенә Сәйфетдинев өстендәге корымлы киемнәр чагылып калды. Алар, ашыгудан авыр сулап, ава-түнә каенлыкка таба йөгерделәр. Фәрхетдин җилкәсендәге йөкне чанага салды, кабаланып утыргыч астына яшерде. Бер минут эчендә, янгын сүндерүчеләр җитезлеге белән, Галимҗан үзенең корымлы сәләмәләрен салып, чанадагы киемнәрне киеп алды. Фәрхетдин атны чишеп чанага утырганда Галимҗан инде өр-яңа киемнәрдән, зур бер чиновникка әверелгән, үзен танырлык та түгел иде. Паровоз китеп барган иде инде. Галимҗан чанага менеп утырды.

— Юлны яхшы беләсеңме? Онытмадыңмы? — дип сорады ул.

— Һи, онытаммы соң...

Башта алар каенлык эчендәге тар юлдан бардылар. Аннан елга буйлап көнчыгышка таба киттеләр.

Алда ниндидер зур бер авыл күренде. Ләкин аны урап калдырдылар. Авыл читендәге баганалы юлдан узып, тагы сулга борылдылар. Калган ара Сакмар суы өстенә салынган кышкы юл буйлап сузылды. Алда печән төягән атлылар кәрваны очрады. Сөлектәй кара юртак аларны бик тиз арада узып китте. Тагы ашлык төягән юлчылар кәрваны күренде.

— Ә-ә, аяклары баш астына туры килгерләре! — дип гасабиланып сукранып куйды Фәрхетдин.

— Син атны кума, безгә хәзер ашыгудан мәгънә юк,— диде Галимҗан.

Чыннан да шулай шул. Фәрхетдин бары артык дулкынланганга гына ярсып ашыга иде.

— Без караңгы төшкәндә кайтып керсәк, шул җиткән,— диде Галимҗан.

— Беләм,— диде Фәрхетдин.
— Белгәч, атны юкка азаплама.
— Мин бу тирәдән тизрәк ычкынырк дигән идем.
— Хәзер инде, минемчә, артык курыкмаска да була.

Фәрхетдин ак бәкәлле озын аякларын югары күтәреп бик кызу юырткан атын тыя башлады. Ат барышын әкренәйтә төште.

Сакмар Җаекка кушылган урында, яр буенда бәләкәй генә алачык бар. Шул алачыктан чыгып, акчаны алып калырга тиешләр.

Бара торгач, шул агач түбәле өй дә күренде. Юл өсте тын, аулак, бер генә җан иясе дә юк хәзер. Галимҗан кузла астындагы капчыкны печән арасыннан тартып чыгарды. Ләкин аларны каршыларга тиеш кеше нигә күренми соң? Ул кыска кайры туннан, биштәрләп капчык таккан булырга тиеш, башта уң кулын күтәрәчәк, аннан атны туктату өчен сул кулын болгаячак. Шул вакыт ат туктый һәм аның белән сөйләшкән арада Галимҗан шудырып кына капчыкны карга төшерә.

...Ләкин нигә юк соң ул кеше? Галимҗан, бәлки караңгы булганга күренмидер дип, игътибарын җигеп өй тирәсен күзәтә башлады. Әмма анда үле тынлыктан башка берни сизелми иде. Алар, аптырашкан хәлдә, әлеге урынны узып киттеләр. Галимҗан борчылып сәгатенә текәлде.

— Безгә тагы бер урап шушы урынга килергә туры килер, ахры, әйттем бит мин сиңа, ул кадәр кума атны дип,— диде Галимҗан шелтә белән.

Фәрхетдин атка чөңгереп кенә куйды. Аргамак та шактый арыган иде инде. Аның сырты, арт саны юешләнеп китте, өстеннән җиңелчә пар күтәрелә башлады. Тик шулай да ул, элеккечә үк булмаса да, ак бәкәлле нәфис аякларын югары күтәреп, һаман әле алга җитез ташлый иде.

Елга өстендәге юлларны бер урагач, алар тагы яр буендагы агач түбәле өй турысына килеп чыктылар. Анда һаман беркем дә күренми иде. Күңел нидер сизенеп шомлана. Ниндидер хәвефле эш алда торган кебек иде. Юлчылар икесе дә иң элек юл читендәге аяк эзләренә игътибар иттеләр. Эзләр күп. Алар алга да, артка да киткән. Бу бер дә хәерле фал түгел иде.

— Провал! — дип кычкырды Галимҗан дәһшәтләнеп.— Ку җанфәрманга атны!!

Фәрхетдин дилбегә очы белән атның сыртына сукты, ачы итеп сызгырып җибәрде. «Стой, стой!» дигән тавышлар ишетелде. Якында гына наганнан аткан тавыш яңгырады, пуля баш очыннан гына сызгырып узды. Ниһаять, ату тавышлары бөтенләй ераклашты. Хәзер бары кара аргамакның ухылдап сулавы, чана алдына кар йомарламнары бәрелгән тавыш кына ишетелә һәм колакларда җил генә сызгыра.

Шәһәр корылмалары бөтенләй ачык күренә башлагач, Фәрхетдин Галимҗанга таба борылды.

— Галимҗан абый, төшегез, калага кереп шылыгыз, безне болай гына калдырмаслар. Сезне бит алар беләләр, тотмасыннар. Мин моны берәр җайлы урынга олактырырмын үзем,— диде.

— Бер дә булмаса, бәкегә, бәкегә җибәр! Аңладыңмы? — диде Галимҗан.

Фәрхетдин атны тыя төште, ләкин Галимҗан туктатканны көтмәде, чанадан сикерде дә карга бата-бата ярга таба йөгерде. Фәрхетдин төшеп аның урынына утырды. Хәзер ул шәһәргә барып керү белән үзен эләктереп алачакларын, шуңа кадәр капчыкны каядыр яшерергә кирәклеген уйлап баш вата иде. Кая яшерергә соң, кая? Елга өсте тип-тигез, әгәр инде кар астына яшерсәң, ул шул ук минутта табылачак. Бәлки яр ягына алып чыгып яшерергәдер. Ә эзләр? Фәрхетдиннең уйлары яшен тизлегендә хәрәкәтләнә иде. Тик аңа артык озак баш

ватарга туры килмәде. Көтмәгәндә каршыга атлы казаклар килеп чыкты. Алар юлдан атларын чаптырып, тавышланып, кычкырып-сызгырып Фәрхетдингә таба бик тиз якынлаша башладылар. Фәрхетдин бая шушы турыдан узганда күзләренә чагылып калган зур бәкене хәтерләде. Атны кисәк кенә шул якка борды. Бәке читенә үк килеп туктады, төшеп кузла астындагы капчыкны алды. Атлы казаклар камчылары белән селтәнеп Фәрхетдинне камап алганда, ул капчыкны бәкегә ташлаган иде инде.



## 33

Тукай, гадәтенчә тезләрен кочаклап, караватында утырып тора иде. Аның уйчан һәм боек йөзенә карап, Хәйруллин дустының күңеле бүген дә төшенке булуын аңлады. Урынын ашык-пошык кына җыйды да ялан аяк, күлмәк-ыштаннан гына идән уртасына басып, физкультура хәрәкәтләре ясарга кереште. Тукай байтак вакыт, аңа игътибар итмичә, каядыр еракка караган килеш, уйлануында булды. Ахырда Миңлебайның артык каты мышнавы аны борчый башлады булса кирәк, ул кырыс кына итеп һәм, әлбәттә, усал шаяртып, әйтеп куйды:

— Син, корьәнхафиз, болай газап чиккәнче, биш рәкагать намаз укы, сәвабы булыр.

Хәйруллин хәрәкәт ясавыннан туктады да Тукай янына килде.

— Сөмсерең коелган, дускаем, эч пошамы?

Тукай карават читенә утырган якташына таба борылды да, әрнеп елмаеп куйды.

— Төш күрдем, карый. Сәгъди абзыйны, Кырлайны. Гүзәл туган якның кара урманында йөредек, аннан киң арыш басуына килеп чыктык. Кояшлы җылы көн, тургайлар сайрый...

Габдулла тынып торды. Аннары пышылдап кына, кечкенә балалар кебек авызын турсайтып: «Сагындым», диде. Аның озын керфекле матур күзләрен яшь элпәсе каплаган иде. Хәйруллин авыр гына сулап түбән карады. Ул дустының сабыйлык көннәрендә бернинди рәхәт күрмичә кагылып-сугылып, үксез бала язмышын кичергәнен яхшы белә иде. Тукайның Сәгъди дигәне исә үзен Кырлайда тәрбияләүчеләрнең берсе. Габдулла, гадәттә, үзенең балалык еллары турында сөйләргә бер дә яратмый, ләкин кайчагында ул ачылып китә, бик күп сөйли, барысын, барысын, узган тормышын да, уйларын да сөйли. Күрәсең, күңелендә җыелганнарны якын бер кешесенә актарып ташлау аның өчен бер ихтыяҗ иде.

Хәйруллин, Габдулланы тынычландыру өчен, Уральск хәбәрләрен сөйли башлады. Бу яңалыкларны ул корьән укырга барган җирендә ишетеп кайта иде.

Габдулла башта игътибар белән тыңлап торды. Ләкин сүз бер байгураның фидиягә вафат булган улының яңа туны урынына үзенең иске бишмәтен биргәнлегенә житкәч, ул Миңлебайны бүлдерде.

— Бу иске тема, карый,— диде.— Син, булмаса, миңа бик матур итеп, мәкамь белән бер корьән укып күрсәт. Көеңнән бәлки күңел тынычланыр.

Хәйруллин Тукай өчен булдыра алганның барысын эшләргә риза иде. Башына килгән беренче сүрәне ул күзләрен йомып, чайкала-чайкала яттан укырга тотынды. Әйбәт, матур укый иде ул корьәнне. Артистлыгы аның бу һөнәрендә дә үзен сиздерә. Тукай сул кулын иягенә куеп, түшәмгә текәлгән хәлдә, тыңлап торды.

— Юк,— диде ул, карый сүрәнең яртысына җиткәч,— киресе килеп чыкты. Синең «Әл-бакра»ң аркасында минем күз алдыма шул ук Кырлай килеп басты. Ахшам намазы вакыты, мәзин моңлы итеп азан укый,

ә басу капкасыннан сыер көтүе кереп килә. Көтүче Сафаның чыбыркы шартлатканы, «һай-һай» дип кычкырганы ишетелә.

Шулай да Миңлебайның ярдәме эзсез калмады. Тукай хәзер ул кадәр ямансуламый иде инде. Ул хәтта әле генә башына килгән шигырь строфасын да сөйләп күрсәтте.

— Миңа ошый,— диде Хәйруллин,— тик менә бу җирен генә үзгәртергә кирәк түгелме икән?

— Ничек итеп? — диде Тукай, күңелсезләнә төшеп. Хәйруллин үзенең белгән кадәресен әйтте. Чынлыкта ул тәнкыйть итү өчен әйтмәгән иде моны. Ул Тукайны күңелсез уйларыннан читкә, җанын фида итәрлек сөйгән шигърият бакчасына алып китәр өчен әйткән иде. Һәм ялгышмады да. Тукай, бөтен дөньясын онытып, Хәйруллин белән бәхәскә керešte. Әйе, Тукайның тиз кабынучан күңеле бераз тырналса тырналгандыр да, әмма ул хәзер элекке хәленә — турыдан ярдырып әйтүне сөючән, ясалмалылык, тәкәллефләрне җаны-тәне белән яратмый торган элекке гадәти хәленә кайтты.

Шигырь турындагы сүз Миңлебайның җиңелүе белән беткәч, Хәйруллин юынып керде дә:

— Ну, бүген мәҗлескә барабызмы? — дип сорады.

Тукай бу юлы да гадәттәгечә ачы елмаеп кына куйды.

— Син кешеләр күрәчәксең, гыйбрәтле вакыйгалар ишетәчәксең, әфәндем,— дип карады карый.

— Фидия козгыннары! Кара, шундый исемдә бер шигырь язарга кирәк әле, малай!

Тукай шунда ук шигырьне чыгарып, күңеленнән кабатлый да башлады.

Кемдер ишек шакыды. Тукай юрган астына чумды.

— Кара аны, сорамыйча кертмә!

Хәйруллин ишекнең келәсен күтәреп өлгермәде, бүлмәгә җилләнеп Камил Төхфәтуллин килеп керде.

— Исәнмесез, әфәнделәр,— диде ул коры гына. Тукай, аны тавышыннан танып, мендәрдән башын күтәрде.

Камил, беркемнән рөхсәт-мазар сорамастан, пальтосын да салмаган килеш, өстәл янындагы утыргычка килеп утырды да, кыйммәтле кама бүреген өстәлгә ташлап, аякларын чалып куйды. Аның йөзендә гадәттә бик сирәк була торган дәһшәт билгеләре чагыла иде бүген. Шулай да ул көязләнергә онытмаган, өстенә фрагын кигән, муенына кара бантик бәйләгән.

— Әфәнделәр, эш харап, барысы да зир-зәбәр килде,— диде ул.

Тукай юрганын читкә ташлап торып утырды.

— Нәрсә булды тагын?

— Матбаганы сатарга туры килә. Полный банкротлык!

— Ә газета-журнал чыгару! Син бит, әфәндем, таш яуса да, мин аларның чыгарыла башлавына ирешәм, дигән идең?

— Барысы да җимерелде. Мин чыгарган газета-журналлардан янадан-яңа мәкруһ нәрсәләр таптылар. Кыскасы, мин бу көннән алып нашир да, мөхәррир дә түгел.

Тукай, соң дәрәҗәдә ярсыган хәлдә, идәнгә төшеп басты.

— Ничек инде син, әфәндем, шулай тиз генә паникага төшәсең?

— Габдулла, син аңларга тиеш, мин шул газета-журналлар аркасында югары чиннар алдында абруемны югалттым, муеннан бурычка баттым.

— Аннан, шуның аркасында икенче Думага депутат булып та сайлана алмады әле ул,— диде Хәйруллин төрттереп.

Камил аңа ачулы караш ташларга гына өлгерде, сүзне Тукай элеп алды:

— Син, Камил әфәнде, һәр нәрсәне акча белән үлчәргә өйрәнә башладың. Ә халыкка, мәгърифәткә хезмәт итү бурычы кайда соң? Нишләп мәсләгеңә хыянәт итәсең? — Тукай Камилнең борын төбендә үк кулларын селки-селки сөйләргә керешә:— Әфәндем, аңларга тиеш син: син чыгарган «Әлгасрел-җәдит» ул татар дөньясында беренче журналлардан. Син үзеңнең кем икәнлегеңне аңлап яшә, хода бәндәсе!

— Мин матбага булдыру өчен, журнал-газеталарымны чыгару өчен барлык байлыгымны салдым. Әтиемнән калган мирас, хәтта хатынымның бирнәсе дә шунда китте. Дөнья кадәр акча бурычка алдым. Нәтиҗәдә нәрсә килеп чыкты?

— Нәтиҗәдә син халкыңа искиткеч хезмәт күрсәттең, зур фидакарьлек эшләдең. Сиңа рәхмәт әйтәчәкләр.

— Һай, рәхмәттән тун тегеп булса иде!..

— Мин синең турыда мактап шигырь язган булам тагы,— диде Тукай,— син андый мәдхияләргә муафыйк кеше түгел икәнсең, Камил әфәнде.— Тукай ярсыган күңелен тыя төште. Паузадан соң:— Я, ярар, саттың ди матбагаңны,— диде.— Кемгә?

— Мәгълүм инде... Алам дип торганда мин аңа сатмый булдыра алмыйм. Бурыч бар бит...

Тукай шунда ук аңлады. Сүз, әлбәттә, Уральск сәүдәгәрләреннән берсе Мортаза Гобәйдуллин турында бара иде. Габдулла ачу белән янган күзләрен Миңлебайга текәде.

— Күрдеңме, кем кулына барып эләкте безнең изге башлангыч эшләребез? — Ул кисәк кенә Камилгә таба борылды.— Димәк, «Фикер»нең дә, «Әлгасрел-җәдит»нең дә наширы моннан соң Гобәйдуллин булачак?

— Сүз әле аңа барып җитмәде,— диде Камил,— сүз хәзергә бары матбага хакында гына барды.

— Соң нинди шартлар куелды? «Фикер», «Әлгасрел-җәдит» чыгачакмы?

— Әйтәм бит, сүз алар турында бармады.

Тукай, балагында буталып, сөрлегә-сөрлегә чалбар кияргә тотынды. Киеп, төймәләрен каптыргач, тагы Камил янына килде.

— Әгәр дә шул Мортаза алдында матбаганы газета һәм журналларны чыгару шарты белән генә сатам, дип катгый рәвештә ультиматум белдермәсәң, сине милләт беркайчан да гафу итмәячәк!

— Без аның турында җаен туры китереп сөйләшербез.

— Һа, куандырды! Сөйләшербез! Әгәр сөйләшмәгән булсаң, хәзер үк бергә барып сөйләшәбез. Әнә, «Әлгасрел-җәдит»нең гранкалары, кызыксынсаң, карый тор,— диде Тукай. Ул күптән журналның да, газетаның да, рәсми булмаса да, фактик редакторына әйләнгән иде. Камил һич кызыксынусыз типография буявы исе аңкып торган кәгазьләр өеменә үрелде. Тукай юынырга чыгып китте.

— Аңламый Тукаев,— диде Камил зарланып.— Мин зәррә кадәр дә үзем өчен хафаланмыйм. Мин инде, эш шуңа калса, җырлап та тамагымны туйдыра алам.

Аның матур йөзе, мәһабәт гәүдәсе һәм хәтта шәп киемнәре хәзерге мескен кыяфәтенә һич ятышмый кебек иде. Гомумән һәр вакыт һаваланырга яратучан, үзен барлык тормыш ваклыкларыннан өстен куючан мөхәррир, нашир, җырчы һәм мөдәррис Камил Мотыйгый Хәйруллинга кинәт кызганыч бер кеше булып тоелды. Ул, әңгәмәне икенче якка борырга теләп, үзенә якын әйберләр турында сүз башлады.

— Безнең спектакльгә әзерләнүебез бушка китте, ә? — диде.

— Спектакль дигәннән, әле кичә миңа теге приказчик Җәгъфәр очрады. Бае белән мөнәсәбәтләре бик начарланган икән. Ул «Урал»га

приказчиклар әхвәленнән мәкалә язып җибәргән булса кирәк, һәрхәлдә, хуҗасы шуннан шикләнә, имеш.

— Гаҗәп икән. Аңа кереп чыгарга кирәк әле.

Тукай юынып керде дә Камилдән:

— Киткәнче чәй эчеп алабызмы, әллә синең вакытың юкмы? — дип сорады.

— Син Мортазаларга бару турындамы?

— Әлбәттә.

— Йа, Тукаев, ай-яй-яй-яй! — диде башын чайкап Камил.— Берәр әйбер синең башыңа керсә, чөй белән дә кагып чыгару ихтималы юк.

— Сүз, әфәндем, матбугат турында бара. Ул халыкның язмышын, киләчәген хәл итүче бер нәрсә. Бәс, шулай булгач, бу мәсьәләгә бармак аша карау җинаять. Әйт, чәй эчертәсеңме безне яки ач көенчә барыйкмы?

— Ачның ачуы яман. Көйләнеп барган эшне бозып куярсыз я. Әле минем эшләрем дә бар. Янә бер сәгатьтән миңа килерсез. Чәй эчегез. Чәйлек акчагыз бармы?

— Акча ягы такыр. Рәхмәт минә Миңлебайга, аның соңгы сәхәрлекләренә яшибез.

— Мин көтепханәмне дә сатарга булдым,— диде Камил. «Бу эштә кайсыгыз миңа булыша ала» дигәндәй, егетләрнең икесенә дә карап алды. Һәрхәлдә, Тукай аның сораулы караш белән текәлүен шулай аңлады, Хәйруллинга күрсәтте.

— Менә китап сату эшенең олуг маһире шушы әфәнде була инде. Син китапларыңны шуңа тапшыр...

— Әмма табыш уртак,— дип өстәде Хәйруллин.

— Оста татар да соң үзегез, билләһи,— диде Камил кәефләнеп — Хәер, мин моңа каршы түгел, акча кирәк. Бүген үк сәүдәгә керешә аласың. Бәяләре турында китап алганда сөйләшербез...

Камил чыгып китте.

Камилләр килеп кергәндә, Мортаза Гобәйдуллин өендә иде. Кабарып чыккан камырдай җәелгән бу кеше, гадәттә бай дигәч тә күз алдына килеп баса торган кыяфәттә иде. Үзенең симезлегенә карамастан, ул шактый житез булып чыкты. Кунакларның бер артына, биш алдына төшеп дигәндәй, туптай тәгәрәп, каршы алды. Тукай өчен тагы шунысы сәер тоелды: бу калын кеше бик нечкә тавыш белән сөйләшә иде.

Өстәл тирәсенә утырышкач та, сүзне Тукай башлап җибәрде:

— Мортаза әфәнде, сез Камил Мотыйгыйдан матбага сатып алырга җыенасыз икән. Мәзкүр[1] матбагада, сезгә мәгълүмдер, бөтен Русия татарлары арасында таралган «Фикер» газетасы, «Әлгасрел-җәдит» журналы басыла. Моңарчы бу газета-журналларның наширы Камил әфәнде иде. Ышануыбызча, бу көннән соң сез аларның наширы булырсыз. Алар чыгуларын алда да дәвам иттерерләр, шулай бит?

Мортаза, аптырап һәм уңайсызлана төшеп, таркау гына елмая башлады.

— Гафу үтенәм,— диде.— Ни өчен миңа бу сүзләрне сез әйтәсез? Матбаганың хуҗасы Камил әфәнде бит...

— Әйе, Камил әфәнде. Мине тәкәллефсезлегем өчен кичерегез, мине шулай булырга мәҗбүрият куша. Мин сезнең белән Русиянең төрле почмакларында яшәүче мөштәриләр[2] исеменнән сөйләшәм. Мин Габдулла Тукай булам, тагы бер тапкыр исегезгә төшерәм. Ә мөштә-

---

[1] Мәзкүр — шушы.
[2] Мөштәриләр — газетага язылучылар.

рилэр «Фикер»нең дә, «Әлгасрел-җәдит»нең дә чыгуын тели. Алар туктальгрга тиеш түгел, диләр.

— Мин сезне аңлыйм, Тукаев әфәнде,— диде Мортаза,— әмма әйтергә тиешмен ки, ул газета-журналларны чыгару ифрат мактаулы эш булса да, аның чыгуын нашир гына тәэмин итә алмый бит әле. Монда беренче скрипканы мөхәррир уйный. Ә менә Камил әфәндегә мөхәррирлекне рөхсәт итмиләр.

— Аптырамагыз,— диде Тукай.— Мин үзем мөхәррир булам.

— Белмим шул,— диде Мортаза.— Ишетүемчә, мөхәррир вазифасын үтәү өчен кеше билгеле бер яшькә җитәргә тиеш. Сезне яшьрәк бу димәсләрме?

— Ә без өлкәнрәк кеше табачакбыз. Ул кул куяр, ә мин мөхәррирлек вазифасын башкарырмын.

Мортазага хәзер чигенергә юл калмаган иде. Әлбәттә, аның халыкка хезмәт итәсем килми, дип әйтергә дә батырлыгы җитми.

— Беләсезме, әфәнделәр,— диде ул,— мин үзем өчен «Фикер» вә «Әлгасрел-җәдит»не чыгаруны зур мәртәбә саныйм. Без барыбыз да милләт хадимнәре ич. Шулай булгач, әгәр имкяният була икән, мин аларны әлбиттә чыгарачакмын.

— Алайса, вәгъдә? — диде Тукай.

— Яхшы.

— Димәк, барлык хезмәткәрләре белән редакция дә сезгә тапшырылачак, шулаймы, Мортаза әфәнде? — диде Камил.

— Яхшы, шулай.

Кунаклар урыннарыннан тордылар.

Тукай, гайрәте суынмаган хәлдә, байга әйтте:

— Менә без сезнең хозурга өч кеше килдек, Мортаза әфәнде. Беребез матбага хуҗасы, нашир һәм мөхәррир, икенчебез шагыйрь, ә өченчебез битараф бер мөштәри. Сез безнең алда, инглизләр әйтмешли, җентелмәннәрчә сүз бирдегез. Онытмагыз!

Мортаза, көлә биреп, Тукайның батырлыгын хуплагандай, симез йомшак кулы белән аның иңбашына суккалап алды.

— Менә күрдеңме, Камил! — диде Тукай урамга чыккач.— Сөйләштек бит. Аяк терәп сөйләштек. Ә син ык-мык итеп куркып торасың.

— Хәл бит бик мөшкел, Габдулла, аның баш тартуы да бар иде.

Тукай шаркылдап көлеп куйды.

— Җүләр син! Ул үзе синнән курка. Бу тотнаксыз Мотыйгый бурычын түләмәс, качар, дип курка.

Яз үзен ярыйсы сиздерә башлаган иде инде. Дымсу җылы һава, ат тизәгеннән көрән-яшькелт төскә кергән юллар, түбә кыекларындагы тамчылы бозлар — барысы да яз галәмәтләре.

Габдулла быел җәй үтү белән солдатка каралырга туган якка кайтачагын исенә төшерде. Аны уйлары яңадан Кырлайга, Казанга алып китте. Ул тынып барды. Чатлыкта Камил ниндидер онытылган эшен хәтерләп, егетләрдән аерылганга кадәр, Тукай бер сүз дә дәшмәде.

— Менә теге Җәгъфәр эшли торган кибет шушы,— диде кинәт Хәйруллин.— Кереп иптәшнең хәлен белеп чыкмыйбызмы?

— Керик, керик,— диде Тукай кинәт җанланып.

Алар кибеткә кереп, аның төрле бүлекләренә үттеләр, ләкин Җәгъфәр прилавка артында күренми иде.

— Сорыйк әле,— диде Тукай, галантерея бүлегенә җиткәч.

Хәйруллин чырадай ябык, ләкин җитез хәрәкәтле бер приказчиктан Җәгъфәрне сорап карады.

— Бай аны сәбәпсезгә эшеннән куды. Без приказчиклар хәзер бик хафада инде, әллә сез аның якыны буласызмы? — диде приказчик.

— Забастовка объявить итәргә кирәк сезгә,— диде Тукай туры

җавап бирмичә,— бу бит гаделсезлек, газетага дөресен язган өчен кешене эшеннән куалармы?! Ә ул үзе кайда соң әле хәзер?

— Бер дә әйтә алмыйм, әйберләрен кичә күтәреп алып китте.

— Гаҗәп,— диде Тукай, Миңлебайга карап.— Ни өчен безгә кермәгән ул?

— Бәлки ул килгәндә без өйдә булмаганбыздыр.

— Һич булмаса, язу калдырырга кирәк иде аңа.

## 34

Фәрхетдинне эт урынына кыйнап төрмә камерасына кертеп ташладылар. Менә өченче көн инде охранка кешеләре аннан җүнле сүз ишетә алмый. Ул телсез һәм саңгырау булып кыланды. Сорау алганда куркытып та, юмалап та, дөресен әйтсә, аңа ирек вәгъдә итеп тә карыйлар, телгә китерә алмагач, Фәрхетдинне рәхимсез рәвештә канга батырып кыйныйлар, һуштан язса, өстенә су сибәләр иде. Менә өченче көн инде бу кыргый рәхимсезлек дәвам итә.

Әлбәттә, Фәрхетдин бу «телсезлек»нең озакка сузылмаячагын аңлый. Ләкин сер ачылмый калган бер генә көн дә җеп очларын яшерү өчен, аныңча, иптәшләренә бик-бик файдалы иде. Шуңа күрә ул барлык көчен, ихтыярын җигеп, авыр газапларга түзде.

...Фәрхетдин ыңгырашып башын күтәрде. Нәкъ кичәгедәй, бүген дә аны иләкләнеп беткән кара бөркәнчек ябылган тимер караватка ташлаганнар иде. Ул күзләрен ачу белән үзенең кайда икәнлеген хәтерләде. Кузгалырга теләде, ләкин, кыймылдарга ирек бирмичә, бөтен гәүдәсе сулкылдап авырта башлады. Ул, күзләрен яңадан йомып, ничектер сәламәтрәк булып тоелган сул кулы белән гәүдәсен сак кына капшап чыкты. Алай сынган сөяк юк шикелле иде. Фәрхетдин хәлдән таеп, байтак вакыт селкенмичә ятты. Күңел болгаткыч дәрәҗәдә авыр иде аңа. Чит-ят шәһәрнең тынчу төрмәсендә кыйналган, мыскыл ителгән килеш, таркалган буыннарыңны җыя алмыйча ят инде! Җитмәсә, аның бит ерак Нәдерендә кадерле кешеләре әле күптән түгел үлгән иде. Шундый зур өметләр баглап көтеп алынган газиз улы, җан парәсе нәни Гыйззәтулласы тилмереп, ятимлектә азап чигә. Фәрхетдингә барысы да, шул исәптән үзе дә, бик-бик кызганыч булып тоелды. Ул тамак төбенә тыгылган күз яшьләреннән буыла башлады, артык түзә алмыйча, тавышсыз гына елап җибәрде. Елаган арада аның күз алдыннан бер-бер артлы фаҗигале күренешләр узып торды. Кинәт хәтеренә Сакмар юлындагы вакыйгалар килеп төште. Фәрхетдин Галимҗанны хәтерләде. Исән-сау котылганмы ул, тотылмаганмы? Фәрхетдин елавыннан туктады да булган вакыйгаларның аерым ваклыкларын күз алдына китереп бастырырга тырышты. Әнә Галимҗан ава-түнә ярга таба чаба. Күзгә аның сөртенеп егылганы да чагылып калды. Шуннан соң ниләр булды? Фәрхетдин артыгын абайламады, чөнки каршыга атлы казаклар килеп чыкты. Аннары инде ул Галимҗанны бөтенләй онытты. Атны борып, җан-фәрманга бәкегә таба чаптырды, капчыкны кузла астыннан алып, ат туктар-туктамаста чанадан сикереп төште, үзе дә, Галимҗан кебек ава-түнә, бәкегә таба чапты. Аны бишмәт чабуыннан эләктереп алдылар, ләкин бу минутта капчык чулт итеп бәкегә төшеп киткән иде инде. Фәрхетдин артына борылып та карарга өлгермәде, аны секунд эчендә богаулап, суярга әзерләнгән сарык шикелле, чанага ташладылар. Авызыннан аракы исе аңкыган бер казак аның өстенә менеп атланды. Фәрхетдиннең әлегә хәтеренә төшкәннәре шулар иде. Әйе, тагы ак бәкәлле аргамак хуҗасы исендә калган. Анысы кара мыеклы, башына папаха кигән извозчик иде... Дилбегәне Фәрхетдингә тоттырганда ул: «Кара аны, братишка,— диде,—

атны каты кума, этидән калган бердәнбер мирас, ул безнең семьяны ашатучы да, киендерүче дә». Димәк, ничек булып чыга инде? Извозчик үзенең атын нинди максат белән алуларын белмичә биргән. Атның кемнеке икәнлеген белү авыр түгел. Әмма шунысы гаҗәп: моңарчы допрос вакытында ат турында ләм-мим сүз булмады. Ә була калса, Фәрхетдингә моннан ары телсез булып кыланырга мөмкинлек бетсә? Барыбер бирешмәс Фәрхетдин, үтерсәләр үтерсеннәр, тик ул Хөсәен абыйсын да, Галимҗанны да сатмас. Әйе, ул атны урладым дияр, ат турында гомер буе хыялландым, вокзал мәйданында җигүле ат күргәч, түзмәдем — утырдым да киттем, дияр. Ә бәкегә нәрсә ташладың дисәләр?.. Фәрхетдин монысына җавап таба алмаудан тәмам гаҗиз калып, газап кичерә башлады.

Чыннан да, нәрсә әйтергә соң? Ничегрәк әйтергә кирәклеген әйтмәделәр дә бит тегеләр. Күрәсең, эшнең уңышлы чыгачагына ышаныч артык зур булган. Тәгаен сатканнардыр аларны. Сатлык җаннар юкмыни. Баксаң-күрсәң, бәлки шул извозчик үзе үк сатлык җандыр әле.

Фәрхетдин, шактый озак баш ваткач, мин бәкегә берни дә төшермәдем, үзем ташланмакчы идем, дияргә булды. Бусы ярыйсы кебек. Ышануын ышанмаслар, тик шулай да аяк терәп кабатларлык бер уйдырма бит бу.

Ул шактый тынычлана төште һәм шул вакытта гына аркасы сызлый башлавын тойды. Күрәсең, аның сыртын чиләндергәнче каезлаганнар, хәзер инде тәннән саркыган кан күлмәккә ябышып каткан, үтереп әчеттерә. Фәрхетдин йөзтүбән ята иде, аягын сакланып кына караваттан төшерде, матрасына сөялеп билен турайтырга теләде. Аркага ябышып каткан күлмәк тартылып китте, кинәт яман каты авырту Фәрхетдиннең йөрәгенә капты.

— Канәчкеч албастылар, муеннары асты өскә килгереләр...— диде Фәрхетдин, аты-юлы белән сүгенеп.

Кинәт ишектәге тимер рәшәткәле тишектән тавыш ишетелде.

— Заговорил таки,— диде кемдер.

Фәрхетдин күрер өчен каерылып шул якка караганда, ишектән сакчы белән гражданский киемле бер кеше кереп килә иде. Фәрхетдин әллә бүген, әллә кичә инде аны күрде бит. Сорау алганда шул бит инде Фәрхетдинне рәхимсез кыйнады. Фәрхетдин, кинәт тәмам хәлсез калып, хайвани бер куркуга бирелгәнлеген тойды, башы әйләнеп китте. Үзүзен кулга алу өчен күп көч куярга туры килде аңа. Ниһаять, ул өнен җыйды. Бернинди авырту сизмәстән билен турайтып аягүрә басты.

— Сөйләшә башладыкмы? — диде керүче кеше. Аның җирәнгеч сары төк баскан симез йөзе, усал, кыргый күзләре мәңге онытылмаслык булып Фәрхетдиннең күңеленә сеңгән иде.

«Мин сөйләшә белсәм дә, синең белән сөйләшмәячәкмен», дигәнне аңлатты Фәрхетдин аңа.

— Нишләп алай? — диде теге ирен чите белән генә елмаеп.— Ошатмадыңмыни мине? Үзең гаепле. Син сөйләшмәгәч, мин нишлим?! Миңа сине ничек итеп булса да сөйләтергә куштылар.

Фәрхетдин дәшмәде, протест йөзеннән караватына утырды.

— Яле, живо! — дип кычкырды кинәт теге кеше явызланып.— Сине тикшерүче әфәнде көтә анда.

Ләкин бу юлы Фәрхетдинне тикшерүче генә көтми иде. Гөлдерәпяңгырап торган төрмә коридорларын үтеп, караңгырак таныш бүлмәгә кергәч, Фәрхетдин сорау алучы такыр башлы кешедән башка, бәлакәй генә бәдәнле ят бер бәндәне күрде. Игътибар беләнрәк карагач, ул ирексездән сискәнеп китте. Чөнки ят кешенең казармада һәр нәрсәгә тыкшынып йөрүче, теге көнне дә егетләргә газета укыганда бәйләнеп маташкан шадра кәрлә икәнлеген белеп алды.

— Таныйсыңмы шушыны? — дип сорады аңардан тикшерүче, Фәрхетдингә күрсәтеп.

— Таныйм, ваше благородие,— диде шадра куштанланып,— нәкъ шул үзе, үзе. Ул телсез түгел, ваше благородие, үзенчә бик шәп сөйләшә. Безнең телдә дә аның белән аңлашырга була. Ул һәр вакыт үзе кебек мөселманнарны җыя да казармада аларга каля-баля нәрсәдер укый.

— Нәрсә укый, ачыграк әйт,— диде тикшерүче.

— Тыелган әйберләр укый. Хак сүз. Мин сорашып белдем. Аннан ул тагы Казанда бишенче елның көзендә бунтовщиклар белән бергә булган. Аларга корал ташыган. Монысын да белдем. Хак сүз. Бунтовщик бу, ваше благородие.

Пеләш башлы, зур яшькелт күзле, чандыр, кырыс тикшерүче Фәрхетдинне сынап башыннан аягына кадәр карап чыкты. Сүз әйтмәде, өстәл өстендә бармак тыпырдатуыннан гына Фәрхетдин аның, җәнлек эзенә төшкән сунарчы кебек, шатлык кичерүен тойды. Допрос башланды.

## 35

Тегe көнне Хөсәен Галимҗанны кичке алтыга кадәр көтәргә тиеш иде. Сәгать алтыны да сукты, җиде дә булды. Ләкин Галимҗан күренмәде. Хөсәеннең күңеленә шом хәнҗәре кадалды. Күңелне дәһшәт тойгысы куырып алды. Димәк, провал. Шулай булмый ни! Әйтмәдемени ул!

Хөсәен идарә бүлмәсендә япа-ялгызы утыра. Ул башта үзен эшләргә мәҗбүр итеп карады. Инде Галимҗанның кайтып җитәр вакыты якынлашкач, Хөсәеннең эше тәмам сүлпәнләнде. Инде соңгы чик тә узгач, ул гасабиланып урыныннан торды да тар бүлмәдә әрле-бирле йөренергә тотынды. Операциянең барып чыкмаганлыгы аңа ачык иде. Аның бу эшне вакытында кисәтә-тыя алмавына хәзер дә күңеле әрнеде. Бу инде күрәләтә утка таба очкан күбәләк хәленә калу кебегрәк килеп чыкты. Аннан башка да язмышы кыл өстендәге газетаны һәм иптәшләрне тиктомалга корбан итү дигән сүз бит бу.

Хөсәеннең шомлануы һәм үзен-үзе табалавы артканнан-арта барды. Ул, берсеннән икенчесен кабызып, өзлексез папирос тартты. Ниһаять, сәгать тугызны сугып, унынчы киткәндә, өй алдында ниндидер хәрәкәт булып алды. Хөсәен ашыгып ишеккә ташланды. Ачып җибәрүе булды — эчке якка Галимҗан авып төште. Аның бөтен өсте-башы ап-ак булып карга буялган, үзен танырлык та түгел иде. Хөсәен шундук иптәшен саклык белән стена буенда торган күн тышлы диванга салды, ашыга-ашыга чишендерә башлады.

— Күрмәделәрме?

— Белмим,— диде Галимҗан, битендә-кашларындагы карны сыпырып.— Мин ике сәгатьтән артык кар эчендә яшеренеп яттым.

— Димәк, полный провал? — диде Хөсәен.— Ә Фәрхетдин?

— Полный провал. Әйберне тапшырырга тиешле өй камалган иде. Провокатор эше, тәгаен, шулай.

— Ә Фәрхетдин, Фәрхетдин кайда соң?

— Әйтә алмыйм, Хөсәен, ул эләккән булырга тиеш.

Хөсәен ачынып: «Их сез!» дип кенә куйды. Аннары дустының йөзенә, кулларына игътибар итте.

— У, син битеңне өшеткәнсең ич! Яле, аяк-кулларың ни хәлдә?

Галимҗанның ике аягы да ап-ак булып өшегән иде.

— Ничек кайтып житә алдың? — диде Хөсәен галошларны һәм ботинкаларны кәнәфи астына ташлап. Ул Галимҗанның аякларын уар-

га керешге. Шул арада Галимҗан үзе дә торып утырды, кулларын һәм ара-тирә бит очларын уа башлады.

— Кайнар чәй эчеп карыйсы мәллә,— диде ул,— бәлки эчкә бераз җылы керер иде.

— Аны хәзер эшлибез. Менә аягыңа гына бераз җан керсен.

— Чәй, чәй,— дип кабатлады Галимҗан,— аякны мин үзем дә уармын.

Хөсәен алгы бүлмәгә чыкты. Хәдичә кухня өстәле янында савыт-саба юып тора иде. Хөсәенне аяк тавышларыннан тоеп, ул борылмыйча гына:

— Эшең беттемени? — диде.

— Чәй, кайнар чәй кирәк, Хәдичә, — диде Хөсәен.

Хәдичә гаҗәпсенә төшеп, иренә текәлде һәм аның агарынган йөзен, качкан чыраен күреп курка калды.

— Ни булды, Хөсәен?

— Әйдәле, Галимҗанга ярдәм күрсәтик, ул өшегән.

Бераздан алар икәүләшеп Галимҗан белән булаша башладылар. Бәхеткә каршы, кичен генә куелган самавардагы су кайнар иде әле. Ярты сәгать тырышканнан соң Галимҗанга хәл керә башлады. Ул торып аякка басты. Озакламый полициянең килеп керүе ихтимал иде. Озакка сузып булмый. Тиз генә моннан чыгып китәргә кирәк. Һич югында, Галимҗанның әлеге почта чиновнигы киемнәре тизрәк олактырылырга тиеш.

Галимҗан үзенең шикләрен әйтте.

— Сатлык үзебезнең арадан булса, ул шөбһәсез экспроприациянең ни өчен оештырылачагын да охранкага тапшыргандыр.

— Хәзер төрле юраулар юрауда мәгънә юк,— диде Хөсәен.— Мин, сине күреп калып, артыңнан килүче булмады микән дип кенә шикләнәм.

— Әйдә, алайса, утларны сүндерик. Нәрсә булыр икән? — диде Галимҗан. Хөсәен, монысы тагы нигә кирәк, дигәндәй, җилкәләрен җыерып куйды. Шулай да лампаны өреп сүндерде.

Алар бераздан дөм-караңгыда калдылар. Өчесе дә тәрәзәгә елышты.

— Күренмиме анда бер-бер зат? — диде Галимҗан. Урам тып-тын, күңелсез һәм аулак иде. Бары моңсу ай гына тоныкнурларын сибеп тора.

— Күрмәгәннәрдер, — дип куйды Галимҗан җиңел сулап, — юктыр. Минем чанадан төшеп калуымны күрделәр микән әле.

— Кай турыда төштең? Сөйлә әле барысын да,— диде Хөсәен.— Хәдичә дә белсен.

Галимҗан барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирде.

— Аңлашылды, — дип куйды Хөсәен. — Димәк, Фәрхетдин кулда инде хәзер.

— Син аңа ышанасыңмы? Ул бит мондый ситуацияләргә эләккән кеше түгел, — диде Галимҗан шомлана төшеп.

— Менә сыналыр инде шунда, — дип куйды Хөсәен.

Хәзер полициянең идарәгә килү ихтималы кимегән иде инде. Галимҗанның чиновник киемнәрен яшерделәр. Ул Хөсәен алып кайткан үз киемнәрен киде. Хәдичә күрше бүлмәгә кереп китте. Хөсәен белән Галимҗан әле байтак вакыт сөйләшеп утырдылар. Галимҗанның өшегән кул-аяклары хәзер ул кадәр әрнеми иде инде. Сәгать уникеләрдә ул, жандармерия килмәячәге инде ачыклангач, өенә кайтып китте.

Иртәгесен экспроприациянең барып чыкмаганлыгы, арага провокатор керүе тагы бер тапкыр расланды. Хәзер барысы да Фәрхетдиннең егетлегенә бәйле иде.

Өч көн үтеп дүртенче көн киткәндә Фәрхетдин турында да кайбер нәрсәләр мәгълүм булды. Идарәгә кичкырын Чынбулат килеп чыкты.

Аны монда тимерче Егор агай җибәргән иде. Фәрхетдин теге көнне чыннан да кулга алынган, ләкин ул үзен ат урлауда гына гаепле санаганлыгын әйткән, ә эшчеләр арасына кереп иснәнеп йөрүче бер җасус исә аңа бер олау гаеп таккан.

Бу хәбәр килеп җитү белән, Хөсәен Фәрхетдингә ярдәм оештыру турында кайгырта башлады. Тикниләр эшли ала иде соң ул мондый катлаулы һәм бик нык саклык таләп иткән бер вакытта? Шулай да Хөсәен РСДРПның җирле группасы һәм эшкә йогынты ясый алырдай танышлары аша суд чиновниклары белән бәйләнешкә керде. Фәрхетдингә адвокат яллаРга алынды. Ләкин, соңыннан мәгълүм булганча, бу эш урынсыз булып чыкты. Чөнки Фәрхетдиннең гаебе ат алып китү генә түгел, ул эшчеләр арасында ниндидер ярамаган политик эш алып барган дип тапканнар. Теге шадра җасус Фәрхетдиннең матрас астыннан табылган «Урал» газетасын, бер брошюраны, рус телендә язылган РСДРП прокламацияләрен китереп биргән. Шуңа өстәп Казандагы бишенче ел вакыйгаларын казып чыгарганнар. Ахырда Фәрхетдин эше буенча дело төзегәннәр һәм барлык формаль эшләр төгәлләнгәч, аны этап белән Казанга озатканнар. Суд шунда булырга тиеш табылган.

Хөсәен ул көннәрдә шактый какшады. Әлбәттә, аның өчен иң мөһиме «Урал»ны вакытында чыгарып бару иде. Хәлбуки, моңа ирешү өчен барлык көчен һәм тапкырлыгын җигәргә туры килде аңа. Җитмәсә, теге фаҗигадән соң Галимҗан нәкъ унбер көн өендә плеврит белән авырып ятты. Ул кул-аякларын гына өшетеп калмаган, бик каты салкын да тидергән иде.

Шулай да Хөсәен бирешмәде, җитәрлек ял итмәсә итмәде, тик газетаны вакытында әзерләп барды.

Инде «Урал»ның 18 нче саны версткада иде. Анда бөтен Россия иле өчен әһәмиятле мәсьәләләр белән бергә, Оренбур вакыйгалары һәм, хосусән, шәкертләр мәсьәләсе дә яктыртылган иде. Вәли мулла мәдрәсендә бер төркем шәкерт демонстратив рәвештә укуны ташлап чыгып китте. Аларга ярдәм оештыруны газета үз өстенә алган иде. Инде байтак кына шәһәр һәм авыллардан иганә акчасы килә башлады. Һәр көнне иртәнге якта идарәгә баш күтәргән шәкертләрнең вәкиле килеп җитә, хатлар белән таныша, акча булса, алып китә. Хөсәен хатлар актарып утырганда Уфадан килгән бер хатка аерата игътибар күрсәтеп, озаклап укып утырды.

— Безгә килеп йөрүче шәкертнең адашы яза, Уфадан, «Галия»дән, — диде ул көлемсерәп, каршында гранкалар укып утырган Басыйрга.

— Вәли мулла мәдрәсәсеннән килүчеме? — диде Басыйр. — Галимҗанмы?

— Әйе, аның адашы Галимҗан Ибраһимовтан хат. Безнең егетләргә иганә җыюлары турында яза. Газетага кертергә кирәк булыр.

Хөсәен ирексездән Уфада уздырылган көннәрен хәтерләде. Коралльы эшче отрядлары төзеде ул анда. Алар белән бергә наганнан, мылтыктан атарга өйрәнде. Заводларда, мастерскойларда агитатор, пропагандист булып җаны-тәне белән бирелеп эшләргә туры килде. Ә приказчиклар һәм шәкертләр арасында соң? Ул аз йөрдеменi? Биш бармак кебек яхшы белә ул Уфаны. Ә менә Галимҗан Ибраһимов белән, бу кыю һәм үзсүзле шәкерт белән ул соңгы тапкыр гүзәл Агыйдел буенда очрашты. Июль кичләренең берсе иде. Алар елга өстенә шәүләсен ташлаган шәфәкъ яктысында сөйләшеп йөрделәр. Галимҗан үзе белән тагы бер шәкерт дустын да ияртеп килгән иде.

— Шаһит Әхмәдиев, минем мәсләктәш, — дип таныштырды ул. Ә менә шуннан соң Галимҗанны төрмәгә утыртып куйганнарын ишетте Хөсәен. Димәк, хәзер азат иткәннәр, котылган егет. Күрәсең, мәдрәсәгә кире кайткан, әллә булмаса, алар белән бәйләнештә генә торамы?

Ишек ачылып китте. Идарәгә Хәдичә килеп керде. Аның йөзендәге борчуны күреп, Хөсәен ашыгып урыныннан купты.

— Я? — дип, сораулы караш белән текәлде ул. Хәдичә цензор янына чираттагы номер материалларына рөхсәт сорап киткән иде. Мөгаен, цензор бик каты бәйләнгәндер.

— Хөсәен, юлда Тимерша әфәндене очраттым. Шуңа күрә кире әйләнеп кайтырга мәҗбүр булдым.

— Хуш, — дип куйды Хөсәен, — артык булмый диме?

— Бүгеннән башлап мине нашир дип исәпләмәгез, ди. Ул озакламый идарәгә киләчәк.— Хәдичә гаҗиз булып Хөсәенгә текәлде: — Нишләрбез икән? Димәк, газета чыгуыннан тукталды дип уйларга каламы?

— Сабыр ит, ул кадәр төшенкелеккә бирелмик әле, Хәдичәкәй. Мин бит бу хәлнең буласын алдан ук сизенгән идем. Тимерша әфәнде күптән бит инде ризасызлык белдереп тора.

— Соң?

— Наширлыкка бер кеше алынырга уйлый.

Хәдичә ул кешене Уфадан ук белә иде. Ул соң дәрәҗәдә аптырап күзләрен зур иттереп ачты.

— Ничек инде аңа ышанырга мөмкин? — диде.— Тимерша әфәндегә уң ни дә сул ни. Ә моңа бит... ул бит идейный меньшевик.

— Беләм, Хәдичәкәй. Ләкин хәзергә башка бернинди дә чара күренми.

Хөсәен бер ноктага текәлеп уйланып торды.

— Әлбәттә, җиңел булмаячак. Әмма ничек тә газетаны саклап калырга кирәк. Ә син цензорга күптән җыенган идең ич, нишләп болай тоткарландың?

— Беләсеңме, Хөсәен, һич аягым тартмый. Син минем ул шакшы бабник белән җәфаланганлыкларымны беләсең! Сеңелкәй, дип, селәгәен агызып елышуы үзе ни тора. Гомеремдә бер күрмәс идем шуны!

Хөсәен хатынына карап куйды. Авырудан соң ул бераз сула төште. Шулай да аның матур ак йөзе, тулы матур иреннәре, нурлы коңгырт күзләре һәм буй-сыны азгын ирләрнең күзләрен яндырырлык әле. Хөсәен бер сүз дә әйтмәде, яңадан эшенә чумды.

— Мин киттем, алайса, — диде Хәдичә.

— Хәерле юл, Хәдичәкәй, — дип калды Хөсәен.

Бер сәгатьтән соң гадәтенчә ашыгып, каударланып, идарәгә Тимерша Соловьев килеп керде.

## 36

«Урал» тирәсендәге кара болытлар көннән-көн куера барды. «Урал»чылар һәм газетага теләктәшлек итүче укучылар, һәр ихтималга әзер булган хәлдә, тетрәнеп, вакыйганың югары ноктасын — дәһшәтле күк күкрәүләрне, охранканың яшенле кылыч селти башлавын көтте.

Хөсәен Гафурга март урталарында ук язган хатында әле күптән түгел генә өч тапкыр тентү булганлыгын, бер тапкыр Хәдичәнең охранкага чакырылуын язган иде. Бу хәлләрне Гафур күңеленә бик якын алып, дусты өчен хафаланып яшәде. Оренбурда күтәрелгән өермәнең шаукымы озак көттермичә, Казанга да килеп житте. Хәер, бу эшләрне кузгатучы Казан охранкасы үзе булмады микән әле? Кайчаннан бирле инде Галиәсгар Камалның «Мәгариф» кетепханәсен филерлар күздән ычкындырмый. Ничә кешене инде шул кибеттән «Урал» брошюрасын сатып алган өчен күзәтү астына алдылар. Бүген ул шулай, ә иртәгә исә «Урал»ны укыган өчен дә төрмәгә яба башлаячаклар. Гафур газетага ярдәм җиштыру турында озак баш ватты. Ләкин бераз материаль ярдәм күрсәтүдән башка, аның башкача эш-гамәл кылу мөмкинлеге юк иде. Ниһаять, ул әле, бәхеткә каршы, кулга алынмаган Миңнулла Вахитов-

ны күреп сөйләште. Миңнулла, чарасына кереп карарбыз, комитет члennарына җиткерермен, диде. Гафурдан берни дә яшерми иде бу революционер эшче, иркенләп Шәрифуллаларда сөйләшеп утырдылар. Тәрҗемә итү өчен Миңнулла Гафурга, Казан комитеты кушуы буенча, прокламация дә тапшырды.

— Ихтимал, безгә тагы бер тапкыр газета файдасына иганә җыеп карарга кирәктер,— диде Миңнулла сүз арасында тагы Оренбур хәлләрен хәтерләп. — Газетның акча ягы шәптән түгел дисең бит.

— Акча яклары әйбәт түгел инде, аны әйтәсе дә юк. Тик хәзер, уемча, ачыктан-ачык «Урал» өчен иганә җыю чоры узды инде. Без акчаны җыйсак, ниндидер башка юл белән генә булдырырбыз.

— Мәсәлән?

— Мәсәлән, спектакль куеп, акчалы спектакль...

Миңнулла хәйләкәр генә көлемсерәп, мыек чылгыйларын сыпырып куйды.

— Ярый бу, Гафур туган, тик егетләр табарбызмы соң театр уйнарга?

— Менә сөйләшергә кирәк. Изге эш башкарачаклар бит егетләр.

— Хәер, — дип куйды Миңнулла. — «Урал» өчен дисәк, бөтенләй сәләте булмаганы да сәхнәгә менеп әтәч булып кычкырыр.

Чыннан да, иртәгесен үк Миңнулла, егетләр белән сөйләшеп, һәвәскәр артистлар тапты, ә Гафур кулай бер пьеса хәстәрләп, режиссерлык эшенә үзе алынырга булды. Спектакль Алафузов эшчеләре клубында куелды. Ул егерме биш сум килер бирде. Гафур шул акчаны иртәгесен үк Хөсәеннәргә җибәрде.

Гафур дустының зур тырышлык һәм ихтыяр көче исәбенә генә «Урал»ны яшәтүен яхшы аңлый иде. Экспроприациянең провалга очравы да Хөсәеннең хатындагы читләтеп әйткәннәре аша мәгълүм булды. Хәлбуки, үзәк рус газеталарында, акча урланды, шик революционер подпольщикларга төшә диелсә дә, асылда, эшнең барып чыкмаганлыгы, «Урал»ның өлешсез калуы ачык иде.

Бу арада Гафур бик кәефсезләнеп йөрде. Карлыккан тавыш белән укучыларына дәрес бирде, кичләрен, температурасы күтәрелүенә карамастан, пьеса язуын дәвам иттерде.

Шундый кичләрнең берсендә, эшләп утырганда, аның янына сеңелесе Суфия керде. Кызның йөзенә ниндидер таркаулык билгеләре чыккан иде. Әллә елаган да иде инде ул бераз, чөнки күзләрендә тоныклык, ялкынсыну чагыла иде.

Гафур сеңелесен бик ярата иде. Аңа бер вакытта да каты кагылганы булмады, авыр елларда да, барлык семья мәшәкатьләрен берүзе тартып барганда да Гафур сеңелесен борчымады, аны укытып кеше итәргә тырышты.

— Берәр йомышың бармы, Суфия? — диде ул.

Суфия бермәл ничектер кыюсызланып торды, аннары, күрәсең, батырчылык итеп сорады:

— Хөсәен абый турысында бернәрсә дә әйтмисең син, абый. Әллә ул хәзер сиңа хат язмыймы?

Гафур көлемсерәп куйды.

— Нигә язмасын, язып тора. Хат саен сиңа атап сәлам җибәрә, Суфия.

— Ул сәлам тапшырылырга тиештер бит? — диде Суфия үпкәли төшеп. Гафур сеңелесенең бик күптәннән Хөсәенгә туганнарча әйбәт мөнәсәбәте барлыгын яхшы белә иде. Суфия Хөсәен абыйсы белән төрле темаларга, күбрәк әдәбият, сәнгать турында сөйләшеп утырырга, ә кайчагында бәхәсләшеп алгаларга да ярата. Ләкин бүген Гафурның күңеленә кинәт: «Ә бу дуслык кына булмаса?» дигән шик килде.

— Хөсәен абыеңның хатларында, Суфия, тагы башка бик күп мө-

һим мәсьәләләр турында язылган була, әнә шулар арасында ничектер сәлам тапшырулар онытылып кала торгандыр. Ләкин монда гаеп миндә, син мине кичерә күр инде.

— Сәламәтлеге ничек соң аның?

— Сәламәтлеге турында берни дә язмый. Нигә әле син аның сәламәтлеге белән кызыксынасы булдың?

— Болай гына, — диде Суфия кызарынып. Гафур аңа карап торды да:

— Шулай да аның сәламәтлеген бу тормыш шактый какшаткан. Узган җәй кайтканда зарлануын зарланмады, ләкин, күренүенчә, йөрәк тә, үпкә дә аның бирешә башлаган кебек.

— Абый, — диде Суфия кинәт кыюланып, — мин аны бу араларда нигәдер бик сагынам. Гел Хөсәен абый турында уйлап йөрим.

— Бу ни дигән сүз тагын, Суфия? Акылыңдамы син? Кешенең хатыны бар...

— Булса ни, мин бит берниндн дә зыян китерергә җыенмыйм аңа.

— Син Хөсәенне безгә килеп йөргән чакларында да ярата идең, әле дә оныта алмыйсың, шулаймы?

— Мин аны хәзер тагы да ныграк яратам, абый.

— Сиңа әле бик тырышып укырга кирәк, Суфия. Ә мәхәббәт үз җае белән бер килер. Үз насыйбыңны табарсың.

— Син дә авырыйсың, Хөсәен абый да. Мин сезне дәвалау өчен докторлыкка укыр идем.

— Авыр булса да, мөмкин эш ул. Гимназияңне әйбәт кенә бетер, сине мин Петербургка Бестужевкага укырга җибәрермен.

— Вәгъдәме?

— Егет сүзе бер булыр, Суфия.

Кыз өстәл читендәге икенче утыргычка күчте.

— Минем киңәшем шул, Суфия, син Хөсәен абыеңа салкынрак кан белән кара. Ул бик мәшгуль кеше. Син моны аңла.

— Мин барысын да аңлыйм, абый, — диде Суфия, — мин кечкенә бала түгел.

Кыз урыныннан торды да, кыяфәте белән үзенең мөстәкыйльлеген күрсәтергә теләгәндәй, горур рәвештә, ашыкмыйча гына чыгып китте. Гафур зур кара күзләрен тутырып хәйран булып карап калды. Мондый хикмәтләр күрсәткәне юк иде әле Суфияның!

Гафур яңадан пьесасына кереп чумды һәм андагы үзе тудырган дөнья белән мавыгып, барысын да онытты. Кичкырын гына аңа Фәрхетдиннең этап белән Казанга озатылуы, аның суды монда булырга тиешлелеге мәгълүм булды. Бу хәбәрне Гафурга Миңнулла Вахитов әйтте. Ул бер үтенеч тә тапшырды: әгәр мөмкин булса, үзе яки шик кузгатмаслык, ышанычлы башка берәү Фәрхетдин белән очрашсын иде, диде. Хәлне ачыкларга кирәк, бу минем генә үтенеч түгел, аңлыйсыңдыр, дип өстәде.

— Башка кешеләр эзләп йөрмим, үзем барам, — диде Гафур. — Ул бит минем якын таныш, авылдаш дип әйтерлек, үзем барам.

Ләкин Фәрхетдинне ул көнне Казанга китереп җиткермәгәннәр иде.

Фәрхетдин Казанга янә ике көннән соң гына килеп житте. Аны шундук Кремль төрмәсендәге политическийлар камерасына яптылар. Әле атнага якын аның белән берниндн дә очрашу рөхсәт ителмәде. Шулай итеп, ниһаять, Казанга кайтуына сигез көн узгач кына, Фәрхетдин белән күрешергә рөхсәт булды. Гафур, җомга көн булуыннан файдаланып, иртәнге сигездә үк Кремльгә таба юнәлде.

Ул тиешле рәсми кагыйдәләр үтәгәч һәм әле байтак кына вакыт көтеп йөргәч, тоткыннар белән күрешү бүлмәсенә әләкте. Бүлмә тимер рәшәткә белән икегә бүлеп алынган иде. Стена буена артсыз озын эскәмияләр куелган, тамакка сылана торган тузан һәм күгәрек исе та-

ралган. Озакламый килер, диделәр. Гафур бүлмәне күзеннән кичерергә дә өлгермәде, рәшәткәнең теге ягындагы тимер ишек йозаклары шалтырый башлады. Өрәк шикелле сузан, ябык тоткыннар күренде. Аеруча күзгә чалынганы шул булды: рәшәткәгә таба таркау бер караш белән текәлеп, йөзен көрән сакал-мыек баскан, ябык, ләкин шактый киң җилкәле бер кеше килә башлады. Аның өстендә ямаулы киндер күлмәк, кара чалбар, аякларында итек, ә башында шомарып, ялтырап беткән түбәтәй иде. Шул кешенең Фәрхетдин икәнлеген Гафур үзенә текәлгән коңгырт күзләрне күргәч кенә таныды. Фәрхетдин исә Гафурны караңгыда таныгач, җанланып китте, аның җөйле йөзенә елмаю билгеләре чыкты. Алар салкын тимер рәшәткәгә тотынып, мөмкин кадәр якынрак торган хәлдә, икесе ике яктан сүз башладылар.

— Фәрхетди-ин, нихәл туган, исәнме?

— И, минем монда икәнлекне белеп килүеңә бик рәхмәт инде, Гафур абый.

— Ничегрәк соң, юлда артык азап чикмәдеңме?

Фәрхетдин тирә-юненә карангалап алды:

— Гафур абый, зинһар дип әйтәм, Хөсәен абыйга җиткерегез, мин үземне тиешенчә тоттым. Кыстылар, үтерә яздылар, тик бирешмәдем, бәлкем атарлар да, тик берегезне дә сатмам.

— Тынычрак, тынычрак, әкренрәк сөйлә,— диде Гафур куркынып,— мондый урында стеналарның да колагы була.

— Әйдә, чәнчелеп китсен барысы да.

— Алай ярамый, онытма, туган, син ялгыз түгел, сине дусларың беркайчан да ялгыз калдырмас. Исеңдә тот, сиңа адвокат ялларбыз. Әйбәт адвокат. Ул камераңа килер, тикшерүчегә сөйләгәннәреңне кабатла. Передача китердем, тапшырырлар, монда тикшергәч кенә бирәләр икән. Инде тагы нинди йомышың бар, әйт?

Гафур сәгатенә карап алды, вакыт бик чикле иде.

— Улым, әнием турында бик кайгырам. Хәдичәбикә аша бер-бер ярдәм күрсәтә алмассыз микән шуларга?

— Хәдичәбикә Әлмәттән киткән, тик кайгырма, булдыра алганны эшләрбез, Фәрхетдин.

Хәдичәбикәнең Әлмәттән китү хәбәре Фәрхетдинне кайгыга салды.

— Борчылма,— диде Гафур.— Әйттем бит, ярдәм итәрбез.

Санаулы минутлар тиз үтә. Төрмә кешесе, бүлмәгә кереп, күрешү вакыты беткәнлеген белдерде һәм шундук тәкәллефсез рәвештә иң элек Фәрхетдинне алып китте. Гафурның колагында бары егетнең богау чыңы гына яңгырап калды.

— Хуш, Фәрхетдин! — дип кычкырды Гафур. Ләкин егет дәшмәде, күрәсең, аның күңеле нечкәреп киткән, җавап бирерлек көче калмаган иде.

Гафурның бөтен барлыгы тетрәнгән иде. Ул, чыккач, нигәдер Воскресенский урамы буйлап бара бирде. Ниһаять, университетның ак колонналары каршына килеп чыккач, аптырап туктап калды. Юк ла, аңа бөтенләй башка якка китәргә кирәк иде бит!

## 37

— Әгәр дә мин наширлык вазифасын үз өстемә алганмын икән, сез инде, Хөсәен әфәнде, аңлый торгансыздыр: мин мондый эшкә билгеле бер максатларны күздә тотып алындым.

— Бераз аңлыйм булса кирәк,— диде Хөсәен,— сез безнең газета аша үзегезнең мәсләгегезне пропагандаламакчы буласыз.

— Алай дип әйтү минем тарафтан әдәпсезлек булыр иде, Хөсәен әфәнде, мин бит мөхәррир түгел. Ләкин шулай да...— Ул алтын балдаклы имән бармагын бермәл күтәреп торды да елмаеп куйды.

Әдәп саклап Хөсәен дә елмайды.

— Әйдәгез, Гариф әфәнде, шулай да ишарә белән ым кагып чикләнмик. Миңа шәрехләп бирегез,— диде.

— Әгәр дә мәгәр сез газетагызда минем карашларыма турыдан-туры, безапелляционно каршы чыгасыз икән, мин бәхәскә керәчәкмен.

Хөсәен папирос алып кабызды. Аны ашыкмыйча гына бер суырды да түшәмгә таба өреп торды.

— Димәк, сез минем хөрлегемне чиклисез булып чыга?

Булачак нашир кулларын аерып ни әйтергә теләгәнен тагы елмаюы белән генә аңлатты.

— Яхшы,— диде катгый бер фикергә килеп Хөсәен,— мин сезнең принципиаль мәсьәләләрдәге карашыгызны рәнҗетмәм. Мин аларның нидән гыйбарәт икәнлеген беләм.

Шуның белән джентельменнарча килешү төгәлләнде. Монысы исә рәсми договорларга караганда да, Хөсәен фикеренчә, мөһимрәк иде. Газета шул ук Кәримовлар типографиясендә басылачак. Монысы турында инде яңа нашир үзе сөйләшүләр, килешүләр алып барды.

Бик аз гына вакытка тирә-юньдә тынычлык тугандай булды. Ләкин Хөсәен бер генә минутка да үзенең саклыгын югалтмады. Бүген булмаса — иртәгә күк күкрәп давыл кубу ихтималы мөмкин иде. Бу тынычлыкны Хөсәен шомланып каршы алды. Бу әлеге зилзилә алдыннан була торган тынлык кебек иде. Цензорның бәйләнүләре чигеннән ашты. Хәзер инде аны ресторанда сыйлау белән генә йомшартып булмый, ул майлы калҗаның үтә саллысын өмет итә иде.

Газета өстеннән төрле шикаять-донослар, хәтта уйдырмалар бер-бер артлы явып торды. Шәһәрнең Вәли хәзрәт житәкчелегендәге карагруһчылары төрле ысуллар белән Хөсәенне һәм Хәдичәне кимсетергә теләделәр. Бердәнбер шатлык: ул гади кешеләрнең елмаеп сәламләве, булдыра алганча ярдәм итәргә атлыгып торулары иде хәзер. Чиксез киң Россиянең төрле почмакларыннан күңелләрне шатлык, өмет белән тутыра торган җылы хатлар соңгы вакытларны аерата күп килә башлады. Шулар күңелне күтәрә иде.

Галимҗан эшли башлады. Ләкин каты авырудан соң ул элеккечә бирелеп җигелә алмый, еш-еш аңын югалтып, берәр сәгать диванда ятарга мәҗбүр. Хәдичә дә бик нык үзгәрде. Кем белә, бәлки ул мине бөтенләй яратмый ук башлагандыр, дигән уй хәзер Хөсәеннең башына еш кына кергәли иде.

Мартның соңгы сишәмбе көнендә Хәдичәне тагы жандарм управлениесенә чакырттылар.

— Бусы, шәт, иншалла, соңгы тапкыр чакыралардыр инде,— диде Хәдичә ачы елмаеп.

— Бик алай тиз генә бирешмик әле, Хәдичәкәй,— диде Хөсәен.

— Ни файда соң, Хөсәен, нигезсез өметләр белән яшәүдән?!

— Ашыкма, башта барыйк әле. Анда күз күрер. Мин дә синең белән барам...

Алар киенеп, әгәр кирәк була калса дип, тиешле газета саннарын да үзләре белән алып, урамга чыктылар. Күп тә узмады, извозчик аларны шәһәрнең котын алып торган таш бинага китереп җиткерде. Урамда яз рухы сизелә, ул күңелләрне җилкендерә, тәнгә рәхәтлек, өмет шатлыгы иңдерә, тәнне оета иде. Әле көн моңарчы буранлап торган иде, менә бүген кинәт җепшетеп җибәрде.

Извозчиктан төшкәч тә Хөсәен Хәдичәне култыклап алды. Читтән караганда бу пардан да бәхетлерәк, тынычрак һәм гамьсезрәк кешеләр юктыр дөньяда диярго булыр иде. Хәлбуки, Хөсәеннең башында хәзер нинди генә юрау-гөманнар тумый, нинди генә җаваплар әзерләнми иде!

Матбугат белән шөгыльләнүче жандарм офицеры, пенсне күзлекле, түгәрәк кара сакаллы, артка таралган чәчле, тулы гәүдәле кеше бу юлы уралчыларны артык нәзакәтлелек күрсәтеп каршыламады. Хәтта ул башын да сизелер-сизелмәс кенә иеп алды. Үзенең мөнәсәбәтен сиздерергә теләгәндәй, кунакларны шактый вакыт алдында аягүрә бастырып торганнан соң гына «утырыгыз» диде. Башта Хәдичә үзенең асыл күлмәк итәкләрен кыштырдатып кәнәфигә чүкте, аннан, ул кадәр нәзакәтлелек сакламыйча, Хөсәен килеп утырды.

Чинлы кеше Хәдичәгә карап сүз башлады:

— Мадам Ямашева, берничә тапкыр кисәтүемә карамастан, сезнең газетагызда тыелган материаллар басыла бара. Шәһәр җәмәгатьчелеге сезнең бу үзсүзлелегегез өчен бик борчуда. Болай артык дәвам иттерә алмыйбыз, мадам.

— Гафу итегез, сез нинди материалларны күздә тотып әйтәсез?

— Газетагызның бөтен эше, тенденциясе правительствога каршы юнәлгән. Әле генә шәһәребезнең могтәбәр кешеләре сезнең газета өстеннән шикаять язып китерделәр. Газетага кушып биргән брошюраларыгыз да аларны соң дәрәҗәдә тетрәткән. Язуларына караганда, сез анда турыдан-туры безнең хәзерге стройга йодрык яныйсыз, мадам.

Хәдичә, «ни әйтәбез» дигәндәй, Хөсәенгә карап алды. Хөсәен тамак кырды да тыныч кына сүз башлады:

— Без, әлбәттә, шәһәрнең могтәбәр әһелләре белән исәпләшми кала алмыйбыз, ваше благородие. Ләкин хәлне төзәтү өчен безгә ул әфәнделәрнең нинди мәсьәләләр хакында борчылуын белергә кирәк иде. Бәлки сез ул шикаятьнамәне укып чыгарга рөхсәт итәрсез?

— Сез инде ничә тапкыр хәлне төзәтергә вәгъдә бирдегез,— диде офицер ачуланып. Ул кискен хәрәкәт белән Хәдичә алдына герблы кәгазьгә язылган дүрт битлек язу ташлады. Аның өч битендә текст, дүртенчесенә имзалар теркәлгән иде. Хөсәен дә, Хәдичә дә, иелеп, тиз генә күз йөгертеп чыктылар. Хөсәенне күбрәк бу «могтәбәр кешеләр»нең кем булуы кызыксындыра иде. Руслар һәм татарлар. Монархистлар, итчеләр, тиречеләр, сәүдәгәр һәм карагруһ дин әһелләре. «Әнә ул,— дип уйлап куйды Хөсәен, Вәли хәзрәт имзасын күргәч,— түзәрлеге калмаган. Соңгы санда «Урал» тагы аның «Дин вә мәгыйшәт»е турында бер материал биргән иде шул. Һич шик юк, шул Вәли мулла оештырган бу эшне. Инде әһеле исламга вәгазьләр аша гына мөрәҗәгать итеп берни дә майтара алмагач, үзенең «кяфер» мәсләктәшләренә сыенган».

Хөсәен ачы рәнҗү аша елмаеп хатынына карап алды.

— Бары да аңлашыла,— дип куйды ул.

— Без хәлне төзәтү өчен һәм шикаятьнамә язучыларны канәгатьләндерү өчен барысын да эшләрбез, ваше благородие,— диде Хәдичә.— Мин үземнең хезмәткәрләремә әйтермен, артык мондый башбаштаклыкларга юл куелмас!

Ләкин полковникның сөмсере коелган, аның Хәдичәгә мыскал кадәр дә ышанмавы йөзендә ярылып ята иде.

Ул корсагын киереп урыныннан торды.

— Соңгы кисәтү шул. Артык бернинди дә сүз булмаячак. Әгәр киләсе номерда ук кискен үзгәреш ясалмаса, алдан бернинди хәбәрсез газетагызны тыячакбыз.

Хәдичә нидер әйтмәкче иде, офицер коры гына:

— Аудиенция шуның белән тәмам, мадам Ямашева,— диде.

Бүген Оренбурда беренче тапкыр татарча театр куела. Ильяс Кудашев белән Сакаев куя. Ләкин кәеф һич театр бәйрәменә лаек түгел иде. Урамга чыгып извозчикка утыргач, Хөсәен үзенең шул хәләтен искәреп куйды.

Театрдан төнге уникедә кайттылар. Апрель үзенекен итә, төн уртасы булуына карамастан, өй кыекларыннан шып-шып тамчылар тама. Күңел җилкенә, әллә кайларга, сихри гүзәллекләр белән өртелгән, бәхет-сәгадәтләр вәгъдә итә торган урыннарга чакыра. Күрәсең, Хәдичә күңелендә дә шундый ук кичерешләр кайный иде. Ләкин ул бу кичерешләрне үзенчә шәрехләде.

— Бер уйласаң гаҗәп инде,— диде.— Адәм баласы газапны гел үзе эзләп йөри. Безнең иң яшь, таза чагыбыз хәзер. Безгә дөньяның рәхәтен татып кына яшисе дә бит. Юк, ярамый! Чит җирләрдә, җиде ят арасында матди һәм мәгънәви азаплар кичереп яшәргә кирәк!

Хөсәен күзләрен тутырып Хәдичәгә карады.

— Бу нинди обыватель фәлсәфәсе тагы? Мин сине аңламыйм. Ни өчендер син мондый, минем өчен ямьсез ятгырый торган сүзләрне еш ычкындыра башладың әле. Нигә син үзеңне бәхетсез кеше дип саныйсың?

— Минем кешечә яшисем килә, Хөсәен. Гомер бер генә... Күрәсең, мин арыдым, алҗыдым, ахры. Өзлексез йөрәгемне телгәләп торган җәфалар, һәр даим курку, дәһшәт астында яшәү...

— Син арымадың, Хәдичә. Син көчле кеше һәм теләсәң без кичергән авырлыкларны җиңә дә аласың.— Хөсәен хатынының йөзенә кискен бер караш ташлады.— Мин шуны сизенәм: син эзләнү газаплары кичерәсең. Минем юл сине канәгатьләндерми, син ниндидер үзеңә башка кыйбла табарга омтыласың.

— Әйе, син бер нәрсәне тойгансың. Ул да булса — мин синең барлык гамәлеңне дә хуплый алмыйм, Хөсәен.

— Ничә елдан бирле инде мин сиңа аңлатырга тырышам... Ахры, тиешенчә аңлата белмимдер, булдыра алмыйдыр. Укымаган эшчегә ул хакыйкатьләрне аңлату ансатрак, күрәсең.

— Бәлки шулайдыр,— диде Хәдичә.— Әйдә шул җирдә сүзне туктатып торыйк.

Ул йөгереп читкә китте дә, бергә яши башлаган көннәрендәге кебек, шаярып Хөсәенгә җепшек кар йомарлап ыргытты. Хөсәен башта сәерсенеп карап торды. Аннары кыр кәҗәседәй җитез чапкан Хәдичә артыннан йөгерде.

Төн узып, яңа эш көне тугач, яңа борчулар, яңа мәшәкатьләр килде. Хәзер бик сак эш итәргә кирәк, күп нәрсәне эзоп телендә әйтергә, киная, ымлау белән генә тирән мәгънәне аңлатып, зирәк укучыга исәп тотып язарга туры килә иде. Хөсәен матбагадагы барлык гранкаларны җентекләп тагы бер тапкыр карап чыкты. Кайбер кыйммәтле материалны шомартып төссезләндереп җибәрү бик кызганыч булса да, башка чара юк иде.

Кичкырын идарәгә Шакир Мөхәммәдов килеп чыкты. Ул шулай еш-еш килгәләп Хөсәен белән Дума яңалыклары, сәясәт, халыкара хәлләр турында сөйләшеп утыра, теге яки бу мәсьәләгә карата Хөсәеннең карашы, фикере белән кызыксына һәм, әлбәттә, берәр кызык мәзәк сөйләми китми иде.

Бу юлы, күрәсең, хәлне аңлады, озаклап утырырга килмәгәнлеген башта ук сиздереп:

— Миңа барысы да мәгълүм, әфәндем, ходай күркәм сабырлыклар бирсен,— диде.

Хөсәен, бер сүз дә дәшмәстән, эшеннән аерылып, аңа карап кына куйды.

— Бүген булмаса иртәгә мине дә шул ук язмыш көтә,— диде Шакир, үзе чыгара торган «Карчыга» журналын күздә тотып.— Ләкин,

дөресен әйтергә кирәк, синең хезмәтең безнекенә караганда саллырак, Хөсәен. Бу дөреслекне икърар итәрлек көчем бар.

Хөсәен әрнеп елмайды:

— Тәгызия уку да [1] башландымыни шулай, Шакир абый?

— Юк, алай түгел, күңелеңә авыр алма. Без бит синең белән реалистлар...

— Якынлашып килгән афәтне күрәм, Шакир абый, тик кул кушырып утырмам, үзең беләсең, андый токымнан түгел мин.

Хөсәен шулай диде, ләкин алда әле ярылып яткан ачык гамәл-юл күренми иде.

Оренбур группасында хәлне яхшы беләләр. Ул, әлбәттә, РСДРПның Урал комитетына да билгеле, Үзәк Комитет та бу турыда Саммер аша хәбәрдар. Соңгы көннәрдә эсерлар шәһәрдә ахмак террор актлары ясап, жандармерия белән полицияне аерата сагайттылар. Алар хәзер шикле кешеләрне бер генә минутка да күздән ычкындырмыйлар. Галимҗан, мәсәлән, хәзер бөтенләй идарәгә килә алмас булды. Ул газета эшен бары өендә генә, анда да әле «мәкруһ» саналмастаен гына башкара. Әйе, муенга салынган элмәк көннән-көн катырак кысыла. Мондый чакны нинди дер чара эзләп тагы бер тапкыр иптәшләр белән киңәшү зарури бер эш.

Хөсәен, эшне озынга сузмастан, бу турыда Леонтьев белән сөйләште, ә өч көннән соң группа утырышында Хөсәен мәсьәләнең торышын, газетаның гомере санаулы икәнлеген, эшне дәвам иттерү өчен ниндидер чаралар күрелергә тиешлелеген сөйләде. Әйе, реакция золмәте Оренбурга да килеп җитте, ул үзенең агулы хәнҗәрен революция тәненә авырттырып кадый башлады. Группа әгъзалары хәлне җиңеләйтерлек бер генә киңәш тә бирә алмадылар. Барысы да сынап карауга кайтып кала, җитмәсә әле, арада хәзергәчә тотылмаган провокатор да бар иде.

Хәер, ул тиздән фаш ителде. Ул кеше әле күптән түгел экспроприация оештырырга алынган, бу авантюрасы аркасында берничә революционерның һәм Фәрхетдиннең башын ашаган Воинов булып чыкты.

Егерме җиденче апрельгә каршы төнне идарәдә һәм Хөсәеннәр квартирасында тагы тентү ясадылар. Газетаның утыз беренче саны әле яңа басылып кына чыккан иде. Аны подписчикларга таратырга ярым-ярты гына өлгерделәр. Нәкъ шул вакытта рәсми рәвештә политик тотнаксызлыгы һәм империянең абруена хилаф эшләрне өзлексез башкарганы өчен моннан соң «Урал» газетасының тыелганлыгын белдергән кәгазь алынды. «Урал» газетасы тагы даими рәвештә хөкүмәткә каршы котки таратуда, социал-демократик идеяләрне пропагандалауда гаепләнгән иде.

Хөсәен мондый хәбәрне көтеп йөри иде инде. Шуңа күрә ул алдан ук хәстәрсез утырмады. Полиция ни өйдә, ни идарәдә бәйләнерлек бернәрсә дә таба алмыйча китеп барды. Ләкин, ни әйтсәң дә, охранка төп максатына ирешкән иде инде. Ул газетаны үтереп китте.

Якты, аяз апрель көннәренең берсе иде... Тирә-юньгә дала якларына хас дуамаллык белән яз тантанасы килде. Җаек һәм Сакмар елгалары, ташудан соң, әле дә ярларына кире кайтмаган. Агачлыкларда кошлар сайравы ишетелә. Җаек аръягында, шәһәр халкы сөеп ялга чыга торган урманлыкта, хәзер инде агачлар бөреләнде. Дала яктан, яшеллек исе аңкытып, җылы йомшак җилләр искәли. Мондый вакытта йөрәк парәседәй газиз нәрсәсен югалткан Хөсәенгә аерата авыр иде. Ләкин ул тыштан берни дә сиздермәде, тыныч булырга тырышты. Группа Май бәйрәмен уздырырга әзерләнә башлады. Хөсәен башы-аягы белән

[1] Тәгызия уку — кайгы уртаклашу.

шул эшкә чумды. Ләкин вакыйгалар тагы да катлауланып, һич көтелмәгән бер юнәлеш алды. Язгы җылы төннәрнең берсендә эсерлар Оренбур прокурорының ярдәмчесен револьвердан атып үтерделәр. Бу исә жандармериягә барлык шик астындагы кешеләрне шәһәрдән сөрергә әйбәт сылтау булды. Шәһәр тузгытылган корт иләнә әйләнде. Хөсәеннәргә полициянең шәһәрдән егерме дүрт сәгать эчендә чыгып китәргә дигән боерыгы тапшырылды.

Әле сәгать сигез генә иде. Хөсәен иртәнге чәен эчәргә утыргач булды бу хәл. Полициянең кече чины биреп калдырган язуны кулына алган килеш, Хөсәен кухня якта бәрәңге кыздырып маташкан Хәдичә янына чыкты. Бер сүз дә әйтмәстән язуны аңа сузды.

Ул Хәдичәгә: «Әйдә, уйлашыйк», димәкче иде. Сүз әйтүне кирәк санамады.

Барысы да мәгълүм ич инде. Хөсәен яңадан төрле шәһәрләр гизеп газета чыгару өчен мөмкинлек эзләячәк, ә Хәдичә исә тынычлыкта калырга тели. Шулай да Хөсәен, хатыны табынга утыргач:

— Башта хәл итәсе нәрсә, Хәдичә, үзең дә төшенә торгансыңдыр...— диде. Ул, минем белән китәсеңме, димәкче иде, ләкин тагы тукталып калды. Аңлашыла бит, болай да аңлашыла.— Хәер,— диде ул җиңелчә көлемсерәп.— Сиңа хәзергә, хәл ачыкланганчыга кадәр, Уфада, я Казанда торырга туры килер.

— Ә син?

— Мин әле тиз генә бирелергә исәп тотмыйм. Көрәшәм әле мин, Хәдичәкәй.

— Барысы да ачык бит инде, Хөсәен. Нигә кирәк ул күрәләтә утка ташлану? — диде Хәдичә ялварып. Ул, беразга тын калып, чәен капты да өстәп куйды:— Безгә шөкерана кылырга кирәк.

— Ни өчен?

— Моннан да начаррак хәлгә калмавыбыз өчен. Әллә син аларның кулыннан башкасы килмәс дисеңме?

Хөсәен бер сүз дә дәшмәде. Бары чәй эчеп табыннан кузгалганда гына әйтте:

— Әйберләрне аерым чемоданнарга салырбыз.

## 39

Габдулла Тукаев Миңлебай Хәйруллинны күзәтеп торды. Карый, күтәренке рух белән авыз эченнән генә нинди дер көй шыңшып, саквояжына әйберләрен тутыра иде. Ул вак-төяк язу әсбапларын бәләкәй генә янчыкка салып, аның авызын бәйләде дә тагы берәр нәрсә калмый микән дип уйланып торды.

— Әнә мисвәгең[1] кала, тәрәзә төбендә. Мәдрәсә истәлеге итеп саклarsың,— диде Тукай.

Карый көлеп җибәрде.

— Анысын инде сиңа калдырам, Апуш.

— Син миңа, менля кем, иске мисвәгеңне калдырганчы, хәтфә кәләпүшеңне ядкарь итеп бир,— диде Тукай.

Чыннан да, Хәйруллинның башында әле генә сатып алынган өр-яңа бәрхет кәләпүш иде. Ул аны Камил Мотыйгый китаплары белән уңышлы гына сәүдә иткән табышка алды һәм менә бу көнгәчә кими саклап тотты. Габдулла исә ул чакны, диндар фанатикларга юри үч итеп, елтыр козыреклы картуз сатып алган иде. Шуны күздә тотып:

— Сиңа картуз килешә төшә,— диде Миңлебай.

— Мин аны синнән истәлек итеп, ядкарь буларак сорыйм. Сагын-

[1] Мисвәг — теш чистарткыч

ганда бер түбәтәеңә карар идем, ичмаса. Юкса, нәрсә ул мисвәк, синең кыек-мыек тешләреңне күз алдына бастыру өченме?

Ике дус бер-берсенә гадәттәгечә чәнечкеле сүзләр әйткәләшеп, никадәр батыр кылансалар да, чынлыкта аларның икесенә дә аерылышу минутлары бик ямансу иде. Аерата Тукайга авыр. Җыештырылмаган, шыксыз, ләхеттәй тар кунакханә бүлмәсендә ул иң якын дустыннан аерылып япа-ялгыз кала бит.

— Син бәхетле, малай,— дип куйды Габдулла. Хәйруллин Тукайның күзләре дымланып китүен абайлап калды. Хәлен җиңеләйтү өчен сүзне уенга борырга ашыкты.

— Бәхетле,— диде көлеп,— кая барып төшәсемне белмәгән сурәттә упкынга сикерүем белән бәхетле.

— Җәһәннәм базына сикерергә дә разый мин эшнең уртасында булу өчен. Син дә, менля кем, яшермә, син дә разый, шуңа күрә син, әфәндем, бик бәхетле дә.

Тукай урыныннан торды да тиз генә киенеп алды. Бу вакытны карый китаплар карап, кирәклеләрен сайлау белән мәшгуль иде. Тукай аның янына барды. Әле генә алган бер китапка күз ташлады.

— Бу бәрәңге кәлҗемәсен карап та торма. Шуны йөк итеп мең чакрымлык юлга алып китәмме соң!

— Көфер сүз сөйләмә. Моның кирәге чыгуы бар. Дөнья ул!

— Яңа кәсеп әҗерсез булса, искесенә тотынырга туры килер дисеңмени? Алай булмый, дускаем. Атып бәр бу дини китабыңны һәм артык бер кайчан да кулыңа алма. Менә шунда чын артист булырсың!

Карый дустына карап торды да:

— Иа хода, ярлыка үзеңнең гөнаһлы бәндәләреңне,— дип, китапны ишеккә таба атып бәрде.

— Ә шулай да кәләм-шәрифне[1] алам, агайне,— диде ул, чираттагы китапны кулына тоткач.

— Ансын инде кара, тик алмасаң яхшырак булыр,— диде Тукай,— чөнки ул синең корьәнхафиз икәнлегеңне исенә төшереп һәр вакыт йөдәтер.

— Йөдәтмәс әле,— диде Хәйруллин,— анысын алам.

Тукай көлеп кесәсеннән портмонетын чыгарды.

— Әфәндем, синең алда зур расходлар тора. Шуңа күрә, икътисад ноктаи назарыннан[2] чыгып, бүген мин үз акчама пәрәмәч китертәм.

Карый дустының фәкыйрьләгән яхшы белә иде. Ул гаҗәпсенеп:

— Мондый артык тәкый гаҗәп хәлләр улмас,— дип көйләп куйды.

— Менә ул акча,— диде Тукай күз кысып,— хәзер мин аска төшеп менәм, безгә Камил әфәнде килгәнче сөйләшеп тә, чәйләп тә өлгерергә кирәк.

— Шунда да, Апуш, бик кызык, синдә акча торуы кызык,— диде карый.

— Саклап тоттым, валлаһи. Менә шушы ямансу аерылышу минутлары өчен сакладым,— диде Тукай. Ул башына картузын киеп, ишеккә таба юнәлде. Ләкин аның Камил әфәнде килгәнче чәйләп алу теләге гамәлгә ашмады. Ул пәрәмәчле чәйгә заказ биреп кире кергәндә, бүлмәдә Камил Мотыйгый утыра, хәтта ялгызы гына да түгел, үзе белән тагы кемнедер ияртеп кергән иде. Тукай, гадәтенчә, чәнечкеле шук сүз әйтү өчен авызын ачты, мәгәр тукталып калды, чөнки Камил белән килгән кешене әле генә таныды. Ишеккә арты белән, Камил янында Хөсәен Ямашев утыра иде.

— Иа хода! — диде Тукай.— Хуш килдегез, мәрхаба! Мөхәррир әфәнде.

[1] Кәләм-шәриф — корьән.
[2] Ноктаи назарыннан — экономик караштан.

Хөсәен Тукайның ябык, йомшак буынлы кулын кысты, моңсу гына көлемсерәп:

— Мөхәррир дип атамасагыз, дөрескә туры килер, Габдулла,— диде.

— Ничек алай? — диде Тукай житдиләнеп. Аңларга теләгәндәй Камилгә карап алды.

— Минем язмышны Хөсәен әфәнде дә башыннан кичергән,— диде Камил Мотыйгый.— Тик ул намуссыз Мортазалар белән юанмаган.

— Нинди Мортаза? — дип кызыксынды Хөсәен сүз арасында.

Камил өметсез рәвештә кул селтәде:

— Минем матбаганы сатып алган купец, Гобәйдуллин. Наширлыкны дәвам иттерәм дип вәгъдә бирде дә алдады. Аның турында Тукай шигырь язарга җыена әле.

Тукай сүзне раслап башын иде.

— Ләкин сез, Хөсәен әфәнде, барыбер мөхәррир,— диде ул.— Чын житлеккән, каһарман мөхәррир!

— Рәхмәт,— диде Хөсәен һәм булып узган вакыйгаларны кыскача сөйләп бирде.

— Бәс, шулай булгач, нишләргә кала? — диде ул Тукайга карап.— Шулай, сез хаклы, ялгышканбыз дияргәме? Әйтегез!

— Юктыр, иншалла,— диде Тукай,— мондый эш сезнең табигатегезгә туры килми.

— Шуңа күрә мин, дуслар, тагы бер талпынып карарга булдым. Бәлки Уральскида берәр имканият табармын дигән идем, тик монда да...

— Юк, монда да шул ук реакция зынҗырлары бик каты чылтырый,— диде Камил.

Хөсәеннең Уральскига килүенә ике көн узган икән инде. Ул биредәге ышанычлы кешеләр белән сөйләшкән, барысы турында да уйлашкан. Ләкин, газетаны аякка бастыру өчен әлегә тернәкләнерлек мөмкинлек таба алмаган.

Хәзер һәркайда жандармерия революциягә каршы явыз рәвештә күтәрелгән иде. Әле Оренбурдан чыгып китәсе көнне генә Хөсәен төрле яклардан хатлар алды. Гафурга газетаның тыелуы мәгълүм булган икән. Ул Хөсәенне тынычландырырга тырыша, өметне өзмәскә куша. Ләкин үзенең артык борчылуы ярылып ята иде. Гафур тагы Фәрхетдин турында язган. Аңа әле генә суд булган. Фәрхетдинне патшага каршы пропаганда алып баруда гаепләп, Казандагы бишенче ел вакыйгаларын кушып, сөргенгә җибәргәннәр. Гафур үзенең хатында Суфия турында да язган. Ул сеңелесенең Хөсәен өчен артык хафада яшәвен дусларча җиңелчә шаяру белән әйткән. Бу юлларны укыганда Хөсәен ирексездән елмая төшеп Суфияны күз алдына китерде. Җыйнак, пакь, оялчан гимназистка. Хөсәен аңың үзен яратканлыгын белә. Гафурларда булган саен ул шушы кызның астыртын гына яратып, аһ итеп каравын тоймый идемени!? Кыз Хөсәенне күрү белән комачтай кызара һәм телдән кала. Хөсәен барысын да белә. Ләкин боларны балалык чорының бер үзенчәлекле, куанычлы саташуы, сукыр мәхәббәт чире дип карый иде.

Әле «Казан» кунакханәсендә ул шуларны исенә төшергәләп сөйләшеп утырды.

— Сез кая урнаштыгыз, Хөсәен әфәнде? — диде Тукай.

— Ул минем кунагым,— диде Камил тиз генә,— бүген ул мотлакан миндә куначак.

— Бар бит мәрхәмәтсез кешеләр,— дип куйды Тукай.— Әгәр сез, Камил әфәнде, Каһирә университетында тиешле тәрбия алган кеше булсагыз, ул кунакны без фәкыйрегезгә бүләк итәр идегез.— Ул карыйга рәнжүле күз карашы ташлады.— Менә бу җүнсез бүген мине таш-

лап китә. Миңа бик күңелсез булачак. Мин шушы ялангач диварлар арасында япа-ялгыз калам.

— Кая китә? — дип сорады Хөсәен. Аңа Миңлебайның поезд белән Саратовка, аннан Казан аша Мәкәрҗәгә сәфәр китәчәген әйттеләр.

Хөсәен, әлбәттә, мондый вакытны бу кызу канлы, хискә бирелүчән шагыйрь дусты янында төнен уздырырга әзер иде. Ләкин ул Камилгә сүз биреп өлгергән иде инде. Шуңа күрә каршы әйтә алмады. Ярдәмгә Хәйруллин килде.

— Мин Габдулланың табигатен бик яхшы беләм. Безнең арада дуслык моннан күп еллар элек урнашты. Хакыйкатән аңа бик-бик авыр булачак. Аерата беренче көнен ул авыр кичерәчәк. Шуңа күрә мин дә, Камил әфәнде, сезнең кунакны Тукаев хөкеменә бирүегезне үтенәм.

Гадәттәгечә, бик фырт киемнән, киң түшен киерә төшеп утырган Камил гамьсез селтәнеп муенындагы ефәк бантын рәтләп куйды да:

— Кунак әфәнде үзе ни әйтер бит әле? — диде.

— Изге эш башкарырга форсат чыккан икән, мин андый мөмкинлектән баш тарта алмыйм инде,— диде Хөсәен, күңелле шаярту тоны белән.

— Ай, афәрин, мең яшәгез! — диде Тукай.

Бер тәлинкә пәрәмәч һәм кайнап торган бәләкәй самавар китерделәр. Сүз хәзер озакламый юлга чыгарга тиешле Хәйруллинга юнәлде. Чәй эчелгәч, барысы да кузгалып аякка бастылар. Тукай белән Хәйруллин вокзалга җыена башлады. Извозчик килеп җитәргә тиеш иде инде. Камил Мотыйгый үзенең тынычлыгын алган финанс мәсьәләләре буенча кредиторларына ашыкты. Ә Хөсәен, Миңлебайны озата алмавы өчен гафу үтенеп һәм Тукайга бик соңгармыйча кайтачагын әйтеп, казакъ дусты Әбелмамбетовка китте.

...Хөсәен Уральск урамнарын гизеп, шактый кеше күреп, яңадан «Казан» кунакханәсенә кайтканда, Тукай нидер язып утыра иде. Хөсәен бүлмәгә керү белән, ул шатланып урыныннан торды, таш чәйнеккә сузылды.

— Чәйләп алабызмы, Хөсәен әфәнде?

— Була ул,— диде Хөсәен, пинжәген чөйгә элеп. Тукай шул кадәр тәкәллефсез һәм риясыз иде ки, аның янында һәр кем, теләмәсә дә, бары үзе булып кына кала иде. Хөсәен дә, әле бары икенче тапкыр гына монда килүенә карамастан, үзен иркен һәм рәхәт сизде.

Йокы өчен алар икесе дә артык исләре китми торган кеше булып чыктылар. Чәй янында башланган әңгәмә эле ярты төннән соң да бетәр кебек түгел иде. Ниһаять, алар караватларга сузылып яттылар. Ләкин берсенең дә йокларга исәбе юк иде.

— Сез Казан хәлләрен дә, Дума хәлләрен генә сөйләдегез, Хөсәен. Ә үзегезнең эш монда ничегрәк тора соң? — диде Тукай.

— Әле иртәгә тагы кайбер иптәшләрне күреп сөйләшәсе бар. Ә бүгенге вояж уңышсыз.

Хөсәен биредә яңа нашир һәм бары исеме өчен генә берәр редактор табып, газетаны торгызып булмас микән, дип өметләнүен әйтте.

— Мин рәхәтләнеп шул подставное лицо булыр идем,— дип куйды Тукай.— Тик, тәәссефкә каршы, яшьрәк булуым эшне харап итә.

— Юк, юк, сезгә һич ярамый,— диде Хөсәен, каршы килеп.— Сезнең барыр юлыгыз билгеләнгән инде, Габдулла туган.

— Ә менә сәрмәя мәсьәләсе ничегрәк соң сездә? — диде кинәт Тукай, тагы кызыксынып.— Мәсәлән, безнең Камил әфәнде шуның аркасында бөтенләй бөлде.

— Камил бит ул — ялгызак каһарман. Ә без күп. Ә акчага килсәк... Анысы да чишелергә тиешле мәсьәлә безнең өчен.

Тукай көлеп куйды:

— Бу — тапкыр солдатның балтадан аш пешерүе кебегрәк икән.

— Бәлки шулай тоеладыр. Бер яктан карасаң, авырraктыр да әле. Ул солдатның эше барып чыккан, чөнки аның баш очында Домокл кылычы асылынып тормаган. Ә икенче яктан карасаң, эш башкачарак тора. Минем бер рус иптәшем бар иде. Ул җиде тапкыр төрмәдән качып кайтты һәм кайту белән үк тагы шул хәвефле эшкә җигелә торган булды.

— Һе, бар бит кешеләр!

— Идеягә бирелгәнлек, Габдулла. Иманың камил булса, нервыларың да нык була, тайпылышсыз рәвештә үз кыйблаңа карап барасың. Олы идеаллар олы гамәлләрне тудыра.

— Юк, миннән булмас андый эйберләр. Мин сынап карадым. Хәтта маевкаларда листовкалар да тараттым. Тик булмый. Бүген генә менә ике дус аерылыштык. Аның күзләрендә яшь, минем күзләрдә яшь. Нинди нервылар инде ул? Тетелгән мунчала. Аннан атлаган саен тукталып, уйланмыйча, тирә-ягыма каранмыйча бара алам микән соң әле мин? Юк, мин сездәй булырга кызыгам, тик революционер чыкмый миннән.

— Ә сез революционер инде. Үз өлкәгездә, татар әдәбияты өлкәсендә сез революционер.

Тукай рәхәтләнеп көлеп алды.

— Бирсен хода!

Тагы тынлык урнашты.

— Юк әле, Хөсәен,— диде Тукай, уйлана төшеп.— Әле башланды гына бит. Хәер, мин үз көчемә ышанам. Билләһи, ышанам. Булдырам мин аны, менә күрерсез, Хөсәен!

Үз чиратында Хөсәен дә көлеп куйды.

— Менә күрәсезме, сез үз кыйблагызны күреп, ничек гайрәтләнәсез!

Алар тынып яттылар.

Сүзне Тукай башлады:

— Тайпылышсыз, армый-талмый үз максатыңа таба бару турында сүз чыккач, минем хәтеремә бер кеше килеп төште. Мин бая да аның турында сөйләмәкче идем, тик ничектер җае туры килмәде. Ул кеше, минем аңлавымча, эзләнүчән бер зат. Ул уйлана-сыный һәм шуның аркасында еш кына ялгыша, бик зур ахмаклыклар эшләп ташлый. Ләкин аның күңеле саф, омтылышлары изге. Беләсезме, аның исеме кем? Җәгъфәр.

Хөсәен сискәнеп башын күтәрде.

— Җәгъфәр? Сез аны каян беләсез?

— Ул биредә булды. Без бергәләп Уральскида беренче спектакль куймакчы идек, бер байда приказчик булып хезмәт итте ул. Ә хәзер кайда икәнен белмим. Кинәт юкка чыкты.

— Ул юкка чыкмаган.

— Сез аның белән хат алышасызмыни? Әллә мөнәсәбәтләр яхшырдымы?

— Китәр алдыннан гына Оренбурга шул кешедән хат килде.

— Хуш, кайда соң ул?

— Ул казакъ арасына мөгаллим булып киткән.

Хөсәен кинәт Җәгъфәрнең бөтен узгандагы эшләрен хәтерләде. Шул ук минутта ничектер аралары çүрәнләнә башлаган Хәдичәсе турында уйлап алды. Әйе, ул Уфага киткәндер инде.

— Габдулла, ул Җәгъфәр дигән кеше сез уйлаган гөнаһсыз эзләнүче генә түгел. Ул крестьянның аумакайлыгын канына сеңдергән бер эгоист та. Аның эзләнүләре безнең өчен бик кыйммәткә төште.

— Аның сөйләвенә караганда, ул сезгә бернинди дә зыянлы эш эшләмәгән. Мин аның гөнаһсыз икәнлеген бөтен күңелем белән тоям.

— Аның җинаяте шунда ки, ул үзен хәтәр, артык җаваплы эшләр башкарырга лаеклы, житлеккән бер кеше дип исәпләде. Ә революция

бармак тидереп, капшап, татып карауларны күтәрми. Монда иманың камил булып, колларың ялгышмый сугарлык дәрәҗәгә җиткәч кенә җитди эшкә керешергә рөхсәт ителәә.

Сүз озак дәвам итте. Таң алдыннан сиздермәстән генә йокы басты... Хөсәен уянганда язгы иртә бөтен гүзәллеген ачып бизәнгән, киенгән иде. Ул, тору белән, тәрәзәне ачып җибәрде. Озакламый Габдулла да уянды. Йокысы туеп җитмәсә дә, ул шат, көр күңелле иде.

Иртәнге чәйне кичәгедәй бик күңелле итеп сөйләшеп эчтеләр. Хөсәен чыгып китәр алдыннан:

— Бер кешене күрәсем калды,— диде.— Әгәр дә юлым уңмаса, мин бүген үк Чиләбегә китәм. Анда татар-башкорт эшчеләре күп. Миассында да, Кучкарында да. Алар белән минем ботка пешә, яратам мин гади эшчеләрне.

Хөсәен чыгып китәр алдыннан Габдуллага таба борылды.

— Бәйләнешне өзмик, Габдулла дус.

— Әлбәттә,— диде Тукай шатланып,— мин бит свободный художник. Югалсагыз, үзем сезне эзли чыгачакмын.

Хөсәеннең юлы уңмады. Аның өчен ут йотып торган Тукай моны Хөсәен бүлмәгә килеп керү белән үк аңлады.

— Ямщик белән сөйләштем, бүген үк китәм,— диде Хөсәен. Тукай авыр итеп көрсенеп куйды.

— Сезнең белән бер туйганчы сөйләшә дә алмадык.

Шагыйрьнең йөзендә балаларга хас, яшерелмәгән авыр сагыш галәмәтләре чагыла иде.

— Булыр әле,— диде Хөсәен аны тынычландырып.— Ходаның рәхмәте киң, әле сез дә, мин дә үләргә җыенмыйбыз бит.

Санаулы минутлар сизелмичә узды да китте. Кунакханә ишеген кемдер шакылдатты. Бүлмәгә чыбыркы тоткан ямщик агай килеп керде. Өчәүләшеп әйберләр күтәреп аска төштеләр.

Тукайга бик-бик авыр иде аерылышу. Бары икенче күрүе иде әле аның Хөсәенне, тик әйтерсең лә гомерлек дустын озата. Әйтерсең лә барлык серләр, хыяллар уртак. Әйтерсең лә тормышның ачысын-төчесен бергә татып уздырган кадерле кешесе ул Хөсәен.

Хөсәен арбага менеп утырыр алдыннан Тукайның кечкенә, җыйнак гәүдәсен ирләрчә каты итеп кочты, тынып торды.

— Сезгә нинди олы бәхет теләгәнемне болай да аңлыйсыздыр инде? — диде ул, ниһаять.

— Аңлыйм,— диде Габдулла,— мине дә аңлыйсыздыр дип уйлыйм.

Хөсәен әрҗәле арбага менеп утырды.

— Ходага тапшырып кузгалдыкмы? — диде ямщик.

— Әйдә,— диде Хөсәен.

Атлар кыңгырауларын чыңлатып кузгалып киттеләр. Габдулла тораташтай кыймылдамыйча Хөсәеннәрнең чаттан борылганын карап торды, олы юлга шул урам аша чыгып була иде.

Авыр сәфәр һәм алда тагы да бик күп хәвефле билгесезлекләр көтә иде Хөсәенне. Габдулла әле һаман урыныннан кузгала алмыйча кыңгыраулар чыңын тыңлап торды. Ниһаять, ул тавыш сүнде, ишетелмәс булды.

— Хәерле юл сиңа, хөрмәтле кеше,— дип куйды Тукай. Башына килгән уйдан ул кинәт яктырып китте. Кешелекне алга алып баручылар, тәрәкъкый иттерүчеләр — шушы Хөсәеннәр бит инде дип уйланды. Үзе дә аңламастан, котырынып дулаган иксез-чиксез диңгезне күз алдына китерде Тукай. Аннары күңелендә күк гөмбәзе җанланды, андагы якты йолдызлар җемелдәшкәндәй булды. Ниһаять, күңелдә туган караңгы төн пәрдәсен куаныч нуры белән яктыртып, тулган ай калыкты...

*Икенче китап тәмам*

## Сәлисә Гәрәева

### Әнкәм күлмәге

Китте әнкәм кабат кайтмас соңгы юлга.
Истәлеккә күлмәк калды минем кулда:
Озын җиңле, бәбәйтәкләп, каеп теккән,
Ситса күлмәк — ак чәчәкле, гади җептән.

Күңел тулса газиз әнкәм искә төшеп,
Сагышымның салкыныннан китсәм өшеп,
Кулларыма аклы ситса күлмәк алам —
Күз алдымда ак күңелле газиз анам...

Искә төшә шул чак садә бала чагым,
Ык буйлары, Сөрмәт тавы — туган ягым,
Учак яккан зәңгәр җилле яланнарым,
Каз саклаган бәбкә үләнле аланнарым...

Аклы ситса бу күлмәкнең сере олы:
Күз алдымда кайнар комлы авыл юлы,
Шаулап үскән игеннәрнең эссе җиле —
Бөтенесе бу күлмәккә сеңгән иде...

Бу күлмәккә кайнар яшьле битем куям,
Чөнки аннан туган туфрак исен тоям.

### Болан

Илмән урманыннан болан чыга —
Сукмак салган Илмән күленә.
Иелә дә күлгә су эчә ул,
Чуер ташлар төптән күренә...

Карап тора болан ташка басып,
Хәйран калган дөнья ямена.
Артта урман, алда күз күреме
Дулкын-дулкын зәңгәр күл генә.

Ул сискәнә кинәт һәм сагая,
Шомлы бер хәрәкәт сизенеп:
Тиен оча, нарат ботагыннан
Күркә төшкән кебек өзелеп...

Ә боланга җитә шул тавыш та —
Ашыгып ул артка чигенә
Һәм юк була. Болан сукмагыннан
Очып үтә зәңгәр җил генә...

## Венера Рәхмәтуллина

### Хәтта хыяллардан ялгыз кайтма

Хәтта хыяллардан ялгыз кайтма,
Хыялларга ялгыз чумсаң да...
Тик үзеңне эзләп үзең йөрмә,
Бу шау-шудан кайчак туйсаң да.

Нәкъ кителеп төшкән көзге кебек,
Күңелең югалтканда зурлыгын,
Тик атлагач кына, чакыручы
Әйтсә көлеп сиңа юл югын.

Күзне йомып, башны тотып кына
Яшәү серләренә ау чыксаң,
Күзең ачкач, бер селтәнү белән
Ышанычны бәреп үк ексаң, —

Чумган төсле булыр бер чыңлауга
Бу дөньяның бөтен тарафы,
Йозаклардан, йозаклардан ул чың —
Бикле серләр, агы-карасы.

«Җир өстендә сукмак буламыни
Хакыйкатькә кадәр илтүче?» —
Уйлар усаллана көчсезлектән,
Табылмый сүз — яшьне сөртүче.

Көчең бетсә, юлда кешеләр күп,
Кешеләргә бул син якынрак,
Яшәү көче шатлык булып артыр,
Гел булса да бәхет арырак.

Каршыла син таңны кешеләр белән,
Төннәреңдә ялгыз булсаң да.
Хәтта хыяллардан ялгыз кайтма,
Хыялларга ялгыз чумсаң да.

## Еллар аша ярату

Сагынудан бәхетле мин,
Шуларны белмисең күк.
Шатлыклар да юк түгел лә,
Сагышларым да шул күп.

Сине түгел, аны күрәм
Яннарымда һәр вакыт.
Үткәнемдә яшим һаман
Сагынып һәм яратып.

Кабатланмый икән сөю,
Бары яңарып таша.
Сагыну да ярату ул, —
Ярату еллар аша.

## Сине очраттым

Сине очраттым, тик күңелдә
Кырпак карлы салкын көз иде.
Сары яфрак — хәтта үпкәсен дә
Аңлатудан гаҗиз йөз иде.

Яфрак түгел, минем хыялларым
Ята иде җирдә боегып,
Ә син елмаясың: «Көткәнсең бит,
Мине күргәч, төштең коелып».

Йөрәгеңне ачтың — пар кул белән
Уртак хыялларга үрелдем.
Шаһитлар юк, бары үзем белдем,
Әйтерсең лә яңа үр меңдем.

Көзләр җиткәч, яз сулышы белән
Кабынучы әллә мин генә?!
Сары яфрак алып тыным өрсәм,
Гел яшәрер төсле, чын менә.


Ләбибә Ихсанова

# ҮКЕНҮ

хикәя

Колхоз малларын коткарганда һәлак
булган авылдашым Рәйсәгә багышлыйм.

## 1



Тагын кич булды. Эшле кешеләрнең эштән кайтыр чаклары җитте. Бил тиңентен карга чумып бишмәт чабуларын бозга катырган кызыл битле, өшегән борынлы малайлар да уеннан туйдылар. Дагалы ат кебек, карлы итекләре белән шак-шок басып, берәм-берәм өйләренә тарала башладылар.

Ут алынуга Сәләхи картның да сигез яшьлек оныгы, мыштым гына кереп, кече якта аш җиткереп йөргән әбисе янына сыенды. Түрдә, өстенә чигүле япма каплаган телевизор каршында, кулларын кушырып утырган чытык йөзле бабасының күзенә күренәсе килмәде. Бераздан почтада эшләүче киленнәре кайтты. Ул да, тавыш-тынсыз гына, көянтә-чиләкләрен алып суга китте. Картның олы улы Галимҗан кайтканчы өйдә адәм тавышы ишетелмәде.

Урамнан эчкәрәк кертеп салынган биек такта коймалар, сәрби куаклары артына ышыкланып, тышкы дөньядан аерылып торган шатрун түбәле бу өйдә болай да шау килеп сөйләшү, шаярып көлешеп алу, гөрләшеп ашап-эчеп утыру гадәте юк иде. Кичә булган фаҗига аны тагын да күңелсезләндереп, үлек чыккан йортка әйләндерде.

Узган атнада колхозның бозаулар фермасында кинәт ут чыкты. Бозауларга да, фермага да зыян килмәгән үзе. Бозау караучы Сәвия ут капкан саламнарны кочак-кочак күтәреп кар өстенә чыгарып ташлаган. Тик үзе хәтәр яман пешкән, диләр. Хәзер район больницасында ята. Дөрес булса, хәле авыр икән.

Сәләхинекеләр Сәвиянең туганы да, йөрешкән, алыш-биреш иткән кешеләре дә түгел. Картның шулай кара коелып утыруына төпчеге Галәү сәбәп. Галәү колхоз электригы. Фермада ут чыгуга ул гаепле дигән сүз тараттылар. Районнан тикшерүчеләр килеп, егетне гаеплерлек олы сәбәп юклыгын әйткәнче, Сәләхи күңеленнәнниләр генә уйлап бетермәде. Бер көнне ул Сәвияләр капкасын да барып какты. Үзе дә бәхетсез ана аның улына ничек ярдәм итә алырын Сәләхи уйлап җиткерә алмады, әлбәттә. Аптыраган үрдәк арты белән суга чума диләр бит. Барганына карап, Сәвиянең әнисе Һаҗәрне өйдә туры китерә алмады. Кызының хәле авыр дигән хәбәр дөрес, ахры, больницада баласын саклап утыра, диделәр.

Инде ни эшләргә? Малайны ничек йолып калырга? Тикшерүчеләрнең күңелен күрергәме? Коры кашык авыз ерта дип, бер көнне Сәләхи карт күңеленнән келәттәге сарык түшләрен барлап утырды. Анысы күбрәк күренде дә чолан киштәсендә эленеп торган каз-үрдәкләргә кайтып төште. Күңел күзе анда да тукталып калмады, баллы кисмәкнең капкачын ачып карады. Бал күзгә күренеп эри барды... Карт күзләрен йомды, боларның барысын бер юлы олауга төяп чыгарып җибәргәндәй күрсенеп куйды. Аннары үз-үзе белән бәхәсләшкән кук итте. Юк, китсен, малы да китсен, балы да. Барсы да табылыр, боерган булса. Малай башы җәл, дип уйлады. Әмма тикшерүчеләр кырыс кеше булып чыктылар. Аларның җитди чытык йөзләрен күргәч, Сәләхи баллы кашык турында авыз ачарга да курыкты.

Бәхеткә каршы, малайның артык зур гаебен тапмадылар. Таякның юан башы өлкән механик җилкәсенә барып төште. Колхоз техникасы өчен җавап бирергә тиешле бу кешене фермадагы электр үткәргечләрен шул хәлгә килеп җиткәнче алыштырмый торуда гаепләгәннәр. Кеше башына төшкән бәлага сөенү яхшы эш түгел түгелен, әмма Сәләхи карт сөенми кала алмады. Улының башы төрмәгә китә дип торганда штраф белән котылу аның өчен чыннан да зур шатлык иде.

Тик Галәүне генә алыштырып куйгандай булды шул көннән соң. Тикшерү килгәнче бер кешегә бер сүз катмыйча, дару ашап миңгерәүләнгән чебен кебек тавыш-тынсыз йөргән егет, комиссия киткәч шаша башлады. Иң әлек урынга капланып, үкереп бер елады. Аннары, гомергә булмаган, Сәләхинекеләр өендә күренмәгән бер хәл, шул кичне чыгып китте дә лаякыл исереп кайтты. Икенче көнне көне буе башын күтәрә алмыйча авырып ятты. Атасы, агасы белән теләште. Менә бүген төш турында чыгып киткән иде, кайда йөридер, әле булса күзгә күренгәне юк. Инде тынычландык, бу бәладән котылдык дип бер тын алган Сәләхи, төпчек улының болай көйсезләнеп китү сәбәбен аңламыйча, аңа күңеленнән рәнҗеп, шул ук вакытта нәрсә дә булса хәл кылудан гаҗиз булып, аптырап утыра иде.

Ишек ачылды. Бер түшәк салкын ияртеп олы улы Галимҗан керде. Кыска тунын салып мич аралыгындагы чөйгә элде, олтанлы киез итекләрен җылы мич башына бастырды да, тузган чәчләрен сыпыра-сыпыра, түргә узды.

— Галәү өйдә юкмы әллә? — диде ул, як-ягына каранып.

Улының тавышына айнып киткән Сәләхи башын күтәрде:

— Чыгып киткән ие әле, ни төсле кайтыр? — диде йөзен чытып.

Юкка көттеләр ул кичне Галәүне. Егетнең юлы район үзәгенә, Сәвия яткан больницага таба булды ул кичне.

Комиссиянең карары аңа тынгылык китермәде. Киресенчә, гипноздан айныган кеше кебек, фаҗигане̇ң зурлыгын, хәсрәтнең таудан авырлыгын ул бары шул көннән соң гына аңлады. Сәвиянең үлем

белән тартышып яткан сәгатьләрендә зур гаепнең анда түгел дип табылуы егетнең вөжданын үртәде. Закон ул параграфлар, статьялар белән эш итә, гаебенә күрә генә җәзасын бирә дә бит, ә вөждан өчен боларның берсе дә юк. Вөждан ул ярым-йорты хөкем чыгара белми, ул сине я бөтенләйгә аклый, я үтереп ташлый.

Ә егетне вөжданы камчылый да камчылый.

Хәзер ул алар янына дип китте. Ни өчен? Эш үткәч...

Үзенең исән-сау булуына, шушы каты карны шыгырдатып йөри алуына авылдашларыннан уңайсызлангандай ашыгып-ашыгып урамнардан үтте ул. Әнә бер читтә Сәвияләрнең хәсрәтле өйләре торып калды. Шулай ук чын булдымы икәнни соң бу хәлләр? Әллә болар барысы да саташулы, коточкыч төш кенәме? Ләкин кар өстендә пыскып яткан салам өемнәрен үз күзләре белән күрде бит ул. Сәвия күтәреп чыккан кочак-кочак утлы салам өемнәрен. Галәү йөгереп килгәндә Сәвия аңын югалтып кар өстендә ята иде инде. Кочагында сасы төтен пыскып торган бодай саламы. Йөгереп килүенә егет аны күтәреп алды. Җылы бәрән тунын чишеп күкрәгенә кысты, кызның салынып төшкән хәлсез кулларын тун итәге белән төрергә, җылытырга тырышты. Ә Сәвия эчтә янган утка түзә алмыйча үрсәләнә, бәргәләнә иде.

Шартлап ярылыр алдыннан ярсып типкән йөрәк кебек, утлы өемнәр балкып-балкып алдылар да, үз көлләренә үзләре тончыгып, берәм-берәм сүнделәр. Ак кар өстендә кара таплар гына калды. Сәвиянең әнисенә, дусларына гына түгел, егет күңеленә дә кара кайгы салдылар ул таплар...

Төш кенә буламы соң? Өн иде бу. Аяныч өн иде. Бөтен җир хәзер Сәвияне искә төшерә. Авылны чыгуга, тау башында алар укыган мәктәп калды. Каш җыерып карап калган борчулы бер кеше кебек булып күренде ул Галәүгә. Әле кайчан гына тәрәз пыялаларын ялтыратып, көлеп каршы ала иде ул аларны. Хәер, малай чагында да төрлесен кичерде Галәү. Тоташ шатлыктан, рәхәттән генә тормады аның малай чак гомере. Күбрәк вакытта бар нәрсәне җиңеллек белән, күп көч куймыйча гына алган яшьтәшләреннән көнләшә, үзенә дигән кечкенә генә уңышның да бик әйләнгеч юллар белән, көттереп килүенә офтанып яши иде ул. Малай чагында иптәшләре таккан сары пошлак кушаматы үзәгенә үтте. Тик ул чакта җиңелрәк иде аңа. Чәч төпләренә хәтле сары сипкел баскан бакыр башында очына чыга алмастай уйлар юк иде ул вакытта. Иптәшләре белән булган каршылыкларны ул ясмык-ясмык сипкел төшкән сөякчел йодрыклары белән хәл итә иде. Сары пошлак янына сугыш чукмары дигән кушамат өстәлсә өстәлде, әмма класстагы малайларга да, кызларга да баш бирмәде. Рәшидә белән Сәвиягә генә кул күтәрә алмады. Кыз бала булганнары өчен түгел, Галәүдән җәбер күргән кызлар класста аз булмады анысы. Рәшидәнең көченнән курка иде ул. Малайларга караганда да зуррак гәүдәле, чүкеч кебек каты куллы бу кыз очрашуларының беренче көненнән үк үзенең өстенлеген сиздереп куйды. Сәвиягә дә кул якмаслык итте.

Алар бишенчегә күчкән елны, колхозлары, шәһәрдәге кебек итеп, дүрт катлы таш мәктәп салган иде. Авылларының ике очындагы башлангыч класслар белән сигез еллыкны бергә куштылар да тугызынчы класска да балалар җыя башладылар. Шулай итеп, алар авылында урта мәктәп ачылды. Ул елны Галәү иртүк барып үз классларын эзләп тапты. Артка борылсаң да, янга карасаң да, урам күренеп торырлык партадан урын сайлады. Абыйсыннан калган портфелен бер селтәнүдә парта астына тондырды. Чит-читләре кыршылып, кара тышлы бәләкәй мендәргә охшап калган иске нәрсә үз

урынына кереп ояларга теләмәде, шап итеп идәнгә килеп төште. Иелеп караган иде Галәү, парта астының ике бүлеме дә буш түгеллеген күрде. Андагы сумкаларның яңалыгына, саклык белән пөхтәләп куелуларына караганда бу урынны кызлар алганы билгеле булды. Кызлар дигәндә хөкеме кыска малайның, сумкаларның икесен бер кулга тотты да үзеннән алдагы партага ташлыйм дип торганда — янына ике кыз килеп басмасынмы. Аларның укытучы ападан да озынрак буйлысын күрүгә үк шүрләп куйды. Бүредән курыккан куян кебек әкрен-әкрен артка чигенә башлады. Күкрәгенә тукмак кебек каты йодрык килеп төртелүгә инде эскәмиянең башына барып җиткән Галәү идәнгә үк әйләнеп төште.

— Кеше әйберенә катылмассың икенче, — диде ул кыз һәм, мәче баласын күтәргәндәй, Галәүнең якасыннан тартып торгызды да алдагы парта арасына китереп тыкты.

— Утыр шунда, — диде ул кечкенә балага әмер биргән кебек итеп.

Галәү хурланды, бу усал кызга ачуы килде, карышырга кыюлыгы гына җитмәде. Шулай да сер бирмәде. Портфелен кызлар күрсәткән җиргә ташлады да, ике кулын кесәсенә тыгып, бер дә исе китмәгән кыяфәт белән сызгыра-сызгыра, класстан чыгып китте.

Ат кешнәшеп табыша, диләр бит. Ә аларның танышлыгы көч сынашудан башланды. Хәер, Галәү артык сынашып торырга теләмәде, Рәшидәнең өстенлеген берсүзсез кабул итте дә башка бер вакытта да аңа бәйләнеп маташмады. Ә аның аз сүзле оялчан дусты, Сәвия исемле кызны, ул баштан ук санга да сукмады. Аңа караган саен сәер уйлар килә иде малайның күңеленә: Сәвиянең аз гына елмайса да батып китә торган бит уртасына карандаш очы белән төртеп карыйсы иде. Күзләренә бармак очын тидереп алсаң, карасы йогар идеме икән? Аннары менә чәчен үргән кызыл тасманы күрсә, кулы кычыта башлый — шуны тартып сүтәсе килә дә тора. Тик ул аларның берсен дә эшләми, Сәвия янында, какшамас кыя кебек, һәр вакыт Рәшидә була.

Яшьләре белән бер чама булсалар да, җиденчеләргә җиткәндә Рәшидә класста иң озын, иң таза гәүдәле кыз булып калды. Кешедән яшерен серләре дә башка кызларга караганда иртәрәк сизелә башлады. Бер елны ул тарих укытучысын яратты. Фатыйх абыйларының председатель чагы түгел иде әле. Институтны тәмамлап кайткач, тарих укыта башлаган елы гына иде. Һәр вакыт дәрескә матур костюмнан килеп керер, ап-ак күлмәк өстеннән чем-кара галстук бәйләгән булыр иде. Авылга концерт куярга килгән артист дип белерсең. Тубалдай булып кабарып торган чәчләре тигезләп кырылган, матурлап таралган. Әз генә ислемай исе дә килеп торыр иде аннан. Болын чәчәкләрен хәтерләткән шушы тәмле ис башын әйләндерде ме, укытучыны күрде исә Рәшидәнең тынычлыгы югала башлады. Ул кышны Рәшидәнең Фатыйх абыйсын гел күрәсе генә килеп торды. Башка бер фәннән дәресен әзерләмәгәндә дә тарихны укып барды. Ул вакытта Фатыйх абыйсының мактаулы укучысы иде ул. Укытучы үзе дә яратадыр, дәресен белгәне өчен генә түгел, яратканга күрә шулай мактыйдыр кебек тоелды.

Бер көнне ул Фатыйх абыйсына хат язарга булды. Армиягә киткән күрше егетеннән апасына килгән хатларны качып-посып укыганы бар иде Рәшидәнең. Шуларның берсен алды да үзенчә җайлаштырып күчереп куйды. Хатның ахырына язылган җырын да калдырмады:

Сөям сине, сөям сине,
Гомергә сөячәкмен.
Үлеп гүрләргә кергәнче
Минеке диячәкмен.

Ошый иде аңа бу хат. Фатыйх абыйсына да ошар дип уйлады. Ләкин укытучының үзенә дә, классташларга да сиздермичә ничек итеп бирергә аны?

Тарих дәресе дә җитте. Әлегә хәтле тыныч иде Рәшидә, укытучы килеп кергәч, ни үткен, ул да коелып төште. Классташлары укытучыны каршылап басканда да урыныннан кузгалмады. Сәвия гаҗәпләнеп аның янтыгына төрткәч кенә торып басты. Аяклары, бөтен гәүдәсе туктаусыз дерелди иде, кулларының калтыравын Сәвиягә сиздермәс өчен чытырдатып парта капкачын кысты. Урынына утыргач та китабын таба алмыйча азапланды, сумкасындагы дәфтәрләрне чәчеп бетерде.

— Сиңа нәрсә булды? — диде Сәвия иптәш кызының кинәт үзгәрүенә гаҗәпләнеп. — Авырыйсыңмы әллә?

Рәшидә, җавап бирмичә, утлы күмер тоткандай кабаланып, Сәвиягә кулын сузды.

— Нәрсә ул? — дип пышылдады Сәвия.

— Хат.

— Хат? Кемгә?

— Фатыйх абыйга, — диде Рәшидә ишетелер-ишетелмәс кенә итеп.

Сәвия гаҗәпләнеп хатны ачты. Парта астына яшереп укый башлады. Рәшидә аны тын да алмыйча күзәтеп торды. Сәвиянең күперенке иреннәре бер ачыла, бер ябыла иде. Кинәт кенә ике бит уртасы кызарып чыкты.

— Кит, җүләр, укытучы бит ул, — диде Сәвия хатны яртылаш укыгач, дустына күтәрелеп карап.

Шул вакыт әлеге чибәр егет, матур киемле Фатыйх абыйлары, борынгы Россиядәге феодал изүләр турында сөйли-сөйли кызлар утырган парта янына килеп басты. Алгы рәттә утырган Галәү шуны көтеп торган диярсең:

— Абый, алар хат укыйлар, — дип әләкли башлады.

Рәшидәнең нидәндер югалып калуын, күңеле белән класста түгел, әллә кайларда йөрүен Галәү күз кырые белән күреп утырган иде. Аларның пышылдап сөйләшкән сүзләрен ишетергә дип, артка ук каерылып та утырды. Тик ишетә алмады. Үтә сак, үтә әкрен сөйләшәләр иде алар. Һәм, билгеле инде, сер сөйләшәләр иде. Нинди сер? Кызлар сере ни булсын... Рәшидә алдында үзен олыларча, егетләрчә тотарга көче җитмәгән Галәү, шул хәлгә эчтән хурланып, «тракторны кузгатырлык» көче булган классташын күңеленнән тиргәп яшәгән Галәү, җае килгән саен аны көзге чебен кебек авырттырып бер чәнчеп ала һәм шуннан рәхәт таба торган иде. Бу юлы да җай чыгудан кинәнеп калды. Ә Рәшидә белән Сәвия исә болай да парта арасына сеңеп китәрдәй булып утыралар иде, малайның сүзеннән котлары алынды. Сәвиянең йомарлап хат тоткан кулы тирләп чыкты. Читлеккә эләккән җәнлек кебек тилмереп, ул укытучының күзләренә карады. Ә Фатыйх абыйсы гаҗизлек кенә түгел, бернинди көчкә дә буйсынмас катылык та күрде бу караштa. «Хатны сорамагыз, үлсәм дә бирмим. Класстан чыгарып җибәрсәгез дә, әнигә әйтсәгез дә...» — диде кызның карашы. «Мин синнән моны көтмәгән идем. Син бит тыйнак, әйбәт кыз идең», — булды җавап. «Ачуланмагыз, мин аны сезгә бирә алмыйм: ул минем серем түгел». Укытучы аңлады. «Я, тынычлан. Моннан соң алай эшләмәссең», — ди иде аның күзләре. Ярты гына минутлык тыныштан соң, сөйләвендә дәвам итеп, кызлар яныннан китте. Орчык кебек бөтерелеп утырган Галәүнең иңбашына кулын салып, аны тынычландырды. Аннан соң класс алдына, үз урынына килеп басты. Сәвия белән

укытучының сүзсез сөйләшүен сизми калган Рәшидә үзенчә юрады: ярата, яратмаса ачуланыр иде, хатны сорап алган булыр иде.

Сәвия исенә килгәч абайлап алды: янында укытучы басып торган арада хатны урталай ертып төшергән икән бит. Инде ни эшләргә белмичә, ике кисәкне бергә ялгап карады да тагын ертты, тагын... һәм кәгазь чүпләрен тын алырга да куркып утырган Рәшидә алдына салды.

— Нишләттең?— дип пышылдады Рәшидә ни әйтергә дә белмичә.

Ә Галәүнең баш артында күзе бар дип белерсең. Ялт кына борылды да кәгазь кисәкләрен Рәшидәдән алда сыпырып та алды. Сәвия йодрыгы малайның аркасына килеп төште.

— Эл-ләү! — диде Галәү, калак сөяген кашып.

Классның тынычлыгы бозылды. Алар ягына борылып-борылып карый башладылар. Укытучы да сөйләвеннән бүленде.

— Альтапова! Сәләхиев! Тыңлап утырыгыз. Кабатлау вакытында сездән сорыйм,— дип кисәтте ул.

Сәвия укытучы сөйләп бетергәнче звонок булсын иде дә сорарга өлгермәсен иде дип, бөтен күңеле белән теләп утырса да, барып чыкмады. Тарих укытучысы өс-башка гына түгел, дәрестә дә бик җыйнак кеше иде. Кырык биш минутның һәр минуты бүленеп куелган аның. Сәгатенә дә карап тормый, югыйсә, сөйләргә дә, кабатларга да, сорап алырга да өлгерә. Менә ул дәрескә йомгак ясады. Укучыларны сынагандай бер минут тын калып, класс өстенә карап торды да:

— Я, Альтапова, крепостной крестьяннарның эш кораллары турында сөйләп бир әле, — диде.

Класста шундый тынлык урнашты, Сәвия үз йөрәгенең дөп-дөп какканын үзе ишетеп торды. Нәрсә дип җавап бирергә соң? Дөп... дөп. Күзгә карап тормаса икән шул Фатыйх абый. Дөп... дөп... Нинди кораллар иде соң әле, нинди?.. Дөп... дөп... дөп...

Шул арада Галәүләр ягыннан пышылдау ишетелде:

— Коор-тик! — дип кабатлады шуны Сәвия. Уйлап-нитеп тормады, нәрсә булса әйтергә кирәк иде бит. Кыз авызыннан шул сүзнең ычкынуы булды, бөтен класс бердән пр-рых итеп көлеп җибәрде. Оятыннан нишләргә белмәгән Сәвия, өстенә кар ишелгәндәгедәй авыраеп, парта өстенә сыгылып төште. Укытучының класс журналына билге куйганын үрелә төшеп карап утырган малай, сөенче алгандай шатланып, ике бармагын тырпайтып күрсәтте.

— Дәресне игътибар белән тыңламавың кызганыч, Альтапова, — диде укытучы, — бәлки безгә Сәләхиев ярдәм итәр.

Ул дәрестә Галәү дә икеле алды.

Сәләхиләр өендә берәү дә эшсез тормый. Мәктәптән кайтуына Галәүне дә дөнья хәтле эш көтеп тора. Кечкенә чанага кисмәк утыртып су ташырга, мал астын тазартырга, мичкә утын кертергә. Көн дә шулай. Иптәшләре кайткач китап укый, түгәрәкләргә йөри, телевизордан хоккей карый. Кайчандыр бер тапкыр Галәү дә өйдәге бу тәртипләргә каршы килеп караган иде. Сәләхи картның чикмән өстеннән буып йөри торган бил каешы малайны шунда ук телсез итте. Хәзер инде ул карышып тормый. Иске итек, иске бишмәтен кия дә караңгы төшкәнче ишегалдында маташа. Кызлар хатын эләктереп кайткан көнне генә ул өйдә тоткарланырга сылтау эзләп карады. Тик ул көнне дә гомере буе ни балаларын, ни үзен яклап ирекә сүз әйтә алмаган әнисе аның ишектән килеп кергәнен генә көткән кебек:

— Сыерга салып кер әле шуны, сарыкларга печән төшер, —дип малайның кулына ашлы су чиләге тоттырды.

Абзар тәрәзәсенең дәфтәр бите хәтле бәләкәй пыяласыннан төш-

кән тонык яктыга куеп Рәшидәнең хатын кисәген кисәккә ялгап укырга теләде. Ләкин өлгерә алмады. Бүген-иртәгә бәрәнләргә торган буаз сарык арттан килеп малайның кулына үрелгән иде, мышнап куйды да, кәгазь кисәкләрен саламлы тирес өстенә очыртып бетерде.

— Китсәнә! — диде малай, сарыкның башына сугып.

Хатны укый алмаса да, җырының ике юлын күреп алган иде. Кызларны үртәргә шул да җитә калды.

Иртәгесен, бик кирәк әйберен эзләгәндәй, сумкасын актарган булып, күз кыры белән арттагы партаны күзәтә-күзәтә, алмагачлары көенә сузып җибәрде:

Сөям сине, сөям сине,
Гомергә сөячәкмен...

Класстагылар көлеп куйды. Мәгънәсен аңлап түгел, Галәүнең чираттагы маймыллануы дип уйлап көлделәр. Ә Рәшидә белән Сәвия исә үзләренә төрттереп әйтелгәнен аңладылар. Рәшидәнең колак яфракларына кадәр ут капкандай булды.

— Күрсәтермен әле кайтканда, сары пошлак, — диде ул әченнән.

Дәресләр бетүгә үк чыгып йөгерәсе калган икән Галәүгә. Өендә гомергә бетмәс эшләре дә көтеп тора, югыйсә. Юк бит, кызларны үртисе килү бизгәге тота аны. Җырның ике юлын әйтә дә йөгерә, кызлар куа килмәсме дип, артына борылып карый. Рәшидә белән Сәвиянең бер дә исләре китмәгәндәй тыныч кына кайтуларын күргәч, тагын туктап көтеп ала, тагын такмаклый башлый:

Сөям сине, сөям сине...

Ә Рәшидәнең мәктәптән бергә чыккан классташлары алдында сер бирәсе килми. Кемне үртәп җырлаганны кем белә, сары пошлакның бияләй хәтле теленә ни килмәс. Инеш буе сукмагы бераз бушансын әле менә, тыкрык башындагы көрткә генә килеп җитсеннәр.

Сөям сине...

Галәү сизми дә кала, ачкан авызын ябарга да өлгермичә, башы белән көрткә чума. Авызына, күзенә, муенына пыяла кебек үткен, каты кар ярмасы тула. Өстенә капланган авырлыктан ул көрткә чума бара, чума бара, чалкан әйләнергә тели, алай итсә аяклары, куллары белән каршы тора алыр кебек, кая ул — кыймылдарга да ирек бирмиләр. Кычкырмакчы була, авыздагы кар комачаулый. Кинәт ул үзенең җирдән аерылганын тойды. Кемдер аны тартып торгыза иде. Сәвия икән. Рәшидәсе инде тыкрыктан йөгереп үткән, урамга җитеп бара. Сәвия Галәүнең читтә аунап яткан бүреген алып каккалады да малайның кар катыш укмашкан чәченә каплады.

— Үзең гаепле бит, үртәшмәскә иде,— диде ул энесен шелтәләгән апа кеше сыман итеп.

Галәү аның кулына сугып җибәрде. Шул вакыт малайның күзләре әчетеп китте. Әллә инде керфекләргә кунган кар эреп күзгә керә, әллә күз яшьләре...

Рәшидәнең усаллыгына исе китмәгән иде, алар яшендә кызлар белән малайлар сугышмый тормый ул, Сәвиянең кызганып каравы әллә нишләтте аны. Класста иң юаш, иң тавышсыз бәләкәй кыз да аны авыру кешегә санаган кебек тоелды. Кәтүк хәтле генә бәләкәй кыз алдында үзенең көчсезлеген танудан гомерендә беренче тапкыр хурланды.

Ул көнне Галәү өйләренә вакытында кайтмады. Урамга керергә хурланып, анда малайлар үртәр дип уйлады, кояш баеганчы инеш буенда йөрде. Хыялында ул шул сәгатьләр эчендә ниләр генә эшләмәде. Иң элек ул үзен озын буйлы, киң җилкәле чибәр егет итеп күрде. Абыйсы Галимҗан да шундый бит аның. Ләкин малай үзен ан-

нан да көчлерәк итеп, кем тәсле... әйтик, дөнья чемпионы Жаботинский кебегрәк итеп күрде. Шул вакыт аның тун астында мускуллары кабарып чыккандай булды, киеме кыскандай, төймәләрен чишеп җибәрде, иңбашларын киереп куйды. Их, күрсәтер иде ул кызларга көчнең нинди булганын! Икесен ике кулына күтәрер иде дә, төшер инде, Галәү, төшер инде, дип ялынганчы һавада селкеп торыр иде. Юк, алай итмәс, әйләнеп карамас иде ул аларга. Хәтта сөйләшмәс тә иде. Нигә дип вакланып торырга.

Юлда аны абыйсы Галимҗан очратты.

— Ни эшләп йөрисең монда? — диде ул.

Абыйсы янында торганда Галәү үз кимчелеген, көчсезлеген аеруча нык сизде. «Гел шулай калырмынмы икәнни» дигән уй йөрәген чәнчеп үтте.

— Абый, әйт әле, мин нишләп шулай бәләкәй булганмын? — диде ул Галимҗанның соравына җавап бирмичә.

— Әти саран кыланган, — диде Галимҗан көлеп.

— Мин чынлап әйтәм, ә ул... — диде Галәү үпкәләп.

— Мин дә чынлап әйтәм. Карун Сәләхи диләр бит әткәйне, — диде Галимҗан китә башлаган энесен кулыннан тартып.— Кешене балчыктан ясыйлармы, балчыктан. Әткәй синә балчыкны кызгангандыр.

— Әй, синең белән сөйләшкәнче!..

— Ха-ха-ха!

Гел шулай ул Галимҗан. Өйдә сөйләшмәгәннәренең әҗерен кеше алдында чыгара. Өй җиткереп башка чыгарга хыяллана ул. Бу турыда атасы белми әле. Сизеп калса, тузыныр иде. Шуңа күрә атасына әйтергә кыюлыгы җитми тора. Бик ачуын китерсә, Галәү күп уйлап тормас, әтисенә әйтеп тә куяр. Йөрсен аннары менә өй салам дип. Галимҗан, көлеп туйгач, авызын турсайтып атлаган энесенең аркасыннан кагып куйды.

— Я, я, ачуланма. Җәй көне үзеңне бүрәнә чыгарырга аппарырмын. Балык шулпасы белән әче ипи килешә ул кешегә. Ак күмәчкә май ягып ашап кына үсеп булмый...

2

Вятка буендагы нарат урманнарының шифалы һавасы, тәнгә дә, җанга да рәхәт талгын су җиле килештеме, төтен исе катыш тәмле балык шулпаларының файдасы тидеме, әллә болай да вакыт җиткән идеме инде, абыйсы белән эшләп йөргән бер-ике ел эчендә үзгәрде дә китте Галәү. Йомырка сарысы яккандай сап-сары битле малай иде, зифа буйлы, киң җилкәле егеткә әйләнде дә куйды. Кояшта, җилдә, яңгырда йөреп каралган йөзендә гомере буе үзәгенә үткән сипкелнең эзе дә калмады. Татарларда сирәк очрый торган бакыр чәчләр дә куе каштан төсенә керде. Холкы да үзгәрде. Ул инде, сукыр черки кебек, юкка-барга бәйләнеп кешенең үзәгенә үтми, салкын канлырак, сабыррак була белә башлады.

Баштанаяк суга чумып, көчәнә-көчәнә, әртил белән бүрәнә тарттырулар, яр буенда учак ягып, җыен юк-барны сөйләшеп утырулар, күршедәге авылларга барып, егетләрен көнләштереп, этләрен өрдереп, кызлар озатып йөрүләр, сал өстендә балык тотулар белән Галәүнең авыр да, кызык та үткән җәйләре артта калды.

Узган ел ул китмәде. Унынчы классны тәмамлыйсы, сынаулар бирәсе елы иде. Өйдә әтисе, эштә әртил башлыгы иркенә бирелеп гамьсез яшәгән егетнең дә башына пошаман төште ул елны. Укудан шәп бармый иде ул. Сынаулар бирмәгәч, өчлеләр тәяп булса да, класстан класска күчә килде. ВУЗга керәм дип хыялланмады.

Идеалы, абыйсы кебек, авылда калып, ватылмыйча тыныч кына яшәү иде. Тик мәктәпне тәмамламый ярамый. Башлаган эшне бетерү өчен генә түгел, акча төшәрлегрәк адәм рәтле эшкә урнашу өчен документ кирәк булганга тырышып йөрүе иде. Шуңа күрә егетнең дә пошмас башына тора-бара борчулы уйлар керә башлады, ахры, төшләрендә өйгә биргән эшләрне эшләми килүләрен, укытучылар сорауганга җавап бирә алмый азаплануларын күреп саташып бетә торган булды.

Галәү бер көнне шулай бик озак синус, косинуслар белән баш ватып утырды да, үзе генә очына чыга алмагач, китапларын кыстырып, Сәвияләргә китте.

Ак пәрдәле ачык тәрәзә янына утырган Сәвияне ерактан ук күреп килде ул. Кыз әле генә идән юып чыгарган иде. Сап-сары нарат сайгакларның кояш нуры төшкән турыннан бөдрәләнеп сизелер-сизелмәс кенә пар күтәрелеп тора. Өстәл өстендәге шомырт чәчәкләреннән өй эченә язгы урман исе таралган. Сәвия чәчәкле банкага китабын сөяп куйган. Ә күзләре китап юлларына түгел, зәңгәрсу ак шомырт чәчәкләренә төбәлгән иде.

Галәү, сиздермичә генә үрелеп, тәрәзәгә башын тыкты да, тәлгәштән биш читле чәчәк өзеп алды.

— Бәхет чәчәге! — диде ул, таҗны кызга сузып.

Кинәт ишетелгән тавышка Сәвия сискәнеп китте. Галәүне күргәч, бит урталарын батырып, елмаеп алды.

— Куркыттың ич! — диде, егетнең кулыннан чәчәкне алып. Таҗның биш канатын да берәм-берәм санагандай, бармак очларын тидереп алды да чәчәкне күпереп торган иреннәренә куйды.

— Мин кайчаннан бирле эзлим инде, әле берне дә тапканым юк.

— Мин бәхетле бит. Шуңа табыладыр. Менә тагын берәү. Монысы алты читле икән әле. Менә тагын...

— Әй мактанчык. Шул бәләкәй генә бәхеткә куанып йөрисеңме?

— Ник куанмаска. Һавадагы торна турында хыялланганчы, кулыңдагы чыпчыкны очырмау яхшырак.

— Хыял ул матур китап укыган кук.

— Хыяллану кызлар гадәте. Егетләр күбрәк эш күрсәтергә ярата.

Сәвия ярты гәүдәсе белән бүлмә эченә кергән егетнең күкрәгенә йомшак кына этеп куйды:

— Тагын мактана инде.

Шул вакыт аларның күзләре очрашты. Кыз уңайсызланып китте, бармак очын тидерсәң карасы йогарлык чем-кара күзләрне каплап, озын керфекләр түбән иелде.

Була бит шундый минутлар, уйламаганда кабынасың.

Әле генә Сәвия бергә үскән классташ кыз иде Галәү өчен. Ул аның белән теләсә ни сөйләшә, бәхәсләшә, кирәк булса кычкырыша да ала, күрми торса исенә дә кереп чыкмый торган иде. Сәвиянең шул минуттагы күз карашыннан югалды да калды Галәү.

Табигатьтә дә шундый хәл була: кайдандыр төшеп, язгы дым белән бакчаңда мәк тишелә. Тамыр җибәрә, үсә, чәчәккә бөреләнә. Син аңа күз дә салмыйсың. Ә бер көнне бакчаңа чыксаң... һушың китә! Мәк чәчәкләре! Түтәлеңне аксыл ал, куе кызыл мәк чәчәкләре каплаган. Күз сөрмәсе кебек күгелҗем нурлар сызылган ут кебек янып торган чәчәкләр. Кичә күз дә салмаган идем, менә син нинди матур икән дигән уйлар килә башыңа. Синең инде бакчаңнан керәсең килми. Тагын, тагын матур чәчәкләрне күрәсең килә. Синең аларны сыйпап карыйсың килә, ә үзең кулың белән кагылырга куркасың. Сәвия дә шулай кинәт ачылды Галәү өчен. Ачылды һәм кыска гомерле мәк чәчәге кебек тиз арада сүнде дә.

Класслары белән җыелып, болынга җуа атнасына төшкән көнне

булды ул. Алар ягында шундый атна үткәрү гадәте бар. Вятканың бозы китеп, язгы сулар арта башлаган чакта, шулай да әле яр буе болыннарын каплап бетермәгән, су уртасында дулкын-дулкын яшь үлән үскән коры җирләр күренеп торган атналарда була ул. Кояш нурларын, әз генә дымлы җылы яз һавасын, болыннарның яшеллеген тансыклаган авыл халкы, сабан туена килгәндәй, киенеп-ясанып су буена төшә, үзенә күрә бер бәйрәм ясап күңел ачып ала. Кармак күтәргән малай-шалайлар яр буенда йөгерешеп йөри. Болганчык суда балыкчы агайларның көймәләре тирбәлә. Кар сулары сырхау-чирләүне алып китә дип ышанган карчык-корчыклар, җир акыртып, салкын суда оныкларының битләрен юалар. Барысы да ак төпле, сыек яшел кыяклы җуалар, әчкелтем сусыл кузгалаклар җыя. Кая карама — гармун тавышы, җыр була ул атнада. Яшьләр уен уйныйлар: әйләнбәйләнә, өченчесе артык, күперле, берәү так уеннары... Иң яратканнары — берәү так. Егетләр-кызлар икешәр-икешәр тотынып тезелеп басалар. Алда так кеше тора. Арттагы рәттән чыгып йөгергән парларның берсен тотып алырга тиеш ул. Булдыра алмый икән — янәдән так кала, тагын алга баса.

Дәртеңне, көчеңне тыеп торуның кирәге юк монда. Болын тигез, болын киң. Кышның кыш буе калын кием астында алҗыган иңбашлар, парта арасында утырып оеган буыннар иркенгә чыккач кинәт язылып киткәндәй була. Яшь тәннең тыелгысыз көче сине, әкияттәге канатлы ат кебек, чиксез киңлекләр буйлап очырта. Аяклар җиргә тими, колак төбендә язгы җылы җил сызгыра. Җил куенга керә, биттән сыйпый, тамакка тыгыла. Кайнарланган тәнең буйлап, салкын су әчкәндәгедәй, рәхәт дулкын үтә. Башың артка ташлап, ике кулың канат итеп, шулай озак-озак йөгерәсе, әллә кайларга җитеп яшел үлән өстенә капланасы, җирнең дымлы салкынында назланып, йөрәк тавышыңны тыңлап ятасы килә.

Рәшидә белән Сәвия ул көнне пардан киенгәннәр иде. Икесендә дә алсу җирлеккә ак борчак төшкән кыек итәкле җиңел күлмәк, икесе дә чәчләрен ал тасма белән үреп салганнар. Артык берни дә юк үзләрендә. Олырак яшьтәге кызлар кебек энҗе-мәрҗән дә такмаганнар, иннек-кершән дә сөртмәгәннәр, табигать биргән матурлык, табигать биргән җыйнаклык кына бөркелеп тора аларда. Тик берсенең матурлыгы күңелне күбрәк тарта, яшь җанны ныграк дулкынландыра иде. Ул көнне Сәвия янында озаграк басып тору, таклы уйнаганда аның кулына орыну рәхәтен тою, куа төшкән егетләргә аны бирмичә, һаман-һаман үзенә генә алу иде егетнең уенда. Так калып, парлылар алдына баскач та ул Сәвия белән Рәшидәнең чиратын көтте. Аларга хәтле булган парларны аерырга тырышмады, юри генә куып киткәндәй булды да кире әйләнеп килде.

— Кызлар, чамалагыз! Берәрегезне эләктерергә тора ул, — диделәр егетләр.

Кызлар көлделәр.

— Галәүгә тагын! Буе озын булса да, кулы кыска бит аның, — дип үртәүчеләр дә булды.

Егет дәшмәде. Күз кырые белән арттагы рәтләрне күзәтте. Ул көнне Галәү Сәвиядән башка кешене күрми дә иде, ахрысы. Сәвия шаяруга катнашмый. Әллә искән җилдән, әллә йөрәк кагуыннан, күлмәге дерелдәп тора. Кызларга чират якынайган саен Галәүнең тынычсызлыгы көчәя бара. Менә өч пар калды, ике... Хәзер алар йөгерәчәк. Алар! Оч, Галәү! Тот алсу чәчәгеңне, күрсәт егетлек ни икәнен!

Рәшидәнең «тоттырма!» дигән тавышы ишетелде. Аннары күз алдында аның озын буе тирбәлә башлады. Галәү аны бер талпынуда узып китте дә кыйгачлап дусты каршына төшәргә уйлаган Сәвия

артыннан йөгерде. Каз мамыгы кебек җиңел гәүдәле кызны тотуы уен түгел иде егеткә. Инде эләктерәм дип сузылуы була, кыз, аны уртәгәндәй, кул астыннан шуып чыга. Рәшидә белән Сәвиянең аралары якынлаша, куллары кулга ялгана дип уйлый егет һәм, бар көчен җыеп, тагын урталарына килеп керә. Ә кызлар, төлкедән качкан каз бәбкәләредәй, тагын икесе ике якка ташлана. Шулай озак куышкач, сулуы кабып, Рәшидә сырт өстендә туктап кала. Ә Галәү белән Сәвия бик еракка, яшел болын түренә китеп уеннан аерылалар.

Галәү терсәген янбашына кыскан, җилкәләрен киереп куйган, башын артка салган, әйтерсең лә сузылып, куян артыннан чапкан ау эте. Менә-менә корбанын эләктереп алыр кебек. Инде ул Сәвиянең эзенә үк басып килә башлады. Бер мәлне, эләктерәм дип, толымына үрелгән иде, кызның чәче сүтелде, егет кулында бары тасмасы калды.

Сәвия тагын ычкынды. Әллә канатлары бар инде ул кызның! Аяклары җиргә дә тимәгән кебек. Җилгә сибелгән куе кара чәчләре җилкән кебек очыртып барамы икән әллә аны?

Ләкин Сәвиянең дә актык көче белән талпынуы булган икән ул. Кояшлы суда яшел үлән башлары тирбәлеп торган бәләкәй күл буена җиткәч, шартларга торган йөрәген учы белән басып, туктап калды. Мәк чәчәгедәй алсу иреннәре нәрсәдер әйтергә тели идеме, ләззәтләнеп салкынча су һавасын эчүе булдымы — бер ачыла, бер ябыла. Кызлар калфагына тезгән энҗе бөртекләредәй матур булып, маңгаенда вак тир тамчылары җемелди иде.

— Менә эләктердемме үзеңне, — диде егет, йөгереп килеп, аның беләгеннән чатырдатып тотып алды. Кайнар сулышы бәрелеп кызның битен пешергәндәй булды. Сәвия ялт итеп читкә тартылды, әмма ычкына алмады.

— Җибәр, — диде ул беләгенең авыртуына йөзен чытып.

— Җибәрмәсәм нишләрсең?

Кыз дәшмәде, егет кулындагы тасмага үрелде, Галәү кулын тиз генә артына яшерде. Аннары, үртәп, баш очына чөеп җибәрде дә, кыз өлгергәнче тотып алып, читкә тайпылды.

Кулны кулга тоташтырасы шушы тасмага үрелергә, алырга тырышкан һәм ала алмаган булып кыланырга, шушы гөнаһсыз балаларча уенны дәвам иттерергә кирәк булгандыр бәлки Сәвиягә. Галәүнең агач чыгарып йөргән җәйләрендә күргән кызлар егетләр белән шулай чытлыклана, юктан гына башланган сүзне дә элеп алырга торалар иде бит. Ә Сәвия, урман пәриенә караган кебек, зур кара күзләрен тутырып карап тик тора.

Бу елгы яз Сәвиягә ак тәлгәшле шомырт чәчәкләрен генә түгел, һич таныш булмаган ләззәтле, газаплы сөю хисен дә китерде. Галәүне класста күрсә дә йөрәге татлы бер сулкылдау белән тибеп куйган Сәвия хәзер аның белән япан кыр уртасында басып тора. Күңеле тулы саф хисләр, эчендәге шатлыгы бөркелеп тышка чыгар да кояштан чәчелгән нур кебек бар дөньяны күмеп китәр сыман. Үзе шундый хисләр кичерде, ә үзе шушы олы шатлыгының бер генә тамчысын булса да яраткан кешесенә бүлеп бирә белмәде. Үз хисләреннән үзе оялып, шатлыгын кара төн кебек кара күзләре төбенә яшерде.

Галәүгә кинәт бик күңелсез булып китте. Иптәшләрен ташлап шушы хәтле җир килүенә үкенү хисе кичерде ул. Еракта, яшел сырт өстендә, басып калган Рәшидәне уйлап куйды: аның белән болай күңелсез булмас иде, аның белән, ичмасам, кычкырышып була...

— Мәсәнә тасмаңны, — диде ул ачынып һәм кызыл ефәкне кызның иңбашына салды. Шартлатып, корыган ат кузгалагын өзеп алды, шуны бөтен гайрәте белән күл өстенә тондырды да олы-олы атлап китеп барды.

Икенче көнне Сәвия белән мәктәптә очрашкач, Галәү һич нинди уңайсызлану кичермәде, күңеле, берни булмагандай, тыныч иде. Бергә үткәрәчәк соңгы айлар булганга, классташларның бер-беренә якынлык хисләре арткан, юк-барга үпкәләшүләр онытылган, вактөяк гаепләр гафу ителгән, вакытны гел бергә үткәреп калырга тырышкан чаклар. Алда — аерылу. Һәркемнең үз хыялы, үз юлы. Кем белә: кайберләре бәлки тиз генә очраша да алмас. Бу көннәрдә Галәү өчен Сәвия дә бик якын, бик дус булды. Ләкин инде ул җуа атнасында кичергән хисләрне уятмый, мәк чәчәге шикелле кинәт балкып, Галәү өчен кинәт сүнгән Сәвия класстагы башка кызлар, Рәшидәләр, Фәнияләр кебек бертигез.

Ял көненә кадәр шулай булды. Ә ял көнне... Ул көнне Галәүгә абыйсы эш кушкан иде. Тыңламасаң да яхшы түгел, болай да күңеле төшеп йөргән чагы дип, Галәү риза булды. Узган атнада шушы өй хакында каты тавыш чыкты. Аталары, Галимҗанның исәбен белгәч, чыгырыннан чыгып тузынды. Йорт таратучы дип, олы улын да, әрәмтамаклар, имгәкләр дип, өйдәгеләрнең калганнарын да сүгеп ташлады. Атна буе кара көеп, беркемгә бер авыз сүз катмый йөрде. Йортта әле тагын бер малай каласы, анысына да озакламый башлыкүзле булырга вакыт җиткәне исенә килдеме, тузынсаң-тузынмасаң да, Галимҗанның үз дигәнен итәсенә, йорттан аерылып чыгасына ышанган идеме, сыкранып булса да ризалыгын бирде. Шулай да:

— Миннән ярдәм көтмә. Күгәргән кадак та бирә алмыйм. Энең барын онытма. Бу йорт та аңа калачак. Сине куган кеше булмады, үзең теләп китәсең, үзең ерып чык,— дип кисәтеп куйды.

Галимҗан атасының холкын белә, артык күпкә өмет итми, өй җиткерергә кирәк булганның вагы-төягенә хәтле әзерләп куйды. Шулай да бура күтәргәндә генә булса да ярдәм итәр дип уйлаган иде. Сәләхнең соңгы сүзләрен ишеткәч, өмете өзелеп, яңа өйгә керүнең көзгә калачагын аңлады. Кайтарткан бүрәнәләре череп ятмасын дип, кабыгын каезларга энесен җибәрде.

Бер караганда бала-чага эше генә булып күренсә дә, эчпошыргыч, кызыксыз иде ул. Җиңел дә түгел. Туктаусыз балта селтәү шактый алҗытты егетне. Абыйсы Вятка буенда сатып алган биш җәпле пәкесен бирәм дип вәгъдә итмәсә, Галәү хәзер иптәшләре белән сынауларга әзерләнеп утырган булыр иде. Юкка ризалашкан, ахры. Ул эченнән абыйсын, аңа каршы килә алмаганга үзен тиргәп, балтасын чабып куйды, брезент бияләйләрен чи бүрәнә өстенә куеп утырды. Изүләрен чишеп җибәрде, куенына рәхәт җил тулды. Галәү авызын зур ачып, күкрәгенә күп итеп салкын һава алды.

Моннан авылның түбән очы аермачык булып күренә иде. Әнә иске мәктәп йорты. Дүртенче класска хәтле Галәү шунда укыды. Хәзер анда балалар бакчасы ачтылар. Аның янында почта өе. Почта тыкрыгын үтеп әз генә баргач, Сәвияләр бакчасы. Чия куаклары төбендә китап укып утырган кызларны Галәү иртәнге якта ук күргән иде. Әле китмәгәннәр икән. Агылый белән тагылый. Ял көнендә дә бер-береннән аерылмыйлар. Укулар беткәч нишләрләр икән болар? Кеше сынауга әзерләнә. Минем өчен имтиханны Пушкин бирер дип уйлыймы әллә бу абый? Барып килим әле, нәрсәдән укыйлар икән?

Галәү әкрен генә килеп чия куаклары артына посты. Кызларның берсе яшел үләнгә капланып яткан да чыбык кисәге белән алдындагы җирне тырнаштыра, икенчесе бөтен дөньясын онытып тезенә салган дәфтәргә төртелгән. Яннарында гына егет барын сизмиләр дә.

— Ташла әле шуны. Тилергән чакта бер язып куйганмын инде, — диде Сәвия, кулындагы чыбыгын ташлап. Дустының алдындагы дәфтәрне алып баш астына салды да чалкан әйләнеп зәңгәр

күккә карап ята башлады. — Синең әнә шул тургай буласың киләме? — диде.

Галәү ирексездән күккә карады. Ни тырышып эзләсә дә, җырчы кошны тапмады, ә тавышы каяндыр эрактан-эрактан колакка кереп тора.

— Менә шушы тургай шикелле югарыга очып менсәң икән дә түбәнгә карап торсаң икән! Я балык булып диңгездә йөзсәң... Дельфин балыгы булып. Кешеләр белән бик дус дип әйтәләр аны.

— Гел хыял синең башыңда, Сәвия. Мине дә хыялый итеп бетерәсең инде.

— Чынмы?

— Чын шул. Кайчагында утырам шулай кымшанмыйча, утырам. Хыялланыйм әле бер, мин әйтәм. Утырам, утырам, башка бернинди дә уй килми бит. Барыбер кузгалмыйм. Утыра торгач, беләсеңме... Шундый бер матур егет килеп баса каршыма... Кашлары шулай, борыны мондый, авызы...

Рәшидә кулы белән бәрәңге борын, зур авыз ясап күрсәтә.

— Синең шул булыр инде, егетләр дә егетләр күңелеңдә,— дип, Сәвия Рәшидәнең кыяфәтеннән тәгәри-тәгәри көлә.

— Ә үзең соң, үзең. Сары пошлагыңны... — ди Рәшидә. Сәвия көлүдән туктый, рәнҗеп иптәшенә карый.

— Я, сук, сук миңа,— дип, Рәшидә, саксызлыгын уенга әйләндерергә уйлап, урыныннан торып йөгерә, Сәвия дә аны куа китә.

Галәү чия куагы төбендә калган дәфтәрне кулына ала, Сәвиянең көндәлек битләрен тиз-тиз актара башлый. Бер җирдә үзенең исемен күреп кала, укый: «Узган елгы ат кузгалагын өзеп суга ташлады да әйләнеп тә карамыйча китеп барды. Су өстенә очып төшкән чүп, үз дулкынында үзе чайкала-чайкала, эчкә йөзеп китте. Шунда мин үземне өзеп алынган әнә шул үләнгә охшаттым. Ташлап китте. Кирәксез бер кеше итеп, ялгызымны ташлап китте. Кинәт дөнья миңа бик күңелсез булып калды. Хыялымда ияреп юлларыма чыккан, эшләгән эшләремә булыша, кая барсам да яныма килеп баса торган кеше итеп күрә идем мин аны. Теләсә кем теләсә генә ни әйтсә дә, минем өчен ул иң матур, иң булдыклы, иң акыллы егет иде. Хыялымда мин аңа дип җырлар җырлый идем. Ә ул я агачка сөялеп, я чирәмгә утырып тыңлый иде. Хыял иде бу. Бәхетле иткән хыялый минутларым иде. Кичтән уйлап яткангадыр инде — бервакытны төшемә дә керде: без икәү ап-ак каен урманында йөрдек. «Телисеңме, Сәвия, шушы агачларны авылга күчереп утыртам», — диде ул миңа. Ә мин көлдем. «Әкияттәге Галәветдин түгелме син? Сихерле лампаң бармы әллә?» — дидем. «Юк, лампам юк минем, Ярмәкәй тавы хәтле экскаваторым бар, шуның белән бер төн эчендә...» Ул бу сүзләрне экскаватор кабинасында әйткән иде кебек. Аннары без җитәкләшеп авыл урамыннан йөгердек. Урамнарның берсендә яфракларыннан бал тамган юкә агачлары, икенчесендә ап-ак киемле яшь каеннар, өченчесендә челтәр яфраклы өрәңгеләр үсеп утыра, имеш. Урамга чыккан кешеләр сөенәләр, безгә таба күрсәтеп нәрсәдер әйтәләр, ә без ишетмибез, кулга-кул тотынып барабыз да барабыз... Төш дип тә әйтерлек түгел үзен...

Ә хәзер бар да бетте. Су өстендә тирбәлгән үлән сабагы күк, болын уртасында берүзем басып калдым. Әкияттәй матур хыял дөньясына да әйләнеп кайта алмам инде хәзер. Тылсымлы күзгемне ваткан явыз җан кебек, өнемне дә, төшемне дә чәлпәрәмә китердең син, Галәү!»

Ул төнне Галәү Сәвиягә кергән төшнең дәвамын күрде. Инеш буе

икән. Галәү тездән суга кергән дә вак балыклар тотып маташа. Каяндыр җыр ишетелгәндәй була. Шундый акрын ул моң, шундый зәгыйфь — егет аның чыннан да читтән киләме, әллә үз күңелендә туып үзенә ишетеләме икәнен дә аңлый алмады. Башта ул аны су буеннан килә дип уйлаган иде. Яр астындагы җикән камышлар кайчагында моңлы бер көй чыгарып шулай җилдә чайкалып утыралар. Билгесез моң торган саен ачыграк, йөрәккә якынрак булып ишетелә бара, бик таныш бер көйгә әйләнеп күңелне кузгата, ниндидер сәер, аңлап булмый торган тынгысыз хисләр кабындыра. Бу — Сәвия тавышы, аның җырлавы иде. Су төбеннән килә икән бу җыр. Галәү иелеп су төбен карый һәм анда Сәвиянең елмаеп торган күзләрен очрата. «Син мине каен урманына алып барам» дип әйткән идең, ди Сәвия. «Әйе, әйе, каен урманына барабыз, мин сине бик озак эзләдем, бир кулыңны», — ди Галәү. Сәвиягә кулларын суза, ә кызның йөзе ераклаша бара, ераклаша бара, менә ул вак дулкыннар арасында тирбәлеп тора-тора да бөтенләй юкка чыга.



3

Бөтен дөньяны кубарып килгән җилле-давыллы көнне булды бу. Адәм чыдамаслык эссе көн иде. Урамда бала-чага түгел, этләр дә күренми. Күләгәгә кереп посканнар да авызларын ачып, эчләре белән сулап яталар. Бәрәңге сабаклары арасында, тузанда тавыклар коена. Эссе һава өйгә үтеп кермәсен дип, кешеләр тәрәзәләрен ябып куйды, пәрдәләрне төшерде. Картларның баш әйләнеп кузгатып, яшьрәкләрнең аяк-кул җегәрен алып кояш кыздыра да кыздыра. Кинәт авылның югары башында пәри туе күтәрелде. Өй биеклеге тузан баганасы, дию пәриенең орчыгы кебек бөтерелә-бөтерелә, юлында очраган таш, агач кисәкләрен, үлән арасында адашып йөргән чебешне, тирес-салам ише чүп-чарны да эченә суырып алып, ажгырып килгән машина тизлеге белән урамның бер башыннан икенче башына үтеп китте. Аның белән генә дөнья тынычланмады. Әйтерсең лә аның монысы җитез атка атланган җиңел разведка гына булган, әйтерсең лә яуның зурысы, дәһшәтлесе артта әле. Кешеләр каралтыкура арасындагы вак-төяк әйберләрен җыештырып куярга да өлгермәделәр, күк йөзен тузанлы кызыл болыт каплады. Кояш тотылган чактагы кебек, авылны эңгер-меңгер басты. Аяктан егарлык көчле җил дулый. Кемнеңдер капкасы шартлап ачылды, кайдадыр түбә калае кубып, эчпошыргыч бер көйгә шакылдарга тотынды. Ул да булмады, караңгы күк йөзен утлы чыбыклар сызгалый башлады. Тау-ташлар ишелгәндәй бер тавыш белән күк күкрәде. Коеп яңгыр яварга кереште.

Галәүнең җәйге көтүлектәге электр саугычларын көйләп кайтып килүе иде. Яңгыр аны авылга якынлашкач, Ярмәкәй тавы астында утырган бозаулар фермасы турында куып җитте. Каршыга бәргән җилле явымнан җиңе белән йөзен ышыклап, егет фермага борылды. Биредә җил тагын да көчлерәк иде. Бер яктан Ярмәкәй тавы, икенче яктан текә инеш яры. Шул тар аралыктан искән үтәли җил зур көч белән күкрәктән этеп артка сөйри, атларга ирек бирмичә аякка урала. Галәү яңы белән торып атлый башлады. Тауның борылып киткән җиренә, тал куаклары сибелеп үскән киң итәгенә җитәргә ашыга иде. Биредә тынычрак. Җил дә, инде юашлана төшеп, елан кебек сызгырмый. Иркенләп тын алу өчен, Галәү адымнарын акрынайтты һәм шул вакытны балта чапкан тавыш ишетте. Бик җайсыз итеп, интегеп чапкан тавыш. Ток... тук. Тук... ток. Кайсы тынгысызы икән ул. Яңгыр туктагач өлгермәс идеме әллә? Нинди ашыгыч эше бар? Га-

ләү, кызыксынып, балта тавышы ишетелгән якка, ферма артына таба борылды.

Чатыр кебек җәелеп үскән карт өянке тамырларын тырпайтып җирдә ята. Калын бер ботагы ферма тәрәзәсенә төшеп, аның рамын җимергән. Ватык тәрәзәдән юеш-салкын җил керә, эчкә сузылган калын ботаклар буйлап яңгыр суы ага. Сәвия шул ботакны чабып төшерергә азаплана, әмма көче җитми. Бердән, ботак бик юан, икенчедән, биек. Югарыга үрелеп, бөтен көчкә сугарга уңайсыз. Кызның өсте манма су, чәчләре сүтелеп юеш тәненә уралган, түгәрәкләнеп килгәнияк очыннан яңгыр суы тама. Туңудан үзе дә дер-дер килә.

Галәүнең аны күкрәгенә кысасы, кочагына алып җылытасы килеп китте. Куенында Сәвиянең җылы сулышын сизгәндәй булды.

— Кая, китер әле балтаңны, — диде ул, кызның иңбашларына орынып.

Сәвия дәшми генә балтасын сузды.

— Суыкта торма, эчкә кер, — диде Галәү, аны кызганып. Болай да юеш учларына төкереп, балтасын җайлап тотты да кизәнеп ботакка сукты. Агач кына түгел, сарай стеналары да дерелдәп куйды кебек. Тагын каерылып сукты, тагын... Як-якка ап-ак йомычкалар очты. Агач ботагын алып ташлагач, икәүләп, рамнары җимерелгән тәрәзә уемын салам белән капладылар. Шуннан соң гына эчкә, бозаулар янына керделәр. Икесенең дә өстеннән шыбырдап яңгыр суы ага иде, аяк аслары шунда ук күл булды. Сәвия каравылчы картның төнлә киеп йөри торган кожанын Галәүгә сузды. Үзе дә шкаф артына кереп өстен алыштырды. Галәү янына чykканда ул җирлеге алсу ак бөрчекле күлмәк кигән, чәчләре тарап үрелгән, тагын шундый ук пөхтә, матур Сәвия булган иде инде. Тик алсу иреннәре суыктан күгәргән, ике учын бер йодрыкка кысып, аз гына калтырап тора. Галәүнең күңеленә тагын шул уй килде: кочакка алсаң, эреп кенә китәр иде бит. Иреннәрен алсу мәк чәчәгенә әйләндергәнче суырып үпсәң, ни эшләр иде икән? Сәвиянең тыйнак күз карашы гына түгел, аннан да зуррак көч тә туктата алмаслык бер ашкыну белән ул кызны кочагына алды, кайнар сулыш бөркеп иреннәренә үрелде. Шул вакыт Сәвия әкрен генә башын борды, егетнең иреннәренә аның алсуланып янган колак йомшагы тиде. Галәү әкрен генә, авырттырмыйча гына шуны тешләп алды. Сәвия егет куеныннан балык кебек шуып төште дә бозау читлекләре арасына кереп посты.

— Минә минеке булдың инде. Колагыңны тешләдем. Элек заманнарда колак тешләшкәннәр бит.

— Кирәкми, Галәү, шаярма. Яратмыйсың бит, — диде Сәвия рәнҗеп.

— Каян беләсең, әллә яратамдыр?

Егет тагын кызга омтылды.

— Беләм, кирәкми, яратмыйсың, — дип пышылдады кыз. Әмма үзе инде чигенмәде, Галәүнең юеш күкрәгенә йөзен каплады.

Әллә ни дә сөйләшмәделәр үзләре. Сәвиянең тыйнаклыгы, тартынуы Галәүгә дә авызына ни килде шул сүзләрне чәчеп торырга ирек бирмәде. Башта шул карт өянкене телгә алдылар. Үзеге корып, эче куышланып беткән иде бит. Каты кабыгы гына калган. Шул хәтле зур ботакларны ничек туендыра алды икән дип гаҗәпләнделәр. Көз җиткәч, шушы өянке үскән җиргә яшь агачлар утыртырга булдылар. Ул турыда Сәвия әйтте. Галәү каршы килмәде, агач утырту түгел, Сәвия аңа сарай салып бир дип әйтсә дә, ризалашыр кебек иде ул вакытта. Аннары Сәвия Галәүгә бозауларын күрсәтте. Озын керфекле матур күзләрен мөлдерәтеп карап яткан бу мәхлукләр, чыннан да, бик сөйкемле иде. Арадан берсе, озын торыклы, очлырак башлы бозау, Галәүне күбрәк кызыксындырды.

— Яңа породамы әллә? — дип сорады.
— Юк. Поши бозавы ул. Яз көне көтүчеләр табып кайтканнар. Анасын браконьерлар аткан ди.

Дөньяга килеп тә җитмичә ятим калган шушы поши бозавын кызганып сөйләшеп тордылар. Табигатьнең матурлыгына кул ягучы имансыз кешеләрне сүктеләр.

Шул кичне Галәү Сәвияне кинодан озата килде.

Кызлар белән йөргән егетләрнең хәлен белә Галәү. Әртилдә эшләүче яшь-җилкенчәк кич җиткәнен көтеп кенә тора иде. Төбе алтындай сап-сары ком белән түшәлгән җылы сулы Вяткада коенып, көндезге тир, тузан һәм ару-талуларын да юып ташлыйлар иде дә киенеп-ясанып күрше авылларга таралалар. «Галиябану» көеме анда, барынямы — аларга барыбер, аяклары белән балчык изәләр дип әйтерсең: баскан урыннарында бик тырыш таптанып биилар дә биилар. Төн урталары җитә. Өендә яшь хатыны көтеп калган завклуб аларны куып чыгара алмыйча интегеп бетә. Ничек кирәк алай утларны сүндереп, клуб ишегенә йозак салгач, егетләр һәм кызлар парлашып койма буендагы бүрәнә өсләренә, капка төбендәге утыргычларга, кайда аулак җир бар — шунда күчәләр. Кайвакытны авыл егетләре арасында берәр кыз өчен тавыш та чыга. Якалашуга хәтле барып җиткәлиләр. Агач чыгаручыларны бу авылга аяк та бастырмаслар дип уйлыйсың. Ә алар дуслашып та алганнар, берни булмаган кебек, кулларын шап та шоп сугып күрешәләр, бер пачкадан тәмәке тарталар. Кайвакытны егетләр карта сугып, учак янында әкият сатып яр буенда калалар. Тагын күрешергә дип вәгъдәләшкән кызлар, әчтән үпкәләсәләр дә, килсәң гаҗәп түгел, китсәң хаҗәт түгел дип, тыштан сер бирмиләр. Әртил егетләренең биредән озакламый бөтенләй китәселәрен, чынлап сөйгән ярлары янына кайтасыларын беләләр алар.

Мондый кичәләрдән Галәү дә калмый. Дөрес, биюләргә катнашмый ул. Бии белмәве бер хәл. Зуррак кызлар аны чакырмыйлар, малайсытып карыйлар. Ә аның тиңнәре үзләре дә клубның караңгырак почмагыннан чыгарга оялып, пышын-пышын сөйләшкән булып, юктан да, бардан да көлешеп, барысы бергә өелеп торалар. Шулай бер читтә тыныч кына карап утыра-утыра да Галәү, клубта уен беткәч, кайтып урынына ава. Нарат исе, дымлы балчык исенә изелеп, яшьлекнең рәхәт, гамьсез йокысына тала. Әле генә күргән кызлар төшенә дә кереп чыкмый, ичмасам.

Шулай да Вятка буена килеп эшләвенең икенче җәендә бер кыз аның тынычлыгын җуя язып калган иде.

Алар эшләгән җиргә үк килеп су трамвае туктый иде ул җәйне. Уенчык кебек кечкенә генә, ак кына, палубасы, трюмы бар, алды пыялалы штурвал будкасы бар. Шул будкада утырган яшь кенә, чибәр генә кызы бар. Кызның өстендә кара галстуклы ак блузка, иңбашларында елгачылар погоны, бөдрәләткән сары чәчләрен капитан фуражкасы каплый. Билгеле инде, кызлар күрсә, егет халкы тик тормый. Су трамваеның килеп туктавы була — салчы егетләр билләрен турайталар. Штурвал тоткан кызга шаян сүзләр әйтәләр, көлдермәкче булып такмак сибәләр, маймылланып биеп алалар. Ә трамвай йөртүче исә ник күз салсын үзләренә. Аның бар игътибары — ярга төшерелгән басмада. Капчыклы агайлар, кәрзинле апалар, рюкзаклы егетләр ул карап тормаса чыга белмиләр дип әйтерсең. Менә актык кеше үтеп китә, басманы әчкә тартып алалар, шуннан соң гына кыз, күңелегез булсын инде дигәндәй, егетләргә бер елмаеп куя, кәефе әйбәт чак булса, кулын селтәп саубуллашкандай итә. Кыска гына гудок биреп ала да, аккош йөзгән кебек, матур гына борылыш ясап китеп бара. Һәр көн шулай. Түбән төшкәндә бер, әйләнеп килгәндә икенче очрашалар.

Көннәрдән бер көнне Галәүгә шушы су трамваена утырып, үзләре эшли торган җирдән ун чакрым еракка, базарлы авылга барып кайтырга туры килде. Палубага менеп җилгә күкрәген куйды да бар кешедән өстә, югарыда утырган капитан кызның ашыкмыйча, каушамыйча, штурвал тәгәрмәчен ничек боргалавын, бу уенчык корабны вак утраулар, су уртасындагы комлы сыртлар арасыннан оста итеп алып баруын сокланып карап тора башлады.

Әзмәвердәй кешеләргә сыңар күзен дә салмаган бу тәкәббер кыз бакыр башлы егет кисәгенә игътибар иткәндер дип кем уйлаган. Ә ул күптәнге танышын күргәндәй елмаеп карады. Бер тукталышта сөйләшеп тә тордылар.

— Кара әле, егет, синең иптәшләрең гел шулай шамакайланалармы?

— Юк, матур кызлар күргәндә генә.

Егетнең җавабы ошады, ахры, ул кызарып китте:

— Матур кызлар күп булыр, — диде.

— Аларына икенче төрле концерт күрсәтәләр.

— Талант бар икән, алайса!

— Ходай рәнҗетмәгән.

Шул сөйләшүдән белеп калды Галәү: кыз Юлия исемле икән. Икенче җәй инде су трамваен йөртә. Ленинградтагы суднолар төзү институтына укырга кермәкче.

Аннары Галәү Юлиянең килгәнен көн саен диярлек көтеп ала башлады. Ул аны бер дә исеннән чыгармыйча туктаусыз уйлап та тормый үзе, һәрчак җаны тыныч була. Ә менә күңел түренә бер кечкенә сәгать утыртып куйганнар да кызның килер вакыты җитүгә шул сәгать сугып куямыни. Тик торганда кылт итеп исенә килеп төшүгә, егет башын күтәреп су өстенә карый. Акрын гына йөзеп борылмадан килеп чыккан су трамваен күргәч, үзалдына елмаеп куя. Инде Юлия егетләр ягына караса, аның өчен генә карыйдыр, барысы арасыннан аны гына эзләп табадыр, елмайганда аның өчен генә елмаядыр кебек тоела иде Галәүгә. Флагштокта җилфердәп барган ак флагны да ул Юлиянең ерактан яулык болгавына ошата иде. Ә менә авылга кайткач, онытты шуны.

Әмма... Сәвия белән үзенең арасын аңлый алмый бик аптырады ул.

Бер-берләрен эзләп тә йөрмәделәр, югыйсә. Болында очрашканнан соң, әле Сәвия Галәү белән ялгыз калырга да уңайсызлана иде. Үзе башлап сүз дәшми, сораганына гына җавап кайтара. Ә менә язмыш очраштырды да торды үзләрен. Җәй көне чия бакчасында... Аннан соң ферма өендә. Очрашкан саен Галәү Сәвиягә ныграк бәйләнә барганын сизде. Бу кыз аны әкрен-әкрен үз иркенә буйсындыра бара иде, ахры.

Давыл еккан карт өянке урынына агач утырту турында сөйләшеп утырганда берсүзсез риза булган иде. Бер-ике төп агач егет кеше өчен нәрсә ул, шәһәр салырга да риза иде ул чакта Галәү. Ә кызның хыялы аның белән генә чикләнмәде. Ярмәкәй тау битеннән башлап, инеш ярына хәтле булган бөтен җирне урман итәргә уйлый иде ул. Кайсы китаптан укыгандыр, кеше үз гомерендә бер генә төп булса да агач утыртырга тиеш, әгәр шулай булмаса, ул үзен утын агачы дип санасын, дигән сүзләрне отып алган. Безнең илдә ике йөз илле миллионнан артык халык бар, ике йөз илле миллион агач үзе бер тайга бит ул дип, әле утыртылмаган урманны уйлап куана. Хыялның йөгәне юк анысы, канаты гына бар, шуңа күрә ул күбрәк һавада очып йөри, мәшәкатьле җир йөзенә сирәк куна, дип уйлый Галәү һәм, аныңча, теләсә нинди эшне дә бушка эшләп йөрү — ул үзе әрәмгә үткән вакыт. Бердән, кешенең үзенә файдасы юк, икенчедән, ул ки-

рәкле эш түгел. Кирәк булса аны колхоз үзе нәрәтен биреп, эш хакын түләп, законлы итеп башкарыр иде. Колхозларның хәле әйбәт хәзер, өмә белән эш эшләтүгә калмаган. Планга кермәгән, нәрәттә каралмаган икән, әлегә бу эшнең кирәге юк дигән сүз. Шулай дип уйлап, бу эштән калырга җай эзләде Галәү, әмма күңеле карышса да, бөтен авыл яшьләре кузгалган көнне ул да өйдә утырмады. «Йөрисең шунда юкны бушка аударып», — дип, атасы мыгырданып калды. «Бозаулар фермасына йөри-йөри, үзең бозауга әйләнмә», — дип, абыйсы Галимҗан да авыз ерды. Канга шулай тоз салгач, егетнең кәефе әйбәт түгел иде, әлбәттә; ләкин иптәшләре арасында күңеле ачылды тагын. Сабан туе, җуа атнасындагы кебек уен-көлке, җыр-бию, көзге саф һаваны яңгыратып көлү иде монда. Кызлар көлүе бигрәк матур. Агач ботакларын сарган пәрәвез җепләренә көмеш кыңгыраулар элгәннәр дә аз гына җил исеп ботакларны селкеткән саен, шул кыңгыраулар чыңгылдап китәләр кебек. Машинага төялеп, алтын-сары, комач-кызыл төсләр кергән урманнан агач төпләп кайту үзе бер кызык булды. Барыннан да рәхәте Сәвиянең янда булуы иде.

Агачларны ни әйтәсең — өйрәнелгән мохитләреннән аерылсалар, кешеләр дә үзләрен җайсыз сизәләр. Галәү дә шундый чирне кичерде. Укытучыларыннан, иптәшләреннән аерылгач, сәлперәеп утырган агач кебек боегып калды. Юкса, бу көнне дүрт күз белән көткән иде бит. Укулар беткәч, җилкәсеннән тау төшкәндәй иркенәеп калыр кебек иде. Мәктәптә укытучылар, өйдә атасы белән агасы иркенә биреп, алар кушканча, аларга охшаганча гына яшәү дә туйдырган иде. Үзен олы кеше, мөстәкыйль кеше итеп сизәсе килде аның. Дөнья мәшәкатьләрен бөтен авырлыгы белән иңенә алырлык ир-егет булып килә бит инде, формулалар ятлап, класстагы кызларны үртәүдән тәм табып, шаянлыгы белән укытучыларның теңкәсенә тиеп беткән яшүсмер чагы түгел. Кесәсендә урта мәктәп аттестаты, шуның янында электрик һөнәренә таныклык. Үзеннең әле генә йомыркадан чыккан йонсыз чебеш булмавыны бөтен дөньяга танытасы иде лә.

Ә иркенлек, Галәү көткән хөрлек алай тиз килмәде. Ул үзен әле дә булса өйдәгеләрдән бәйле саный иде. Алар көн дә Галәүнең колак итен ашыйлар: «Пәтих әнә Зәйни кызын читавыт иткән. Син гена авыз ачып йөрисең, арурак эш сорап кал, йомыкый. Иликтрик язуын кесәдә таушалдыру өчен генә бирмәгәннһрдер бит...» Нишләсен ди Галәү, сорап та бирмәгәч, тартып аласыңмыни ул урынны. Тәхет өчен көрәшүче патша малае түгел лә ул.

Атасының Пәтих дигәне аларның элекке тарих укытучысы. Бер елны колхоз председателе итеп куйганнар иде, шуннан бирле әйбәт кенә эшләп килә. Район гәзитләрендә басылган сводкаларда колхозларының исеме астан өскә таба күчте. Авылдашларының күбесе үзендә укыган кешеләр булганга, кайсын нинди эшкә куярга кирәген дә бик белә. Шулай дип уйлап йөргән Галәүне председательнең бер эше гаҗәпкә калдырды. Рәшидә мәсьәләсендә түгел. Бу мәсьәләдә Галәү үзе дә килешә. Рәшидәнең идарәгә хисапчы булып киләсе сынаулар беткәнче үк билгеле иде инде. Килсә дә килә бит бәхет кешегә, тир түкми, бил бөкми, счет төймәләрен шалт та шолт китереп, өстәл артында утыра хәзер. Сәвиягә генә рәтле эш бирмәде Фатыйх абыйлары, бозаулар фермасына илтеп тыкты. Үзенең иң яраткан укучысын, классның иң башлы кызын, теләсә нинди институтның ишеген төбенә хәтле каерып ача алырлыгын... Болай булгач, Галәүгә әллә ниләр өмет итәр урын калмый.

Яз көнендәге ашкыну урынына егетнең күңелен түзеп булмаслык әч пошу биләп алды. Ялгызлык хисе дә җанны ашый иде. Армиягә

хәтле берәр җиргә барып, акча төшереп кайтасымы әллә, дигән уйлар күңелгә килә башлады. Бөтен җаны-тәне белән авыл малае иде ул. Авылының тыныч, тын табигатен ярата, җылы тузан белән яңа сауган сөт исе, бөтнек исе тулы кичләрен, яшел үләннәргә абына-сөртенә йөргән каз-үрдәк бәбкәләрен, бакча башларына муенчаклап җибәргән моңсу карашлы яшь бозауларын ярата иде. Вятка буенда эшләгән җәйләрендә шуларны сагынып үлә иде. Хәзер дә ул авылны ташлап китә алмаслыгын аңлый, ләкин...

Галәүнең дә бәхете йоклап ук бетмәгән икән. Борын салындырып йөргән көннәренең берендә аны Фатыйх абыйсы чакырып алды. «Карап-карап йөрдем мин сиңа, авылда төпләнергә исәбең барлыгын сиздем. Ялгышмаган булсам, әйдә, тотын, иртәгәдән электрик булып эшли башла», — диде ул.

Ялгышамы соң? Председательнең күңеле сизгер аның. Сәвия хакында гына бераз ялгышты... «Әйдә, кемдә булмый алай гына. Сәвиянең үзенә ошый бит, эшләсен ошагач», дип уйлаган егет соңыннан, кыз белән дуслашып йөри торгач, анысының да сәбәбен белде. «Ферманы кулыңа ал. Берәр ел бик әйбәтләп эшләп кара, әгәр чыннан да ошаса, институтка үзем барып урнаштырып кайтырмын. Дөньяда иң күп сөт бирә торган сыерлар токымы кирәк безгә. Шуңа өйрән»,— дип киңәш биргән аңа Фатыйх абый. Анысы да шундый бер хыялый кеше. Сыерның сөте телендә икәнен белмимени инде ул? Шуның өчен генә биш ел укып йөрүнең кирәге бармы икән? Сәер кешеләр алар — Сәвия дә, Фатыйх абый да. Шул сәерлекләре белән үзләренә карата-лардыр да әле. Сәвиянең дә шул гадәте ошаттыра түгелме соң? Кызык иде аның белән. Җил исүен дә тыныч кына тыңлый алмаган кыз белән сөйләшеп йөрүләре нинди рәхәт иде! Яфраклар кыштырдавын, Сәвия кебек, гашыйкларның серле пышылдавына да ошата белми үзе. Ни тырышып эзләсә дә, зәңгәр күк йөзеннән ак җилкәнле ак кораблар да күрә алмый. Ә Сәвия «күрәм!» ди. Ак болытларны ул биек-биек тауларга да, чабып барган атларга да, бозлар патшасы саналган ак аюларга да ошата ала.

Яңа җирдә чирләп утырган агач, ниһаять, тамыр җибәреп, бәрәкәтле туфракның шифалы суын эчә башлаган кебек, Фатыйх абыйсы яныннан чыккач, Галәү дә, рухы күтәрелеп, каштан чәчле башын югары тотып йөри торган булды. Ул инде авылның бик кирәк кешесе. Күбесенең аңа эше төшә, аның җае, вакыты белән хисаплашырга мәҗбүрләр. Хәзер ул урамның кыл уртасыннан йөри. Резин итекләренең кунычын тубыгына кадәр кайтарып кигән, техас курткасын киң каеш белән буган, каешында әрекмән яфрагы хәтле зур резин перчаткалар. Җилкәсендә үткен тешле тимер «мәче». Плакатлардагы рәсем төсле, шулай шартын китереп киенүе аның — Сәвия өчен. Бер вакытны ул, сиңа шулай бик килешә, дип әйткән иде. Ә егет бу сүзләрне, мәхәббәт теленә күчереп, мин сине шул кыяфәтеңдә яратам, дип аңлады.

Яшьлекнең шунысы кызык: сөйләшәсең, сөйләшәсең, сөйләшеп сүзләр бетми. Телең бер төрле әйтә, ә күңел аны үзенчә юрап, үзенчә кабул итә. Кайчагында дәшми генә утырасың. Алай да рәхәт. Бу дөньяның барлык тынгысыз уйлары кайдадыр бер чик артында торып калган. Моң тулы, наз тулы күңелгә андый уйлар сыймый бу минутларда. Таң җиле китергән чыклы үлән исеннәнме, икең бер җан булып утыру ләззәтеннәнме исереп, мәхәббәт диңгезенең тылсымлы дулкыннарында акрын гына чайкаласың да чайкаласың. Багана башындагы утлар инде әллә кайчан сүнгән. Авыл өйләре таң алдының куе караңгылыгына күмелгән. Әтәчләр дә йокыларыннан бер уяныш тавыш биреп алалар да мәгънәсез түгәрәк күзләрен тагын йомалар.

Бервакытны шулай утырганда каршыдагы өйдә ут алдылар. Нуры сүнгән күз кебек ике тәрәзәдә сүрән яктылык күренде.

— Мәүлихә әби, — дип куйды Сәвия, экият дөньясыннан әйләнеп кайткандай сискәнеп.

— Намаз укырга торгандыр. Карчык кеше бит.

— Шулайдыр шул. Утсыз интегә. Я керосины булмый, я лампа куыгы таба алмый. Читен бит ялгыз карчыкка, — диде кыз, күрше карчыгын кызганып. — Фатыйх абыйны да әйтер идем инде.

Колхозлары зур яхшылык эшләде Мәүлихә карчыкка, сүз дә юк. Тик җиренә генә җиткереп бетерә алмады. Ятим карчыкка сап-сары бүрәнәләрдән җыйнак кына итеп өй салып бирде, шунда бер кулдан ут кына үткәреп куя алмады. Әзмени колхозда яңа өй җиткерүчеләр. Барысына да ут кирәк. Кайсының бала-чагасы күп, дәрес карыйсы бар. Кайсысы туй итәргә җыена, утсыз — ике күзсез. Берәүләр таңнан торып эшкә бара, аңар ничек ут бирмисең. Табыла инде сәбәп. Шулай сабыр гына көтеп торган Мәүлихә әби кала да кала. Ул йөдәтеп йөрми. Өе өчен дә бик канәгать ул — изге теләкләрен тели-тели дога кыла.

— Фатыйх абыйга үпкәләп булмый анысы, — диде Галәү, председательне яклап, — эш күп бит, электриклар җитми.

— Галәү, әйдә бер яхшылык эшлибез шул әбигә.

Егет сагая калды.

— Нинди яхшылык?

— Ут кертеп бир син аңа.

— Нәрәт бирмиләр бит, нәрәт булса — мин әзер.

— Ә син болай гына, эштән соң килеп... Ә?

— Әйбере булса...

— Аңар күпме кирәк инде. Ишектән түргә җитле биш адым. Складтан үзем яздырып алырмын.

— Сорап йөрмә. Табармын.

Икенче көнне кичкә таба икәүләп Мәүлихә карчыкка ут керттеләр. Егет эшләде, кыз аңа булышып торды. Әле чүкечен суза, әле кадак бирә, я чыбык очын тотып тора. Куллары шундый җитез йөри, Галәү сораганны да көтеп тормый, кирәк әйберне үзе белеп бирә.

— Операция ясаган кешеләр кебек без, әйеме, Галәү, — ди үзе тагын хыялга бирелеп, — син хирург ди, ө мин синең ассистентың.

— Укырга китсәң, син үзең хирург булып кайтыр идең әле, китмәдең бит, — диде егет һәм әйткән сүзеннән каушап калып, шөребен шундый каты итеп борды, ролик дигәне чатнап идәнгә коелды. — Ярый әле, китмәгәнсең, хирург булсаң, безнең ишеләргә әйләнеп тә карамас идең.

Сәвия, чыннан да, хирург булып кайткан диярсең:

— Карамаган ди. Хирурглар да электриклар йөргән юлдан йөри бит. Профессияләре генә ике төрле,— диде ул, Галәүне юатып.

Мәүлихә карчык яшьләрнең эшенә дә, сүзләренә дә катнашмады. Мыштым гына чәй әзерләп йөрде. Чоланнан капкачлы таш савыт белән бал, түгәрәкләп төргән алма кагы алып керде. Шикәр савытына җир җиләге рәсеме төшерелгән кәгазьле конфетны учлап салды. Кара җимешен дә чыгарды. Котү кайткач, кәҗәсен савып керде дә бер савыт җылы сөт китереп куйды. Самаварын ике-өч кат яңартты. Кече як сәке өстендә намаз да укып алды, дисбесен тарта-тарта, Галәү белән Сәвиягә хәерле тәүфыйклар, бәхет-сәгадәтләр теләде. Яшьләрнең эше тиз генә бетмәде. Карчык инде йокымсырап бара иде, өйдә кинәт гөлт итеп ут кабынды.

— И рәхмәт төшкерләре, бәхетегез мул булгырлары. Аягыгыз-кулыгыз сызлаусыз булсын инде, мин-карчыкны сөендергән өчен,

ходай үзегезне сөендерсен, — дип сөйләнә-сөйләнә, яшьләрне чәйгә чакырды. Яшьләр утырырга теләмәде.

— Мәүлихә әби, хәзер әнине кертермен, электр яктысында сөйләшә-сөйләшә икәүләп чәй эчәрсез, без бик ашыгабыз, үпкәләмә инде,— дип, Сәвия нәүмиз булып калган карчыкны юатты.

— Алайса, ни инде менә... аяк ялы булсын, — дип, Мәүлихә әби Галәүгә биш сум акча сузды.

Алып кесәсенә салганда ук Сәвиянең йөзе караңгылануын сизгән иде егет. Чынлап үпкәләве булган икән.

— Бөтен шатлыгымны бетердең, — диде, урамга чыккач.

— Нәрсәсе бар аның, эшләгән хакы гына бит, — диде Галәү, кызның кәефе кырылуга сәерсенеп.

— Ире, ике улы сугышта үлгән ятим карчыкның акчасына кызыкмасаң!

— Я инде, чәенә дә утырмадык, акчасын да алмасаң, үзе үпкәләр иде бит.

— Акланып торган була тагы!

— Бер мин генәме әллә, бөтенесе шулай ала.

— Кеше суга төшә дип син дә төшәрсеңме?

— Дурак дип белдеңме әллә син мине?..

Бу көнне алар үпкәләшеп аерылыштылар.

Ак пароходлар гына йөзеп йөрми икән зәңгәр күктә, кара болытлар ишелеп, дөньяны каплаган чаклар да була икән. Әй, син, мәхәббәт алласы! Шундый чакта, утлар чәчеп принциплар бәрелешкән вакытта, син дә артыңа борыласың, ахры. Икедән берсенең кулына ак яулык бирергә синең дә көчең җитмимени соң?

Сәвиянеңниләр уйлавын, нинди утларда януын Галәү белмәде. Ә үзен ул бер дә юкка рәнҗетелдем дип саный иде. Урламады, таламады, эшләгәненә күрә ризалык белән бирделәр. Телгә алырлык зур сумма булса икән, биш йөз түгел, илле дә түгел, биш тәңкә бит, нибары биш тәңкә. Биш тапкыр нәләт суксын икән аны, нәләт! Сәвиянең күз алдында ук ертып ташлыйсы калган булмаса. Аның белән генә араны төзәтеп булыр идеме икән соң?

Төзәлә торган булса, Галәүнең бу акчаны ертырга көче дә җитәр иде бәлки. Ә болай...

Әллә гомер буе кулына акча кермәгәнгә, шушы кыштырдавык, рәсемле кәгазьгә кызыгып җаны чыгар дәрәҗәгә җитә иде. Бәләкәйрәк чагында ун тиен, унбиш тиен түләп, мәктәп буфетыннан әйбер сатып алучыларга кызыга торган иде. Озын тәнәфес булдымы, дөбер-шатыр килеп, малай-шалайлар шунда йөгерә, шикәргә катырган төче күмәч, өстенә колбаса куйган ипи телеме алалар, баллы су эчәләр. Ә Галәү әнисе төреп җибәргән майлы ипиен чәйнәп класста утырып кала. Әй, шул чакта уфтанулары... Тагын бер вакыйга хәтерендә бик калган.

Бишенчене бетергән елны аларны класслары белән рәсемгә төшерделәр. Буе бәләкәй булганга фотограф аны алга, класс җитәкчесе янына ук утырткан иде. Шундый да ачык чыккан — сипкелләрен берәм-берәм санарлык. Бер атнадан карточкаларны ясап китерделәр. Балалар аны шунда ук егермешәр тиенгә сатып алып бетерде. Акчасын икенче көнне китерермен дип, Галәү дә берсен алып кайтты.

Кул яссуы хәтле генә шушы рәсем күп сүзләргә сәбәп булды ул кичне. Иң әлек, акча кадерен белмисең дип, атасы тузынды, гомер буе эшләп тә өстеннән брезент кожан төшмәвен йөз дә әллә ничәнче кабат искә алды. Аннары, күкәй урлап сатма, матри аны, санап куям, дип кисәтте. Галимҗан абыйсы алай тузынмады, кызып китә торган гадәте юк анысының. Көлеп кенә бер-ике сүз әйтсә дә, үзәгеңә үтәрлек итеп әйтә:

— Шул сипкелләреңне акча түләп карамакчы буласыңмы әллә, тиле?! Әнә, көзге бушлай күрсәтә. Җаның теләгәнчә кара. Ишек төбендәрәк торсаң, Николай патша портреты хәтле булып күренәсең.

Ул төнне Галәү елый-елый йокыга китте дә иртәгесен рәсемне кире китереп бирде.

Фотограф әллә кызганды малайны, әллә инде алып китеп нишләтәм бу рәсемне дип уйладымы, Галәүнең кулына аны бушлай тоттырды. Шул көнне Галәү, үсеп кенә җитим, берегезгә бер ялынычым төшмәс, күп итеп акча эшләрмен, дип, үз-үзенә ант итте.

Җәй көне абыйсы белән Вятка буена китүенә сәбәп буй үстерү теләге булса, аннан да көчлерәге, аның үзе генә белгәне — күп итеп акча эшләү иде.

Беренче елны Галәүне абыйсына ияреп килгән үсмер малай итеп санадылар. Эшнең дә малайлар көче җитәрлеген генә кушалар иде. Билгеле инде, эшенә күрә ашы була. Акчасы да артык күп таммый иде. Үз кесәсенә төшеп ятса, бәлки анысы да куандырган булыр иде. Ләкин Галәүгә кул гына куярга кушалар, хезмәт хакының аңа тигән өлешен дә агасы бөтереп үз кесәсенә салып куя торган иде. Эх, шул чакта абыйсының кесәсенә кызыгып карап торганнары!

Гомер буе кеше кулына карап яшәргә димәгән бит инде. Кесәсендә биш сум акчасы да булмагач, егет кешемени ул?! Аның үз уйлары, үз планнары булуы бар. Ә егеткә әле булса акыл өйрәтәләр. Дулкын чәчле бу матур башы аның үзенчә дә уйлый белә ләбаса, кызлар кызыктырыр өчен генә йөрми ул егет җилкәсендә.

Җеннәре шулай котырта торгач, Сәвия белән очрашмый йөрүләре шактый озакка сузылды. Ул көннәрдә Сәвия клубка я бөтенләй чыкмый, чыкканда да Рәшидәдән бер минутка да аерылып тормый, Галәү ягына борылып та карамый, күрсә дә, күрмәгәнгә салыша иде.

Сирәк-сирәк кенә күзләр очрашкан арада Галәү Сәвиянең карашында әрнү генә түгел, бик тирәнгә яшеренгән, үзәкләрне өзәрлек сагыш та күрә. Сагышлы күз карашы... Шулар Галәүне котыртып торган җеннәр белән сугышка чыгалар, аларның көчләре арта бара, арта бара, җеннәре җиңелә бара, җиңелә бара...

Һәм бер көнне егет Рәшидәне күрә:

— Килештер әле безне...

— Синең турыда уйлап та карамый инде ул.

— Ник?!

— Мин теләгән кеше булып чыкмады ул, дип әйтә.

— Минме?..

Горурлыгына тиюдән, үртәлүдән егет әйтер сүзен әйтә алмыйча тотлыгып кала, кып-кызыл булып кызара, йоклап беткән җеннәре тагын баш калкыта.

— Әйбәтләрен тапсын, алай булгач!

Аларның яңадан дуслашуына бозаулар фермасының тузып беткән электр үткәргечләре сәбәп булды. Үкенечкә каршы, баштан акылны алырлык фаҗиганең сәбәбе дә шул иде.

Колхозның өлкән механигы бер көнне Галәүгә терлек абзарларындагы электр үткәргечләрен карап чыгарга кушты. Егет үзе сыер абзарларына барып, Сәвия эшли торган җиргә ярдәмчесен генә җибәрергә булган иде. Вакыты килеп җиткәч, кире уйлады. Тимер «мәче»сен иңбашына утыртып, бозаулар фермасына китте. Күрәсе килмәгән кешенең күзенә керергә кирәкми дип, җеннәре котыртып торганда Сәвия янына иң башлап үзе килүе читен иде егеткә. Шулай да горурлыгын җиңәргә тырышты. Аны күрү өчен булса, ике аягым-

ның берен атламас идем. Эш куштылар бит. Сәвиягә әйләнеп тә карасым юк, үзе эндәшмәсә, сүз дә кушмам дип, кәҗәләнеп маташкан шул кире беткән җеннәрен дә тынычландырган булды.

Ялгыз җирдә ике яшь очрашса, аларның бер-берләрен яратулары хак булганда, сер бирәсе килмәүдән генә хисләрен тыярга тырышып торганда, ике арада сүз чыкмый каламы соң? Электр чыбыкларына гына түгел, аларның өзелә язып калган күңел кылларына да сынау булды бу көнне.

Дөрес, эшен дә онытмады егет. Фермаларда электр чыбыкларының тузган булуын, күз җитеп, кул тимәгәнгә генә алыштырмый торылуын ул болай да белә иде. Моннан ун еллар элек үткәрелеп тә алыштырырга кул җитмәгән, каралып беткән, урыны белән роликларыннан чыгып салынгалап торган чыбыкларны җиңел кулдан гына рәтләп куярлык түгел иде. Акт язды да Галәү, сырлап-сырлап кулын куйды, Сәвиядән дә кул куйдырып алды. Аның уенча кул яссуы шушы зәңгәр кәгазь шул кичне үк өлкән механик өстәленә килеп кунар да күптән эшләнергә тиеш эшне кузгатып җибәрер кебек иде.

Бәндә юллый, язмыш юрый дигәндәй, ул көнне Галәү өлкән механикны күрә алмады. Районга бер атналык семинарга киткән дип әйттеләр. Егетне күрше авылдагы бригадага җибәрделәр. Ике көннең-көн буена мәктәпнең физика кабинетына көндезге яктылык бирә торган лампалар куйдылар. Инде эшләре бетеп килә иде, бервакыт Галәүнең кул астында эшләүче егет:

— Бер җирдә эш бар, килгән көе кул шомартып алабызмы әллә? — диде. Иптәшенең икеләнеп торуын күргәч, — акчалы эш, — дип өстәде.

Аның соңгы сүзе Галәүне уйга калдырды. Ике авыл арасын таптау туйдырган иде инде. Ни рәтле йокы күргән юк, иртүк торасың да шунда чабасың, ни иптәшләр белән очрашып булмый, эт булып, арып кайтасың. Сәвия турында әйткән дә юк инде. Түзеп торуына әле дә аптырый Галәү. Бер уйласаң, кулга керә дип торган егерме-утыз сум да кесә төбен тишмәс кебек. Сәвия белән дуслаштым дип, үз принципларыннан ваз кичәргә җыенмый иде ул. Тик моны кызга белдермичә, яңадан үпкәләшүгә сәбәп булмаслык итеп эшләргә кирәклеген уйлый иде. Үзе юкның күзе юк диләр бит, башка авылда аның ни эшләп йөргәнен Сәвия каян белә. Кул астында эшләүчене ныгытып куйсаң ул әйтмәс, шайтан кебек үзе котыртып йөри бит.

Яңа алынган эш шактый катлаулы булып чыкты. Җитмәсә, мәктәп директоры эшне озакка сузасыз дип көйсезләнә башлады. Ул арада фермадагы эшне башларга дигән әмер килеп җитте. Кырыкка ярылырдай булды егет. Читтән алган эшне ташлап китәргә дә уйлаган иде, куен кесәсенә кереп яткан шытырдавык кәгазьләрне кире чыгарып бирәсе килмәде. Кул астында эшләүче иптәше белән киңәштеләр дә Галәү эшне төгәлләргә, ә иптәше фермага кайтып эшли башларга ниятләделәр.

Ярдәмчесе үткен егет иде, Галәүнең мәктәп эше белән калуына өлкән механикны ышандырып бетергән. Кичтән килеп сөйләп китте: фермадагы иске чыбыкларны кубарып алганда Сәвия, үзең генә эшләсәң, озакка сузарсың инде, Галәү кайчан кайта соң? дип аптыратып бетергән. Көннәрнең кыска чагы бит. Керосинлы фонарь белән эшләве читен дигән була икән. Галәүнең үзенең дә күрәсе килеп ашкынуын беләме икән ул кыз? Әллә ут булсын өчен генә көтеп торуымы? Аңар ышаныч юк, фермасын артыграк күрәдер әле, сәер кыз бит ул. Кинәт кенә Галәү үзендә көнләшүгә охшаш бер хис тойды. Рәтле кешеләр сөйгәннәрен егетләрдән көнлиләр, ә мин, тиле, бозаулардан көнлим дип үзен үртәп алды. Шулай да Сәвиянең шатлы-

гына сәбәпнең бары тик үзе белән очрашудан гына тууын тели иде ул.

Эш бетергән кичне авылга бик соң кайтты. Өйдәгеләр мунча ягып торган икән. Озак итеп, кат-кат чабынып мунча керде. Иртәгесен Сәвия янына өр-яңа кеше булып барырга тели иде.

Төн урталары җитә дигәндә абыйсы кайтып керде. Ул инде бөтен буш вакытын авылның түбән очында, Сәвияләрнең бакча башындарак салынган яңа өендә үткәрә башлады. Яңа елны үз өендә каршыларга тырышып йөри.

Чоланда көндез Галәүнең иптәше калдырып киткән тимер чыбык бәйләмнәрен күргән икән. Ишектән керүгә шул турыда сүз башлады.

— Әллә энекәш минем өчен тырышып йөри инде? Проводлар алып кайткан.

— Сиңа, ди, көтеп тор. Үзең яздырып алырсың әле, — диде Галәү, агасының тел төбе кая барганын аңлап. — Фермага ул.

— Бозаулар фермасынадыр инде?

Бу юлы Галәү өчен атасы җавап бирде:

— Шуңа булмый, кая дип беләсең. Аның бар тапканы хәзер Альтап кызында булыр инде.

Атасының гаделсезлеге күренеп торса да, Галәү каршы сүз әйтә алмады, шуңа үртәлүдән бүртенеп, ачулы күзләрен түбән төшерде. Галимҗанның эшне үпкәләшүгә җиткерәсе килми иде, энесен сул кулы белән кочып алды да, атасына сиздермичә генә, исең китмәсен лә дигәндәй, күз кысты.

— Башмакчының башмагы юк дип әйтәләрме әле? Мин дә шуның ише инде. Энем электрик була торып, өемә ут кертә алмый йөрим. Әйдә, малай, эшлә әле бер яхшылык, ут кертеп ташла әле иртәгә.

— Иртәгә булмый. Фермага нәрәт бирделәр. Материалларың да юк бит әле.

— Аннан эш тормас. Материал булыр диде Фатыйх абый. Иртәгә үк сорап алырмын. Тик син эшли башла.

— Башта ал, аннан сөйләшербез.

Сәләхи тагын улларының сүзенә катышасы итте:

— Ай-яй, закунный. Синнән башка белмиләр ди ул закунны. Пычагым булганмыни ферма утына. Моңарчы торды бит әле. Тагын бер-ике көн торыр.

Торыр... Галәү дә шулай дип уйлаган иде бит. Әллә чыннан да Галимҗан агасына барырга инде. Ул бик яхшы аңлый: агасының төп йорттан тизрәк чыгып китәсе килә. Төпчек малай булмаса, ул үзе дә биредә калмас иде. Әллә чыннан да, агасы әйткәндәй, бер яхшылык итәргә инде. Ярдәмчесе үзе генә эшли тора ла. Сәвия белән бер генә көн күрешми торырга була. Сагындырды инде сагындыруын, сер бирмәү дә ярап куя торгандыр. Әнә, Галимҗан агасы хатынын ормый-сукмый, кыерсытмый, кеше күрмәгәндә эшенә булышкалый, ә шулай да артык иркәләп тә бетерми. Галәүгә дә аның кебек булырга кирәкмиме икән?

Шулай да ул җиңел генә бирешәсе итмәде. Ризалашканга хәтле абыйсын үртәп, бераз җанына тиеп аласы килде.

— Бир миңа электр белән кырына торган машинкаңны. Бирсәң барам.

Бу хәтле сөмсезлекне Галимҗан энесеннән көтмәгән иде. Ни әйтергә белми ык-мык итте.

— Бигрәк инде син... Чит кешегә эшләгән кебек,— дип куйды. Аннары кыза төшеп: —Андый хакка мин любой кешедән эшләтәм,— диде.

— Эшләт.

Беразга сүз киселеп торды. Эредән кубып, теләсә кемнән эшләтәм дип әйтсә дә, Галимҗан чарасыз утыра иде: чит кешегә ялынсаң егерме сумлык машинка гына түгел, артыгы белән чыгып китәчәк. Аннары әле ул арада гына кешесен каян табасың. Колхоз куйган чиратны көтсәң озакка китә. Энекәшнең җаен тапмый хәл юк, эшен эшләткәч күз күрер әле.

— Әйдә, миннән булсын яхшылык, — дип кулын селтәгән булды Галимҗан. — Иртәгә ут кертеп бетерсәң, машинка синеке.

— Юк инде, агаем, иң элек хакын түлисең. Беләм мин сине, эшеңне эшләтер идең дә...

— Ышанмыйсыңмыни?

— Ышанмыйм. Яз көне биш җәпле пәкемне бирәм дип алдадыңмы — алдадың. Аннары теге укалы галстугыңны тактырып карыйм дип әйткәнең бар иде, анда да сүзеңдә тормадың.

— Кайчан?

— Бура күтәргәндә булышкан өчен.

— Хан заманындагыларны искә төшереп утырма инде.

— Бер дә хан заманы түгел. Машинкаңны хәзер үк бирсәң, иртәгә эшкә чыгам, бирмәсәң — икенче кеше эзлә.

Агасы кырыну машинкасын моңа кадәр кеше кулына тоттырып та карамый иде, бу юлы да бирмәс дип уйлады Галәү, ләкин ялгышты. Галимҗан теләмичә генә:

— Мә инде, алайса, ал! Тала агаңны, — дип, көрән пластмасс тартманы энесенә сузды. Үзе бер дә исе китмәгәндәй елмайган була. Әмма Галәүнең дә сабый чагы түгел, агасының күзендә елмаю катыш нинди дер хәйлә дә барлыгын күреп өлгерде.

— Бирдеңме? Бирсәң — машинкаңны соңгы кат күрәсең, карап кал, — диде Галимҗанны үртәп.

Бу юлы агасының күзендәге елмаю сүнде, миләш капкан кеше кебек йөзе чытылды.

— Ни эшләтәсең?

— Анысы минем эш.

Сәләхи улларының сүзенә катышмады. Аларның шулай җан атып сатулашулары ошый иде картка. Берсе дә авызына капканны кешегә бирмәс, ходайга шөкер, улларым үземә ошаган, дөнья көтәрлек малайлар үстердем дип куанып утырды.

Икенче көнне Галәү, сүзендә торып, абыйсының өенә китте. Көне буе күңеле тынгысызланып, эче пошып эшләде. Бу хәлен ул Сәвия янына бармый калуыннан күрде. Кереп утырса да утыра икән күңелгә кеше. Очрашырга тиеш булып та очрашмый калган чаклары элек тә бар иде. Ул вакытта да егет татлы да, газаплы да уйлар кичерә торган иде. Бүгенгесе бөтенләй башка төрле. Тоташ газаптан тора, күкрәк авызында нәрсәдер таш булып утырган да бертуктаусыз әрнетә.

Егет төшке ашка да туктамый, баш та күтәрми эшләде. Тизрәк бушанасы, кичкә таба булса да Сәвия янына барып кайтасы килә иде. Әңгер-меңгер төшеп килгәндә ул өй эчендәге эшләрне бетерде. Инде багана башыннан чыбык үткәрәсе генә калды. Агасы куанычыннан ни эшләргә белми йөри, ә Галәүнең эчен мәчеләр тырный.

Өйдә, тәрәзә буенда эшләгәндә, Галәү, җил сызгырган тавышка карап, буран купты, ахры, дип уйлаган иде. Дөрес икән. Ишекне ачып тышка чыгуга ачы җил аяктан ега язды. Яуган кары юк, җәяүле буран себерә, ә җиленә чыдар хәл юк. Көч-хәл белән юга-

ры менгән Галәүне баганасы-ние белән йолкып атарлык булып кылана.

Багана башына менеп җиткәч, егет өшегән кулларын сулышы белән җылытып, бераз эшли алмый торды. Бу минутта аның күзе әллә ни ерак та түгел, су буенда, Ярмәкәй тау итәгендәге бозаулар фермасында булды. Кичке эңгер-меңгердә иске салам эскертенә охшап күренгән ферма өе Галәүгә нигәдер бик кызганыч тоелды. Җилдән ышыкланып тау итәгенә сыенгандыр, түбә калаемны кубарып атмагае дип куркудан ишек-тәрәзәләрен калтыратып, бөтен гәүдәсе белән дерелдәп утырадыр кебек булды. Юк, таза бина бирешмәс, аның эчендәге бозаулар хәвефләнеп борчыладыр, шулар янындагы Сәвиягә кыендыр кебек тоелды.

Электрик ярдәмчесе дә кайтып киткәндер, бу вакытта колхоз эшендә калалармыни, ә Сәвия калгандыр, сәер кыз бит ул, андый чакта бозаулар янында кунып калырга да күп сорамас.

Бар эшен ташлап шунда йөгерәсе килде Галәүнең.

Агасының гына эшне туктатырга исәбе юк, гел караңгыга калганчы багана башыннан өйгә чыбык сүздырырга ашыга.

Эшли торгач, егет тагын бер кат ферма ягына борылып карады һәм нindидер сәер хәлне, яхшыга юрап булмый торган сәер хәлне күреп катып калды. Кинәт ишек ачылып, аннан шактый зур ут шарының тәгәрәп чыкканын күреп калган иде ул. Кызыл-сары энәләр чәчә-чәчә, ут шары кар өстеннән тәгәрәп китте. Озак та үтмәде, җил себереп китергән карга тончыгып, ахры, утлы шар юкка чыкты. Ул да булмады, бер шәүлә ишеккә ташланды. Тагын бер ут йомгагы тәгәрәп чыкты... Инде ишектән ялкын телләре сузыла башлады. Ферма яна бит! Ут чыккан! Ут!

Сәвия янына кеше кертмиләр иде әле. Аны күрү теләгенә ирешә алмады Галәү. Шулай да бер юаныч хәбәр әйттеләр үзенә: кызга катлаулы операция ясаганнар, сәламәтләнеп китәренә ышаныч арткан хәзер. Пешкән урыннарына сәламәт, яшь тән кирәк булган икән. Больницага илтеп салганнан бирле дусты яныннан китми йөргән Рәшидә шуны ишетүгә үк врачлар янына килгән. Хәзер алар икесе янәшә койкада яталар икән. Сәвиянең әнисе Һаҗәр апа бер урынына ике авыру саклый, ди.

Бу хәбәрләр егетне бераз тынычландыра төшкәндәй иткән иде, ләкин кайтыр юлга борылып бераз җир алдыргач, күңелен тагын бер үкенү борчый башлады: Рәшидә урынына ул кереп ятарга тиеш иде лабаса. Ичмасам, шул егетлекне генә дә эшли алмады бит Галәү.

# КамАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

**МАРТ, 1975 ЕЛ**

Узган ел азагында Чаллыда Татарстан өлкә һәм шәһәр партия оешмалары активы җыелышы булып узган иде. Анда КПСС Үзәк Комитеты һәм СССР Министрлар Советының «КамАЗның беренче чираты объектлары турында» карарларында куелган мәсьәләләр тикшерелде. Бу документ төзү-монтаж эшләрен тәгәлләү чорында программа булып тора.

Хәзер массовый төстә монтаж һәм технологик җиһазларны урнаштыру эшенә өзерлек бара. Инженер-техник бурычлар көннән-көн катлаулана, эшчеләргә һәм производство җитәкчеләренә таләпләр арткннан-арта. Бу шартларда партия оешмаларының, төзелештәге барлык коммунистларның мобилизацион роле аеруча мөһим. Эшнең уңышлы нәтиҗәсе, башлыча, аларның кешеләрне туплау, планнарны, йөкләмәләрне үтәү һәм арттырып үтәү буенча социалистик ярышны яхшы итеп оештыра белүләренә бәйле.

СССР Верховный Советы депутаты Рәис Сәлахов җитәкчелегендәге йорт төзү комбинаты бригадасының башлангычы бөек төзелеш елъязмасына алтын хәрефләр белән язып калыныр. Бу алдынгы коллектив төзелешнең һәр объектында заданиеләрне һәр көнне яхшы сыйфатлы итеп һәм арттырып үтәү өчен ярыш башлап җибәрде. Инициативаны партиянең Татарстан өлкә комитеты бюросы һәм Чаллы шәһәр комитеты хуплады. Башлангыч партия оешмалары, секретарьлар советы бу яхшы башлангычны киңәйтү, ярышны оештыруда формализмнан арыну буенча зур эш башкардылар. Бүген, сәлаховчылар үрнәгендә, йөзләрчә коллектив нормаларны арттырып үти, удар өш нәтиҗәләре күрсәтә.

Шунысын басым ясап әйтергә кирәк: төзелешне тизләтүнең төп шартларыннан берсе — удар хезмәт һәм бригадаларның тәгәл оешканлыгы. Төзелеш һәм монтаж подразделениеләрендәге партия оешмалары бригада җитәкчеләрен сайлап алу, аларны тәрбияләү, авторитетларын күтәрү һәм эшкә сәләтләрен үстерүгә зур игътибар юнәлтәләр.

Барлык төзелеш оешмаларында булдырылган бригадаларның җәмәгатьчелек советлары зур әһәмияткә ия. Алар производство мәсьәләләрен генә түгел, хезмәт дисциплинасын ныгыту, төзүчеләрне тәрбияләү, яңа, алдынгы башлангычны киңәйтү мәсьәләләрен дә хәл итәләр.

Тәҗрибәле бригадир, Социалистик Хезмәт Герое Алексей Новолодский җитәкчелегендәге Үзәк совет алдынгы хезмәт алымнарын актив пропагандалый һәм киң куллана. Совет карары нигезендә бер төркем бригадирлар атаклы төзүче Николай Злобин янына Зеленоград шәһәренә бардылар. Аннан соң бу сәяхәтнең нәтиҗәләре турында фикер алышу булды, анда бригадалы хуҗалык исәпләве системасына күчү чаралары билгеләнде. Хәзер утыздан артык бригада яңача эшли.

КамАЗ төзүчеләрнең уңышлары тагы шуңа бәйле: хуҗалык җитәкчеләре, партия оешмалары охшаш оешмалар төзүчеләре белән хезмәттәшлек мөнәсәбәтләрен үстерәләр һәм ныгыталар. Мәсәлән, «Металлургстрой» идарәсе коллективы, аның партия комитеты Тольяттидагы «Промстрой» тресты белән тыгыз элемтәгә керде. Алар үзара тәҗрибә уртаклашалар, бер-берсендәге яңалыкны кабул итәләр. Чаллы, Тольятти, Түбән Кама шәһәр төзүчеләре арасында эшлекле, файдалы сугышчан ярыш бара.

Эшләрне үз вакытында тәгәлләү өчен төзелештә кирәкле ресурслар җитәрлек. Ярыш көннән-көн көчәя, ул коллективларның инициативасын, иҗади энтузиазмын үстерү өчен куәтле фактор булып тора. Партиянең шәһәр комитеты төзелеш һәм монтаж подразделениеләрендәге башлангыч партия оешмалары Кама гигантын тизрәк сафка бастыру өчен барысын да эшлиләр.

**«Правда», Мәскәү.**

Мәскәүдә, И. А. Лихачев исемендәге автозаводта ведомствоара сынаулар өчен «КамАЗ»лар семьясыннан дүрт автопоезд әзерләнде.

Машина кузовы 13 тонна йөкне бик җиңел күтәрә, үзбушаткыч механизмнары яхшы эшли.

— Мондый ярымприцеплар моңа кадәр безнең илдә эшләнми иде, — ди «ЗИЛ»ның баш конструкторы, РСФСРның атказанган фән һәм техника эшлеклесе, СССР дәүләт премияләре лауреаты А. М. Кригер. — Бу конструкцияне Кама автомобиль гиганты өчен Мәскәү һәм Балашов инженерлары ясады. Өч күчәр тягачтан һәм үзбушаткыч ярымприцептан торган автопоездны без ведомствоара сынаулар өчен ясадык. Озын сынау юлына аның белән бергә авыл хуҗалыгы өчен эшләнәчәк тягач һәм аның үзбушаткыч прицебы чыга. Аның үзенчәлеге шунда: җиде тонна сыешлы кузовы йөкне өч якка, ә прицебы һәр дүрт якка бушата ала.

ТАСС, Мәскәү.

Чаллыда Казан «Заря» кондитер фабрикасы филиалы ачылуга ике ай гына вакыт узды әле. Коллективның эшенә инде югары бәя бирелде: фабриканың Чаллы филиалында эшләнә торган ике тортка Дәүләт сыйфат билгесе бирелде.

«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».

КамАЗның меңнәрчә төзүчеләре һәм эшчеләре Бөек Ватан сугышында һәлак булган егетләр өчен эшли. Алар арасында Александр Жогалев бригадасы да бар. Чаллыдан егерме кеше Мәскәүдә Җиңү байрагы янында рәсемгә төшү хокукын яулап алды. Шуларның берсе — бригадир Александр Жогалев.

«Комсомолец Татарии», Казан.

Шушы көннәрдә автомобиль заводының бинаһая зур корпусы эчендә зур вакыйга хөрмәтенә оркестр тантаналы маршлар уйнады: биредә технологик җиһазларны монтажлау башланды, беренче станок үзенең даими эш урынына урнаштырылды.

Бер ел элек В. Казанцев, Н. Демченко бригадалары җыю заводы комсомолецларын беренче станокны монтажлау хокукын яулап алу өчен социалистик ярышка кушылырга чакырганнар иде. Төп технологик җиһазларны монтажлый башлау уңае белән үткәрелгән митингта бу патриотик инициативаның нәтиҗәләре турында приказ укылды. Җиңеп чыккан бригадалар исемлегендә Юрий Рыбаков бригадасы да бар. Приказда шулай диелә: «Ярышта җиңеп чыгучыларны истәлек таныклыгы белән бүләкләргә, аларга беренче станокны монтажлау бурычын тапшырырга, исемнәрен беренче станокка беркетелгән эмблемада мәңгеләштерергә».

«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».

Профсоюз нәшрияты «Бишьеллык батырлары» дигән китап бастырып чыгарды. Аның авторлары — язучылар, күренекле эшчеләр. Илебезнең төрле почмакларын — Ерак Көнчыгышны да, Украинаны да — күрергә була аның битләрендә; анда син яшьләр белән дә, олыраклар белән дә, бригадирлар, мастерлар, эшчеләр белән дә очрашасың. Алар автомобиль җыялар, йортлар төзиләр, кием тегәләр, тимер юллар салалар, иген үстерәләр...

Кеше эштә күренә — авторлар әнә шул теманы яктырталар. Чаллыдагы Камгэсэнергостройның штукатурлар бригадиры Галина Филяшина үзенең дус кызлары хезмәте турында яза, аларны ничек итеп бердәм коллективка туплавы турында сөйли.

«Труд», Мәскәү.

«Энергетик» культура сараеның спорт залында «Труд» спорт җәмгыятенең Татарстан өлкә советы беренчелегенә волейбол буенча ярышлар тәмамланды. Ярышларга алты команда катнашты. «Камгэсэнергострой» командасы беренче урынны алды, икенче урынга Казан шәһәренең «Текстильщик» спортчылары, өченче урынга «Казаньхимстрой» командасы чыкты.

«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».

Дүрт ел элек безнең автоскреперчылар бригадасына Кама автомобиль заводлары төзелешендә беренче булып Коммунистик хезмәт коллективы исеме бирелде.

Без бу мактаулы исемгә социалистик ярышта югары күрсәткечләргә ирешүебез өчен лаек булдык.

Бригада һәр елны үзенең эше, хезмәт һәм көнкүреш тәртибе белән бу югары исемгә тап төшерми. Һәркем белә: бу исемне яулап алудан да саклау кыенрак. Ә «Камгэсэнергострой» бригадаларының берсендә нәкъ шундый хәл булды: бригада күз алдында таркала башлады.

Бригада партгруппоргы Алексей Григоровский, комсорг Вячеслав Телега һәм мин, үзара киңәшкәннән соң, үз бригадабызны калдырдык та артта калган бригадага күчтек. Бу коллективта вакытында Коммунистик хезмәт ударнигы исеме бирелгән эшчеләр дә бар иде. Шулар белән берлектә бригада советы оештырдык. Бригада советының һәр члены яшь эшчеләрне шефлыкка алды һәм аларны хезмәтнең алдынгы алымнарына, яңа һөнәрләргә өйрәтергә керешге. Без бригадада һәркемнең иң югары уңышларга ирешергә сәләтле булуына ышаныч тудырырга тырыштык.

Бригададагы яңа тәртип бар кешегә дә ошады. Дөрес, кайберәүләр белән саубуллашырга да туры килде, бригадада 50 кеше калды. Аларның һәрберсе үзалдына бурыч куйды — Коммунистик хезмәт коллективы исемен яулап алырга! Һәм күптән түгел бу мактаулы исем безнең коллективка бирелде.

(Бригадир У. Наурбаев мәкаләсеннән.)
«Труд», Мәскәү.

Шәһәрнең яшь художниклары үз әсәрләренең икенче күргәзмәсен оештырдылар. Күргәзмә Бөек Ватан сугышында җиңеп чыгуга 30 ел тулу юбилеена багышланган. Экспозицияләргә рәсем сәнгате, графика, скульптура әсәрләре куелган.

«Социалистическая индустрия» на
строительстве Камского автозавода».

Фрунзе автомобиль төзүчеләре КамАЗга радиаторлар җибәрә башладылар. Инструментчылар Чаллыга 18 мең бораy озатты, ә электровакуум машина төзелеше заводы Дәүләт сыйфат билгесен алган «Астра» яктырткычларын җибәрде. Күптән түгел генә әле республика комсомолы вәкилләре завод һәм шәһәр салуга катнашу өчен Кама буена киткән иде.

«Правда», Мәскәү.

Кама автомобиль комплексы төзелеше елъязмасына тагын бер якты сәхифә язылды: 10 февральдә җыю конвейеры хәрәкәткә килде. 192 метрлы участокта «КамАЗ» машиналарының шассилары җыелачак.

Шассилар җыю конвейеры март аенда гына монтажланып бетәргә тиеш иде. Матур итеп бизәлгән тактага зур хәрефләр белән болай дип язылган: «КПСС Үзәк Комитетының совет халкына мөрәҗәгатенә җавап итеп, иптәш В. А. Осипенко бригадасы шассилар җыю конвейерын 1975 елның 23 февраленә монтажлап бетерергә йөкләмә алды».

«Социалистическая индустрия» на
строительстве Камского автозавода».

Чаллы шәһәре паспорт өстәлендә ике йөз меңенче кеше теркәлде. КамАЗ төзелеше барышында шәһәр халкы 160 мең кешегә артты. Автомобиль төзүчеләр шәһәрендә 63 милләт вәкилләре дус семья булып яшиләр. Соңгы елларда Чаллыда өч меңгә якын никах теркәлде. Меңнән артык никах төрле милләт вәкилләрен берләштерә.

«Правда», Мәскәү.

РИЗда үткәрелгән митингка 2 мең ярым кеше катнашты. Алар В. И. Ленинның тууына 105 ел тулу уңае белән коммунистик өмәгә чыгу турында мәскәүлеләр инициативасын яклaдылар.

— Безнең комсомол-яшьләр сменасы, — диде үзенең чыгышында групкомсорг Б. Вергасов, — 19 апрельдә иң югары хезмәт җитештерүчәнлеге күрсәтергә сүз бирә. Заданиене 133 процентка үтәргә йөкләмә алабыз, бүтән сменаларны да бездән үрнәк алырга чакырабыз.

«Социалистическая индустрия» на
строительстве Камского автозавода».

## Мәдинә Маликова

# БАМ БАШЛАНГАН ҖИРЛӘРДӘ



Байкал — Амур магистрале Байкалдан түгел, Лена станциясеннән башлана. Без барганда, узган елның май азагында, тимер юл Лена буена килеп җитә иде дә пристань янында тармакланып өзелә иде. Килгән йөкләр шунда баржаларга төялә, су юлы белән меңнәрчә чакрым ераклыкларга озатыла иде. Ә Лена аръягында әле бернинди юл юк, анда бары вертолетлар белән генә барып була иде.

Без дә Лена аръягындагы урманнарга беренче тапкыр өстән карадык. Йөк төялгән «МИ-6» вертолетында пассажирлар күп түгел иде. Без акбур тулы капчыклар өстеннән үрмәләп, әле бер як тәрәзәдән, әле икенчесеннән җирне күзәттек. Җир өсте тигез түгел, итәкләре белән бер-берсенә тоташкан калкулыклардан — сопкалардан тора. Әйтерсең лә бик борынгы заманнарда ук җирдә яшәгән бинихая зур җанварлар, көтүләре белән барган җирдән кинәт тукталып, сыртларын кабартып ятканнар да мәңгелек йокыга талганнар. Бу көтүнең иге-чиге күренми. Калкулыкларның өсте урманнар белән капланган, кайбер тау араларыннан боргаланып-сыргаланып зәңгәр елгалар ага. Күксел рәшәгә төренгән офык сызыгына якынайган саен, тау аралары томанлырак күренә, җир өсте тигезләнә барган сыман тоела.

Күз күреме бөтен җирдә урман белән капланган сопкалар. Тайга... Әмма тайга тоташ бертөсле түгел. Урыны-урыны белән ул ачык яшел — анда яфрак яра гына башлаган каеннар һәм ак чыршылар үсә. Таңнар биредә бездәгедән биш сәгатькә алданрак атса да, язлар бер айга соңарып килә икән: май ахырында яфраклы агачлар яшәреп кенә бара, шомырт яңа гына чәчәк аткан иде әле. Кайбер сопкаларның түбәләре кара кучкыллайып тора — алар көнчыгыш чыршылары һәм эрбет агачлары белән капланган. Кайсы сопкаларга кара шырпы сипкәннәрмени: шәрәләнеп торган соры җир өстендә аркылы-торкылы агач кисәүләре генә ята. Болары — янгын урыннары. Ул янгыннар бәлки инде берничә ел элек дөрләп үткәндер, ә урман яңармый, җир өсте һаман шәрә, чөнки урманы юкка чыккан тау битләреннән уңдырышлы туфракны янгыр сулары, язгы сулар агызып алып китә, җил очыра. Бары тик шушындый урыннарны үз күзләрең белән күргәч кенә, янгыннарның урманнарга никадәр куркыныч икәнен аңлыйсың.

Сопка араларында, елга буйларындагы уйсулыкларга җете яшел кәтфә келәм җәйгәннәр кебек — карарга матур, ләкин ул җирләрнең

мүк япмасы җәелгән төпсез сазлык икәнен уйлап, күңел шомланып куя.

Тайганың безгә мең төрле, ләкин барыбер аңа нидер җитми, аны күргәч, күңел нәрсәнедер юксына. Без җирне кеше хезмәтенең эзләреннән — авыл-шәһәрләрдән, басулардан, бакчалардан, юллардан башка күз алдына китерә алмыйбыз. Ә биредә сәгатьтән артык очабыз инде, дөньяда кеше яшәгәнен сиздерә торган бер нәрсә күрмәдек дисәк тә ялгыш булмас. Вертолет бары тик яңа салынган ике кечкенә поселок өстеннән генә очып үтте.

Я дөнья, синең шушындый иркен, моңарчы кеше кулы тимәгән киңлекләрең дә бар икән әле! Табигать никадәр генә бай булмасын, кеше булмаган җирдә ул буш, ятим икән, күңелсез икән! Менә-менә офык сызыгында зур шәһәр, я, һич булмаса, берәр авыл күренер шикелле тоела.

Сәгать ярым очканнан соң, ниһаять, офыкта бер үзгәреш сизелде, ләкин аннан шәһәр дә, авыл да түгел, ак болытлар күтәрелә башлады. Якынлашкан саен, алар биегрәк булып күренәләр, алар астыннан сары болыт мендәрләре калыккандай була. Бары бераздан гына без аларның болыт түгел, кар-боз капланган тау сыртлары икәнен чамалый башладык. Ул таулар инде офыкның яртысын биләп күтәреләләр. Бу— Байкал сырты.

Менә нинди җирләрдә салыначак икән ул БАМ — Байкал — Амур тимер юлы! Менә нинди урманнарны, елгаларны, тауларны кисеп үтәчәк икән! Без вертолеттан Көнбатыш участогын гына күрдек бит әле — нибары 284 километрын гына күз алдыннан үткәрдек, калган 2900 километрдан артык өлеше офык сызыгының артында калды, аларны безнең күздән ак тау түбәләре каплады. Ләкин бу кадәресе дә безне хәйран калдырды. Шушы очыштан соң гына без бу бөек төзелешнең колачын әз булса да чамалый башладык.

БАМ узачак урыннарны картада эзләп тапсаң, ул төшләрнең бик күп урыны кызгылт-көрән төсләргә буялганын күрәсең — бу тимер юл күпчелек очракларда таулы-калкулыклы җирләрдән үтәчәк дигән сүз. Тауларның түбәләре болытларга ашканнары, өстән ташкын елгалар акканы да, ташлар коелганы да бар. Юл җиде тау сырты астыннан салыначак, унбер зур елга һәм бихисап вак елгалар аркылы үтәчәк. Аның ярты буе мәңге бозланып каткан җирләр өстеннән сузылачак. Ә өстен кузгатуга ул бозлыклар эриләр, чөнки аларны эрүдән бары тик мүк катламы гына саклап тора. Мүкне алдың исә, баткаклыклар хасил була, машиналар бата, җир иңә.

Кешелек тарихында бөтен трасса буена шундый авырлыклар очраган мондый озын тимер юлның салынганы юк әле. БАМда өч мең күпер булачак, аларның 142 се Лена, Амур, Зея кебек киң елгалар аша салыначак. Буласы кайбер тоннельләрнең озынлыгы уннарча чакрымнар белән үлчәнә. Юлга нигез салу өчен 300 миллион кубометр җир токымын бер урыннан икенче урынга күчерергә кирәк. Ул токымнарның яртысы тау-таш яки мәңгегә каткан җир... Әле шунысын да онытмаска кирәк: әйткәнебезчә, төзелеш элек үзләштерелгән җирләрдә, кеше яшәгән урыннарда бармый. Анда яшәү өчен шартлар тудыру да, техниканы китерү дә зур кыенлыклар белән бәйле. Кыскасы, БАМ — бик катлаулы, искиткеч зур хезмәт таләп итә торган һәм кыйммәткә төшә торган төзелеш.

БАМ төзелеше берничә урыннан алып барыла: көнбатыштан — Лена буеннан, көнчыгыштан — Амурдагы Комсомольскидан, Себер тимер юлы белән тоташкан урыннан — Тындадан.

Без сәяхәтебезне Лена буеннан башладык.

Лена — дөньяда иң зур елгаларның берсе булып санала, ул Себерне көньяктан төньякка таба кисеп үтә. Якутлар аны — Улахан Юрәх, ягъни Бөек Елга дип атыйлар. Озынлыгы 4400 километрга сузылган бу елга аша моңарчы бер генә күпер дә булмаган. Беренче күпернең озынлыгы — 432 метр.

Күпер БАМ төзелеше өчен су кебек, һава кебек кирәк, чөнки ансыз елганың аръягына авыр техниканы да, кирәкле материалларны да чыгарып булмый.

Күпер төзелеше Якурим дигән авылдан, дөресрәге, авыл аркылы башлана, тимер юл авылны кисеп үтә, шуңа күрә төзелешне авыл йортларын сүтүдән башлаганнар. Ә күпер төзүчеләрнең — 5 нче мостотрядның — үз поселогы авылдан чакрым ярым ераклыкта үсеп чыккан.

Күпер салучы егетләр, килеп урнашкач та, палаткаларда һәм вагоннарда торганнар, терәкләр салу эшенә керешкәннәр, бетон ташыганнар. Елга төбеннән бетон корылмалар күтәрелгән арада, алар өчен уңайлы йортлар, клуб, ашханә, балалар бакчасы, фельдшерлык пункты төзелгән. Барысы да кирәк, барысы да ашыгыч, чөнки күпер салучылар эшли генә түгел, тормышның бөтен законнарына буйсынып яши дә. Алар ял вакытларында күңел ачалар, гашыйк булалар, өйләнешәләр, балалар үстерәләр. Мостотрядта беренче туй да, бала туу да, төзелештәге зур җиңү шикелле үк, истәлекле, куанычлы вакыйга санала.

Яңа поселокның исеме юк иде әле. Төзүчеләр аны искечә атарга теләмиләр, алар кичергән горурлык хисен, яшьлекнең онытылмас вакыйгаларын мәңгеләштерерлек шигъри исем эзлиләр. Бу мәсьәлә җыелышта да куеп тикшерелгән, төрле тәкъдимнәр булган: «Кар бөртеге», «Аленка», «Ленагород», «БАМ ачкычы»...

«БАМ ачкычы»н ясаучылар арасында без үзебезнең якташ егетләрне дә очраттык.

Егетләргә бу төзелешкә килеп катнашу бәхете ансат кына бирелми икән. Менә Фәрит Хәсәнов. Буа егете. Һөнәре буенча электрик. Ул армия сафларында Чита өлкәсендә хезмәт иткән, Себер табигатен яраткан. Демобилизациядән соң БАМга килергә омтылган. Ләкин төзелеш теләгән бер кешене кабул итеп ала алмый, төзелешнең үз планнары бар. Шуңа күрә ВЛКСМның Иркутск өлкә комитеты БАМга килгән егетләрнең бер өлешеннән удар отряд оештырып, бик мөһим төзелешкә — Усолье-Сибирское дигән район үзәгенә 1200 башлык сыер фермасы төзергә җибәргән. БАМнан еракка, өлкәнең көньяк өлешенә. 90 кешелек бу отрядның командиры итеп Насих Заһитовны билгеләгәннәр.

Бөек төзелешкә дип килеп, терлек абзары салып ятарга тиеш булган егетләрнең күңелендәниләр кайнаганын алар үзләре генә аңлагандыр. БАМга яңа десантлар ташлана, анда күперләр төзелә, «зимник»лар — кышкы юллар салына, ә алар Татарстан өчен дә гади булып тоелган корылма салып тир түгәләр. Дөрес, Себер якларында терлекчелекне үстерүдә бөек төзелеш өчен кирәк, ләкин егет күңеле көрәшнең иң кызган төшенә омтыла бит ул.

Алай да егетләр сер бирмиләр. Электрик Хәсәновка бетон изәргә дә, кирпеч өяргә дә, җилкәсенә салып цемент ташырга да туры килә.

Бары тик шушы фронтта үзен чын егет итеп күрсәткәч кенә, бары тик куелган бурычны комсомолларча үтәгәч кенә, егетләргә БАМга путевка бирелә. Барысына да түгел, 90 кеше арасыннан унбишенә.

Шушы унбиш арасында Насих Заһитов белән Фәрит Хәсәнов та булалар. Күпер төзелешендә алар инде, әлбәттә, үзләрен сынатмый.

Азнакай районының Түбән Якый авылы егете Нәҗип Галимовның юлы турырак булган, ул комсомол путевкасы белән туп-туры Лена буена килеп төшкән. Үзе шофер. Ләкин бередә һөнәр белән исәпләшеп торып булмый, кайда кирәгрәк, шунда эшлисең, яңа һөнәрләр үзләштерәсең. Нәҗип Лена күпере терәкләренә бетон салышуы белән үзен мең бәхетле саный.

Узган кышны бетончыларның эше аеруча җаваплы, аеруча ашыгыч булган. БАМның төзелеше шушы күпергә килеп терәлгән. Бетончы егетләр өчәр смена эшләгәннәр — язгы ташуга кадәр терәкләрне торгызып бетерергә тырышканнар.

Без барганда күпердә монтажчылар эшли, ә безнең егетләр туган якларына кайтып, сабан туйларын күреп килергә әзерләнәләр иде. Нәҗипнең өстендә аркасына, җиңнәренә рәсемнәр төшерелгән яшел куртка, ә Фәрит сәдәф урынына сары чылбыр таккан, чигешле-чуклы камзул кигән. «Усолье истәлеге», — ди ул моны. Егетләрнең кулларында — магнитофоннар, түшләрендә — БАМ значоклары. Башларын югары тоталар — шулай булмый ни, «БАМ ачкычы»н коялар бит алар, бөек төзелеш тарихының беренче битләрен язалар! Хәер, болай дию бик үк дөрес булмастыр, мөгаен. БАМ бүгенге көндә тулысы белән чынбарлыкка әверелә барса да, аның тарихы шактый күптән башланган инде. Бүгенге төзүчеләр күптәнге бөек хыялны тормышка ашыралар дип әйтү дөресрәк булыр. Һәм бу алар хезмәтенең дәрәҗәсен тамчы да киметмәс.

Себергә тимер юл салу мәсьәләсе узган гасыр ахырында күтәрелә. Ул чакта ук инде Байкал күленең төньягыннан Амур елгасына таба юл сузу турында ныклап уйлана башлыйлар. Инженерлар юлның ике вариантын чагыштырып карыйлар: бер вариант буенча, юлны Байкал күленең көньягыннан, икенчесендә — күлнең төньягыннан салырга планлаштырыла. Төньяк юл көньяк юлдан кыскарак була, ләкин көньякта кешеләр яши һәм, җир тигез үк булмаса да, кыенлыклар төньяктагыдан кимрәк дип табыла. Шуңа күрә Себер юлы Байкал күлен көньяктан әйләнеп уза.

Ләкин БАМны төзү, ягъни Байкал күленең төньягыннан Ерак Көнчыгышка тимер юл салу көн тәртибеннән төшми. Совет власте елларында бу юл узачак урыннарда тикшерү эшләре өр-яңадан киң күләмдә башлана. Ватан сугышы алдыннан бу тикшеренүләр өчен күп көч куела, автомашиналар, тракторлар, хәтта самолетлар бирелә. Партиянең XVIII съездында БАМны төзүгә карешү турында җитди сүз бара. Хәтта сугыш елларында да бу эш онытылмый — 1943 елда Амурдагы Комсомольскидан Советская Гаваньга кадәр тимер юл салына.

1938 елны БАМның Тайшеттан алып Ленага кадәр булган 700 чакрымы төзелә башлый, 1946 елда юлны салып бетерү эшенә ныклап керешәләр. Ул юл 1951 елны сафка баса һәм Братск төзелешендә, Урта Ангарадагы зур промышленность комплексын барлыкка китерүдә зур роль уйный.

Бу хыялны тормышка ашыру, БАМны булдыру эшенә ныклап тотыну безнең көн яшьләре җилкәсенә төште. 1974 елның язында, ВЛКСМның XVII съездында комсомоллар бөек төзелешне үзләренең изге бурычы дип таныдылар. Съездга килгән делегатлардан удар отрядлар төзелеп, алар Мәскәүдән туп-туры Лена ярларына юнәлделәр.

## Йолдызлар шәһәрендә

БАМ поселокларының күбесе десант ташлаудан башлана. Төзүчеләр Лена аркылы күпер салынганны көтеп тора алмадылар, елга

аръягында тайгада берничә урында эшне башлап җибәрделәр. Көнбатышта беренче десант Таюра елгасы буена юнәлде.

1974 елның 10 январенда 266 нчы төзү-монтаж поездының десанты Усть-Куттан чыга. Десантта биш бульдозер, дүрт торак вагоны һәм егерме егет була. Алар белән поездның начальнигы Петр Петрович Сахно җитәкчелек итә. Егетләр Лена бозы аша чыгалар да, билдән карга чума-чума, мең яшәр агачларны кисә башлыйлар. Десант шулай көненә ике-өч чакрым җир үтә, аның артыннан «зимник» — төзүчеләр өчен кан тамыры шикелле кирәкле кышкы юл сузылып кала. Бер ай дигәндә десант алтмыш дүрт чакрымлы юл салып, БАМ станцияләренең беренчесе булачак урынга, Таюра белән Ния елгалары кушылган төшкә килеп җитә. Яр буенда бердәнбер корылма — аучылар ял итеп, хәл алып чыксын өчен бүрәнәдән салынган ялгыз йорт — «зимовье» тора. Десантчылар шул йорт янына беренче палаткаларын корып, тимер мич ягып җибәрәләр. Ә иртәгесен булачак поселок өчен урын әзерләргә — урман кисәргә керешәләр.

Алар әзерләгән урынга беренче отрядлар килеп төшә. Май башында, комсомолның унҗиденче съезды залларыннан туп-туры Таюра буена килгән егетләр дә шулай ук кулларына пычкы, балта алалар.

Без килгәндә бу вакыйгалардан соң бер ел гомер үткән иде. Таюра буена урнашкан «Звездный» — «Йолдызлы» поселогы иске поселок булып санала иде инде.

— Ни өчен «Звездный»? Төзелеш планнарында бу тимер юл станциясе «Таюра» дип атала бит!

Поселоктагы «Таежник» исемле клубта җыелган яшьләргә без шундый сорау бирдек.

— Ә сез төнлә чыгып, күк йөзенә карагыз әле, шунда аңларсыз, — диделәр безгә.

Чыннан да, тайга күгендә йолдызлар бигрәк чекерәешеп яналар икән. Урман якын, тын, шомлы, ә йолдызлар күңелне юатып, елмаеп карый, алар шундый якын, кулыңны сузсаң, учыңа үзләре төшәр сыман...

Поселокның сап-сары такта белән тышланган берәр-икешәр катлы, берничәшәр квартирлы йортлары, әллә ничәшәр бүлмәле тулай тораклары урам-урам булып тезелеп киткән. Урамнар арасында тыкрыклар түгел, баскычлар салынган. Чөнки ул урамнар сопканың текә күкрәгенә киртләр ясап, басма-басма булып утырганнар.

Без клубтагы яшьләрдән, нәрсәләр бар сездә? дип сораштыра башладык. Алар көлеп:

— Җиде мең кеше яши торган шәһәрчектә нәрсә булырга тиеш булса, шул бар, — диделәр. — Сез бездән нәрсә бар дип сорамагыз, нәрсә юк дип сорагыз.

Чыннан да, тайга уртасында төзүчеләргә бөтенесен булдырырга тырышылган. Поселокта ашханә, кибет, кунак йорты, мунча, почта — һәммәсе бар. Хәтта үзенең загсын да ачканнар — ансыз да булмый, ел әйләнәсендә поселокта кырык дүрт туй шаулап-гөрләп үткән.

Биредәге урта мәктәп беренче чыгарылышын ясаган — дүрт яшь кеше поселок тарихында беренче өлгереш аттестатларын кулларына алган.

— Көздән мәктәпкә 42 бала килгән иде, — дип сөйли мәктәп директоры Леонид Аполлонович Выговский. — Хәзер безнең укучылар саны 268 гә җитте, уку елы барышында алар тагын артачак әле. Кешеләр квартира алалар, семьяларын китерәләр, яңа төзүчеләр килә.

Җәй башында Леонид Аполлонович, комсомол комитеты белән бергәләшеп, өлкән класс укучылары өчен җәйге хезмәт лагере оештыру турында кайгыртып йөри иде. Бирегә күп кенә шәһәрләрдән укучылар

килеп ял итәчәк икән. Урман һавасы суларлар, чыныгырлар, ныгырлар, кулларыннан килгәнчә төзелешкә булышырлар. Хәтта пионер яшендәге балалар да БАМ төзелешенә катнашу турында хыяллана бит.

Леонид Аполлонович безнең якташларыбызны мактап искә алды. Мәктәп бинасын төзегәндә Өлфәт Дәүләтшин, Рәшит Исәнгилдин кебек егетләр зур тырышлык күрсәткәннәр икән. ВЛКСМның XVII съезды делегаты Дәүләтшинның рәсеме Звездный мәктәбенең музеена куелган, ул Иркутск комсомол өлкә комитетының Мактау грамотасы белән бүләкләнгән икән.

Йортлар салучыларга ихтирам зур, ләкин, беренче чиратта, юл салучылар — урман кисүчеләр һәм механизаторлар — игътибар үзәгендә. Бүгенге көндә БАМ сызыгын сызучылар — шулар. Юл уңаеннан әйтергә кирәк, БАМ салу өчен Румыния территориясе кадәр мәйданда урман киселәчәк, ә бу эшне башкаручылар уңайлы поселокларда, суы краннан агып тора торган йортларда яши алмыйлар. Хезмәтләре аларны көннән-көн поселоктан ераграк алып китә.

Шушындый авыр һәм җаваплы эшне башкаручылар арасыннан безгә алдынгы бригадир Рәшит Кәлимуллин исемен атадылар.

Урман кисүчене мин нык бәдәнле, юан гәүдәле, сакалы түшенә салынып төшкән, бите җилдә янган кеше итеп күз алдына китерә идем. Бигрәк тә, бригадир кеше гайрәтле ир булырга тиеш иде кебек. Ә минем каршымда оялчан елмаеп, нечкә билле, нәфис, чиста йөзле егет утыра. Ул заманча киенгән, чәчләре дулкынланып баш артына ук төшеп тора.

Рәшит эштәге батырлыклары турында да, тайгада яшәүнең җайсызлыклары турында да сүз куертырга яратмый. Вакытны юкка сарыф итмиләр, эшкә бөтен көчне куялар, коралларын тәртиптә тоталар һәм иң мөһиме — бригадада бер-берсенең күңелен күтәрә беләләр. Дуслык, бердәмлек, дәрт, илһам — уңышка ирешүнең һәр эштә беренче шарты бит.

Рәшит поселоктагы кызыклы һәм күңелле вакыйгалар, көлкеле хәлләр хакында да сөйләргә талпына.

— Эш коралы дигәннән, бер заман шундый хәл булды, — ди. — «Дружба» пычкысы ватылды. Нишләргә, яныбызда аңа кирәкле запас часть юк, ә китереп биргәннәрен көтсәң, өч көн утырырга туры киләчәк. Кичен, эш беткәч, киттем мин поселокка. Иртәнгә кадәр кирәкле запчастьны алып килермен, дим. Барам шулай аяк астын чамалап кына, урман тып-тын, бер тавыш юк. Шактый ара узгач, инде карангы төшкәч, артымнан кемдер килгәндәй тоела башламасынмы! Аяк тавышлары аермачык ишетелә, хәтта авыр итеп сулыш алганы да сизелә. Беттем, дим. Аю бу, мөгаен. Тайгада аюларның күплеге турында күп сөйлиләр, аларны хәтта «тайга хуҗасы» дип тә атыйлар бит. Абына-сөртенә тотындым бар көчемә чабарга! Әйтерсең аюдан качып котылып була! Нишлим соң, кулымда бернинди корал юк, кычкырсаң, беркем ишетмәячәк. Шулай бик озак чаптым бугай. Күпме вакыт үткәндер, миңа бик озак тоелды. Бәхетемә, юл читендә бер куыш күрдем. Шуңа, очып баргандай йөгереп, кереп егылдым. Аяк тавышлары якынайганнан-якыная бара. Куыш авызыннан башымны тыгып карасам, мөгезле баш күрәм. Поши! Мин пошидан куркып җан-фәрман чапканмын икән!

Бу егетнең артыннан пошины да җиткермәслек тизлек белән йөгерүенә ышанып була. Ул — поселокта танылган спортчы. Тулай торакта алар яшәгән бүлмәнең киштәсендә спорт кубогы саклана. Ул кубокка алтынсу хәрефләр белән «БАМның Көнбатыш участогы буенча беренче эстафета ярышында җиңеп чыккан командага» дигән сүзләр языл-

ган. Бу эстафета кышын чаңгыда Таюра һәм Лена бозлары өстендә уздырылган. Җиңүче команданың башлыгы — Рәшит Кәлимуллин, ә команда членнары аның бригадасында эшләүчеләр.

Яңа поселокның үз традицияләре туып килә инде. Бередә яшьләр үзләре төзегән шәһәрләргә генә түгел, тауларга, аланнарга, елгаларга да яңа исемнәр кушалар. Звездный поселогының артында күтәрелгән калкулык «Мәхәббәт сопкасы» дип атала. Яшьләр анда күзгә-күз очрашып серләшергә йөриләр. Рәшитнең дә бар җан сөйгән яры поселокта, алар да сирәк кенә булса да мәхәббәт тавына күтәреләләр. Таюра артында калкып торган сопка «Аерылу сопкасы» исемле. Чөнки Усть-Кутка киткән вертолетлар шул сопка артына кереп күздән югалалар... Сөйгән ярларын озатканнар елга буендагы вертолет мәйданчыгында моңаеп кала...

Телисеңме-теләмисеңме, бередә яшисең икән, синең тормышың табигать белән тыгыз бәйле. Ял вакытларында елгага балыкка яисә урманга ауга йөрисең. Бәхетең булып, монда туй үткәрсәң, сине яшьләр, махсус саллар ясап, Таюрада агызырлар. Звездныйның шундый йоласы да бар әле.

Рәшит тормышның гел күңелле, матур якларын искә ала, гел елмаеп сөйләшә. Аның бүлмәдәше, Баулы районының Каразирек авылында туып-үскән егет — Илдар Латыйповның гомумән бу төзелешкә дә, тормышка да фәлсәфирәк караганы сизелә. Аның нык гәүдәсеннән, ак йөзеннән уйчанлык бөркелеп тора. Ул, кайберәүләр шикелле, бирегә гомер күрмәгән яңа шартларга кызыгып та, романтика эзләп тә килмәгән. Эшләргә килгән, тырышып карыйм әле, нәрсә булыр, ошамаса, бер елдан кайтып китәрмен, дип килгән. Ул шулай ук былтыр май башында, беренче комсомолецлар белән килеп төшкән һәм бу турыда горурланып сөйли. Әйе, ул бередә эшләү-яшәүнең авырлыкларын да яшерми, ул аларны идеаллаштырудан ерак тора. Илле градус салкын көннәрдә палаткаларда яту әниеңнең йомшак түшәгендә йоклау түгел ул. Иртән торуыңа мыегың бозланып каткан була. Ярый ла бер атна яки бер ай гына булса... Еллар буена андый шартларда яши башласаң, шуның өстенә авыр эштә, бөтен көчеңне биреп эшли башласаң, монда инде романтика белән ымсынып яшәү генә җитми. Эшләргә кирәк, нык-лык кирәк — менә нәрсә! Югыйсә, кайберәүләрнең кышкы салкыннардан борыннары бик тиз төшә, ә җәен черки сарса да, талпан тешләсә дә сыкрана башлыйлар. Илдар боларның барысын да ачыктан-ачык сөйли һәм шул ук вакытта бередә эшләүчеләрне башка уңайлырак шартларда эшләүчеләрдән өстенрәк итеп тә куймый. Бередә тормыш шартлары шундый, теләсәң-теләмәсәң дә, гомуми агымга бирелеп башкалар төсле яши башлыйсың. Кирәк булды — ул үзенең сварщик һөнәреннән тыш тагын берничә төзүче һөнәрен үзләштерде: балта остасы да булды, ташчы да. Кичләрен поселокта нишлисең, тулай торакта тик ятып булмый бит. Башка егетләр поселокта ачылган кичке мәктәптә укый башладылар, ул тугызынчы класска керде, урта мәктәпне тәмамлап чыкты.

Боларның барысын да Илдар, бер дә искитәрлек нәрсә юк, романтика-романтика дип очынасы түгел, дигән сыманрак тыныч тавыш, җитди йөз белән сөйли. Гадәти тормыш белән яшибез, диясе килә аның. Ләкин шушы эш, уку, бергәләп күңел ачу, спорт белән тулы тормышның гадәти булуы, шушы тормышның сүлпәнрәк егетләрне дә үз агымына ияртүе үзе сокланырлык күренеш бит!

Әйе, Илдар хаклы, төзелештә авырлыклар җитәрлек. Бигрәк тә бу беренче поселокны — Звездныйны күтәргәндә сизелгән. Хәзер төзелеш җитәкчеләре «Звездный сабак»лары турында җитди сөйләшү алып баралар. Поселокны сала башлаганда техника һәм материаллар кыш-

кы юлдан җитәрлек китерелмәгән була. Күп нәрсәне вертолетлар белән ташырга туры килгән. Ә бу бик кыйммәткә төшә һәм бик авырлык белән эшләнә. Шунлыктан, материаллар һәм техника җитмәү сәбәпле, төзүчеләр эш фронты белән җитәрлек тәэмин ителмәгән чаклар да булгалый. Шуның өстенә беренче отрядтагы яшьләрнең күбесе төзүче һөнәрен үзләштермәгән әле, моңа эш барышында өйрәнергә туры килгән.

Хәзер яңа урыннарга яңа десантлар җибәргәндә боларны кабатламаска тырышалар: төзүне ныклап башлаганчы, кышкы юллардан кирәкле материалларны җитәрлек итеп китереп куярга, кирәкле һөнәргә ия булган, әзерлекле кешеләрне генә эшкә алырга, килгән кешеләрне палаткаларда яшәтмәскә, һәркайсына җылы торактан урын бирергә... Болар бары да бик яхшы, әлбәттә. Ләкин мондый зур төзелешнең кыенлыкларсыз гына баруын барыбер күз алдына китереп булмый. Хаталар, әлбәттә, төзәтелер, ләкин яңа поселоклар салынганда яңа мәсьәләләр күтәрелер, яңа проблемалар туар, яңа кыенлыклар очрар. Шуңа күрә бирегә, Звездный егетләре кебек, кыенлыкларны җиңеп чыга белүче егетләр кирәк тә. Ничек карыйлар алар бу авырлыкларга — Рәшит Кәлимулин кебек елмаеп, юмор беләнме, әллә Илдар Латыйпов шикелле җитди итеп, уйланыпмы — хикмәт анда түгел, хикмәт егетләрнең бирешмәвендә, үз эшенә, үз бурычына намус белән каравында.

## Улькан

Көнбатыш БАМда биш поселок бар: Звездный, Грузия Ниясы (анда Грузиядән килгән төзүчеләр отряды эшли), Магистральный, Улькан, Кунерма. Байкал сырты өстендә тагын бер десант эшли, ләкин анда поселок салына башламаган иде әле — карлы тауда кара бер нокта булып, геодезистлар палаткалары гына тора.

Биш поселокның һәркайсы үзенчә төзелгән, һәркайсының үз тәртибе, үз йөзе, үз кыяфәте бар. Магистральный Киренганың бер кушымтыгы буендагы үзәнлеккә утырган. Андагы урманнарны кырып-себереп кисеп ташлаганнар. («Йорт тирәләрендә, урам кырыйларында агачларны калдырсалар, матуррак булыр иде бит», дип тә уйладык без.) Анда урамнар бик зур тәртип белән шакмаклап, төгәл итеп сузылган.

Ә Улькан парк эчендә утыргандай итеп салынган. Аның бер өлеше беркатлы зур агач биналардан, икенче өлеше — «Лунный поселок» — зәңгәр вагоннардан гыйбарәт. Поселокның бер башын икенчесеннән яшеллек аерып тора. Ульканда яшәүчеләр үз поселоклары белән горурланалар, аны иң матур дип саныйлар: «Ульканда булмаган — БАМны күрмәгән», диләр.

Бу поселокка беренче десант 1974 елның икенче ноябрендә төшерелгән. Ә Руслан Касыймов 33 нче кеше булып килгән.

БАМ — яшьләр төзелеше. Ләкин мондый зур эшне яшьлек дәрте, илһам, тырышлык, энергия белән генә башкарып чыгып булмый. Мондый эштә өлкәннәрнең тәҗрибәсе, акылы, сабырлыгы, җитдилеге дә кирәк. Киң күкрәкле, киң ак йөзле, җитди карашлы, йомшак, ләкин нык сүзле Руслан Касыймов шундый өлкән буын вәкилләренең берсе санала. Ул коммунист, аңа утыз өч яшь. Ул төзелештә профсоюз оештыру комитеты председателе булган, хәзер профсоюз комитетының председатель урынбасары. Руслан Касыймов Ульканга бик күп егетләрне алып килгән кеше.

БАМда кадрлар туплау мәсьәләсе бик җитди куелган һәм ул бик җентекләп башкарыла. Юкса, бирегә кем теләсә шул килеп, кем теләсә шул китеп торса, вертолетлар килгән-киткәннәрне ташудан бушамас, йөк ташырга аларның мөмкинлекләре дә, вакыты да калмас иде.

БАМга төзүчеләрне күпчелек очракта комсомол оешмалары җибәрә. Ләкин урындагы оешмаларның бу төзелешнең үзенчәлекләрен белеп бетермәве дә мөмкин. Шуңа күрә төрле республикаларга БАМның үз вәкилләре барып, отрядларны туплаганда алар зур ярдәм күрсәтәләр. Руслан Касыймов шундый эш белән узган кышта Әзербәйҗанга барган.

БАМ төзүчеләренә нинди таләпләр куела соң? Иң беренчесе — кешенең үз теләге булырга тиеш, әлбәттә. Теләмәгән кешене үгетләп китерүдә мәгънә юк. Икенче шарт — кешенең төзү һөнәренә ия булуы. Монда эш белмәгән кешене өйрәтеп тору шактый кыен. Өченче шарт — кешенең холкы, үз-үзен тота белүе. БАМ поселоклары зур түгел, монда коллективны сөймәсәң, холыксыз булсаң, яшәү читен. Шуңа күрә егетләрнең элек эшләгән урыннарыннан характеристикалар алына. Дүртенче шарт — сәламәтлек. Себер шартларында эшләү өчен таза, чыныккан егетләр кирәк.

— Йөз илле кеше сайлап алдык без Әзербәйҗанда, — дип сөйли Руслан Касыймов. — Һәрберсенең биографиясе белән кызыксындык, һәркайсы белән аерым-аерым сөйләштек. Әгәр кеше «бер дөнья күрим әле» дип кенә кузгала икән — андыйлар безгә кирәкми. Бу сиңа туристик поход түгел. Биредә ныклап нигезләнеп, тырышып эшләргә килсәң генә эш майтарып була. Шулай ук акча эшләп кайтырга дип омтылганнарга да кочак җәеп тормыйбыз. Дөрес, биредә акчаны яхшы гына эшләүчеләр бар, егетләрнең шактые машина алырга җыена. Ләкин бу акча бары тик тырыш хезмәт өчен генә бирелә. Без турысын әйттек, БАМда акча күктән яумый, безнең егетләр уртача аена өч йөз сум эшли, дидек. Бер күңел ачып кайтыйм әле, дип уйлаганнарга да аңлаттык. Бездә егетләр борын салындырып йөрмиләр, әмма БАМ күңел ачу урыны түгел, аның поселокларында хәмер сатылмый, ул хезмәт урыны, дидек. Моңа каршы безгә килгән егетләр: «Без акча артыннан кумыйбыз, уен-муенга бармыйбыз, безнең бөек төзелешкә катнашасыбыз килә»,— дип җавап бирделәр. Алай да черки мәсьәләсендә куркучылар булды, аңсына чыдап буламы, дип сораштырдылар. Ул черкиләр, харап, дибез, берсе-берсе карга тикле бар, вертолеттай зырылдап киләләр дә каян әләксә шуннан бер калҗа итеңне умырып алып китәләр. Шулай дигәч, шаркылдап көләләр үзләре. Чыннан да инде, егет кеше черкидән куркып торамы! Төзүчеләргә черкидән саклый торган махсус киемнәр бирелә бездә! Черки тешли дип, БАМнан качкан кешене күргәнем юк әле.

Руслан үз эшенең нәтиҗәләренә куана ала. Ул төзеп алып килгән отряд Ульканда үзенә бер кечерәк поселок булып яши, җитди сәбәбе булмаганда, ошамый дип кенә, өенә кайтып китүче юк икән әле.

— Кая ул, — ди Руслан. — Берәр гаебе өчен БАМнан кире җибәрергә дигән карар чыгарсак, күз яше белән елыйлар егетләр.

Нәрсә тота соң биредә егетләрне? Бөек төзелешкә катнашудан туган горурлану хисеме? Җаваплылык хисеме?

Горурлык, җаваплылык кирәк, әлбәттә. БАМ төзүчеләр бу хисләрне уртак кичерәләр. Ләкин кешеләрне биредә бурыч кына тота, дисәк, бу дөрес үк булмас иде. Тайга поселокларында яшәүнең бер нәрсә белән дә алыштырып булмый торган яхшы яклары да бар. Беренчедән, табигать. Без килгәндә бөтен тайга чәчәккә күмелгән иде. Елгалардан йөзеп барганда ярлардан шомырт чәчәкләре исе бөркелә, аланнарда йөргәндә ут кебек янып торган «жаркиларга», баданнарга, үрмә гөлләрнең ак чәчәкләренә сокланып туймыйсың. Нинди генә юк ул чәчәкләрнең? Аклы-шәмәхәле кыңгыраучыкларны бер-берсенә кигезеп куйганнары да, мәче чыраен хәтерләткәннәре дә, чигүле башмакка охшаганнары да бар... Без шул якларда гомер кичергән бер сунарчыдан чәчәкләрнең исемен сорап караган идек. «Монда алар хисапсыз, бары-

сының да исемен белсәң, башың артык зур булыр»,— диде ул. Аучылар чәчәк бәйләмнәре түгел, капчык-капчык «черемша» — әчкелтем дә, татлы да кыяклы үсемлек сабагын җыялар иде. Кышка киптерергә, зәңгелә куркынычыннан котылырга кирәк анысы. Тайганың сые яздан көзгәчә бетми: җәен гөмбә, көзен нарат җиләге, мүк җиләге, эрбет чикләвеге... Ә елгадагы балыкларны әйтеп тә торасы юк, ашкынып, бөтереләп, башларны әйләндерерлек дәрәҗәдә кызу аккан Улькан елгасының салкын, саф суындагы хариуслар элегрәк хәтта коры кармакка каба торган булганнар, дип сөйлиләр. Эштән кайткан егетләр бер чиләк шулпалык балыкны ярты сәгать эчендә каптырып алалар. Ә кышын ауга йөриләр.

Дөрес, биредә табигать кырыс, бер тәүлек эчендә һава җылылыгының аермасы егерме җиде градуска кадәр үзгәрә кайчак. Көндез кара тиргә батып йөрисең, ә төнлә вак яңгыр шикелле салкын чык ява. Әмма кеше сәламәтлеге өчен биредә шартлар искиткеч, ди Руслан. Һава саф, кояшның нурлары Сочидагы кебек якты.

Тормышны ямьләгән, күңелле иткән икенче шарт — ул кешеләр арасындагы мөнәсәбәт, психологик климат. Бирегә егетләрнең, кызларның асыллары килә. Алар арасында кайнап яшәү кешенең күңелен күтәрә, тормышны мәгънәлерәк итеп корырга мөмкинлек бирә. Бу турыда миңа бераз башкачарак итеп, Звездный поселогында Илдар Латыйпов та сөйләгән иде. Чыннан да, БАМ поселокларында кешеләр яраткан эш таба алалар, үзләренә чын, тугрылыклы дуслар табалар, мәхәббәтләрен, бәхетләрен табалар.

Руслан Касыймов кебек егетләр кешеләр арасында кайнап яшәүнең тәмен, җаен бик яхшы белә. Биредә спорт белән шөгыльләнмәгән кешене табу кыендыр. Ульканда балык тотучыларның да ярышлары үткәрелә. Руслан Касыймов исә — өстәл теннисы буенча икенче разрядлы спортчы, беренче разрядлы шахматчы, беренче разрядлы футболчы. Бөек Җиңүгә утыз ел тулу уңае белән Ульканда үткәрелгән футбол ярышларында ул җитәкләгән команда беренче урынны яулап алган. Хәзер команданың егетләре шул җиңү хөрмәтенә бүләккә алынган спорт костюмнарын горурлык белән киеп йөриләр.

Бәйрәмнәр биредә үзенчә үтә. Кыш озату бәйрәмен үткәргәндә, һәр милләт вәкилләре үзләренең осталыгын, гадәт-йолаларын күрсәтергә мөмкинлек алганнар. Аланда куелган мичләрдә әзербәйҗанча шашлыклар да, украинлыларның варениклары да пешкән. Татар егетләре, очына тун тагылган баганага үрмәләп, осталыкларын күрсәткәннәр.

Дуслык, теләктәшлек эштә, ял иткәндә генә түгел, дөньяның һәр мәшәкатен караганда кирәк. Касыймов бригадасы көндез мәктәп төзи, ә эштән соң егетләр еш кына бригадирларына ярдәмгә өй салышырга баралар. Руслан биш егет белән бергәләшеп биш квартирлы йорт сала. Ул ашыга, аның тизрәк хатыны белән ике баласын китерәсе килә. Тулай торакка түгел, сагыз исе аңкып торган бүрәнәләрдән салынган берничә бүлмәле квартирга китерәсе иде аларны. Бу эштә дә дус-ишсез булмый.

Гасыр төзелеше кешеләрдән тырышлыкны, осталыкны, илһам белән эшләүне таләп итә, шул ук вакытта ул аларның тормышына берни белән алыштырып булмый торган мәгънә дә бирә.

## Киләчәккә бер караш

Риваятьләрдә «Себер» сүзе — йокыга талган җир дигән мәгънәне аңлата икән дип сөйлиләр. БАМ — ул шушы «йокыга талган» җир аркылы бер җеп булып сузылып ятачак тимер юл гына түгел, Байкал — Амур магистрале — йөзләрчә чакрым киңлектәге җирләрне мәңгелек

йокысыннан уятачак зур төзелеш ул. Бу юл Якутиянең, Чукотканың һәм башка өлкәләрнең экономик үсешенә нигез булып ятачак. БАМ тирәсендә зур промышленность зоналары үсеп чыгарга тиеш.

Заманында бөек рус галиме Ломоносов: «Россиянең куәте Себер белән артачак», — дигән. Себер тайгалары, Себер таулары астында иксез-чиксез байлыкларның яшеренеп ятуы ул чакта ук мәгълүм була. Совет власте елларында бу мәсьәләгә әһәмият аеруча көчәйде. ГОЭЛРО планын төзегәндә үк Себер байлыкларын үзләштерү турында җитди сүз барды.

Себернең БАМ узачак өлкәләрен өйрәнү әле һаман тәгалләнмәгән, һаман дәвам итә һәм анда торган саен күбрәк файдалы казылмалар барлыгы беленә. Соңгы елларда Удокан бакыр чыганагы ачылды, тауларда тимер рудалары, ташкүмер, никель, молибден, нефть, газ барлыгы беленде. Ул байлыклар барысы да илнең хәзинәсенә алыначак. БАМ төзелү нәтиҗәсендә бер миллион квадрат километр территориядәге табигый байлыкларны хуҗалык өчен файдаланырга мөмкинлек ачылачак. Ә Себер үз серләрен һаман ачып бетермәгән, Себердән ил көтелмәгән яңа бүләкләр алачак әле.

Без барганда гына да БАМда бу турыда хәйран калып сокланып сөйлиләр иде. Байкал сырты аша тоннель салу өчен разведкага килгән геологлар, мәсәлән, кар тауларын скважина белән тишеп, грунт үрнәкләрен алмакчы булганнар икән. Аларның скважинасыннан егерме метр биеклектәге кайнар су фонтаны бәреп чыккан. Хәзер галимнәр, ничек итеп шул кайнар чишмәләр аша тоннель сузу мәсьәләсен хәл итү турында баш ваталар...


Яңа магистраль илләрне, халыкларны бер-берсенә якынайтыр. Тын океан тирәсендә урнашкан илләр белән сәүдә итүгә яңа мөмкинлекләр ачар. Ул юл буйлап көнчыгыш илләрдән көнбатыш илләргә һәм киресенчә бик күп йөкләр үтәр.

Без йөргән җирләрдә юлны 1978 елда салып бетерү күздә тотыла. Ике елдан магистраль Байкал сырты тоннеленә килеп җитәчәк. Төзүчеләр 1982 елда БАМның буеннан-буена поездлар җибәрү турында хыялланалар.

Әгәр бәхетем булып, шул поездлар йөри башлагач, тагын да вертолет белән үткән җирләр өстеннән оча алсам, минем күз алдыма бөтенләй башка төрле манзара ачылыр. Мин төз урамлы яңа шәһәр-поселоклар, тимер юлдан як-якка омтылган асфальт юллар, завод-фабрикалар, елгалар аша челтәрле күперләр, бетон буалар, электр станцияләре, иген үсеп утырган басулар, аланнарда утлап йөргән көтүләр күрермен. Шул ук вакытта тайга да булыр — шулай ук мең төсле, гүзәл булыр, барча гөлләрен, кешләрен, пошиларын, аюларын үз куенында яшереп саклый торган булыр ул. Шулай булырга тиеш, чөнки бүген БАМ тирәсендәге урманнарны саклау, табигатьнең яшел хәзинәсен киметмәү турында зур сүз бара, моның өчен чаралар күреләэ, юл төзүче яшьләр бу хакта бик җитди сөйлиләр. Кыскасы, Себер үзенең чиксез гүзәллеген саклар, әмма инде ятим булып, буш булып тоелмас.

Марсель Зарипов

# УРАКЧЫ ЕГЕТЛӘР



Рәфит Хәеров, Михаил Латышев, Геннадий Кривошеев, Леонид Гордеенко, Алексей Ерочкин һәм аларның сменадаш иптәшләре нинди зур эш башкарып чыкканны сез, мөгаен, белмисездер әле. Ул хакта кыска гына белешмә укып күрсәтим: «Дивинил заводының «В» сменасы (Рәфит Хәеров җитәкчелегендәге смена шул инде) яңа ацетонитрил дигән эреткечне куллануны гамәлгә ашырып, цехның куәтен икеләтә арттырырга сүз бирде».

Бу рәсми документны комбинатның партком секретаре Илһам Мортазин күрсәтте. Ул әле секретарь буларак яшь, беренче елын гына эшли.

— Карагыз әле безнең егетләрне! — диде ул, чын күңеленнән горурланып. — Шундый зур эшкә тотынырга җөрьәт иткәннәр бит!

Комбинатның реакторларында көне-төне бертуктаусыз катлаулы үзгәрешләр барып торган зур производство — станок яки комбайн гына түгел ул сезгә. Станокта яки комбайнда үз эшенә күңел биргән теләсә кем уңышка ирешергә мөмкин. Ләкин менә комбинат тикле комбинатта һәм тәүлегенә өч смена эшләп торганда исә нибары бер смена кешеләре ничек итеп цехның проектта каралган куәтен бермә-бер арттыра алырга мөмкин икән соң? Монда тагын шунысы да бар: бер смена никадәр генә тырышып эшләсә дә, бүтәннәре чак кына төгәлсезлеккә юл куйса, тәүлекләр буена тырышып җайга салынган хезмәтнең җилгә очачагын көт тә тор!

Әмма мәсьәлә монда реакторларның проект буенча исәпләнгән куәтен ике мәртәбә арттыруда гына да түгел. Андый мисаллар тормышта булгалап тора. Хикмәт шунда: продукция эшләп чыгаруны ике мәртәбә арттырырга дигән йөкләмәне үз өсләренә алганга кадәр уннан артык аппаратчы да, смена башлыгы өлкән инженер-технолог Рәфит Хәеров та әлеге ацетонитрил дигән эреткечне күргәннәре генә түгел, хәтта аның турында ишеткәннәре дә булмаган. Ә эреткеч — химик-аппаратчының төп эш коралы. Нәкъ менә шул эреткеч дигән нәрсә белән «сихерләп», химик чималдан ни кирәк шуны эшләп чыгаралар да инде.

Смена башлыгы Рәфит Хәеров иптәшләре арасында иң яше дияргә була. Өйләнүенә әле ел тулып үткән генә.

Рәфитнең егерме сигез еллык тормышын өч өлешкә аерып карарга кирәктер. Беренче өлеше — авыл. Поездлар да туктамый, самолетлар да төшми торган Тәкәнеш авылы. Рәфит шунда туып үскән, шунда унбер классны тәмамлаган.

Икенче өлеше — химия-технология институты.

Хәеров Менделеев таблицасына нигезләнгән химик формулаларны мәктәптә укыганда ук яттан белә һәм теләсә кем, теләсә кайчан сораса да әйтеп бирә ала торган була. Шуңа ул КХТИга һич тә икеләнмичә керә. Ул Түбән Кама нефть-химия комплексында эшләү өчен белгечләр әзерли торган махсус группада укый. Укып бетергәч, аларны — унсигез яшь инженерны — Түбән Камага эшкә җибәрәләр.

Институтта алты елга якын укыган чагында Хәеров Менделеев таблицасында күрсәтелгән һәм нигездә безнең әйләнә-тирәбездәге материяне тәшкил итә торган элементларның йөзләрчә, меңнәрчә төрле рәвешләргә керә алуларын өйрәнә, тикшерә һәм шул үзгәрешләрне чагылдыра торган формулаларны күңеленә беркетеп, ятлап куя. Ә менә ацетонитрил дигән нәрсә белән аңа танышырга туры килми.

Рәфит Хәеров биографиясенең өченче һәм иң кыска, ләкин бик әһәмиятле өлеше, үз чиратында, өч кисәккә аерылып тора. Башта аны комбинаттагы экспериментальпромышленность җайланмасына аппаратчы итеп билгелиләр. Исеменнән үк күренеп торганча, бу җайланмада әле бөтенләй үк ачыкланып бетмәгән, әмма игътибарга лаеклы булган технологик процессларны сынап карыйлар. Әнә шунда әйбәт кенә эшләгәч, Рәфитне каучук цехларын эшләтә башларга җибәрәләр. Ә инде анда азрак тәҗрибә туплагач, аны смена башлыгы итеп дивинил заводына күчерәләр. Нәкъ әнә шунда эшләгәндә Хәеров алда әйтеп үтелгән тәкъдимне күтәреп чыга. Әмма байтак кына башлангычларны күтәреп чыгып, матур-матур вәгъдәләр биреп, зур-зур йөкләмәләр алып, һәм баштагы чорларда бик нык шаулап та соңыннан суынып, эшне ахырынача очлап чыга алмыйча калган очраклар, кызганычка каршы, тормышта булгалап тора. Ләкин Хәеров җитәкчелегендәге аппаратчылар әйткән сүзләрендә нык торалар: проект буенча дүрт блокта да эшләп чыгарылырга тиешле продукцияне нибары ике блоктан алуга ирешәләр.

Монда шунысын ачыклап китәргә кирәк: Госстрой нормалары алай бик мулдан булмый. Завод-фабрикаларны шул нормада күрсәтелгән вакытка бар көченә эшләтә башлау, ай-һай, алай бик үк ансат нәрсә түгел ул. Комбинатта дүрт блок төзергә кирәк дип исәпләп чыгарган галимнәр уйламыйча эшләмәгәннәр, әлбәттә. Тик шулай да... Әйтик, океан корабына дүрт двигатель куелган, ди. Ә аның командасы шуның икесен генә эшләтеп тә әлеге дүрт двигатель бирә торган тизлеккә ирешә!

*
* *

Мин комбинатта космоска очарга әзерләнгән ракеталарга охшап торган колонналарга карап, алар эчендә кеше акылы җитмәстәй серле үзгәрешләр баруы турында уйланып йөргәндә Хәеров сменасының ял көне иде. Шуңа күрә аның белән очрашырга теләвемне дүрт йөз дә бишенче цехның башлыгы Владимир Иванович Кудеровка әйтеп калдырырга туры килде.

Кудеров минем үтенечне вакытында җиренә җиткергән иде булса кирәк, Хәеров миңа кунак йортына үзе шалтыратты. Ләкин мин очрашу турында авыз ачуга, ул: «Кирәк нәрсәгезне телефоннан сорагыз», — дип, минем белән озаклап сөйләшеп торырга нияте юк икәнлеген сиздереп куйды.

Бу хәл миңа сәеррәк тоелды. Әмма нишлисең, дөньяда төрле хәлләр була. Әйтик, бик шаулап бер яңалыкны күтәреп чыгалар. Аның инициаторларына бөтен кирәкле шартлар тудырыла. Шуның аркасында аларның эш нәтиҗәләре шаккатырлык дәрәҗәдә яхшыра. Шуннан соң шул ук башлап җибәрүчеләрне күрсәтеп: «Карагыз, әнә ничек эшләргә кирәк!» дип, бүтәннәрне дә алга өнди башлыйлар. Башкалар, чыннан да, моны күтәреп ала: гадәттәгедән яхшырак, күбрәк һәм әйбәт сыйфатлырак итеп эшләргә тырышалар. Ә инициаторлар тик үзләренә генә бөтен кирәкле шартларны тудырганга һәм тик үзләрен генә мактаганга иптәшләре алдында кыенрак хәлдә кала.

Менә шушындый ясалма оештырылган нәрсәләр нәтиҗәсендә кайчакта шактый көлке хәлләр килеп чыга. Бер автоколоннада, мәсәлән, менә мондый «әмәл» уйлап тапканнар. Колоннадагы шоферлар үзләре ташыган йөкнең бер рейсын чиратлашып бер иптәшләренә яздырып баралар. Нәтиҗәдә теге кеше ай буе алдынгы булып, макталып йөри. Ә икенче айда икенче бер шоферны шулай «күтәрәләр» һәм, шул рәвешле, бер елда унике кеше «герой» булып йөри. Гадел алым булмаса да, гыйбрәтле һәм үзенә күрә талантлы кеше уйлап тапкан нәрсә бу!

Хәеров минем белән очрашырга теләмәгәч, мин ирексездән менә шул турыда уйлап алдым һәм, дөресен әйтим, әллә боларда да эшләр шулайрак булган микән дип шикләнеп тә куйган идем. Шикләнмәслек тә түгел: Хәеров башта, мин очрашыр-

га теләгән вакытка, кинога билет алынган, диде. Мин, ике серияле фильмнар да өч сәгатьтән арыга бармый, кинодан соң күрешик дигәч, ул тагын сәбәбен табып, минем бер көнлек ял йортына барасым бар, путевкам кесәмдә инде, диде. Мин анысына да риза булып, син ял иткәндә шәһәрегез белән таныша торырмын, шуннан ары сөйләшербез дигәч, ул тагын җавабын тапты һәм, ул чакта инде миңа сменага эшкә чыгарга вакыт җиткән була, диде. Эшләр болайга киткәч, мин дә чәер урынына ябыштым тегеңә. Ярый, бик әйбәт икән алай булгач: мин комбинатка барып, эшләгән эшләрегезне тагын бер тапкыр карап кайтырмын, дидем.

Тик шуннан соң гына, ниһаять, Рәфит минем янга килергә булды.

Озын буйлы, таза һәм чибәр йөзле егет икән ул. Эшләгән эшенең бәясен белә торган кешеләргә хас булганча, шактый җитди дә күренә иде. Сөйләшә-белешә торгач, аңлашылды: алар башкарган эшләр, чыннан да, җитди һәм катлаулы булган икән шул.

Рәфит кулына каләм-кәгазь тоткан кешенең тикмәгә генә йөрмәвен яхшы белә иде булса кирәк. Ул минем номерга кереп, пальтосын салмыйча гына кәнәфигә ипләп утыргач, беренче сүзе итеп:

— Әйтегез әле, сез бу турыда язмыйча булдыра аласызмы? — диде.

— Ә нигә язмаска икән? — дидем мин аның бу соравына бераз гаҗәпләнеп. — Мин язганнан сезгә мораль канәгатьлектән башка һич бер нәрсә булмас, әлбәттә. Ләкин аның башкаларга файдасы тиюе мөмкин.

— Анысы бәлки шулайдыр. Ләкин бик уңайсыз килеп чыга: радиодан Хәеров дип сөйлиләр, газеталарда Хәеров дип язалар. Барысы тик безнең сменаны гына мактый. Ә монда безгә кадәр күпме сукалаганнар! Без нәрсә? Без сөрелгән, чәчелгән кырда үскән игенне урыр вакыт җиткәч кенә килеп төштек. Икенче төрле итеп әйткәндә, уракчылар гына бит без. Ә менә хәзер теге сөргән-чәчкән кешеләр читтә кала, ә без герой булып йөрибез... Эш ничек булды дисезме? Цех начальнигы урынбасары Турбайцев Юрий Николаевич бер көнне бөтенебезне дәшеп алды да: «Дүрт блокта эшләнергә тиешле продукцияне ике блоктан алырга тырышып карыйсызмы? Әгәр йөрәгегез җитми икән, кирәкми, тотынмагыз. Мин бүтәннәр белән сөйләшермен», — диде. Без ул чакта бераз ялгыштык. «Бүтән сменалар белән сөйләшмичә без бу эшкә алынмыйбыз!» — диясе калган аңа. Бер тәүлек вакыт әрәм китсә китәр иде. Ә Турбайцевны, күрәсең, бик ашыктырган булганнар. Шуңа күрә безне бик коры тотты булса кирәк. «Әйдәгез, әйдәгез, нигә куркасыз, үз көчегезгә ышанмыйсызмыни?» — дип, борылырга да урын калдырмады ул безгә.

— Бүтән сменада эшләүчеләр сезгә үпкәләгәннәрмени соң? — дидем мин.

— Юк. Шулай туры килгәнен аңлыйлар. Бүтән график белән эшләгән чак булса, бу таяк башкаларга эләгер иде... Ә ул чакта эш менә болай булды: бүтәннәр башлаган эшне без я распарга, яки, бу башлангыч бернигә дә ярамый дип, аны кире кагарга тиеш идек. Шуңа күрә безнең турыда гына язарга кирәкми. Югыйсә бик тә гади, бик тә ансат килеп чыга: аппаратчылар тели икән — шалт! — бөтенесе шулай була да куя. Ләкин хикмәт анда түгел. Иң мөһиме: аерым кешеләрнең генә түгел, уннарча, йөзләрчә, меңнәрчә кешеләрнең теләге һәм тырышлыгы кирәк...

Рәфит менә шуларны әйткәч, аларның эше белән кызыксынуым тагын да арта төште: аларга кадәр кемнәр «сөргән» дә кемнәр «чәчкән» хәзер атаклы булып киткән бу «җирне»?

*

* *

Без сүз алып бара торган дивинил заводы сызым-проектларын 1966 елда эшлиләр. Башта ул заводны Тольятти шәһәрендә төзергә планлаштырган булалар, әмма соңыннан, ситуация үзгәргәч, тоталар да әзер проектны Идел буеннан Камага күчерергә карар кылалар.

Итекчегә — күн, корыч коючыга тимер рудасы ничек кирәк булса, химикларга да дивинил шулай ук кирәк. Башта аппаратчылар гади күз белән бөтенләй күреп тә булмый торган нефть газын яки сыеклаидырылган углеводородларны реакторларда

тэрле компонентларга аералар. Бутан, пропан, гексан, пентан, изопентан... саный китсәң очына чыгарлык түгел. Аларның һәркайсы үзенә бер төрле продукт алу өчен кирәкле чимал. Бутан катнашмасыннан, мәсәлән, бутиленнар аерып алына, ә бутиленнардан — дивинил. Дивинил исә, үз чиратында, Арктика салкыннарыннан да, тропик эсселәрдән дә курыкмый торган махсус каучук эшләүгә тотыла. Һәм башкалар, һәм башкалар...

Бу очракта без тышкы, ягъни географик үзгәрешкә түгел, бәлки заводның технологиясендәге үзгәрешкә күбрәк игътибар итик. Нәкъ әнә шул әлеге проектчылар технологик аппаратлардагы реакцияләрне элеккечә, гадәттәге ысул белән гамәлгә ашыру өчен кирәк булачак исәп-хисапны чыгарып азапланган айларда Ярославльдә синтетик каучук мономерлары фәнни-тикшеренү институтында шул ук реакцияләрне яңа ысул белән башкару процессын уйлап табалар. Бу ысул белән эш иткәндә моңарчы кулланылып килгән ацетонның хаҗәте калмый. Бутан фракциясеннән башта бутилин, аннары дивинил китереп чыгару өчен ацетонитрил куллану күздә тотыла. Ярославль галимнәре бу эшне 1965 елның 1 февраленә тәгәллиләр.

Монда, кыскача гына булса да, аңлатма кирәк. Реакторларда көне-төне бертуктаусыз булып торган катлаулы химик һәм физик үзгәрешләрне ике сүз белән генә дә әйтеп була: кушылу һәм аерылу, аерылу һәм кушылу. Барлык үзгәрешләр дә нигездә әнә шуңа кайтып кала. Теләсә нинди катлаулы молекуланың бер атомын алып ташлыйсың яки аңа бер атом өстисең икән — башта алган бер әйбердән бөтенләй бүтән төр әйбер барлыкка килә. Ясалма каучукны иң беренче булып уйлап тапкан Сергей Владимирович Лебедев моңа ничек ирешкән? Икмәктән куылган спирттагы ике су һәм бер водород молекуласын аерып алган да — шуннан дивинил килеп чыккан. Яки менә икенче бер мисал: агулы булган метил спирты молекуласына бер углерод, ике водород атомы кушасың икән, ул гап-гади аракы спиртына әйләнә дә куя.

Табигать үз эшенә читтән тыкшынуны яратмый. Ул үзен һәртөрле үзгәртүләрдән сакларга тырыша. Материянең яшәеше әнә шуңа бәйләнгән. Чыннан да, тормыш шарты — көрәш. Көрәш тукталса — тормыш бетә. Күз алдыгызга китереп карагыз: элементларның химик каршылыгы бетеп, алар бик ансат һәм тиз генә бер төрдән икенче төргә күчеп тора башласалар, ничек булыр иде икән? Ул чакта җир йөзе күмерсез, нефтьсез, алтынсыз һәм башка шундый бик күп төрле минераль байлыкларсыз калыр, ягъни кешелек дөньясын табигать үзе үк талап бетерер иде. Ярый әле, табигать-анабызга үзенең даимилеген саклау дигән нәрсә хас. Һәм, әйтергә кирәк, бу бөек эшен ул бик тырышып башкара. Мәсәлән, әлеге реактор колонналарына меңәр тонна чимал тутырырга һәм аны әллә нинди зур басымнар астында кайнатырга, парга әйләндереп бер колоннадан икенче колоннага кудырырга һәм шуннан соң да ул чимал бернинди үзгәрешсез калырга мөмкин. Ә ул чимал ничек үзгәртелә, ничек бер төр продукциядән икенче төр продукция алына соң? диярсез. Бу мөһим эшне эреткечләр башкара. «Сихерче» аппаратчылар әнә шул эреткеч дигән «сихерле таяк»лар ярдәмендә реакторлардагы катлаулы чималдан үзләренә кирәкле продукцияләрне аерып алалар. Образлы итеп әйтсәк, табигатьне үзләренә буйсындыралар, кешегә хезмәт иттерәләр.

Алгарак китеп булса да әйтеп куясы килә: әлеге ацетонитрил белән эш итә башлау нәтиҗәсендә Түбән Кама химиклары беренче елны ук ике миллион табыш алуга ирешәләр. Ә ил күләмендә шулай эшләгәндә нинди зур табыш булган булыр иде? Хәер, Ярославль институты галимнәре нәкъ менә шул киләчәк табышларны күздә тотып тырышканнар да инде.

Ләкин түбәнкамалыларга кадәр аның белән бүтән беркайда кызыксынмаганнар.

Хәзер инде тарихка күз салыйк. 1927 елның 29 декабрендә Ленинград галиме Сергей Владимирович Лебедев һәм аның җиде хезмәттәше үзләре тапкан беренче ясалма каучукны, посылкага салып, Мәскәүгә җибәрергә ашыгалар. Кайсы посылканың ящигын ясый, кайсы төргеч әзерли, ә Сергей Владимирович үзе шул каучукны ничек итеп эшләп чыгарырга кирәк булган аңлатма-формулаларны яза. Галимнәр ашыга, чөнки бу көн — ясалма каучук табуны күздә тотып игълан ителгән бөтен дөнья конкурсының инде соңгы көне була. Иртәгесен әлеге посылка Мәскәүдә, СССР Халык хуҗалыгының Югары советы карамагында булырга тиеш. Ленинград галимнәренең берсе дә үзләренең бу ачышы иң уңышлы ачыш икәнен, аңа беренче приз

бирелачаген, әлбәттә, белми әле. Ләкин аларның берсе дә ачышларның иң яхшысы һич тоткарланмыйча эшкә ашырыла башлавына шикләнми.

Бу ачышның язмышын күздән кичереп үтик. 1928 елның февралендә Ленинград галимнәре конкурсның беренче призын алалар. Аннары тәҗрибә ясау корылмасының конструкциясен һәм ул корылманың үзен төзеп, шунда ясалма каучук алу технологиясен үзләштерәләр. Сүз уңаенда шунысын да искәртеп китик, әлеге экспериментны дәвам итү өчен кирәк булган унөч мең сум акча аларга Сергей Миронович Кировның шәхси күрсәтмәсе нигезендә бирелә. Ә инде 1930 ел башында тәҗрибә заводы төзелә башлап, алты айдан соң ул завод үзенең беренче продукциясен — күз алдыгызга китерегез! — тулы бер тонна дивинил эшләп чыгара. Дивинилдан каучукка — бер генә адым! Утыз икенче елда, июль аенда Советлар Союзында Ярославль синтетик каучук заводы эшли башлый. Шул ук елның октябрендә Воронеж, утыз өченче елда Ефремов, ә утыз алтынчы елда Казан заводлары сафка кертелә. Боларның барысына сигез ел вакыт үтә.

Ярославль галимнәре ацетонитрил белән эш итү процессын уйлап тапканнан соң да шулай ук сигез ел вакыт узып китә. Ләкин аларның регламенты архив киштәләрендә бернинди хәрәкәтсез тузанланып ята бирә. Моның сәбәбе нәрсәдә? Шундый зур отыш бирәчәк хезмәтне яшереп саклаганнардыр яки аның турында белмәгәннәрдер, ишетмәгәннәрдер дип уйламыйм мин. Ул эшне институт нефть-химия һәм нефть эшкәртү промышленносте министрлыгы тәкъдиме буенча, Главкаучук заказы нигезендә башкарган лабаса. Галимнәрнең отчетларын өйрәнмиләр яки, һич югында, күздән кичермиләр микәнни?

Бу гадәти ачышны Бутлеров тарафыннан хәзерге заман химиясенең әлифбасы һәм югары математикасы булган органик кушылмалар теориясе тудырылу яки атом төшен бүлүгә ирешү кебек эпохаль зур ачышлар белән тиңләштерергә һич тә җыенмыйм. Ләкин шунысына шигем юк: соңыннан зур-зур ачышларга китергән иҗтимагый процесска меңнәрчә һәм меңнәрчә гади тикшеренүләр нәтиҗәсендә ирешелә. Бөек хыялый-реалист Фрэнсис Бэкон әле уналтынчы гасырда, урта гасыр хорафатлары хөкем сөргән заманнарда ук, киләчәктә зур үзгәрешләр булачагын алдан сизенеп, эшнең башын йөз күзлегә, ә азагын йөз куллыга тапшырырга кирәклеген әйтеп калдырган. Нигә азагын йөз куллыга икәне мәгълүм — эш озакка сузылмасын өчен!

Акрын кыймылдау әле уналтынчы гасырларда ук зыянлы нәрсә булгач, безнең заманда, атом гасырында, фәнни-техник революция чорында аның никадәр хәвефле икәнен озаклап аңлатып торуның хаҗәте дә юк. Тик бер мәсьәләгә генә укучыларның игътибарын юнәлтеп китәсе килә. Галимнәр һәм аларга ярдәм итүче хезмәткәрләр саны 1950 елдан алып 1960 елга кадәр ике ярым тапкырга, аннан соңгы ун елда ике тапкырга арткан. Хәзер безнең илдә фәнни хезмәт белән шөгыльләнүчеләрнең барысы өч миллионга җитте. Шул темп белән артып барган тәкъдирдә аларның саны егерменче гасыр ахырында егерме дүрт миллионга җитәчәк, диләр. Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, ул чакта фәнни ачышлар саны да галимнәр санына нисбәтән артык булачак.

Менә шушындый хәлдә сорау туа: фән үсешенең ул катлаулы юлында барышлый очраган һәр вак-төяк түмгәк янында тукталып, акыл трубкасын пыскытып җибәреп, нишләргә, кая барырга, кирәкме бу нәрсә, кирәкмиме, дип озаклап уйланып тора башласак — прогресс биеклекләренә кайчан күтәрелә алырбыз икән без?

Әле сугышка кадәр үк нибары сигез ел эчендә илебез шундый зур эшләр эшли алган — дөньяда беренче булып ясалма каучук индустриясен тудырган икән, хәзер мөмкинлекләребез ул чактагыга караганда мең мәртәбә арткач, нигә гадәти эш тәртибендә гамәлгә ашырылырга мөмкин булган гади идея шулай ук сигез ел буена үзенең кулланылышын таба алмыйча архивта яткан соң?

Күрәсең, моның сәбәпләре күп булгандыр. Ихтимал, ацетонитрил процессын ачкан галимнәр, без үзебезнең эшне эшләдек, дип тынычланып калган, ә аларның идеясен практикада куллана башларга тиешле предприятие башлыклары, бәлки ул эш барып чыкмас, шуңа күрә ашыгырга кирәкми, карап-көтебрәк торудан да яхшысы булмас мондый чакта, ә менә бүтәннәр алынып эшли башласа — анда күз күрер, дип, кирәгеннән артык саклык-тыйнаклык күрсәткән булуы да мөмкин. Гаеп кемдә булгандыр — анысын әйтүе кыен. Ләкин шунысы бәхәссез: Рәфит Хәеров һәм аның

иптәшләре, ацетонитрил процессын куллану нәтиҗәсендә, ацетон процессына караганда күп тапкыр зуррак уңышка ирешергә мөмкин икәнен расларга алынган вакытта ул эретмә белән безнең илдә эш итүче беркайда да булмый әле. Шуңа бөтен комбинатка дан китергән ул башлангычның кая алып барып чыгачагын беркем дә алдан әйтә алмаган...

*

* *

Яңа дивинил заводында төзүчеләр башта бутилен цехын өлгертәләр. Ләкин аны ничек һәм нәрсә белән эшләтә башларга? Цехның блоклары ацетон процессына исәпләнгән проект буенча корылган. Аны ничек итеп ацетонитрилга көйләргә? Монда кнопка басып кына эш чыгарып булмый, күп кенә җитди үзгәрешләр кертергә туры киләчәк...

Ә вакыт һаман үтә тора. Комбинат исеменә адресланган телеграммаларның саны көннән-көн арта бара. Аларның барысы да ашыгыч, барысы да «тизрәк» дип таләп итеп сугылган. Күп санлы шул телеграммаларның тик берничәсен генә китерик. Менә Тимертаудан килгәне: «Производство хаҗәтенә 350 тонна дивинил тәяп озатуыгызны үтенеп сорыйм кайчан күпме озатуыгызны телеграф белән хәбәр итегез җавабыгыз өчен түләнгән Карпиловский». Ә менә монысы Ефремов шәһәреннән: «Дивинил булмаганлыктан каучук җитештерү киметелде тизрәк тәяп озатуыгызны сорыйм Лукьянович». «Хөрмәтле Николай Васильевич, — диелгән Новокуйбышевскидан килгәнендә, — безгә 800 тонна бутилен кирәк шуның 500 тоннасы хәзер үк бик тиз тәяп озату мөмкинлеген табуыгызны үтенеп сорыйм нәтиҗәсен ашыгыч көтәм хөрмәт белән Богуславский». Салаваттан килгән телеграммада да шул ук үтенеч: «Капиталь ремонттан соң производствоны җибәрү уңае белән тизрәк бутилен озата башлавыгызны сорыйбыз Леонтьев».

Менә шушындый хәлдә ни эшләргә?

Комбинатның генераль директоры Николай Васильевич Лемаев яңа заводны эшләтә башларга тиеш кешеләрне үз кабинетына җыйный да әйтә:

— Бутилен цехын ничек җибәрәбез? — ди. — Борынгы бабаларыбызны хөрмәтләп, искечә — ацетон белән эшлибезме? Әллә, фәнни-техник революцияне алга таба этәреп, ацетонитрил белән эшләргә талпынып карыйбызмы? Цехны ацетон белән эшләтә башласак, режимга вакытында керербез, ихтимал, премияләр дә булыр, рәхмәт сүзләре дә ишетербез. Ләкин исәнләшергә алай ук хөрмәтләп кул бирмәсләр. Һәм алар хаклы булыр. «Акыллы башлар табылган! Соңгы ноктасы инде моннан сигез ел элек куелган проект буенча завод салганнар да, хәзер шуны эшкә керттек дип кукраеп йөриләр!» дип үк әйтмәсәләр дә, эчтән генә бездән көлеп йөрерләр. Тәвәккәлләп ацетонитрил белән эшләргә тотынып та, аны булдыра алмаслык — шулай ук хурлыкка калуыбыз бар. Нишлибез? Әйдәгез, шул мәсьәләне хәл итик!

Аның соравына сорау белән җавап бирәләр:

— Баштарак нәрсә карадык соң без? Ни уйладык?

Бервакыт мин болай кызыксынып кына цех начальнигы Кудеровтан комбинатта эшләүчеләр Лемаевка ничек карыйлар? дип сораган идем. Кудеров — Лемаевны әле Уфада гади аппаратчы чагыннан ук белә торган кеше — иңбашын сикертеп куйды да:

— Кем белә инде аны, — диде. — Яраталар дип үк әйтергә батырчылык итмим, башлыкларны яратырга түгел, ә хөрмәт итәргә тиешләр. Хөрмәт итүен итәләр, аның белән сөйләшкәндә алай артыгын ычкындырмыйлар. Лемаев сорый, таләп итә, ә бүтәннәр аңа җавап бирә.

Владимир Иванович миңа ул чакта әнә шулай дигән иде. Ә менә бу юлы ул кагыйдә бозыла: генеральный кулы астында эшләүчеләр сорый, ә ул аларга җавап бирергә тиеш була.

— Без нәрсә карадыкмы? — ди Лемаев чак кына уйланып торганнан соң. — Без британ парламентындагы кебек сүз көрәштердек. Һәм як-ягыбызга каранып тордык: бәлки берәрсе башлап юл күрсәтер, янәсе. Ләкин башлап юл ячучы табылмады. Карале, Перлин, — ди ул аннары, җитештерү-техника бүлеге башлыгына мөрәҗәгать

итеп. — Технология өлкәсендә син безнең патша да, алла да. Кызыксынып караганың юкмы: Омскида, Тольяттида, Стәрлетамакта эшләр ничегрәк тора икән? Ацетонитрил белән эш итеп караганнары булмады микән?

— Юк. Тольяттида җыенып караганнар икән, хәтта проектын да төзегән булганнар, ләкин эшкә керешмәгәннәр.

— Алайса, алар консерваторлар икән, ә без менә прогрессны алга сөрергә җыенабыз булып чыгамыни?

— Аларга кыенрак: аларга эшләп торган производствоны туктатырга, барысын да үзгәртеп корырга туры килер иде. Шундый зур мәшәкатьләрдән соң да эшләре җайга салынмаса, яңадан искегә кайтырга мәҗбүр булырлар иде.

— Без дә үзебезнең «сигараларны» утыртып куйдык, безгә дә үзгәрешләр кертергә туры киләчәк бит. Һәм шуннан соң безнең кайнашу да бушка китсә?

— Ул чакта — эшләр харап!

— Ә моннан ун ел элек эшләнгән проектны яхшылап тикшермичә, кирәкле җирләрен заманга яраклы итеп үзгәртмичә торып, шуның буенча завод төзү — эшне харап итү түгелмени?

Проект, имеш, безнең кайгы түгел. Безгә бирделәр — без алдык булып чыга. Алайса безнең ни хаҗәтебез кала соң? Бәлки, безгә көтеп торырга кирәктер. Бәлки, бу эшне бүтән берәр заводта башлап җибәрерләр дә без шуннан соң гына тотынырбыз, ә?..

Әлеге проектка нигә алданрак үзгәреш кертмәүләрен, нигә заводны инде эшләтә башлар көнгә килеп терәлгәч кенә бу мәсьәләне кузгатып, «Ни эшләргә» дип баш ватып утырганнарын болай тәфсилләп сөйләвемнең сәбәбе шул: моның белән мин инде күптән мәгълүм булган, бер дә ялгышмаган кеше түгел, бәлки вакыт-вакыт ялгышкалап та ахыр чиктә барыбер дөрес юлга барып чыккан кеше — чын кеше була, дигән хакыйкатьне тагын бер кат искәртеп китмәкче булдым. Эшләмәгән кеше генә ялгышмый, дигән бит борынгылар.

Искиткеч зур комбинат шау-гөр килеп эшләп тора, реакторлар инде ацетон белән эшли башларга әзер, ә генераль директор кабинетында җыйналган кешеләр иртәгә эшли башларга тиешле шул корылманы ничек көйләү турында баш ватып утыралар. Мәсьәләне вакытында күтәреп чыгарга соңга калулары өчен алар үзләрен-үзләре тирги. Сигез ел эчендә инде әллә ниләр эшләп булган булыр иде дип үкенешәләр. Ә хәзер, запаста бер минут та вакытлары калмагач, ниндидер җитди чара күрергә кирәк булуын тоеп, борчылалар. Ә тәэминат бүлегендә әллә никадәр телеграмма өелеп ята. Аларның барысының да эчтәлеге бер төрле: «Бутилен бирегез!» «Кайчан дивинил эшләп чыгара башлыйсыз?» Тагын шунысы да директор кабинетында утыручыларның күңеленә шик төшереп тора: ә Ярославль галимнәренең лаборатория шартларында ясалган исәп-хисабы практикада гамәлгә ашмаса нишләргә?

Дәүләт тарафыннан куелган җитәкче буларак, генеральный директор бу яңа заводны нинди процесс белән эшләтә башлау мәсьәләсен ялгызы гына, приказ тәртибе белән дә хәл итә алган булыр һәм менә хәзер монда утыра торган кешеләр аның ул боерыгына берсүзсез буйсынырлар да иде. Ләкин Лемаев команда бирү юлы белән генә эш итүче җитәкче түгел. Ул — аппаратчыдан башлап хезмәт баскычының барлык басмаларын да үтеп, генеральный директор дәрәҗәсенә күтәрелгән практик кеше — югарыдан бирелгән боерыкларның язмышы, ахыр чиктә, барыбер ул боерыкларны үтәүчеләрнең эшкә нинди мөнәсәбәттә булуына кайтып калганлыгын яхшы аңлый... Менә комбинатның производство-техника бүлеге башлыгы Перлин. Лемаев аны Түбән Каманы төзи башлаган көннән үк белә... Үзе әле яшь булса да, инде зур һәм катлаулы производствоның — дивинил заводының директоры булып эшли башлаган Венюков... Әнә цех башлыгы Кудеров. Ул Лемаев белән Яңа Уфа заводында бергә эшләгән иде: берсе — аппаратчы, икенчесе өйрәнчек булып...

Дөрес, Лемаев кул астында эшләүче кешеләрнең үзе биргән боерыкларны үтәгәнен ярата. Ләкин үзе дә, директор буларак, коллектив фикере белән исәпләшә. Менә хәзер дә, яңа ысул белән эшли башларгамы-юкмы дигән мәсьәләне хәл иткәндә дә, ул кешеләрнең җитәкче боерыгын үтәүләрен генә түгел, бәлки эшкә үз ризалыклары белән керешүләрен тели. Боерык үтәү һәм эшне үзең теләп, аның шулай кирәк икәнлегенә ышанып үтәү — болар икесе ике нәрсә бит!

— Мин ацетонитрил белән эш итә башлауны хуплыйм! — ди дивинил заводы директоры Венюков.

— Ә мин риза булмыйча кая барыйм? — дип аңа кушыла ПТО башлыгы Перлин.— Ләкин монда икенче проблема килеп туа бит әле: ацетонитрил юк ич безнең. Колонналарны нәрсә белән тутырырбыз икән соң? Галимнәр пробиркасы белән генә эш итә алмаячакбыз.

— Без хезмәтне бүлгәләп эшләү чорында яшибез шикелле, — ди Лемаев, сүзгә кушылып.

— Анысы дөрес.

— Алай булгач, менә болай килешик: бүтәннәрегез барыгыз да үз эшегезгә тотыныгыз, ә ацетонитрил табуны мин үз өстемә алам. Иң мөһиме шул: һәркайсыбыз үзенә төшкән эшне намус белән, үзем өчен генә түгел, барыбыз өчен дә дип, җиренә җиткереп башкарыйк. Килештекме шулай?

— Килештек!

— Алайса, озаклап монда утырудан мәгънә юк, эшкә керешик!

*

* *

Түбән Кама комбинатында дивинил заводын эшләтә башларга җыенган вакытта безнең илдә, чыннан да, ацетонитрил җитештерелми иде әле. Ярославль галимнәре үзләренә тәҗрибә өчен аны шактый ансат һәм гади юл белән — аммиакны серкә кислотасы белән синтезлап табалар. Һәм шул үзләре тапкан кадәресе аларга экспериментлар ясау өчен бик җитә. Ләкин завод тикле заводны даими эшләтер өчен литрлар, килограммнар гына җитми, аның өчен кубометрлар һәм тонналар кирәк ләбаса!

Дөрес, Новополоцк химия комбинатында акрилонитрил җитештергәндә барлыкка килгән калдыклардан ацетонитрил эшләү өчен корылган җайланма бар барын. Ләкин ул әле эшләми, ә производство калдыкларын элеккечә яндырып, һавага очыра баралар. Шуңа алай итәләр, чөнки ацетонитрил аларның үзләренә кирәк түгел, ә читтән сораучылар юк. Ә вакыт һаман үтә тора һәм шул рәвешле сигез ел узып та китә... Күрәсез, бер яктан карaганда, барысы да бар, барысы да бик җиңел генә хәл ителер шикелле. Ә икенче яктан, барысы да гадәттән тыш катлаулы, четерекле. Менә мондый кыенлыклар киләчәктә дә кабатланмасын өчен планлаштыручы оешмаларның эшен яхшыртырга һәм камилләштерергә кирәктер. Гадәттә тормышта юрганыңа карап аяк сузасың. Ә кайчакта аякка карап юрган эзләргә дә туры килә. Их, әнә шундый чакларда аягыңны сузганда кирәкле юрганы булса, ә юрганы булганда аяк сузучысы табылып торса, эшләр ничек әйбәт китәр иде. Ә менә без әйтеп үткән очракларда юрган сыручылар белән аяк сузучылар бер-берсен очрата алмаган һәм шуның аркасында әзер ацетонитрил процессы сигез ел буена беркайдан да кулланыш таба алмыйча яткан да инде!

...Ацетонитрилны юллау өчен Новополоцкига комбинатның административ-хуҗалык бүлеге инженеры Генрих Адольфович Седлачекны җибәрәләр. Мондый четерекле хәлләрне күп күргән, тәҗрибәле һәм кайда ничек эш итәргә кирәк икәнен бик яхшы белә торган бу кеше ничек итсә итә, әмма бер тәүлек эчендә тиешле урынга барып җитә.

— Кисәү башыгыз шактый нык төтенли икән, — ди ул, Новополоцк комбинатының озын кара ялын болгап янып торган факелына ымлап.

— Сездә төтенләми мәллә? — дип төрттереп куялар аңа.— Нефть белән эш иткән һәр җирдә производство калдыкларын шушылай яндырырга туры килә торгандыр бит инде.

— Төтене бездә дә бар, — ди тегеләргә Генрих Адольфович. — Ләкин безнең хәлләр башкачарак. Безнең кисәү башының беркемгә дә кирәге юк.

— Ә безнекен алырга чират торалар дип беләсезме әллә? Установканы коруын кордык. Алтын биреп, читтән кайтарттык. Бүген хутка җибәрсәк тә була үзен.

— Нигә эшләтмисез соң? Рәтен белүче кешеләрегез юкмыни? — ди Седлачек, мәсьәлә ул теләгән якка борыла башлаганга эченнән куанып.

— Хикмәт анда түгел. Продукциясен кая куясың аның — хикмәт менә шунда!

— Складларыгыз бардыр ич?

— Аңа складлар ничек төткәрмәк кирәк?

Седлачекка шул гына кирәк тә:

— Куяр урын табылыр — безгә бирерсез, — ди ул. — Тик установкагызны эшләтә генә башлагыз!

— Бер тоннасы 164 сум тора бит аның. Шул бәягә риза буларсызмы?

— Хакыннан тормабыз. Ацетонның тоннасына ун тапкыр артыграк түлибез бит әле. Сезнең ул ацетонитрилыгыз күпме булыр?

— Өч йөз тонна чамасы.

«Өч йөз тонна — безнең өчен бик аз шул, — дип уйлап ала Седлачек. — Аның белән әллә кая барып булмый. Ләкин шунысы мөһим: — ацетонитрил бар икән бит дөньяда! Табарга була икән бит аны телəгəндə!»

Ул чактагы сөйләшү болай тәмамлана: Новополоцк комбинаты җитәкчеләре Түбән Кама комбинаты өчен ацетонитрил җитештерә башларга риза булалар һәм шул хакта Генрих Адольфовичка рәсми кәгазь бирeп җибәрәләр.

Шуның белән бу гаять четерекле мәсьәлә хәл ителми әле. Моннан ары тагын дүрт тапкыр Новополоцкига барып кайтырга туры килә Генрих Адольфовичка. Шуннан соң да эш җайга салынмый. Чөнки новополоцкилылар түбәнкамалыларга ути алмаслык таләп куялар: «Ацетонитриллы буласыгыз килә икән — каустик сода бирегез безгә!» ди алар.

Тик Түбән Кама комбинатының генеральный директоры Лемаев бу эшкә үзе керешеп, РСФСР Верховный Советы депутаты буларак та, шундый зур комбинатка җитәкче итеп куелган дәүләт кешесе буларак та, мәсьәләне тиешле министрлыклар алдына куеп хәл иткәннән соң гына, ниһаять, Новополоцкидан Түбән Кама комбинатына цистерналар тагылган составлар агыла башлый...

*

* *

Шуннан соң аппаратчы егетләргә «уракка төшәр» вакыт килеп җитә.

Ләкин аннан соң да эшләр шома гына бармый әле. Ни тырышып та айның беренче унбиш көнендә бер грамм продукция дә бирә алмый егетләр. Анысы әле бер хәл. Шунысы бик хәтәр була — реакторлар эштән чыга яза. Углеродлы корычтан эшләнгән гадәти аппаратлар ацетонитрил алу өчен кирәк булган кислоталы шартларда эшли башлагач, колонналарда серкә кислотасы барлыкка килә дә колонна стеналарын күгәртергә тотына. Шулай итеп, реакторларны бөтенләй эштән чыгару куркынычы килеп баса. Нишләргә? Барысына да кул селтәп, яңадан искечә — ацетон белән эшли башларгамы?..

Иң көчле кеше — үз ниятен гамәлгә ашыру өчен җан-фәрман тырыша торган кеше дип, тикмәгә генә әйтмәгәннәр шул. Ә Түбән Кама комбинатында йөзләгән кеше йөзләгән характер барысы да ныклы бер фикердә торып эш иткәннәр. Шуңа күрә көчле һәм тәвәккәл булганнар, шуңа тапталган иске юлдан китмичә, һәртөрле кыенлыкларны җиңеп, үзләре яңа юл салып барганнар һәм максатларына ирешмичә туктамаганнар.

Хәер, бу комбинаттагы кешеләр өчен эштә яңа юллар салу күнегелгән нәрсә икән инде. Мәсәлән, алар изопрен каучугы цехларын проектта каралган куәтенә план буенча билгеләнгәннән унбиш ай элек эшләтә башлаганнар. Үзәк газ фракциясе корылмасын план буенча каралган алты ай урынына унбиш көн эчендә гамәлгә керткәннәр. Ә япон дивинилы заводындагы реакторларны ул производствоны эшкә кертү турында дәүләт акты төзегән көнне үк проектта каралган график буенча эшләтә башлаганнар. Һәм, гомумән, аларның моңарчы бары тик тропик яклар хәзинәсе булып кына саналган һәм ясалма юл белән табу мөмкин түгел дип исәпләнгән нәрсәне — каучук эшләп чыгара башлаулары искиткеч зур батырлык һәм тәвәккәллек түгелмени?!.

Ә бит бу эшкә алар немецлар тырышып-тырышып производство ачып, меңнәрчә тәҗрибәләр ясап та, ясалма каучук алуга ирешә алмыйча инде кул селтәгәннән соң, химик Готлиб «каучукны синтезлауга сарыф иткән елларымны мин җилгә очкан

вакыт дип саныйм» дип әйткәннән соң һәм гасыр «пәйгамбәре» Эдисон үзе дә «моны берничек тә эшләп булмаячак» дигән нәтиҗәгә килгәннән соң тотынганнар.

Ярославльдән Түбән Камага процесс авторлары үзләре — Тамара Георгиевна Заикина белән Владимир Александрович Горшков килә. Алар, без галимнәр дип, бөерләренә таянып, читтән күрсәтмәләр генә биреп тормыйча, аппаратчылар белән бергә үзләре дә җиң сызганып эшкә керешәләр. Үз чиратларында аппаратчылар да, без аппаратчылар гына, безгә барысын да белү мәҗбүри түгел дип, кул кушырып утырмыйлар, үзләре дә галимнәр шикелле үк һәр нәрсәнең бөтен нечкәлекләрен аңлап калырга тырышалар. Тиешле режимны тапканга кадәр аларга бер үк процессны уннарча, йөзләрчә вариантларда сынап карарга туры килә. Ләкин беркем дә эшнең уңышлы барып чыгачагына шикләнми һәм, ахыр чиктә, барыбер үз дигәннәренә ирешәләр.

Чималны аппаратларга беренче тапкыр 4 ноябрьда тутыралар. Әзер продуктның беренче килограммы тик беренче декабрьда гына эшләп чыгарыла. Ә шуннан соң нибары бер ай үткәч исә ике блок проект буенча шундый дүрт система чыгарырга тиешле продукцияне бирә башлый!

Ниһаять, телеграммаларның эчтәлеге үзгәрә: моңарчы гел таләп итүдән, үтенүдән генә гыйбарәт булган күп санлы телеграммалар янына Ефремов шәһәреннән килгән менә шушы телеграмманы да теркәп куялар: «Январь — февраль айларында дивинилны бик яхшы җибәреп торуыгыз өчен завод коллективы исеменнән рәхмәт белдерәбез Түбән Кама нефть-химия комбинаты мартта да аннан ары да дивинилны вакытында җибәреп торыр безнең коллективка еллык планны һәм соцйөкләмәбезне үтәп чыгарга мөмкинлек бирер дип ышанабыз

Завод директоры Шмаровоз<br>
Партком секретаре Полищук<br>
Завком председателе Воеводский<br>
ВЛКСМ комитеты секретаре Шуклин».

Бу урында мин тагын Рәфит Хәеров белән ике арабызда булган сөйләшүнең дәвамына әйләнеп кайтмакчы булам.

— Ярый, — дидем мин аңа, — инде таныш булган ацетон процессына кабат кайту турында уйламагансыз, ди. Ә айлар буена сузылган, һәрбер көне бер еллыкка тиң булган физик һәм психологик киеренкелекне ничек җиңеп чыга алдыгыз соң сез?

— Белмим, — диде ул. — Чынлап та, ул чакта нәрсә уйлаганыбызны да һәм кыенлыкларны ничек кичергәнебезне дә белмим. Ләкин шунысын кистереп әйтә алам: ул чорда без, әлбәттә, артык фәлсәфәгә бирелеп тормадык. Ләкин бер нәрсә күңелемә уелып калган: ул чорда мин үз-үземә ачуланып, ярсып йөрдем.

— Нишләп алай?

— Шундый термин бар: эшнең төгәллек дәрәҗәсе. Токарьларның, фрезеровщикларның төгәллеге детальне ни дәрәҗәдә чиста эшкәртә алу белән билгеләнә. Һәм төгәллек микроннар белән генә түгел, бәлки микронның ун меңнән бер өлеше белән үлчәнә. Ә химик-аппаратчының осталыгы — реакциянең төгәллегенә кайтып кала. Сүз дә юк, гадәти завод шартларында эшләүче аппаратчының төгәллеге белән лабораториядә эшләүче химик-аппаратчының төгәллекләре арасында аерма булырга тиештер инде ул. Һәрхәлдә, экспериментатор төгәлрәк, нечкәрәк эш итәргә тиеш. Моны без — аппаратчылар — яхшы аңлыйбыз. Ләкин, шул ук вакытта, күңелдә нигә алар бездән, ягъни производствочылардан остарак, без алардан кай җиребез белән ким, нигә алар эшли алган кайбер нәрсәләрне без булдыра алмыйбыз соң әле? дигән сорау туа да кимсенеп куясың. Бер кислота белән генә дә күпме нерв бозарга туры килде. Кешегә әйтсәң кеше ышанмас: кислота дигән ул нәрсә минем төшләремә кереп йөдәтә иде. Башта без кислотаны утыз җиденче колоннага бирә башладык. Аппаратны сәгатенә ун-унбер килограмм кислота кудыра торган итеп көйләдек. Бер вакыт үткәрдек — рәт чыкмады. Икенчесе узды — тагын мәгънәсе юк. Өченчесендә «я, ничек, барып чыгамы?» дип, лаборантларны аптыратып бетердек. Ләкин барыбер берниндидә алга китеш юк иде әле. Ә эшләгән эшең алга бармаса, аның нәтиҗәсе күзгә күренмәсә — аннан да яман нәрсә юк бит инде ул. Минем дә кәефнең рәтечираты сүтелгән иде ул көннәрдә. Ну, мин әйтәм, булды, җитте, бу «сабан туен» тук-

татырга кирәк. Менә шулай ни эшләргә дә белмичә аптырап йөргән чакта кинәт башка бер уй килеп төште: утыз җиденче колонна — системаның соңгы колоннасы. Анда реакция инде беткән була, шуңа күрә аммиак процессны эшкәртеп бетерә алмый. Димәк... Тагын кирегә, баштагы аппаратларга әйләнеп кайтырга туры килде безгә. Башлангыч фракция бүленә башлый торган унберенче колоннага җитеп тукталдык. Җиденче тәүлектә, ниһаять, эзләгәнебезне тәки таптык бит, әй! Безнең өчен бик зур бәйрәм булды ул көн.

Ярославль галимнәре белән эшләгән чакта без әнә шул хисне кичердек һәм һәр эшебезне мөмкин кадәр алар шикелле үк төгәл итеп башкарырга тырыштык. Ирешкәнебез — әнә шул тырышлыкның нәтиҗәсе дип уйлыйм.

*

* *

Алда сөйләп үткән хәлләргә тагын бер нәрсәне өстәп китмәсәк, бу язма тулы булмас иде.

Ацетонитрил мәсьәләсен уңышлы хәл итеп чыкканнан соң Түбән Кама комбинатында дивинил заводын тагын да киңәйтергә булалар. Теге чакта ацетоннан ацетонитрилга күчкәндә «артык» булып калган теге ике блокны тиешенчә җиһазлап эшләтә башлагач, заводның куәте тагын да артырга тиеш. Күпме ул, азмы? Безнең илдә төзелгән беренче ясалма каучук заводының бөтен куәте әлеге шул тонналарга исәпләнеп эшләнгән икәнен хәтергә төшерик. Ул завод эшли башлагач, ясалма каучукның авторы Лебедев «үз фикереңнең шушындый грандиоз җанлы эш итеп гамәлгә ашырылуын күрү — зур бәхет» дип әйткән.

Ә бик отышлы ацетонитрилны куллану безнең илдә көннән-көн киңәя бара. Тольяттида инде ацетоннан шуңа күчтеләр. Омск, Сумгаит, Стәрлетамак комбинатларында шулай ук ацетонитрил процессына күчәргә әзерлек алып баралар.

Әлбәттә, зур тырышлык белән сафка кертелгән һәм шактый күп табыш китергән бу яңалыкны түбәнкамалылар гына түгел, бүтәннәр дә гамәлгә ашыра алган булыр иде. Әлеге ацетонитрил процессының регламенты алар кулында да бар һәм ул аларга да күптән таныш булган бит. Әгәр бу эшне икенче бер химкомбинат коллективы башкарып чыккан булса, мин алар турында да бик рәхәтләнеп язган булыр идем. Ләкин ни хәл итмәк кирәк? Очерк — документаль әсәр. Анда автор хыялы булган факт чикләреннән артып китәргә тиеш түгел. Анда, теләсәң дә, булмаган хәлне булды дип яза алмыйсың — ярамый!

Хәер, бу хакта артык сүз озайтып торуның хаҗәте дә юк. Ә менә эшләмичә калырга мораль яктан хаклары була торып та, аңа тәвәккәлләп алынып, егетләрчә башкарып чыккан кешеләргә күп итеп рәхмәт әйтик. Дөрес, яңа эшкә башлап тотынмаган, үзләренең инде өйрәнелгән эшләрен гадел һәм җиренә җиткереп дәвам иткән кешеләр дә хөрмәткә лаеклы, әлбәттә. Ләкин, ничек кенә булмасын, дөньяны үз иңнәрендә яңалыкны алга сөрүчеләр алып бара...

**Риф Якупов**

# АРХИВТАГЫ ЯЗУЛАР НИ СӨЙЛИ

**Килер заман, һәр язучының үзен, сүзен вә шәхси тормышын инәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыгарлар әле.**

**Г. Тукай. «Уянгач беренче эшем».**

Татар халкының сөекле шагыйре Габдулла Тукайның тормыш юлына бәйле кадерле урыннарның берсе — Балтач районындагы Сасна пүчинкәсе. Шагыйрьнең әнисе Мәмдүдә, ире Мөхәммәтгариф үлгәннән соң, Сасна пүчинкәсе мулласы Шакир Фәйзуллинга тормышка чыга. Кечкенә Габдулла да гомеренең бер өлешен шушы авылда үткәрә.

Г. Тукайның Сасна пүчинкәсендә яшәгән чоры әдәбият белгечләре тарафыннан бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән. Шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлын тикшерүчеләр ул турыда, нигездә, «Исемдә калганнар» дигән автобиографик очеркы буенча гына фикер йөртәләр. Дөрес, бу очерк — әдәбият белгечләре өчен бик мөһим чыганак. Ләкин аның да Сасна пүчинкәсе турындагы өлеше, шагыйрь үзе язганча, сабый хәтерендә сакланып калган минутлар гына. Очеркта «булган», «булганмын» рәвешле язу да әнә шуның белән аңлатыла.

Шагыйрь «Исемдә калганнар»ында авылның исемен «Сасна» дип атый. Шуңа нярэп булса кирәк, Г. Тукай турындагы барлык китапларга ул Сасна авылы булып кереп киткән [1].

Хәлбуки, Сасна авылы һәм Сасна пүчинкәсе, икесе ике авыл булып, аларның беренчесе район үзәгеннән — өч, икенчесе унбиш километр ераклыкта урнашкан. Пүчинкәдә яшәүчеләр үз вакытында Сасна авылыннан күчеп килгәнлектән, аңа Сасна пүчинкәсе дигән исем бирелгән. Күчену 1850 елларда булган булырга тиеш. «Вятка губернасының статистика буенча материаллары» дигән китапта язылганча, Кече Сасна авылы (Сасна пүчинкәсе русча шулай йөртелгән) соңгы ревизиягә кадәр 6 ел элек барлыкка килә [2]. Соңгы ревизия исә Россиядә 1857—1859 елларда үткәрелгән. Шушы ук китаптан күренгәнчә, бу авылда 1884 елда 17 хуҗалык булган, анда 56 ир-ат һәм 48 хатын-кыз яшәгән. Г. Тукайның да әнисе, хәзергә кадәр барлык китапларда язылганча, Сасна авылында түгел, ә Сасна пүчинкәсендә яши, шунда дөнья куя.


Ул кайсы елда үлгән һәм ул вакытта Габдулла ничә яшендә булган соң? Әлеге хакта да Г. Тукай турындагы әдәбияттан төгәл мәгълүмат табып булмый. Мәсәлән, язучы Әхмәт Фәйзи Г. Тукай ике яшь ярымлык вакытта әнисез калган дип исәпли [3].

---

[1] Р. Башкуров, В. Воздвиженский. Навсегда в сердце народа. Рус телендә. Казан, 1966 ел, 8 бит; Я. Агишев. Тукай. Казан, 1961 ел, 65 бит; Ф. Миңһаҗева. Тукай мәктәптә. Казан, 1968 ел, 66 бит h. б.

[2] Материалы по статистике Вятской губернии. Мәскәү, 1886 ел. I том, 51 бит.

[3] Габдулла Тукай. Избранное. Ә. Фәйзинең кереш мәкаләсе, Мәскәү, 1956 ел, 3 бит.




*Г. Тукайның әнисе Мәмдүдәнең кайчан үлүе турында язылган метрика кенәгәсе бите. Шагыйрьнең әнисенең исеме өченче юлда (астына сызылган).*

Филология фәннәре кандидаты Якуб Агишев бу вакытта Габдуллага 2—3 яшь, филология фәннәре докторы, профессор И. Пехтелев — өч, филология фәннәре кандидаты Р. Башкуров дүрт яшь булган дип саныйлар [1]. Татар әдәбияты буенча тугызынчы класс дәреслегендә Тукайга бу вакыт биш яшь булган, диелә [2]. Авторларның кайсы хаклы соң? Шушы мәсьәләне тәгәл хәл итәрлек берәр документ булсын иде. Әмма Г. Тукайның Сасна пүчинкәсендә яшәгән чоры турында бүгенгә кадәр нинди дә булса документ табылганы юк. Ә менә әнисе Мәмдүдәнең кайчан үлүе турында язылган таныклык кәгазенең Балтач район загс бүлегендә саклану ихтималы мөмкин бит.

Шундый максат белән, 1967 елның башында мин район загс бүлеге мөдире Бибинур апа Йосыповага мөрәҗәгать иттем. Ул Вятка губернасының Малмыж өязендәге Көшкәтбаш һәм Кучкән Сасна (Сасна пүчинкәсе ул вакытта шулай дип тә йөртелгән) авылларында 1865—1895 елларда үлгән кешеләрнең исемнәре теркәлгән кенәгәнең хәзер дә саклануы турында хәбәр итте.

Менә өстәлдә — метрика дәфтәре. Аның битләре вакытлар үтү белән сары төскә кергән. Кенәгәнең 1890 елга караган бүлеген ачабыз. Анда «Мәетнең исеме» дигән графада «Мәмдүдә», «Каю айда вафат» дигән бүлектә «Гыйнвар 18 ендә» дип язылган. «Ата вә бабасының исеме» графасында «Атасы Зиннәтулла мулла» дигән сүзләрне укырга мөмкин. Калган графалардан күренгәнчә, Мәмдүдә егерме алты яшендә эч китү авыруыннан үлгән һәм Сасна пүчинкәсе зиратына күмелгән. Димәк, шагыйрьнең әнисе 1864 елда туган һәм Габдуллага 3 яшь тә 9 ай булганда дөньядан киткән.

Бу документны Көшкәтбаш мулласы Әсхәтдин Ибраһимов тутырган. Г. Тукайның үги атасы Сасна пүчинкәсе мулласы Мөхәммәтшакир Фәйзуллинның бу эшне башкару өчен хокукы булмаган [3]. Чөнки ул указсыз мулла булган. Кызганычка каршы, Мәмдүдәнең кабере бүгенге көнгә кадәр ачыкланмаган. Бу авылда иске һәм яңа зират булып, хәтта шуларның кайсысына күмелгәнлеген белүчеләр дә юк.

Мәмдүдәнең үлгән елын тәгәл белмәү аркасында, моңарчы Тукайның Өчиледә

---

[1] Я. Агишев. Творчество Габдуллы Тукая. Казан, 1948 ел, 6 бит; Г. Тукай. Стихотворения и поэмы. Кереш мәкалә. Мәскәү-Ленинград, 1963 ел, 6 бит; Р. Башкуров, В. Воздвиженский. Навсегда в сердце народа. Казан, 1966 ел, 7 бит.

[2] Татар әдәбияты. Урта мәктәпнең IX классы өчен дәреслек. Казан, 1973 ел, 5 бит.

[3] Бу турыдагы мәгълүматлар Балтач районында чыга торган «Хезмәт» газетасының 1967 елгы 26 апрель санында «Шагыйрь тормышына бәйле яңа документ» дигән мәкаләмдә хәбәр ителде.

һәм Казанда кайчан яшәгәнлеге дә бутап йөртелде. Мәсәлән, шагыйрьнең 1958 елда рус телендә чыгарылган җыентыгында: «1889 елда Тукайны Казанга илтәләр һәм Мөхәммәтвәли исемле баласыз кустарь семьясына тәрбиягә бирәләр», — дип языла [1]. Бу китаптагы мәгълүматка караганда, кечкенә Габдулла әнисе үлгәнче үк Казан шәһәренә асрарга озатылган булып чыга. 1967 елдан соң чыгарылган китапларда да шундый ук төгәлсезлекләр очрый. Мәсәлән, «Аларның исемнәре белән Казан урамнары аталган» дигән китапта: «Бабасы (Зиннәтулла — Р. Я.) малайны 1889 елда Казанга озаткан», — дип хәбәр ителә [2].

Шагыйрьнең әнисе Сасна пүчинкәсенә кайчан килгән соң?

Г. Тукай «Исемдә калганнар»ында түбәндәгечә яза: «Тол калган анам янында мин берничә вакыт торгач, анам мине авылыбыздагы Шәрифә исемле бер фәкыйрә карчыкка вакытлыча асрарга бирел калдырып, үзе Сасна нам карьянең (исемле авылның — Р. Я.) имамына кияүгә чыкмыштыр... Мин үзем ул карчыкта үткән заманның ничеклеген белмим. Ул вакыт мин ике-ике ярым яшендә генә булганмын дип уйлыйм» [3].

«һәрвакыт халык йөрәгендә» исемле брошюрага мөрәҗәгать итик: «Габдулла туып биш ай үткәч, аның әтисе кинәт үлеп китә. Чама белән бер-ике елдан соң әнисе Мәмдүдә, сабый баласын авылларындагы Шәрифә исемле бер фәкыйрь карчыкка вакытлыча асрамага калдырып, үзе Сасна авылы мулласына кияүгә чыга» [4].

Шагыйрьнең тормыш юлына караган башка хезмәтләрдә дә шундый ук хәл: Мәмдүдәнең Сасна пүчинкәсенә килү вакыты чама белән генә язылa.

Әлеге датаны ачыклау өчен Мәмдүдәнең Шакир мулла белән никах язуын табу да җитәр иде. Ләкин Кучкән Сасна авылының метрика кенәгәсендә әлеге никах язуы табылмады. Арча районы загс бүлегенә барып эзләнүләр дә нәтиҗә бирмәде. Бәлки никах Мәмдүдәнең әтисе Зиннәтулла яшәгән авылда укылгандыр дип, Өчиле кенәгәсен дә тикшереп карадык. Кызганычка каршы, бу авылның 1880—1890 еллардагы метрика язмалары сакланмаган.

Дөрес, бу әле никах язуы шушы авыл кенәгәсендә булган дигән сүз түгел. Һәрхәлдә, эзләнүләрне дәвам итәргә кирәк иде.

Элек метрика кенәгәләре муллалар тарафыннан ике данәдә тутырылып, берсе авылда калдырылган, икенчесе губерна үзәгенә җибәрелгән.

Ниһаять, 1974 елда, республика Үзәк дәүләт архивына кереп, атналар буе казынулар бушка китмәде. Биредә Мәмдүдә белән Шакир Фәйзуллинның никах язуы табылды. Анда: «Казан өязе, Яңа Кишет волосте, Малый Бирәзә (Өчиле авылы ул вакытта шулай аталган — Р. Я.) илендә имам Зиннәтулла Зәйнелбәшир углының тол кызы Бибимәмдүдәне Малмыж өязе, Сасна авылының мулла Мөхәммәтшакир мулла Фәйзулла углына никах ителде. Кияү — 40 яшендә, кыз — 23 тә», диелгән [5]. Мөхәммәтшакир Мәмдүдә өчен 30 таңкә мәһәр түләгән. Никах 1888 елның 22 декабрендә укылган. Димәк, шушы көннән соң Мәмдүдә кечкенә Габдулланы Кушлавыч авылына илтә һәм аны асрарга бирел калдыра, ә үзе Мөхәммәтшакир белән Сасна пүчинкәсенә китә. Мәмдүдә беренче ире Мөхәммәтгариф үлгәннән соң озак та үтми, Өчилегә, әтисе Зиннәтулла һәм үги әнисе Латыйфа (Мәмдүдәнең үз әнисе Камилә яшьләй үлә) йортына кайтып киткән була. Ләкин ярлы тормышлы һәм күп семьялы атасы йортына сыя алмый һәм 69 яшьлек [6] карт мулла Мөхәммәтшакирга кияүгә чыгарга мәҗбүр була.

Ә Тукай үзе Сасна пүчинкәсенә кайчан килгән соң? «Исемдә калганнар»ны укуны дәвам иттерәбез: «...Мин хәзердә дә атка утырып Саснага барганымны, үземне бер киң вә рәхәт галәмдә хис иткәнемне, юлда барганда күз алдымда әллә нинди нурлар уйнаганын онытмаган шикелле булам.

Саснага барып җиткәнмен. Ничек, ни рәвеш бардым, мине кемнәр каршылады — анысын белмим; ләкин үги әтиемнең мине сөюе, миңа чәй янында кәрәзле балны ак

---

[1] Габдулла Тукай. Стихи, поэмы и сказки. Казан, 1958 ел, 3 бит.
[2] В. Белокопытов, Н. Шевченко. Их именами названы улицы Казани. Казан, 1973 ел, 288 бит.
[3] Г. Тукай. Әсәрләр. IV том. Казан, 1956 ел, 12 бит.
[4] Р. Башкуров, В. Воздвиженский. Күрсәтелгән хезмәт, 8 бит.
[5] Казан губернасы, Казан өязе буенча 1888 елда туган, өйләнешкән һәм үлгән кешеләр турында метрика кенәгәсе. Коллекция, 11 том, 267 бит.
[6] Балтач район загс бүлегендә саклангaн язмалардан күренгәнчә, Мөхәммәтшакир 1916 елның 3 декабрендә 97 яшенә җитеп үлгән. Күрәсең, никахны язган Зиннәтулла мулла карт кияүне шактый «яшәрткән».

күмәчкә ягып бирүе, минем шунда куанганнарым, биш минутлык төш шикелле генә, әле дә булса хәтеремдә», — ди шагыйрь [1].

Кояш нурлары карда матур ялтырыйлар. Гадәттә бу кыш ахыры яки яз башы була. Кечкенә Габдулла нәкъ менә шул чакта Сасна пүчинкәсенә килгән булырга тиеш. Ә. Фәйзи дә «Тукай» романында Габдулланың Кушлавычтан Сасна пүчинкәсенә көн язга авышкач китүе турында яза [2]. М. Укмасый шагыйрьнең апасы Сәҗидәнең сөйләве буенча язган истәлегендә кечкенә Габдулланы әнисе белән үги әтисе Мөхәммәтшакир Кушлавычка ат белән килеп, икәүләп урталарына утыртып алып кайталар, дип күрсәтә [3]. Шунда ук Габдулланың кире Өчилегә кайту тарихы да язылган: «Мәмдүдә авырый башлагач та, Шакир мулла кайнатасы Зиннәтуллага Мәмдүдәнең авыруы турында хат яза. Ләкин бу хат ничектер тапшырылмый кала.

Шулай итеп, Зиннәтулла кызының авыруыннан хәбәрсез кала. Беркөнне ул, Сәснага барып, баласы һәм киявенең хәлләрен белеп кайтмакчы була. Барса, кызы Мәмдүдәнең инде дөньяда юклыгын кинәт ишетеп, Зиннәтулла һушы китеп егыла. Һәм айныганнан соң, Шакир киявенә мөрәҗәгать итеп: «Кияү! Инде син өйләнерсең, бу бала барыбер синеке була алмас, мин аны алып кайтыйм», — дип, Габдулланы үзе белән алып китә [4].

Мәмдүдәнең 18 январьда вафат булуын искә алсак һәм истәлектәге вакыйгаларны чагыштырып карасак, бу хәл 1890 елның февраль-март айларында булган дип уйларга нигез бар.

Истәлектә: «Габдулланың киредән Өчилегә кайткан елы 1891 елгы көчле ачлык ел булганга, Зиннәтулланың тормышы искиткеч авыр бара» [5], — дип язылса да, күрсәтелгән дата чынбарлыкка туры килми. Алтмыш чакрым ераклыктагы кызының үлү хәбәрен Зиннәтулланың еллар буе ишетмичә яшәве мөмкин түгел. Ул кызы исән чакта да, үлгәч тә Сасна пүчинкәсенә еш килгән. Бу хакта әлеге истәлекнең үзендә үк язылa: «Зиннәтулла үзе шагыйрь булып, аның язган шигырьләре күп булган. Кызы Мәмдүдә үлгәч, Зиннәтулла аны бик сагына, һәр вакыт аның каберенә бара торган була. Бервакыт аның кабере янында кызына атап язган түбәндәге шигырен укый. Мин (М. Укмасый — Р. Я.) бу шигырьне кыскартып, бирелә күчереп үтәм:

**Нуры газизем, кызымның төрбәседер бу мәзар,**
**Әйләмеш нәзек вөҗүден хак дәвре рузыклар,**
**Исме Бибимәмдүдәдер гаилә ирде гаян**
**Денлап ирде тәшкилә вәгазь, мәсагыл һәм мәгаи.**

. . . . . . . . . . . . . . . . .


**Ни сәбәптер и ходая ризкы аз, гомре тәмам.**
**Күрмәдем күзем туйганчы, улды бәңә кальмәнам.**
**Дары михнәт, дары хәсрәт, дары залим бу мәкам**
**Шунда мәхбүбә мөрәссәгә дөрне кылды ингидам.**

Шигырьнең мәгънәсе: «Газиз нурымның кабере бу урын, дөньяның туктаусыз әйләнеп исә торган җилләре аның нәзек гәүдәсен туфрак иттеләр. Ул бик акыллы булып, аның исеме Бибимәмдүдә иде, ул төрле мәгънәләрне, мәсьәлә һәм үгет сүзләрен тирән теләк белән тыңлый торган иде, ни сәбәптәндер, аның ашыйсы ризыгы аз булды, гомере озын булмады. Мин аны күзем белән туйганчы күрә алмый калдым. Аны күрүем төштә генә төсле булды. Бу дөнья азап, кайгы, изү йорты булып, тезеп куйган энҗе күк гүзәл сөйгән кызымны юкка чыгарды» [6].

Язылганнардан чыгып, шуны әйтә алабыз: Тукайның әнисе хәзерге Балтач районына 1888 елның 22 декабрендә килгән һәм 1890 елның 18 гыйнварында үлгән. Ә Габдулла исә Сасна пүчинкәсенә 1889 елның март-апрель айларында килеп, 1890 елның февраль-март айлары тирәсендә киткән булырга тиеш. Димәк, Габдулла Тукай бер елга якын Балтач районында яшәгән [7].

---

[1] Г. Тукай, IV том, 13 бит.
[2] Ә. Фәйзи. Тукай. Роман. Казан, 1956 ел, 17 бит.
[3] М. Укмасый. Сайланма әсәрләр. Казан, 1958 ел, 106 бит.
[4] Шунда ук, 107 бит.
[5] Шунда ук, 107 бит.
[6] М. Укмасый. Сайланма әсәрләр. 105—106 битләр.
[7] Мәмдүдә белән Мөхәммәтшакирның никах язуы табылу уңае белән язылган «Тукай Сасна пүчинкәсендә» исемле мәкаләм «Хезмәт» газетасының 1974 елгы 5 һәм 7 сентябрь саннарында дөнья күрде. Бу мәкалә шулай ук Арча районы газетасы редакциясе тарафыннан да күчереп басылды.



*Бибисаҗидәнең үлеме турындагы язманың фотокүчермәсе.*

Кушлавыч авылының метрика дәфтәрен таптык. Шуннан 1886 елда үлгән кешеләрнең исемлеген карыйбыз. Анда: «Мөлля Мөхәммәтгариф ибне Мөхәммәтгалим август 29 ында 44 нче яшендә кату зәхмәте илә вафат булды. Казан өязе Кушлавыч авылында. Казан өязе Мулминский волосте Орнаш иленең указный мулласы Камалетдин мөлля Шәмсетдин женаза укып кулым куйдым», — дип язылган. Димәк, шагыйрьнең әтисе 1842 елның икенче яртысында яки 1843 елның беренче яртысында туган.

Шушы ук загс бүлегендә Г. Тукайның тууы турындагы язма да саклана. Билгеле булганча, шагыйрьнең туган көне дә төрле китапларда төрлечә күрсәтелә. Мәсәлән, күренекле тукайчы Гали Халит «Габдулла Тукай» дигән җыентыкта[1] шагыйрь искечә стиль белән 14 апрельдә, ә «Тукай үткән юл» дигән гыйльми хезмәтендә[2] 15 апрельдә туган дип яза. Шагыйрьнең 80 еллык юбилее хөрмәтенә чыгарылган фотоальбомда әдәбият белгече Р. Башкуров та: «Габдулла Тукай 1886 нчы елның 27 апрелендә (яңа стиль белән) ...дөньяга килә», — дип яза.

Ә әлеге дәфтәрдә: «Габдуллаҗан 14 апрельдә туган» дигән сүзләрне укырга мөмкин. Калган графалардан күренгәнчә, Г. Тукайның атасы указлы имам Мөхәммәтгариф, бабасы Мөхәммәтгалим, анасы Зиннәт кызы Миңсафа булган[3] һәм бала Кушлавыч авылында туган. Авылның мулласы буларак, Мөхәммәтгариф абзый метрика дәфтәренә шагыйрьнең тууы турындагы мәгълүматларны үзе тутырган. «Кушлавычта указный имам Мөхәммәтгариф мөлля Мөхәммәтгалим угылы кулым куйдым», — дип язган. Димәк, Мөхәммәтгариф гади мулла гына түгел, ә указлы имам булган. Шул ук вакытта бу дәфтәрдәге почеркның шагыйрь почеркы белән бик охшашлы булуын да билгеләп үтәргә кирәк. Тагын шунысы кызык: Мөхәммәтгариф абзый Кушлавычта Г. Тукайдан соң беренче булып 1886 елның 8 июнендә туган ир балага да Габдуллаҗан дип исем кушкан. Дәфтәрдән күренгәнчә, Тукай искечә стиль белән 14 апрельдә, ягъни яңача дата белән 26 апрельдә туган һәм аның тулы исеме Габдуллаҗан булган.

Шагыйрьнең замандашы һәм дусты «Әлислах» газетасы редакторы Вафа Бәхтияров та: «Чын исеме Габдуллаҗан, паспортында шулай язылган иде», — ди үзенең истәлекләрендә[4]. Күренекле татар шагыйре Сәгыйть Рәмиевнең дә, аны хөрмәтләп, бөек әдипкә «Тукайҗан!» дип мөрәҗәгать итүе шул сәбәптәндер дип уйларга кирәк[5].

«Габдуллаҗан»ның ни өчен «Габдулла» дип кыскартылуы шагыйрьнең «Исемнәребез хакында» дигән мәкаләсеннән яхшы аңлашыла. «...Фәкать хәйваният һәм шәһваният хисеннән туган «җан» ләфзын (сүзен — Р. Я.) муллалар тукми-чәчмичә Россиягә алып кайтканнар. Алып кайту белән генә канәгатьләнмичә, безнең Тимер, Алтынбик, Япанчы... кеби гүзәл милли исемнәребез урынына шул Сәлим «җан», Галим«җан» кеби мөрәккәп (катлаулы — Р. Я.), ямьсез, татарлар өчен хурлык, әйтергә тел теләми торган исемнәр тудырганнар»,— дип яза ул[6].

Әтисе үлгәндә Габдулла ничә айлык булган соң? Бу хакта ул «Исемдә калганнар» дигән автобиографик очеркында болай дип яза: «Минем туганыма 5 ай заман үткәч, атам, аз гына вакыт авырып, тәрке дөнья итмештер» (үлгән — Р. Я.).

Татар әдәбияты буенча IV класслар өчен басылган дәреслектә исә: «Габдулла Тукай... алты айлык чагында атасыз, биш яшендә анасыз калган», — диелә.

---

[1] Г. Халит. Габдулла Тукай. Казан, 1948 ел, 6 бит.
[2] Г. Халит. Тукай үткән юл. Казан, 1962 ел, 6 бит.
[3] Балтач загс бүлегендәге язуда шагыйрьнең әнисе Зиннәтулла мулла кызы Мәмдүдә дип исемләнгән иде. Арчадагы язуда исә Зиннәт кызы Миңсафа дип куелган. Зиннәтулла мулланы сабакташлары яки якын дуслары Зиннәт дип үз итеп әйтүләре бик мөмкин. Ә менә Мәмдүдә ни өчен Миңсафага әверелгән? Татарларда элек исем бозу йоласы булган. Бала сырхауласа, бу авырудан коткару өчен, аның исемен алыштырганнар. Янәсе, исемен алыштырган кешене чир таба алмый. Шагыйрьнең әнисенең дә исеме шушы йола нигезендә үзгәртелгән булырга тиеш.
[4] Тукай турында замандашлары. Казан, 1960 ел, 86 бит.
[5] Шунда ук, 208 бит; «Кояш» газетасы, 1913 ел, 4 апрель.
[6] Г. Тукай. Әсәрләр. IV том, 94 бит.

Метрика дәфтәреннән исәпләп чыгарабыз: әтисе үлгәндә Габдулла нәкъ дүрт ай ярымлык булган. Күренә ки, шагыйрь, бала чак хатирәләрен чамалап кына язса да (билгеле, беркем дә үзенең 4 ай ярымлык вакытын тәгәл хәтерли алмый), дөреслеккә күбрәк якын килгән.

Бөек шагыйрьнең биографиясендәге иң бәхәсле урын — аның Кырлайда яшәгән чоры. Газизә Зәбирова, Камил Мотыйгый истәлекләренә караганда, Г. Тукай Кырлайдан Уральскига 1895 елның кышында килгән [1]. Хәлилерахман Гобәйдуллин исә үзенең истәлегендә: «Хәзергә кадәр чыккан китапларда язылганча, Габдулла Кырлайга 1892 елда килмәде, ә 1894 елда килде һәм аннан 1895 елда китмәде, ә 1897 елда китте»,— ди [2]. Бу уңай белән Гали Халит «Тукай үткән юл» дигән китапта түбәндәгечә яза: «һәр очракта да сүз хәтер чамасына гына нигезләнгәнлектән, ул даталарны, әлбәттә, тегеяки бу күләмдә дөреслеккә якын версияләр итеп кенә карарга туры килә. Шулай да 1895 ел датасын нигезлерәк санап, Уральскига килгәндә Тукайга 9—10 яшь тирәсе булгандыр дию белән чиклибез. Тыштан караганда, бу мәсьәләнең әллә нинди әһәмияте дә юк шикелле. Әмма Габдулланың Кырлайда алган тормыш тәэсирләрен, укый башлавын һәм гомумән шунда беренче башлап дөньяга күзе ачылуын искә алганда, һичшиксез, ул дата мәсьәләсенең дә әһәмиятен бөтенләй үк кирәксез дип булмый» (8 бит).

Чыннан да, шагыйрьнең биографиясен өйрәнгәндә бу даталарны ачыклауның әһәмияте кечкенә түгел. Әмма аларны ничек ачыкларга соң? Без белергә теләгән вакыйгалардан соң күп сулар аккан, күп еллар узган. Без хәзер инде шагыйрьнең 90 еллык юбилеен каршылыйбыз. Димәк, бу даталарны ачыкларга азмы-күпме ярдәм итәрдәй тере шаһитларның да кимендә шушы яшьләр чамасында булуы шарт. Ләкин, кызганычка каршы, бу авылда шагыйрьне якыннан белгән картлар хәзер юк инде. Х. Гобәйдуллин да үзе әйткән даталарны, кирәк икән, документлар белән күрсәтәм, дип язса да, истәлегенә берниндн документ теркәмәгән.

Сәгъди абзыйның кечкенә Габдулланы уллыкка алуы турындагы язу шагыйрьнең Кырлайга кайчан килүен ачыкларлык дәлил булыр иде. Әмма бу язуны эзләү файдасыз. Чөнки Габдулланың уллыкка алынуы рәсмиләштерелмәгән. Әгәр рәсмиләштерелгән булса, Кушлавыч авылы кешесе Бәдри «икмәкнең поты фәләнчә кадәр кыйммәт вакытта 3—4 ел ашатып торгызган» Сәгъди абзыйдан Габдулланы бик җиңел генә алып китә алмас иде. Газизә Зәбирова истәлекләренә караганда, Бәдри абзыйның да Габдулланы алып китү өчен берниндн рәсми кәгазе булмаган һәм ул, хәйләгә керешеп, Сәгъди абзый алдына кесәсеннән русча язылга иске кәгазьләр генә чыгарып күрсәтә алган.

Тукайның Уральскига киткәнче яшәгән чорын өйрәнүдә аның «Исемдә калганнар» дигән автобиографик очеркы төп чыганак булып санала. Ләкин анда да вакыйгалар еллары белән күрсәтелмәгән, бәлки күпчелек очракта «бервакыт», «кайвакыт», «шул вакыт», «кайчакта», «бер заман» дип кенә язылган. Бу — табигый хәл. Чөнки «Исемдә калганнар» хәтердә сакланганнардан гына чыгып язылган.

Анда телгә алынган күп кенә вакыйга һәм фактлар шагыйрьнең тормыш даталарын ачыклау өчен нигез булып торалар. Очеркта, мәсәлән, Г. Тукай Кырлайга килгән елда Сәгъди абзыйның җиткән кызы Сабираның вафат булуы әйтелә: «Иртә белән, таң сызылып килгәндә, колагыма: «Сабира апаң вафат булды; син йоклап ятасың, тор, тор!» — дигән бер тавыш килгәч, күземне ачып карасам — каршымда әни тора иде»,— дип яза шагыйрь бу хакта. Башка әгәр загс бүлегендә Сабираның кайчан үлүе турында язулар сакланса, Габдулланың Кырлайга килүе датасын бик тиз ачыкларга мөмкин бит дигән уй килде. Бәхеткә каршы, бу язулар исән булып чыкты. «Шәмсетдин угылы Сәгъдетдин кызы Бибисабира 30 нчы июльдә 23 нче яшендә җен зәхмәте илә вафат һәм Кырлай авылында күмелде», дип язылган анда. Бу язма 1892 елга карый. Димәк, Габдулла Тукай Яңа Кырлай авылына 1894 елда түгел, ә 1892 елда килгән.

Очеркны укуны дәвам иттерәбез. ...«Мин бу җәйне үткән җәй кеби йөгереп, уйнап үткәрә алмадым,— ди шагыйрь.— Чөнки шушы язга чыгар алдыннан гына

---

[1] Тукай турында замандашлары. Казан, 1960 ел, 42 һәм 63 битләр.
[2] Шунда ук, 36 бит.

Сәгъди абзыйның бер ир баласы дөньяга килгәнгә, мин, әни эштә чагында, һәр вакыт шул баланы юатып тирбәтеп утыра идем.

Менә тагы урак вакыты да җитте; үткән җәй, бөтен авыл халкы эштә булганда, урам буе чабып йөргән мин бер малайны быел Садрины (ул бала Садретдин исемле иде) тартып йөрергә уракка да алып чыктылар».

Загс кенәгәсеннән карап, Сәгъдетдин угылы Садретдинның 1893 елда туганлыгын беләбез [1].

Очеркта Сәгъди абзыйның хатынының исеме язылмаган. Шагыйрьнең замандашларының истәлекләрендә ул Зөһрә дип атала. Кенәгәдән күренгәнчә, аның тулы исеме — Бибизөһрә һәм ул Габделхалик угылы Габделгани кызы булган. Озын исемле кеше — озын гомерле була дигән иске ышануга нигезләп, бу заманда балаларга катлы-катлы исемнәр кушканнар.

Тукайның Кырлайга 1892 елда килүен тагын бер тарихи датага бәйләп карарга кирәк. Ул — 1891 елгы корылык. Гадәттә корылыклы елның авырлыгы аннан соңгы елга, ягъни бу очракта, 1892 елга кала. Бу ел чын мәгънәсендә ачлык ел була. Габдулланың бабасы Зиннәтулла да, Өчиле авылының мулласы булуына карамастан (гадәттә патша заманында муллалар бай тормышта яшәгәннәр), күрше баерак авылларга барып хәер сорашып йөргән. Шунлыктан Г. Тукай да «Мин исә, Казаннан кайтканнан бирле юньләп аш йөзен күрмәгәнгә күрә, бик шәп бер иштиһа (аппетит — Р. Я.) илә икмәк белән катыкны ялт иттердем», — дип яза. Сәгъди абзыйның һәм Зөһрә апаның «икмәкнең поты фәләнчә кадәр кыйммәт вакытта» дип әйтүләреннән дә сүзнең 1892 елгы ачлык турында баруын яхшы шәйләргә була. Шулай итеп, Г. Тукай 1892 елда Кырлайга килә. Хәтта бирегә шагыйрьнең кайсы айда килүе дә очерктан шактый ачык аңлашыла. Г. Тукай әлеге истәлектә Кырлайга килүенең беренче елында сабан туе хакында бернәрсә дә язмый. Әгәр ул бәйрәмгә кадәр килгән булса, һичшиксез, сабан туе турында да язган булыр иде. Сабан туеның элекtә май аенда үткәрелүен исәпкә алсак, шагыйрь Кырлайга шушы айдан соң килгән дип гөман кылырга мөмкин. «Бу вакыт (күчену вакыты — Р. Я.) җәйнең матур чаклары булганга, әтрафтагы яшел чирәмнәр вә урманнар, артык эссе булмыйча, үзенең нурлары белән сөеп кенә торган кояш, икенче яктан, тагы рәхәтләндерәләр иде... Мин барып бер аймы, күпмедер торгач, урак вакыты җитте», — дип яза шагыйрь. Авыл халкы гадәттә июль урталарында уракка төшә. Шулай булгач, кечкенә Габдулланы Кырлайга июнь урталарында алып кайтканнар дип ышанып әйтергә була.

Бирелән ул кайчан китә соң? Килгән датаны белгәннән соң, бу сорауга очерктан ачык җавап табып була. Аннан аңлашылганча, шагыйрь бу авылда яшәвенең өченче көзендә Кырлайдан китә. Шагыйрь Кырлайдан китәсе елда Сабираның сеңелесе Сәҗидәнең чахотка белән бик озак авырып үлүе хакында яза. Загс кенәгәсеннән күренгәнчә, Сәгъдетдин кызы Бибисәҗидә 1894 елның 30 нчы апрелендә 15 яшендә чахотка авыруыннан үлгән. Бу факт та шагыйрьнең Кырлайдан 1894 елда китүен раслый.

Сәҗидәнең үлеме турындагы язмада: «Яңа Кырлайда... дәфен кылдым (мәетне күмдем — Р. Я.) имам хатиб вә мөгаллим Фәтхерахман мөлля Гатаулла угылы», — дигән юллар да бар. Аннан алдагы язмада Фәтхерахман Гобәев дип тулы итеп язылган һәм Гатаулланың атасы Гобәйдулла дип күрсәтелгән. Кем соң ул Фәтхерахман Гобәев? Очеркка мөрәҗәгать итик. Анда: «...Әни мине кулымнан җитәкләде дә үзебездән биш-алты гына адым булган Фәтхерахман хәзрәт өенә алып барды... Авылыбызның мулласы Фәтхерахман хәзрәт, белмим, бер заман әтинең шәриге я дусты булганмы, нидәндер, миңа атна саен 5 тиен акча бирә иде», — дип яза әдип. Бу шәхес Сафа Мөхәммәтшин истәлекләрендә дә очрый. «Мәктәпкә кергәч тә, — ди ул, — озак тормыйча, Фәтхерахман мулла аны (Габдулланы — Р. Я.) үзе укыта башлады. Без күбебез Хәбри хәлфәдән генә укый идек. Фәтхерахман мулланың беренче мәктәпкә кергән елны ук аны алай үзен генә аерып укытуына без көнләшә башладык. Аның бик тиз арада гына «һәфтияк» иҗеген укып бетереп сүрәгә керүе, язга кадәр «һәфтияк» сүрәсен бетереп коръән укырга башлавы безне бераз кытыкландыра иде. Чөнки башка балалар тик ике-өч ел эчендә генә алай укый алалар иде. Без аның бик тиз

[1] Ләкин Арча районы архивында Садретдин хакында башка мәгълүматлар юк. Кырлай картларының әйтүенә караганда, Садретдин революциядән соң Кырлай авылында беренчеләрдән булып Кызыл Армиягә языла һәм гражданнар сугышында һәлак була.

арада зур укып китүен аның зирәклегеннән дип түгел, аны мулла укытканлыктан дип белә идек».

Хатиб һәм мөгаллим (ягъни мәчеттә хотбә укуга хаклы мулла) оста оратор, укытучы — шагыйрьнең беренче ир укытучысы әнә нинди сәләтләргә ия булган. Мәкаләбезнең башындарак телгә алынган Хәлилерахман Гобәйдуллин — Фәтхерахман мулланың улы. Хәлилерахман үзенең истәлекләрендә әтисенең Мөхәммәтгариф абзый белән Кышкар мәдрәсәсендә бергә укыганлыгы, кечкенә Габдулланы үз өенә кунакка чакыруы, ә инде 1913 елда Тукайга кунакка баруы турында хәбәр итә.

Кырлайдан Габдулла туп-туры Уральскига китми. Башта ул Кушлавычка Бәдри абзый өенә килә. Бу хәлне очеркта шагыйрь болай сурәтли: «Чәй эчтек, Бәдри абзыйның Гайшә исемле зур гәүдәле, күк күзле, ачык кына йөзле бер хатыны, Камалетдин исемле 14—15 яшьлек бер угылы, вә Кәшифә исемле 12 яшьләрендә бер кызы, вә Нәгыймә исемле бер имчәк баласы бар иде».

Күренә ки, Г. Тукай өлкән балаларның яшьләрен чама белән генә язган. Шуңа күрә безне имчәк бала күбрәк кызыксындыра. Имчәк бала дип гадәттә бер яшь-яшь ярымлык баланы атыйлар. Бу баланың туган елын белү өчен, без Габдулла Кушлавычка кайткан бер елны чигерәбез. Димәк, Нәгыймә 1893 елда туган булырга тиеш. Кушлавыч авылында 1893 елда туган кешеләрнең исемлеген эзлибез. Анда Нәгыймә 1893 елның 14 маенда туган, әтисе — солдат Бәдретдин Хисаметдин угылы, әнисе Гайшә Мөхәммәтсадыйк кызы дип язылган. Димәк, даталар тәңгәл килә. Бу — Габдулланың Кырлайдан 1894 елда китүенә тагын бер дәлил.

Кырлайдан кайтканнан соң Г. Тукайның Кушлавычта мәктәптә укып йөрүләрен, бераз вакыт Казанда торуын һәм 18 көн кибиткада баруын исәпкә алсак, шагыйрь Уральскига 1894 елның ахырында яки 1895 елның башында килгән дип әйтергә тулы нигез бар.

Метрика кенәгәләренә карап, Камалетдин һәм Кәшифәнең дә төгәл яшьләрен белергә мөмкин. Аларның беренчесе 1882 елның 1 январенда, икенчесе 1885 елның 1 ноябрендә туган. Әйтергә кирәк, бу даталар Ә. Фәйзинең «Тукай» романында ялгыш күрсәтелгән. «Аларның берсе ун яшьләр чамасындагы малай, икенчесе уникеүнөч тирәсендәге кыз иде»,— дип яза ул. Чынлыкта исә бу ир бала Кәшифәнең абыйсы була.

Арча район загс бүлегендә очерктагы башка детальләрне ачыклардай мәгълүматлар да табылды. Мәсәлән, Сәгъдетдин абзыйның вафаты турындагы язу. Ул 1904 елның 20 маенда 67 яшендә фалиҗ (паралич — Р. Я.) зәхмәтеннән үлгән. Сәгъдетдиннең әтисе Шәмсетдин икәнен язган идек инде. Бу язудан Шәмсетдиннең әтисе Салих булуын да белергә мөмкин. Шулай ук язмада Сәгъди абзыйның сословие титулы государьский крестьян дип күрсәтелгән.

Г. Тукай «Исемдә калганнар»ында Сәгъди абзыйны зур хөрмәт белән искә ала. «Әти белән без бик, бик тату идек. Ул бер дә миңа каты сүз әйтми иде. Мәсәлән, бервакыт минем Казаннан киеп кайткан күлмәк-ыштаннарым, читек-кәвешләрем, кәзәкиләрем тузгач, әти үзенең мин килмәстән бер ел элек үлгән угылының күк киндер күлмәге илә бишмәтен миңа бирмәкче булды»,— дип яза.

Архивта бу үлгән угыл турында да кайбер мәгълүматлар сакланган. «Сәгъдетдин угылы Садретдин 1890 елның 12 январенда сигезенче яшендә эч авыруы белән вафат», диелә анда. Димәк, Габдулла арба белән тартып йөргән бала икенче Садретдин була. Биредә ике Садретдин булуында гаҗәпләнерлек урын юк. Элек татарларда үлгән баланың исемен, аның истәлеге итеп, яңа туган балага кушу йоласы киң таралган була.

Сәгъди абзый семьясының фаҗигале язмышы — революциягә кадәрге меңнәрчә татар крестьяннарының уртак язмышы ул. Бер семьядан бер-бер артлы өч бала үлә. Сабираның үлеме исә җен зәхмәтеннән дип кенә күрсәтелә. Бу аяныч факт үзе генә дә электә татар халкының никадәр караңгы һәм авыр тормышта яшәвен ачык күрсәтә.

Төрле архивларда табылган мәгълүматлар Габдулла Тукай биографиясендәге бәхәсле моментларны фәнни нигездә хәл итүдә зур әһәмияткә ия. Бөек шагыйребез турында киләчәктә фәнни хезмәтләр һәм әдәби әсәрләр язганда галим һәм язучыларыбыз бу мәгълүматларны һичшиксез искә алырлар дип ышанырга кирәк.

## Ибраһим Нуруллин

# ТУКАЙ

Фикер» газетасының 1906 ел, 17 апрель санында Г. Тукайның «Безнең миллэт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?» исемле мәкаләсе басылып чыга.

Татар милләте үлмәгән дә, йокламаган да, ди шагыйрь. Соң ни сәбәпле ул бу чаклы артка калган? Болай булырга кирәк: «...борын заманда безнең милләт, үзенең иптәшләре вә аркадашлары булган башка милләт илә, фәкыйрь генә, тыныч кына, күңелсез генә яшәгән. Берничә гасырлар безнең милләт алар илә казандаш һәм чәйдәш (мәдрәсәдә барлыкка килгән атамаларга игътибар итик — И. Н.) булып, барчасы бергә ачлы-туклы гына булса да, тыныч кына, тату гына гомер иткәннәр. Шулай тыныч кына торганда, ни хикмәттәндер, башка милләтләр, һәрберсе бер Сөләйман мөлкен алып, үзләренә җилләрне, парларны, утларны, һаваларны хезмәтче иткәннәр; һәр төрле җан-җанвар, кош-кортларны мәсәххәр иткәннәр (буйсындырганнар — И. Н.), хәтта тәхеткә утырып, күкләргә очып, су төпләрендә балыклар илә бергә йөри башлаганнар. Безнең милләт, мескен, шул вакытта йоклаганмы, ни эшләгәндер, мин аныСын белмим, ләкин безнең милләт баягы иптәшләренең кисәктән генә болай ук югары китүләренә тәкать тота алмаган, дәрхаль һушы китеп егылган; «Саглук» китабынча әйтсәм, могамма галәйһи булган. Менә шул ятуыннан безнең милләт һаман да ятадыр.

Соң инде аны ничек һушына китерик?

Бу турыда минем фикере касыйрем [2] болай дип әйтә: «Без ул милләткә әдәбият гөл-сулары сибик, газета мәрвәхәләре (веерлары) илә йомшак җил истерик һәм авызына иттихат (бергәлек — И. Н.) вә иттифак сулары салыйк; җан рәхәте булган музыкалар илә дәртләндерик, хәтта рәсемнәр илә милләтнең үз сурәтен үзенә күрсәтик; тәмам күзе ачылсын, дүрт ягына карансын, гакылын җыйсын».

[1] Дәвамы. Башы 2 санда.

[2] Фикере касыйр — кыска, аз фикер.

1906 елның октябрендә язылган «Милләтә» шигырендә шагыйрь болай ди:

Җөмлә фикрем кичә-көндез сезгә гаид, милләтем;
Сыйххәтеңдер — сыйххәтем һәм гыйлләтеңдер — гыйлләтем.

...Һәр хыялдан татлыдыр милләт хыялы, ля мәхалъ;
Бу хыялятдән кәлүр, гәр кәлсә мәҗнүниятем.

Ягъни: «Бөтен уем кичен дә, көндез дә синң гына кагылышлы, милләтем. Синең саулык — минем саулык, синең авыру — минем авыру... Милләт хыялы, һичшиксез, бар хыяллардан да татлырак, шашсам да, шул хыялдан гына шашармын».

Милләтеңне ихластан ярату белән буржуаз милләтчелек арасына тигезлек билгесе куярга ярамау — мәгълүм нәрсә. Үз анасын яратмаган кеше бүтән аналарны да ярата алмаган кебек, үз милләтенә салкын караучы кеше башка милләтләрне дә хөрмәт итә алмый. Чөнки мондый кеше үзенең «мин»еннән башка бернәрсәне дә сөйми. Иҗат юлының башында ук татар милләте бүтән милләтләр белән «чәйдәш» һәм «казандаш» булып бертугандай яшәде дип язган Тукайның буржуаз милләтчелек белән бернинди алыш-биреше юк иде.

Әйтелгәннәрдән ачык булса кирәк, 17 октябрь манифестын Габдулла, барыннан да элек, милләт интересыннан чыгып кабул итә, җыелачак Думага, булачак конституциягә башлыча милләт ихтыяҗларын күздә тотып өмет баглый. Аны иң шатландырганы — милләтләргә, янәсе, тигез хокук бирелү («Тигез булды законда татар, урыс, япон да»). Аннары — вәгъдә ителгән матбугат иреге. «Хөррият хакында» шигырен «Кайда китте цензурлык, коллык, тарлык, ким-хурлык» дигән сүзләр белән башлап китүе һәм ары табан «Китте хәсрәт, әләмнәр, ирекләнде каләмнәр» дип белдерүе очраклы хәл булмаса кирәк.

«Хас» һәм «гам»ны бер-берсенә ук атмаска, бер тән, бер җан булып тупланырга, искелеккә, наданлыкка каршы көрәшергә чакыруы да («Иттифак хакында») әнә шул милләт хакына, милләтне алга җибәрү хакына иде.

Рус һәм татар телендәге либераль-буржуаз матбугатның манифестны, булачак Дума һәм конституцияне мактау хоры да яшь Тукайга тәэсирсез калмаган, әлбәттә. Алдынгы эшче һәм социал-демократларның манифестка һәм Думага карата әйткән сүзләре, сул газеталардан һәм тыелган әдәбияттан укылган фикерләр вакыйгаларга күбрәк милли азатлык күзлегеннән караган һәм конституцион иллюзияләр йогынтысына бирелгән Тукайның колагына керсәләр дә, хәзергә әле аның фикер-хис юнәлешен бик үк үзгәртмичә, миенең бер почмагына кереп сыенганнар.

1905 елның ахырында һәм 1906 елның беренче яртысында Тукайның нәрсә турында язуы һәм язарга тиешлеге беркадәр аңлашылгандыр дип беләм. Әйтелгәннәрдән тыш, яшь шагыйрь яңа газета-журналларны тәбрикләде, яздырып алырга, укып барырга чакырды; фәнгә, әдәбиятка һәм поэзиягә мәдхияләр багышлады; яшь буынны тырышып укырга, бозыклыктан, исрафчыллыктан сакланырга өндәде; крестьянны, ялкаулыктан ваз кичеп, хезмәт белән яшәргә чакырды; ишаннарга һәм реакцион муллаларга уклар очырды һ. б. һ. б.

Тукайның ничек язуы мәсьәләсенә килсәк, соңыннан зур әдип, тарихчы, телче, тәнкыйтьче һәм җәмәгать эшлеклесе булып танылган Галимҗан Ибраһимов сүзләре искә төшә: «Бездә һичбер шагыйрь Тукай чаклы начар, буталчык вә корама тел белән башламады». Халыкчанлык ягыннан беренче урынга чыккан Тукай турында болай әйтү сәер түгелме? Сәерен сәер, әмма бу сүзләрнең дөреслеген кире катып булмый. Күрәсең, Мирхәйдәр Чулпаный һәм Габделвәли Әм-

рулланың[1] «сабаклары» бушка китмәгән: төрек телендә яисә гарәп-фарсы сүзләре һәм әйләнмәләре белән тулы корама телдә язылган шигырьләр генә Габдуллага башта чын поэзия булып тоелган. К. Мотыйгыйның язучылык тәҗрибәсе дә яшь Тукайга йогынтысыз калмаган булырга кирәк. Бит Камил үзенең хикәяләрен купшы, корама телдә язган кебек, кульязма «Әлгасрел-җәдит» журналын да шундый ук тел белән язып тутыра иде.

Тукайның әлеге сигез ай эчендә язып бастырган егермедән артык шигъри әсәрләреннән алтысы гына саф татар телендә. Ни өчен болары тел ягыннан аерылып тора? Әйтик, А. Кольцовның «Что ты спишь, мужичок?» шигыреннән ирекле тәрҗемә ителгән «Мужик йокысы». Чөнки ул «мужик»ка адреслап язылган. Татар крестьянына шагыйрь төрек телендә мөрәҗәгать итсә, бик тә сәер тоелыр иде. «Хөррият хакында», «Дусларга бер сүз», «Иттифак хакында» кебек шигырьләре турында да шуны ук әйтергә мөмкин. Дөрес, боларда шагыйрь тулаем милләткә мөрәҗәгать итә. Ләкин бит милләтнең күпчелеген «гам», ягъни түбән катлаулар, башлыча, крестьяннар тәшкил итә. «Дусларга бер сүз» шигырендә мондый ике юл кызыклы:

Яхшы булыр тапшырсак без дөньяларны
Абразауный егетләргә тәмам, имди.

Тукай әйтерсең лә крестьяннарның берсе булып үз сыйныфташларына эндәшә: әйдә, «абразауный» егетләр безне өйрәтсен, җитәкләсен, алга әйдәсен, ди.

Яисә «Кечкенә генә бер көйле хикәя» исемле шигъри повестена күз ташлыйк. Әсәр Уральскидагы Сафи һәм Фатыйма исемле ирле-хатынлы кешеләр тормышыннан алып язылган. Юаш ат кебек башын иеп яши торган вак сәүдәгәрнең чая һәм мут хатыны үз катына егетләр китерә башлап азып китә һәм ахыр чиктә авыр хәлдә кала. Тормышның үзеннән алынган мондый прозаик вакыйганы ничек инде купшы стильдә, гарәп-фарсы әйләнмәләре белән тулган аңлаешсыз телдә язмак кирәк?

Күренә ки, шигырьнең «адресаты» һәм тормыш материалы яшь шагыйрьне аерым очракларда халыкның сөйләм телендә язуга этәргән.

Әлбәттә, Тукайның бу төркемгә кергән шигырьләре сәнгатьчәлек ягыннан бик үк югары түгел. Әсәрдә тормышчан картиналар һәм характерлар булса да, идеясе «азмагыз, азсагыз, Фатыйма хәлендә калырсыз» дигән фикергә кайтып кала. Мәдхияләренең күпчелегенә дә шундый ук дидактизм хас. Берәр нәрсәне яисә шәхесне күккә күтәреп мактау белән бергә, ул өнди, чакыра, үгетли.

Шагыйрь үзе дә мондый шигырьләргә политик «агитка» итеп караган. «Ифтирак соңында», «Гыйшык бу, йа!», «Дәрдмәнд дәгелмием?» кебек мәхәббәт шигырьләре һәм «Пушкинә» исемле ода язуы да шул фикерне раслый. Болар, чын мәгънәсендә лирик шигырьләр булып, сәнгать ягыннан югары торалар. Әмма аларны аңлар өчен... татарчага тәрҗемә итәргә кирәк.

Габдулланың 17 октябрь манифестыннан соңгы куанычлары озакка бармый. Вакыйгалар аның иллюзияләрен бер-бер артлы җимерә башлыйлар. Шулай булмый хәле юк. Эшчеләр һәм кресть-

[1] Мирхәйдәр Чулпаный — «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә укыган мулла-шагыйрь. 1902—04 елларда Тукай белән аралашкан. Габделвәли Әмрулла — Төркиядән качып чыккан яшь революционер, шагыйрь. Ярты ел чамасы «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә яшәгән һәм Тукай белән дуслык мөнәсәбәтендә булган.

яннар әнә, манифестны бар дип тә белмичә, һаман көрәшәләр. Корал ташларга исәпләрендә дә юк. Мәскәү эшчеләре, баррикадалар корып, хөкүмәт гаскәрләре белән сугышканнар, ди. Ун көн буе бөтен каланы дип әйтерлек үз кулларында тотканнар. Казанда да революционерлар, шәһәр думасына бикләнеп, полициягә һәм солдатларларга атканнар. Патшаның вәгъдәсе кәгазьдә генә калды. Габдулла моны үз күзе белән дә күреп тора. Шәхес иреге диделәр — кешеләрне һаман төрмәгә тыга торалар, җыелыш иреге диделәр — урамда бер-ике дистә кеше җыелдымы, полиция яисә казаклар хәзер килеп җитә; матбугат иреге диделәр — цензура һаман борынын тыга, охранка күзәтеп тора. Әнә бит 4 январь көнне ике участокның мировой судьясы, прокурор ярдәмчесе һәм пристав, пүнәтәйләр белән берлектә, «Уралец» редакциясенә басып керделәр дә, редакция бүлмәләре һәм типографиянең астын өскә китереп, тентү ясадылар. Сәбәп — газетаның 1 январь санында чыккан берничә «крамолалы» материал икән.

Тикшерү, сорау алу башланды. Редакция һәм типография работникларын, шул исәптән К. Мотыйгыйны, шактый вакыт азаплагач, газетаны туктаттылар, редакторы Н. Д. Аржановны судка бирделәр. Менә сиңа матбугат иреге!

Габдулланың социал-демократлардан ишеткәннәре, сул газеталардан һәм тыелган әдәбияттан укып белгәннәре баш калкытып, бимазалый, уйландыра башлыйлар. «Мөхәбәрә вә Государственная Дума» мәкаләсенең март санында, мәсәлән, түбәндәге юллар бар: «Сүзнең төрекчәсе, бу думада ат уйнатканнар җөмләсе ерә вә парәя кәниш (җиргә һәм акчага ия — И. Н.) әлле кешеләр улачак. Дума да байлар думасы улачак». Шунысы кызык: үз кулы белән шушы сүзләрне язса да, Тукай һаман әле Думадан өмет өзеп бетермәгән. Бу каршылыкны аңлату артык кыен түгел. Бит мәкаләнең оригиналы — «Война и дума» брошюрасы — бойкот аркасында туа алмый калган Булыгин думасына каршы юнәлтелгән иде. Хәзер исә закон чыгара торган дума көн тәртибенә килеп басты. Өметсез шайтан ди, бәлки бусы берәр эш чыгарыр. Россия тарихында беренче мәртәбә «парламент» сайлау шау-шуы да йогынтысыз калмаган, билгеле.

Менә сайлау кампаниясе тәмам. Дума әгъзалары Петербургка юл тоталар. Башкаладан ярыйсы гына өметле хәбәрләр килә башлый. Сул карашлы депутатлар аяк терәп сөйләшәләр, хөкүмәткә таләпләр куялар, министрларны гаепләләр.

Ләкин вакыт уза, Таврида сараеның һавасы нотыклардан тетрәнсә дә, илдә үзгәреш сизелми, йөк үз урынында тора бирә. Тукайның тәмам какшаган иллюзияләре юкка чыксын өчен бер кечкентәй этәргеч кенә кирәк иде. Һәм ул үзен озак көттермәде: патша хөкүмәте I Дәүләт Думасын куып таратты. Бу вакыйга, демократик интеллигенциягә авыр тәэсир иткән кебек, Габдулланы да айнытып җибәрде.

«Фикер» газетасының 14 июль санындагы кыска гына баш мәкалә мондый сүзләр белән башлана: «Государственная Дума 8 нче июльдә таратылды. Дәһа (тагы да — И. Н.) тугърысы Дума куылды». Бүтән бер газетадан күчереп басылган материалда исә түбәндәге сүзләр бар: «Аз җирле крестьяннар алпавытларга кол булып, аның өстенә бик күп имана түли-түли фәкыйрьләнеп беткәннәр иде. Дәүләт Думасы хәзинә җирләрне алып, үз кулы илә эшләүчеләргә бирмәкче булды. Хөкүмәт бу эшне кабул итмәде». Баш мәкаләне язу яисә әлеге материалны күчереп басу Тукай тарафыннан башкарылганмы, юкмы — хәзергә безгә билгесез. Әмма

шул ук газетада чыккан «Государственная Думага» шигырендә шагыйрь думага һәм, димәк, күпмедер дәрәҗәдә политик стройга, үзенең мөнәсәбәтен ачык итеп әйтеп бирә. Думага эндәшеп, шагыйрь ирония белән болай ди:

Ач-ялангач мужикларга
Кайда ирек, кайда жир?

Бирәм диден, вәгъдә бирден,
Күрсәт жирен! Кайда? Бир!

Түбәндәге юллар да кызыклы:

Ник куылдың син үзең соң,
Ник кумадың үзләрен?

Кемнәрне куу турында сүз бара? Билгеле инде, башында патша торган хөкүмәтне.

Тукайның революцион-демократик позициягә аяк басуы аңлашылса кирәк. Моннан соң инде аның шигырьләренә һәм мәкалә-фельетоннарына социализм төшенчәсе килеп керә. «Соры кортларга» исемле шигырендә ул, мәсәлән, «минем чөн мәсләгем-юлым бөтенләй социаллардай»,— дип белдерә.

«Шартлар» исемле фельетонынннан түбәндәге сүзләрне укыйбыз: «Капиталистический строй бетеп, дөньяга социалистический тормыш чыкмыйча, капиталның һәр хакыйкатькә пәрдә булып торуы бетмичә, мин үземезне мөселман дип йөрүдә бер мәгънә дә тапмыйм».

Яшь Тукайның социализмы без белгән фәнни социализм түгел, әлбәттә. Революцион социал-демократлар белән беррәттән, социалист-революционерларны да социализм тарафдарлары итеп каравы, алар арасындагы принципиаль аерманы күреп җиткермәве дә шуны раслаcа кирәк. Моны Г. Кариев истәлегеннән дә чамаларга мөмкин: «Тукаев шул кышны (1906 елның ахыры, 1907 елның башы — И. Н.) дүрт ай чамасы сул партияләргә ихлас куеп йөрде вә шуның тәэсире илә язылган, сулрак рухта булган берничә шигыре «Тавыш» [1] газетасында басылды».

Ул гына да түгел, яшь Тукай берара хәтта эсерларны аеруча үз иткән. Менә күп санлы дәлилләрнең кайберләре:

«Царь-голод»ны тәрҗемә итә һәм татар эсерлары органы «Таң йолдызы» газетасына җибәрә.

1907 елның апрелендә шул ук таңчыларның «Тавыш» исемле газетасы чыга башлагач, котлау шигыре яза һәм, эшчеләргә мөрәҗәгать итеп, эшче туган, «бу «Тавыш» — тик сезнең тавыш», — ди. Эсерлар лозунгысын файдаланып, болай дип тә өсти: «Эшче туган! Тартыш кирәк, кирәк тартыш, тартышмаган эшчеләргә бик батар теш».

«Бер татар шагыйренең сүзләре»нең беренче басмасында болай дип белдерә:

Курыкмаслыкта күңлем мисле эс-ер минем,
Күңлем дузәх, авызымнан ут чәчәр минем.

Хискә бирелүчән барышняларга гына түгел, бәлки яшәп килүче тәртипләрдән риза булмаган яшь интеллигенциягә, шул исәптән Габдуллага, сул эсер романтик нурга төренгән каһарман булып күренгән икән, бу бер дә гаҗәп түгел. Әнә бит алар фәлән байгурага «фәлән вакытта, фәлән урынга мең сум китереп куймасаң, башың китәчәк» дигән язу җибәргәннәр. Нишләсен, мең сумын илтеп куйган ди тегe. Бер төркем эсерлар банкны, икенчесе почта

[1] «Тавыш» — татар эсерлары органы.

поездын талаган. Фәлән шәһәрдә губернаторга бомба ташлаганнар, фәлән калада жандарм полковнигын атып үтергәннәр, ди.

Конституцион иллюзияләрдән арынган Тукайда бу вакыт полиция һәм чиновникларны, зур корсак байларны һәм аларның «адвокатларын» куралмау тойгысы бермә-бер куәтләнә. Аның ачуын кабарткан нәрсә милли изү генә түгел инде хәзер. Моңа «ач-ялангач мужик»ларны, ачлыктан һәм сырхаудан кырыла торган балаларны кызгану тойгысы өстәлә. Әнә шул килеш, җәбер-золымны эче-тышы белән дошман күргән яшь Тукайның карап торышка революцион активлык белән аерылып торган эсерларга теләктәшлек итүе табигый хәл иде. «Таң йолдызы» газетасының программ мәкаләсендәге мондый юллар да аның күңеленә хуш килми калмаган: «Бөтен дөньяга рәхәт тудырыр өчен, туганлык ясар өчен тырышкан партияләр хәзер ирекле-ирексез көчкә каршы көч куярга мәҗбүр булалар».

Биредә җитди иҗтимагый сәбәп тә бар. Мәгълүм булганча, эсерлар вак буржуаз катлаулар, аерым алганда, крестьяннар ягыннан теләктәшлек табалар иде. Татарларда исә ул чакта пролетариат руслар һәм кайбер бүтән милләтләр белән чагыштырганда, сан һәм сыйфат ягыннан кайтышрак булып, милләт башлыча крестьяннардан тора иде. Менә ни өчен татар демократик интеллигенциясенең күпчелеге эсерларга симпатия белән карады. Һәм шактый өлеше бу партиядә әгъза булып торды.

Тукайның эсерларга мөнәсәбәтенә чагыштырмача күп урын бирүем укучыны гаҗәпләндермәсен. 1906 елның ахырында һәм 1907 елның башларында шагыйрьнең эсерларга симпатия белән каравы, эсерлар фикерен уртаклашуы аның революцион-демократик позициягә басуын раслаучы өстәмә дәлил булып тора. В. И. Ленин үзенең күп кенә хезмәтләрендә эсерларны, мәгълүм булганча, XX йөз башы революцион демократиясенең состав өлеше итеп карады. Бер мәкаләсеннән без мондый сүзләрне укыйбыз: «Без элеккечә үк, социалист-революционерларның карашларын социалистик карашлар дип түгел, ә революцион-демократик карашлар дип саныйбыз»[1].

«Фикер» газетасының 1907 ел, 6 январь санында түбәндәге игълан басыла:

«Мин бу көннәрдә генә мәдрәсәи «Мотыйгыя»дән чыктым.

Бинаән галәйһи (шул сәбәпле — И. Н.) дусларыма вә якыннарыма иглан итәмен ки, бу көннән ары миңа язачак мәктүпләренә адресын болай язсыннар:

Уральск.

Гостиница «Казань».

А. Тукаеву.

Бакый ихтирам: Г. Тукаев».

Күренә ки, бу вакытларда Габдулланың дөньяга карашында гына түгел, бәлки шәхси тормышында да борылыш булган икән. Чөнки биредә сүз торак урыны алыштыру турында гына түгел, бәлки мәдрәсә белән араны рәсми рәвештә өзү, ташлап чыгу турында бара. Безнең Габдулла хәзер инде — профессиональ журналист, публицист һәм шагыйрь.

Тукай тормышындагы үзгәреш турындагы әлеге мәгълүматны Г. Кариев та тулыландыра. 1906 елның кышында (декабрь ахыр-

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр. Дүртенче басмадан тәрҗемә. Татарстан китап нәшрияты, 1957, 10 том, 7 бит.

ларында булса кирәк) ул, ягъни Кариев, Тукай янына — «Мотыйгыя»гә барып чыккан һәм ниндидер мәҗлескә туры килгән. Төн буе утырганнар, күп сүзләр сөйләнгән. Шунда, — дип яза истәлекче, — «без (Тукаев, мин, Сиражетдин Белюков дигән бер шәкерт) өчәү мәдрәсәдән чыгарга, мин үзем икенче мәдрәсәдән булсам да, бер номерда бергә торырга уйлап, бер көнне извозчикка төянеп, «Казан» миһманханәсе дигән номерга килеп төштек». Тукайның «бу көннәрдә» дигән сүзләренә караганда, күчену январьның беренче көннәрендә булган. Кем белә, бәлки алар, яңа елны яңа урында каршыларга һәм яңа елда яңача яши башларга теләп, 31 декабрьда күчеп килгәннәрдер... Өстәвенә, гостиница үзе дә яңа, җитмәсә, «милли» кунакханә: күптән түгел генә башында Мортаза Гобәйдуллин торган компания тарафыннан ачылган.

Әнә шул гостиницаның 7 нче номерында безнең Габдулла аена 15 сум түләп тора башлый. Бүлмә зур түгел, бөтен җиһазы — караватв, өстәл һәм ике урындык. Гостиница чаклы гостиницада аерым номер хуҗасы булып алгач, безнең егерме яшьлек Габдулла, билгеле инде, тагын да дәртләнебрәк эшкә ябышкан, күп эшләгән, күп язган. Бүлмәсендә төне буе ут сүнми иде, диләр замандашлары.

Бүтәнчә була да алмый. «Уклар» журналы тулысынча Тукай өстендә. «Фикер» һәм «Әлгасрел-җәдит»тәге эше дә корректорлык белән генә чикләнми. Материалларны эшкәртү һәм редакцияләү эшен дә Мотыйгый Габдулла җилкәсенә күчерә бара. Үз шәхесен калкытыбрак куярга ярата торган Камилнең Тукай турында «Фикер», «Әлгасрел-җәдит» вә «Уклар» исемле газета-журналларның иң моктәдир (куәтле — И. Н.) шагыйре вә мөхәррире дәрәҗәсенә ирешеп, бөтен эшне үз кулына алырга якынлашты», дип белдерүе күп нәрсә турында сөйли.

Әле бит аның төп эше бар: шигырь артыннан шигырь, мәкалә артыннан мәкалә, фельетон артыннан фельетон яза. Җәмәгать эшләрендә дә элеккеге кебек үк актив: шәһәрдәге игътибарга лаеклы бер генә вакыйга да Тукай күзенән ычкынмый.

Әмма К. Мотыйгый редакциясендә Тукайның төнне көнгә, көнне төнгә ялгап эшләве инде төгәлләнеп килә... Менә февраль башында нашир һәм редактор Камил Мотыйгый Габдулланы эшеннән чыгара. Нәрсә булды әле бу? Ни өчен? Тукайның Мотыйгыйга кагылышлы кайбер язмаларын күздән кичерсәк, гаҗәпләнүебез тагын да арта төшәр.

«Әлгасрел-җәдит» журналының 1906 елгы август санында басылган «Мөхәрриргә» дигән шигырьдә без түбәндәге юлларны укыйбыз:

> Һәр заман хакны сөвәннәр сез кеби мәкъһур улыр,
> Күстәрер бер көн кәлүр дә милләтең миһри сәңа.
>
> . . . . . . . . . . . . . . . .
>
> Бәхтиярсән дүрт җәрида сахибе улмакла сән,—
> Чөн акар һәр дүрт тарафдан мәгърифәт нәһри сәңа.

Моннан да зур мактау була алырмы? Дүрт газета-журнал хуҗасы булуың белән бәхетле син, ди Тукай, чөнки сиңа дүрт яктан мәгърифәт елгасы ага. Һәр заманда да хаклыкны сөйгән кешеләрне сезне каһәрләгән кебек каһәрләгәннәр. Килер бер көн, милләтең сиңа үзенең мәхәббәтен белдерер.

Шушы сүзләрне язган Тукайны Мотыйгый эштән куа! Сәбәп нәрсә?

К. Мотыйгыйның үзен тыңлыйк. «Шуның өчен (танылган кешеләргә охшарга тырышу гадәте булганга — И. Н.), шул елларда мода-

да булган, эшчеләрне забастовкага котыртучылар мәзһәбенә дә кереп китеп, минем матбагада булган барча эшчеләрне дә миннән жалунье арттыруны сорап, эш ташларга котыртты. Бу хосуста мин Габдулла әфәнденең бу эшен сизеп, берничә мәртәбә тәһдид кыйлып (кисәтеп — И. Н.) куйсам да, файда бирмәде. Ул һаман үзенең котыртуында дәвам итте. Шуның өчен ахрел-әмер аны матбагадан (матбагам ябылмастан бары ике атна әүвәл) бөтенләй хезмәттән чыгарырга тугры килде».

Күренә ки, К. Мотыйгый белән Тукай арасы һич тә ал да гөл булмаган. Без Габдулланың 1904 елда ук инде Камилнең йомшак якларын абайлап алганын, үзеннән олырак иптәшенә тәнкыйть күзе белән карый башлаганын белеп киткән идек. 1905 елда типография хуҗасы, нашир һәм редактор булып алгач, Мотыйгыйның үзен күрсәтергә, ялтырарга омтылу сыйфаты тагын да куәтләнгән дип уйларга кирәк. 1906 елның башында Думага сайланырга йөрүе үзе генә ни тора! Болар Тукайның, әлбәттә, саруын кайнаткан, ачы-ачы сүзләренә, иронияcенә сәбәп булган. Әмма аралары бозылуга, һаман кискенләшә баруга төп сәбәп торткан юл һәм карашларының туры килмәвенә кайтып кала. Әгәр К. Мотыйгый элеккечә үк либераллар сукмагыннан атлый бирсә, Тукай, күргәнебезчә, революцион демократия юлына аяк басты. Әнә шул хәлдә алар арасында тулы татулык була алмый, әлбәттә. Нәшриятта конторщик булып хезмәт иткән Г. Гадельшин болай яза: Камил Мотыйгый белән ул һәр вакыт бу я теге мәсьәлә турында тарткалаша, сүз көрәштерә иде. Бер көнне шулай гонорарның азлыгы, эшнең күплеге турында кычкырышалар. Ахырында гомумән эшчеләр көченнән файдалану мәсьәләсенә күчеп, Тукайның сиңа шөһрәт, безгә хезмәт! дип әйткәнен хәтерлим».

Моннан инде эшчеләрне забастовкага өндәүгә дә ерак калмый.

Бу урында Тукайның эштән куылу сәбәбенә бәйле икенче версиягә дә тукталып китми булмый. Ул версиянең авторы... К. Мотыйгый үзе. Утызынчы елларда язылган һәм архивта саклана торган истәлегендә ул: Тукай «...эшчеләрне эш ташлау хәрәкәтенә чакыруы өчен чыгарылмады һәм ул мондый эшне эшләгәне дә юк» дип белдерә. Чын сәбәп, янәсе, шагыйрьнең эшкә чыкмавы, чыкканда да, тәртип бозып йөрүе. Үзенә күрә дәлиле дә бар: К. Мотыйгый карамагындагы газета-журналлар «бик революционный эчтәлекле» булганга, боларны чыгаручыларны эш ташларга котырту, күрәмсең, үзе үк ярамаган эш.

Үзен-үзе кыйнаган Камил абзагызның кыяфәте — укучым, син дә килешерсең — бик үк матурдан түгел. Бу җайсыз хәлдән Мотыйгый ничек чыга соң? 1914 елда ул Тукайны шәп итеп күрсәтер, укучыларга революцион тәрбия бирер өчен шулай дип язган була. Аннары бит ул чорда, янәсе, цензура шартларында чын хаклыкны язып та булмый иде. Бусы инде гаҗәп логика! Тукайның эш ташларга котыртуы турында язарга яраган икән дә тәртип бозып йөрүе турында әйтергә ярамаган...

Хәер, Камил Мотыйгыйның хәленә дә керми ярамый. Соңгы истәлеге язылган утызынчы елларда аның хәле чынлап та шәптән түгел. Рәсми даирәләр һәм җәмәгатьчелек, 1905—1907 еллардагы файдалы эшчәнлеген онытып, аңа кырын карыйлар. Тукайның Мотыйгыйга каршы юнәлтелгән сатирасы да үз эшен эшли. Җитмәсә, ул бит әле шагыйрьне революцион эшчәнлеге өчен эштән куган кеше. Үзенә карата урнашкан шундый мөнәсәбәттән гаҗиз булган К. Мотыйгый тота да, җилкәсендә яткан бер авыр ташны төшерергә теләп, әлеге версияне уйлап чыгара...

Тукайга килсәк, листовка басу һәм тарату белән генә канәгатьләнә алмаган егетнең зурракка омтылуы, типография эшчеләрен забастовкага өндәргә керешүе табигый. Табигый гына түгел, урынлы һәм кирәкле. Чөнки, беренчедән, депо һәм тегермән эшчеләре эш ташлаганда, типография читтә кала алмый. Икенчедән, социал-демократларга һәм бүтән сул партия вәкилләренә типография кирәк икән, эшчеләр киләләр, эшлиләр.

Инде хәзер тагын бер мәсьәләне хәл итәсе калды: мәкалә һәм фельетоннарында Тукайның К. Мотыйгый файдасына әйткән сүзләрен, «Мөхәррирга» исемле шигырен, ул гына да түгел, бу шигырьне 1907 ел ахырында Казанда дөнья күргән җыентыгына кертүен ничек аңлатырга? Риялык түгелме бу, принципсызлык түгелме? Түгел, һич тә түгел.

Мотыйгыйның шәхес буларак кимчелекләрен күрсә дә, фикерләре туры килеп җитмәсә дә, тулаем алганда, Габдулла бу шәхеснең милләт өчен, халык өчен файдалы эш башкарганлыгын яхшы аңлый. Гаять авыр шартларда эшләве дә аның күз алдында. Беренчедән, материаль кыенлык. Ике газета, ике журнал бит ул! Яздырып алучылардан һәм берәмләп сатудан килгән акча чыгымның яртысын да каплый алмый. Икенчедән, хөкүмәтнең идарә органнары һәм охранканың «дамокл кылычы». «Уралец» газетасын җирле властьлар җентекләп күзәтеп баралар. «Фикер» газетасына да күзәтүче билгеләнгән дип уйларга кирәк. Әле бер материал, әле икенчесе уңае белән каядыр барырга, аңлатма бирергә, җайларга, котылу чараларын эзләргә туры килә. Ниһаять, өченчедән, татарның үз эчендәге искелек тарафдарлары һәм реакцион матбугатның «Фикер» белән «Әлгасрел-җәдит»кә аяк чалырга, редакторы К. Мотыйгыйның тормышын агуларга тырышулары. Казанда чыга торган «Бәянелхак» газетасының һөҗүмнәре һәм өстереп торуы бушка китми: Хәйрулла Гаделшин исемле купец белән Гайнетдин Кари «Фикер» матбагасын һәм редакциясен тар-мар итү, Мотыйгыйны һәм гаилә әгъзаларын кыйнау өчен хәтта «отряд» оештыра башлаганнар. «Бәянелхак»ның нашире Әхмәтҗан Сәйдәшев белән К. Мотыйгый судлашуга кадәр барып җиткән.

Әнә шундый хәлләргә Тукай, билгеле, битараф кала алмаган. «Бәянелхак» газетасын һәм Ә. Сәйдәшевне хурлыклы сурәткә кертеп, фельетон артыннан фельетон яза, Уральскиның үзендәге кара фикерле кешеләрдән эштән чыгарып көлә. Бер яктан, К. Мотыйгыйны дәртләндерү, аңа көч-куәт бирү, икенче яктан, аның дошманнарын хурлык баганасына кадаклап кую максаты белән әлеге «Мөхәррирга» исемле шигырен яза.

Мотыйгыйның баш өстендә исә болыт һаман куера бара. Наширлык һәм редакторлык эшчәнлеге инде төгәлләнеп килә...

1906 елның ахырында Камил Мотыйгый, атасы Мотыйгулла хәзрәт белән берлектә, зур бәлагә юлыга: алар судка эләгәләр. Моның тарихы болай булган.

1906 елның январенда «Уралец»ның редакторы Н. Д. Аржановның хөкемгә тартылганлыгын һәм газетаның туктатылганын белеп киткән идек инде. Бу юлы «җиңел курку» белән генә котылган Мотыйгый, озын-озак уйлап тормыйча, үз наширлыгында һәм редакторлыгында «Уральский дневник» исемле икенче газета чыгарырга рөхсәт сорап, тиешле урынга 25 январь даталы прошение бирә. Прошениедә ул үзенең яшен арттырып күрсәтә, чөнки берочтан сайлау кампаниясендә дә катнашырга тели.

Башта эш шома гына бара. Мотыйгый «Уральский дневник»ны

чыгара башлый, депутатлыкка ирешә алмаса да, гади сайлаучы гына түгел, выборщик була.

Әмма «без капчыкта ятмый» дигәндәй, донос аркасында туу турындагы таныклыкның сере фаш ителә. 1907 елның башында тикшерү, сорау алу башлана. 12 ноябрьда суд була һәм суд Мотыйгулла Төхфәтуллинны 5 айга крепостька ябарга, ә Мөхәммәт-Камил Төхфәтуллинны бер елга төрмәгә утыртырга карар чыгара[1].

Судны көтеп тормастан, властьлар 22 февральдә Камил Мотыйгыйны редакторлык һәм баширлык хокукыннан мәхрүм итәләр. Тәрәккыйпәрвәр булып кыланырга яратучы «миллионщик» Мортаза Губәйдуллин типографияне редакцияләре белән берлектә сатып ала һәм редактор итеп мәдрәсәдә хуҗалык эшләрен башкаручы Вәлиулла Хәмидуллинны утырта.

Билгеле инде, Вәлиулла абзасы Тукайны бик теләп эшкә чакырып алган: газета-журналларны кемдер чыгарырга тиеш ич.

Тукай яңадан дәртләнеп эшкә керешә. Ләкин аның куанычы озакка бармый. «Фикер», «Әлгасрел-җәдит» һәм «Уклар» май ахырларына кадәр авырлык белән, аксый-туксый баралар да туктап калалар. Чөнки Мортаза бай матбугат эшенең борчулы эш икәнен, табыш урынына зарар гына китергәнлеген аңлап ала да бу бәрәкәтсез шөгыльне ташларга ашыга. Тукайның:

Матбага алгач, сине инсане галидер дисәм,
Кайда галилек синдә, хали икәнсең син һәнүз,

— дигән юлларны эченә алган «Матбага белән уйнаган бер байга» исемле шигыре шушы кешегә адресланган.

Безнең шагыйрь тагын эшсез. Материаль як та кысынкылана бара. Ярый әле, Габдулла дус бар. Аның карилектән килгән акчасы арага керә. Шуңа өстәмә рәвештә тагын бер чыганак ачыла.

К. Мотыйгыйның, матбагадан тыш, «Прогресс» исемендәге китап кибете дә булган. Типография белән берлектә магазин да ябыла. Калган китапларын сатып бетерүне Мотыйгый Г. Кариевка тапшыра. Килгән акчаның күпмедер өлеше сатучыга тәгаенләнгән булырга тиеш. «Әлбәттә, — дип яза Кариев, — китап сатар өчен разрешениефәләнем юк иде, һәм аның кирәк икәнен дә белмидер идем. Бераз вакыт сату иткәч, разрешением булмаган өчен полиция китапларымны алып китте, үземне бер кич частьта кундырдылар».

Ни сәбәптәндер, ул бөтенесен дә әйтеп бетермәгән. Архив безгә мондый мәгълүмат бирә: 1907 елның 8 июлендә приставка РСДРПның Урал оешмасы тарафыннан басылган ике данә прокламация килеп керә. Тапшыручы кеше аларны Миңлебай Хәйруллиннан (Г. Кариевтан) алганлыгын әйтә. Мондый очракта полиция тиз кыймылдый бит: Кариев номерына тентү белән киләләр һәм берничә исемдәге революцион брошюралар табалар. Билгеле инде, егет котылу юлын эзли: прокламацияләрне урамнан таптым, брошюралар Л. Мотыйгый китаплары арасында иде, ди.

Архивтагы икенче бер документта М. Хәйруллинны гаепләү буенча тикшерү эшенең тәмам булуы һәм материалларның җибәрелүе турында Саратов Суд палатасы прокурорына хәбәр ителә.

---

[1] Күп бусагаларны таптау һәм күп язулардан соң гына хөкем карары 1908 елның апрелендә Саратов Суд палатасы тарафыннан юкка чыгарылган.

Эш судка ук барып җитмәгән. Г. Кариев, күрәсең, хәлнең җитдиләнә баруын абайлап, Уральскидан чыгып сызу ягын караган. Шул елның августыннан башлап без аны яңа гына оешкан «Сәйяр» труппасы составында күрәбез.

«Шуннан соң (тентүдән соң — И. Н.), — дип дәвам итә Г. Кариев,— Тукаев партия кешеләре белән араны тәмам өзде, икебез дә тәүбә иттек». Кариевның жандармерия тырнагына эләгә язгач өркеп калуы һәм революционерлардан тайчынуы хакында әйтеп чыгуы гаҗәп түгел. 1913 елда басылган бу истәлегендә прокламация һәм брошюралар мәсьәләсен телгә алмаганы кебек, сул партияләр белән араны өзеп, тәүбә итүләренә басым ясавы үз хәвефсезлеген истә тотып эшләнгән булуы бик ихтимал.

Тукайның партия кешеләре белән арасын өзүе турындагы сүзләрдә беркадәр дөреслек булырга мөмкин. Берәр партиядә рәсми рәвештә әгъза булып тормаса да, без Габдулланың революцион эштә практик рәвештә дә катнашканын белеп килгән идек. Без шулай ук аның эсерларны якын итүен, шушы партия вәкилләре белән теләп аралашуын да күреп узган идек. 1907 елда, талантына, шагыйрьлегенә тәмам ышанган Тукай, төп эше әдәби иҗат дигән фикергә килгәч һәм бигрәк тә дусты белән булган хәлдән соң, башлыча эсерлар рухындагы практик эшләрдән читкә киткән икән, бередә шулай ук артык гаҗәпләнергә урын юк.

Г. Кариев истәлегендәге «тәүбә иттек» дигән сүзнең Тукайга кагылышлы өлешен исә кире кагарга кирәк. Безнең шагыйрь үзенең Җаекта калыплашкан иманыннан, ягъни революцион-демократик карашларыннан беркайчан да чигенмәде.

*Дәвамы бар*

Йосыф Гәрәй

# «КАЛӘМ», «НУР», «АШКАДАР»

**Ай, Стәрле кала, сәхрә-дала,**
**Һай, тауларың! Мисле манара [1].**
**Аерылганда, дустым, төсең калдыр**
**Бик сагынган чакта карарга.**

Халык җыры.

Татар әдәбиятының даһие Галимҗан Ибраһимов 1929 елда «Татар хатыннилэр күрми» романына баш сүздә бу әсәрнең 1909 ел Миасс заводында язылуын әйтә. «1910 елда, — ди ул, — хәзерге Башкортстан җөмһүриятенең кантон шәһәрләреннән Эстәрлетамакта «Къәләм» көтепханәсендә беренче басмасы чыкты. 1911 елда шул ук көтепханә әсәрне икенче тапкыр басты...»

Кечкенә шәһәрдә роман чаклы роман бер-бер артлы ике мәртәбә басылган! Бу безгә бик кызык һәм әһәмиятле тоелды. Шуңа Стәрлетамакның тарихын бераз тикшереп карау теләге туды.

«Каләм» чыгарган башка китап күзгә чалынса, бу теләк, бәлки сүнәр дә иде. Галимҗан бит! Аның эзеннән туфрак җыярга күнегелгән. 1967 елда да әдипнең юбилее уңае белән күп йөрелде. Яңа фактлар, замандашлары табылды. Вакытлы матбугат өчен берничә мәкалә яздым. Аңа чаклы да, классикны күргән, белгәннәргә тагылып: «Яз инде. Соңлатма. Син әйтеп тор, алайса, мин языйм!» дип кыстап, күңелле мәшәкать күп чигелде. Шулай язылганнарның барысы да Г. Ибраһимов турында истәлекләр китабына керде. Янә ике шигырь бастырдым Галимҗаным хакында. Шуңа күрә аңа бәйләнешле бу арзу [2] — тәүге романы басылган җирдәге шараитны белү теләге дә үскәннән-үсә барды.

Ә нәрсәдән башларга бу «экспедиция»не? «Иң әүвәл Стәрле пенсионерларын табарга кирәктер». Ике көн телефон төбеннән китмәдем. Белгән картлар, карчыкларны барлап чыктым. Белеш-танышлар арасында Стәрле кешеләре юк икән ләбаса. Күрше-күләндә дә юк. Шулай да, томанлырак булса да, бер-ике сукмак табылды кебек.

1969 елның җәе иде. Көн сүрелгәч, картлар бакчага чыга дип, Агыйдел буендагы Крупская исемендәге бакчага бардым.

...Аста күркәм һәм данлы Агыйдел, ялтырап, озын күкшел гәүдәсен салмак кына төньяккарак шуыта. Кыя башында бакчаның җәйге зиннәте котырынган. Эскәмияләр-

---

[1] Стәрлетамак янында, Агыйделнең уң ярындагы «йөрәк тау», «тоРатау»ларга ишарә.
[2] Көчле теләк.

дә, карашларын еракка төбәп, миңа зарур булырдай аксакаллар утыра. «Сез Стәрле ягыннан түгелме?» дим таныш булмаган күп кенә бабайларга. Юк, табылмады стәрлеләр. Беренче сабан туйда ук батырга чыга алмавым бер дә гаҗәп түгел. Әмма бакчаны, карт наратларны дикъкать белән карап, әңгәмәләшеп, ике әйләндем. Әйләнми ни, монда Галимҗан да Хәдичәсе[1] белән күп йөргән бит. Бу сап-сары наратлар аларның кордашы...

Картларның оясы, мин әйтәм, Ленин скверы инде ул. Шунда керергә кирәк кайтышлый.

Керсәм... Менә кая икән ул «партархив»! Бер аллеяда ут-су кичкән азаматлар утыра, икенчесендә — шәрафәтле карчыклар. «Мазлумнар бакчасы» дип юкка шаярмыйлар бу шаян картлар. Алар һич тә мазлум түгел. Тик юморга каршы килеп булмый. Шаярсыннар шаяннар.

Монда озак та сорашып йөрергә туры килмәде. Берәү «чиртте». Фәлән урамда, имеш, Стәрле кешесе тора.

— Кем ул?

— Телче бар иде бит әле. Кем соң? Ят фамилияле... Әй, бу нәләт төшкере склерозны!..

Берничә фамилия әйтеп карадым. «Юк. Бүтән. Хәзер искә төшәр...»

— Алпаровмы әллә?

— Шул үзе. Аның энесе монда. Ул белми булмас. Галимҗан белән авылдаш диярлек.

— Адресы ничек?

— Менә ул кадәресен белмим шул.

Адрес табар өчен фамилиядән тыш исем дә матлуп булганга, эзләнүне икенче тарафка бордым. Үзәк китапханәнең картотекасын карау башланды. Һәй, кая гына чыкмаган татарча китап! Петербург, Мәскәү, Казан, Уфа, Оренбург, Әстерхан, Чиләбе, Троицк, Бөре, Миасс, революциядән соңгы Бөгелмә, Бәләбәй нәшерләре күренә. Арада «Каләм» авторлары да юлыга: Г. Алпари, Бәдрелдин Гыйбадуллин, Мохтар Ибраһимов... «Татар хатыны ниләр күрми» дә килеп чыкты... Байтак нәрсә табылды. Укый башладым.

Бер атнадан Стәрлегә барып, «Каләм»не юллап, шәһәрне чарлап, егермеләп кеше белән очрашып, янә берникадәр хәбәрдар булдым. Истәлекле йортлар фотога төшерелде. Менә шулай башланды бу мәкалә.

Соңгы бишьеллыклар Стәрлетамакны эре сәнгать үзәге итеп тә үстерде. Ул зур шәһәрләр төсен алды, республикада Уфадан кала икенче урынга чыкты. Революциягә чаклы эре һәм вак сәүдәгәрләр, вак һөнәрчеләр, приказчиклар, азмы-күпме эшчә яшәгән ул кечкенә, караңгы өяз шәһәрчеге, нигездә, сәүдә үзәге булган. Бөркү мещанлык тормышына атнасына ике базар, ел саен язгы-көзге ике ярминкә генә җан кертеп торган. Шулай да биредә 1905 елда инде РСДРП оешмасы була һәм шәһәрнең политик тормышына йогынты ясый башлый.

Ә 1905 елгы революциядән соң монда да җәдитчә (яңача) укыта торган чын татар мәктәпләре ачыла. Ике класслы татар-башкорт мәктәбендә татар теле-әдәбияты аерым фән булып керә башлый. Шәһәрдәге биш мәдрәсәдә дә кайбер фән (хисап, җәгърәфия, табигатьне өйрәнү) буенча дәресләр бирелә. Шул рәвешчә, иҗтимагый тормышка яңа идеяләр бәреп керә. Ислам фанатизмы ярыйсы ук чигенә.

Уфада Г. Алпаровның кече туганы Габделхәмид ага, ниһаять, табылды. Минем килүнең максатын белгәч тә, ул күршедәге балдызын алып керде. Бу төс ташламас карчык Әбләизова Рәхилә, апалары Гөлсем, Зөһрә Стәрледә артистка булганнар, тәүге спектакльләргә катнашканнар икән. Хәмит абый үзе дә — бермәл артист.

1912 елда Приказчиклар җәмгыяте татар-башкорт клубы ача. Аны мәшһүр елга исеме белән «Ашкадар» дип атыйлар. Өстә — кечкенә зал, сәхнә. Монда милли кичәләр, репетицияләр үткәрелә. Аста — китапханә, Фәхретдин Вәлидов музыкаль

[1] 1915 елларда, Уфа мөгаллимәләр мәктәбендә укыганда, Хәдичә Фәтхуллина Г. Ибраһимов белән якыннан таныша, әдип Ялтада ялгызы калгач, аның янына барып, никахлы хатыны була.



*«Ашкадар» клубының беренче артисткалары (сулдан уңга) Рәхилә, Зөһрә, Гөлсем Әбләизовалар.*

түгәрәктә яшьләрне скрипка, мандолина, гармун уйнарга өйрәтә. Хәмит ага да шунда мандолина уйнарга өйрәнгән. Шунда ук «Алга» исемендә җилем басма белән күбәйтелгән кульязма журнал да чыга. Аны Ибраһим Сәйфуллин, Гарифә Вәлидова, Мөбәрәкшаһ әл Хәнәфи, Габделхәй Алпаров, Гобәйдулла Әбдерәшитов эшлиләр. Спектакльләрне исә клуб күбесенчә «Мираж» кинотеатры залында куя. Рәхилә (хәзер Кәримова) апа ул заманны әле яхшы хәтерли: «Мираж» залы зур. Халык шыгрым тула. Бөтен Стәрле куба спектакль дигән көнне. Кино бинасында яхшы буфет була. Аны бай сәүдәгәрләр чиратлап оештыралар. Кичә ахырында артистларны сыйлыйлар, акча да бирәләр. Минем Зөһрә апага — унлык алтын, башкаларга өчәр, бишәр сум тия»[1].

Беренче спектакль 1912 елның көзендә куела. Г. Камалның «Бәхетсез егет»ен уйныйлар. Әмма башта хатын-кыз роле Гайнине уйнар кыз табылмый. Соңыннан шәһәр читендәге кечкенә бер агач өйдә яшәгән ярлы Гобәйдулла Әбләизовның Зөһрә исемле сылу кызын табып алалар. Беренче репетициядән кайтканда ук мәчет әһелләре аны юлда очратып кыйныйлар. Ләкин, чәмләнеп, ул үз эшен барыбер дәвам итә. Башка вакытта Зөһрәне ике-өч кеше клубтан өенәчә озата торган була. Зөһрә тамашачының мәхәббәтен яулый. 1918 елда аны чехлар, юеш подвалга ябып, ач тотып харап итәләр. 1912 елда ук спектакльдә баш рольләрнең берсен башкарган Мостафа Идрисовны да шул чак атып үтерәләр. Кайбер артистлар Стәрледән качарга мәҗбүр

[1] Байларның бу «юмарт»лыгы, әлбәттә, халыкны алдау, үз тәэсиренә алу өчен эшләнә.

була. Ул заманда, реакционерлар карашынча, культура эшлеклеләре большевикларга тиң булганнар. Гобәйдулла Әбдерәшитов исә үзе дә чын большевик була. Аны да аклар аталар.

...Хатын-кызлар клубка ул чак бик йөрмиләр. Шуңа, учитель Шәрәфи Мәхмүдов тырышлыгы белән, 1914 елларда гел кызлардан гына торган концерт төркеме оеша. Анда Маһруй Шәриф кызы Фәйзуллина (соңыннан Ходайбирдина)[1], Суфия Мәхмүдова, Шәмсенәһар Богданова, Зизи Байракова, Фатыйма Таһирова һ. б. катнаша. Башта кызлар аерым өйләрдә чыгыш ясыйлар. Тыңларга карчыклар гына килә. Бара-тора, ирле хатыннар, кызлар да иялэшә башлагач, концертлар Мәхмүдов укыткан русча мәктәпнең сыйныф бүлмәләрендә үткәрелә. Революциядән соң бу кызлар чыгышны Ашкадар клубында дәвам итәләр.

Бу шәһәрнең культура тарихында мөһим хадисә — «Къәләм» ширкәте (русча: товарищество, бүгенгечә: кооперация). Ул 1906 елда төзелә һәм китап чыгара башлый. Ширкәтнең инициаторлары шәһәрнең прогрессив интеллигенция вәкилләре Шәрәфетдин Мәхмүдов («Шәрәфи учител»), Бәдретдин Гыйбадуллин («Бәдри учител») була. Алар икесе дә Казан рус-татар укытучылар мәктәбен тәмамлаганнар, укытучы булып күп еллар эшләгәннәр. Икесенә дә Стәрлетамакның шәхси почетлы гражданнары («Личный почетный гражданин») исеме бирелгән. Шәрәфи Мәхмүдов (1853—1932) III Дәүләт думасына да сайланган. «Минем тормышым» дигән китабының кульъязмасы булганы да билгеле.

Ширкәт башта китапларны Уфада чыгара. Иң тәүге китап булса кирәк, 1906 елда «Электрическая Губернская Типография»дә[2] «Ходаның гадел хөкеме — гүзәл гыйбрәтле хикәя» басыла. Аның аңлатмалары итеп: «Үчител Бәдердин Гыйбадуллин әсәридер»... «1906 ел, 8 июнь... Печатано без предварительной цензуры» дигән сүзләр язылa.

Бер басма табак күләмендәге һәм русчадан тәрҗемәгә охшаш бу китапта күп халыкка бәла салган бер юлбасарның тиешле җәза алуы хикәят ителә.

Уфада «Шәрык» матбагасы ачылгач, «Къәләм» китаплары шунда басыла башлый. Шуларның беренчеләреннән берсе — «Милиунлар табу» (1909) романы.

Аның хакында: «Французчадин һәр төрли телгә тәрҗимә иделмеш, гайәт мәракълы (кызык, интригалы — Й. Г.) үә гүзәл гъибрәтле руман улуб, бу дәфгъә (бу юлы. — Й. Г.) госманлыйчадин (төрекчәдән — Й. Г.) татарчага тәрҗемә иделмешдер»[3], диелә. Тәрҗемәчеләр — Мохтар Ибраһим (Г. Ибраһимовның икетуган агасы) һәм Гыйбадулла Алпари (Гыйбад Алпаров). Әсәрдә акчасы югалганга акылдан язган карт һәм юк миллионнарны эзләүгә гомерләрен сарыф иткән яшьләрнең харап булуы сурәтләнгән. Маҗара жанры ягыннан караганда, ул заман өчен, бәлки, азмы-күпме яңалык булгандыр. Мораль камиллеккә өндәү ягыннан әһәмияте юк түгел. 1910 елда Бәдретдин Гыйбадуллинның маҗаралы икенче хикәясе чыккан. Монысы да русчадан тәрҗемә. Ул берәүнең Нью-Йоркта гаепсез көе кешe үтерүдә гаепләнүе һәм ахырдан шәфкатьле кыз ярдәме белән котылуын тасвирлый.

Уфада басылган бүтән китапларны табып булмады.

1910 елда Стәрлетамакның үзендә типография ачыла. Бу хакта бер китап тышында шундый игълан бирелә:

«Уфа вәләяти Эстәрлитамак шәһәрендә мөселманлар «Нур» исмендә бер ширкәт тәэсис итүб (оештырып — Й. Г.), 1910 елда 28 июльдә матбага ачдыйлар. «Къәләм» ширкәти һәм «Нур» ширкәтинә мөсәдар (инициатор — Й. Г.) исә дә, «Къәләм» үз ширкәтени дәүам итдерәдүр. «Къәләм» көтепханаси идаресени гүзәлрәк, диккәтлирәк әсаска куймак фикерендәдер. Киләчәктә ширкәткә дәхи икътидарлырак (сәләтлерәк — Й. Г.) затлар кушылачагыннан, идарә мөштәриләренә (сатып алучыларына — Й. Г.) һәр кирәк китапларный үз вактында хәзер булдырмага үәгъдә итәдер». Бу ширкәтнең составы Үтәмешев, Айтуганов, Баязитов, Усманов, Дьяконов кебек бай сәүдәгәрләрдән

[1] Башкорт революционеры Шәһит Ходайбирдиннең бик яшьли тол калган хатыны.
[2] Электротехника кулланганга, күрәсең, шулай аталган.
[3] Цитаталар үз орфографиясе белән, теле оригиналдагыча итеп алынды. Кирәк җирдә каты «к», «г» — «къ», «гъ» төсендә бирелде.

тора. Ә «Каләм» — коллектив пайщик була. «Нур» татарча китаплардан тыш, русча, татарча визит карточкалары, «мәхәббәт почтасы», төрле контора журналлары, квитанция, ярлык кенәгәләре кебек нәрсәләр дә баса.

«Нур» ачылгач, Стәрле нурланып китә, китаплар күп чыга башлый. Сафуан Яхшыгуловның «Башкорт хәлләре» (1911 ел), Зыя Ярмәкинең «Күрсәтәм» (1912 ел) исемле шигырь җыентыклары дөнья күрә.

З. Ярмәки, китабына эпиграф итеп, бер строфа ала:

**«Үтә ел, үтә ай, үтә көн.**
**Шулайтеп гомергә бетәм.**
**Сүнә дәрт, бата ай, кала төн.**
**Гомер бу! Янам да үтәм.**

Китапта бу «Җыр» дигән шигырьнең тагын бер строфасы бар:

**Күчә ил, бетә эз, кара — көн.**
**Бетә ил, димен дә бетәм.**
**Түгәм яшь, йокысыз үтә төн, —**
**Бәхетсез... үтәм.**

Китаптагы унҗиде шигырь дә шушы рухта. Нишлисең, ул заманда «өмидсезлекни җырлау»ны да лирик поэзия дип аңлаучылар күп булгандыр шул З. Ярмәкинең бу шигырьләре реакция елларында тууын истән чыгармыйк. Әмма шулай да, күңел боеклыгына җирлек буларак, кайбер шәхси һәм иҗтимагый шартлар да урыны-урыны белән чагылып киткәли:

**Дуст диеп йөргән моранларга [1] кул бирмәс идем,**
**Ялгызым вөҗдан белән тормакка пакь җир булсачы!**
**...Аһ! Илдә вөҗдан булсачы!**

**(«Шикаять вә арзу» [2].)**

Шагыйрь С. Яхшыгулов шигырьләре иҗтимагый темаларга язылган. «Башкорт агаларга хитап» шигыре халыкны мәгърифәткә, башкалардан артка калмаска чакыра:

**Һәр урында төрле милләт кузгалыша.**
**Мәгариф тәрәккъыигә юллар ача.**
**Сезләр йоклап ятасыз һәнүзгәчә,**
**Нигә уйганмайсыз һаман, башкортларым!**
**Сездә бар истигъдад [3] һәм кабилиәт [4],**
**Укуга, укытуга кылыңыз гадәт.**
**Укудыр дөнья — ахирәттә сәгадәт [5].**
**Уйганыгыз, уйганыгыз, башкортларым!**

Әдәби нәшерләрдән И. Исәнбирдиннең «Мансур илә Галия» (1911), Хәсән Кәримовның «Шакир хәлфә дәресе» (1911), Әхмәджан Биктимеровның «Хәлфә» драмасы (1912), Г. Смаковның «Бичара хәзрәт»е (1911) бәхетсез мәхәббәткә багышланганнар, аларда фанатик хәзрәтләр, надан кадимче хәлфәләр, ишаннар, «яңалаша башлаган» сылу Нәфисәләрне («Хәлфә»), уңган Галияләрне («Мансур илә Галия») көчләп кияүгә биргән рәхимсез ата-аналар фаш ителә.

Бу китапларда рационализм хөкем сөрә әле, уңай каһарманнар күренми диярлек, ә бүтәннәренең эче-тышы үтә шөкәтсез. Кыскасы, алар чын сәнгать әсәре булып җитә алмаганнар. Ләкин алар барыбер үз заманы өчен таяныч, алга өндәгеч булганнар.

Алда саналган китаплардан башка «Каләм»нең 1910—1912 елда тагын унлап әдәби китабы чыккан.


Ширкәт фольклорга да игътибар иткән — Б. Гыйбадуллинның «Дүрмән — башкорт хикәйәсе», Рәифә Гыйбадуллинаның «Ертанач һәм угры — башкорт хикәйәсе» дигән китапларын бастырган. Арада брошюра исемнәре дә очрап куя. Исемлектә Гыйбад

[1] Моранларга — рияланучыларга.
[2] «Шикаять вә арзу» — «Зар һәм теләк».
[3] Истигъдад — зирәклек.
[4] Кабилиәт — сәләт.
[5] Сәгадәт — бәхет.

Алпаровның «Кесәлек мәңгүлек калиндар»лары бар: «Сәна һиҗри үчүн», «Сәна миладиә үчүн». М. Ибраһимовның «Ломоносовның тәрҗимәви хәле», Ш. Мәхмүдовның «Задачник», «Хисаб дәреслеге», шулай ук Л. Г.[1] инициаллары белән чыккан «Әхлакдин тәрбиә бакчасы» кебек педагогик нәшерләр булган. Моннан кала Хәй Алпаровның (Гыйбадның туганы) «Кырык төрле фукс»ы, «Шерлок Холмс турында хикәя», М. Хәнәфинең «Аракы ачуы», Хәбиб Сатлыковның «Эчкелеккә каршы» дигән китаплары дөнья күргән. Атаклы Стәрлебаш мөдәррисе Шакир Тукаевның «Стәрлебаш» исемле китабында авыл тарихы бәян ителә.

«Каләм» һәм «Нур»ның иң уңышлы нәшере — Галимҗан Ибраһимовның «Татар хатыныниләр күрми» повесте. Тәүге басманың тышына:

«Г. И. — «Татар хатуни ниләр күрми?» Ирләр сурәтендә йөргән хатун. Эстәрлитамак өязендә булган вакыйга. Ширкәт «Къәләм» мөсарәфи (чыгымы — Й. Г.) илән басылдый. Стәрлитамак. Типография товарищества «Нур». 1910» дип язылган.




*Г. Ибраһимовның «Татар хатыны нилэр күрми» китабының тышлыгы.*

Авторның кереш сүзен тулысынча китерү дә артык булмас.

«Белә торгансыздыр, безнең татар галәмендә үзенең агыр тормышына, җәбер вә җәфага түзә алмый качуб китүб, тәбигъәтнең биргән хатунлык сыйфатыни яшерүб, ирләр сурәтендә йөрергә мәҗбүр булган мәзлумәләр сирәк-сирәк очраштыргалыйлар.

Борын заманда җиде кыз ирләр киәфәтинә керүб күб еллар мәдрәсәдә укуганлар, имеш... Соңра зур фаҗигага очыраганлар, имеш, диләр. Болар хакында байтак җырлар вә хикәяләр дә бардыр.

Шул ачи хәкъикъәтни мин үзем ики мәртәбә очыраттым. Берси Эстәрлитамак өязендә, икенчеси Ырынбурда булуб, һәр икеси дә екерменчи гасырдадыр.

Эстәрлитамак өязендәгеси тикшерелгәннән соң кулыңыздагъи мона шул сәхифәләр караланды.

[1] Мөгаллим Лотфи Галимов булса кирәк. — *Авт. искәрмәсе.*

1909 ел. Синтәбер».

Бу ширкәт башка бер китапны да икенче мәртәбә чыгармаган. Г. Ибраһимов әсәре, күрәсең, бик үтемле булган. Анда бит хәзерге Ауыргазы районы, Балыклы авылында булган чын вакыйга — әчкече иренең, усал кайнанасының җәберенә чыдый алмый качып, ирләр киемендә күп маҗаралар аша кичкән Хәтимә дигән хатынның язмышы сурәтләнә. Моны халык шушы көнгәчә риваять итеп сөйли.

Бу батыр кызның бала чагын әдип бик типик шартларда оста тасвирлый. Гөлбану бик җитез, эшкә оста, гәүдәгә таза, кыю кыз булып үсә: «Уракта аның артый көлтә белән тулы булуб, алар нык һәм өлкән булалар иде. Ярышуб урганда күп вакыт агаларындан да арттыра иди... Матурлыкда ул ауылда бер иди». Гөлбану аулак өйләрдә гармун уйнарга да өйрәнә. Ләкин күңелле үсмер чак озакка бармый. Әтисе Нурый карт аны, мәкерле Фәрит хәзрәт димләве белән, 17 яшьтә үк кияүгә бирә. Ире Закир, «черегән бай» малае, бозык табигатьле кеше була. Инде чыдар хәле калмагач, йөз кыйналган, мең тиргәлгән уңган килен Гөлбану авылдан качып китә.

«Кызганып» Урал артына алып китүчеләр Гөлбануны карт башкорт баена өченче хатынлыкка бирәләр. Аның «өст-башы — ука да ефәк. Һич шелтә юк. Ире Солтан Гөлбануны табыну дәрәҗәсендә ярата, иркәли... иди». Әмма Гөлбану юан корсаклы картны яратмый, нәфрәтләнә. Тиздән Солтанны юлбасарлар үтереп ташлыйлар. Ә Гөлбану борынгы йола буенча аның 11 яшьлек энесенә хатын булырга тиеш. Гөлбану тагын кача. Чәчен кисеп, ирләрчә киенеп, «Габдуллага әйләнә». Шуннан аның әсәрдә сурәтләнгән икенче газаплы тормышы башлана...

Хатын-кызларның хокуксызлыгына каршы Гөлбануның инкыйлабын яшь язучы — булачак классик — шундый маҗаралы әсәрдә үзенчәлекле ситуацияләрдә күрсәтә, аны нык характерлы кыю шәхес итеп сурәтли.

Мәгәр соңыннан роман авторны канәгатьләндермәгән. Монда типик шараит булса да, Гөлбану-Габдулланы типик образ дип булмый. Яшь Ибраһимовның теле дә бу әсәрдә чарланмаган әле. Беррәттән утызар-кырыгар җөмлә, үткән гасыр әдәби телендәгечә, «иди» (иде) белән бетә. Аннан «Габдулла» шундый ситуацияләргә куела ки, ул мотлак фашланырга тиеш. Гел ирләр белән генә урман кисеп, Сакмарда сал бәйләп, сал агызып аның сере ачылмавы бик гаҗәп. Хикәянең халык телендә сакланган вариантында ул Урал аръякларына китми, үз ягындарак бер сәүдәгәрдә унбиш ел кучер булып тора. Бу версия чын фактка якын.

Әсәрнең әдәби җәһәттән зәгыйфь икәнен Г. Ибраһимов соңыннан үзе дә әйтә, һәм 1929 елда бөек әдип яшьлек дәвере әсәре урынына хәзер классик дип танылган башка әсәр яза. Бу соңгы «Татар хатыны ниләр күрми» романында инде типик шартларда типик Гөлбану образы тиңсез осталык белән сурәтләнә. Монда элеккеге әсәрдән кайбер геройларның исеме (Гөлбану, Закир, Фәтхия, Сабира) калса да, элекке Фәтхия, Сабираның фигыль-гадәтләре бераз сакланса да, бу романны Г. Ибраһимов баш сүздә өченче басма дип атаса да, ул — бөтенләй башка әсәр. Аның күләме дә Стәрледә чыкканга караганда икеләтә зур. Иҗтимагый җирлек тә киңрәк. Тормыш картиналары, конфликт, характерлар чын маһирлык белән бирелгән. Гөлбануның язмышы катлаулы, бөтенләй үзгә. Кыскасы, хөрмәтле автор безгә әдәби җәүһәр бүләк иткән.

Китапханә шүрлекләрен тикшерә торгач, моңа чаклы безгә мәгълүм булмаган бер башкорт шагыйре табылды. Ул үзе җитмеш яшәр тузан эчендә ятмаган, әлбәттә, «Кибетчеләр китабы» — «шагыйре башкорт Актүрә бине Җантүрә Агашев» дигән җыентыгы 1907 елда Троицкида төзелгән, Миасс шәһәрендә басылган. Тышындагы игъланны укыйбыз. Анда бу китапның «Сатыла торган урынлари Казанда — Камалетдинов, Чиләбедә — Һадиев, Оренбургта — «Кәримов-Хөсәенов», Уфада — Идрисов. Орскида — Исхаков, Петрапаулда — Сөләйманов, Троцкида — «Хезмәт» [1], Эстәрледә — «Къәләм»... дип күрсәтелә.

Димәк, «Каләм»нең китап сәүдәсе дә булган. Библиограф Фатыйма Кудоярова күрсәткән «Әсами көтеб» («Китап исемнәре» дигән реклама-брошюра) тышына шулай

[1] Бу «Хезмәт» дигәннәре дә бер ширкәт. Ул да китаплар нәшер иткән. Аның мөдире Фәйзелрахман Чиркасов булган.

язылган: «Уфа вәләяти Эстәрлетамак шәһәрендә имам Мөхәммәтгариф Рәмиев үә мөгаллим сабыйк (элекке укытучы — Й. Г.) Бәдретдин Гыйбадуллиннар тәэсис иткән «Каләм» көтепханәсенең Әсами көтеби. «Нур» матбагасы. 1910».

Эчтәлеге сатуда булган өч йөзләп китап исеменнән гыйбарәт. Исемлек алдыннан шундый мөрәҗәгать бирелгән: «Хөрмәтле әфәнделәр! Бу соң сәналәрдә милләтемезнең укуга һәвәсе нисбәтендә төрле китапларга ихтыяҗ күренә... Ысул җәдидә мәктәпләри күбәйди... Без, шул җәһәтләрни искә алуб, фәкать бер хезмәт миллиә касди илә (милләткә хезмәт итү ниәте белән — Й. Г.)... һәр төрле китап булындырмага карар кылдык... Һәм дә кара, кәгазь, каләм, госманли вә рус пиралари, язу такталариндан һәр төрлиси хазер улуб, арзан хакка сатылмактадур...»

Китапханәнең китап һәм язу-сызу кирәк-яраклары сату белән шөгыльләнүе бәлки кайберләргә сәер тоелыр. Әмма татар нәшриятлары «Умид», «Мәгариф», «Милләт» һ. б. да үзләренең китап магазинын — сәүдәсен шулай атаганнар: «Көтебхана» — китаплар йорты дигән сүз бит.

«Каләм»-«Нур»ның китаплары төрле кибет, магазиннарда да сатылган, үзенең дә ике махсус китап магазины ачылган. Бу — «Каләм»нең китаплар нәшер итү, бастырудан башка өченче төр эшчәнлеге.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә:

1906—1912 елларда «Каләм»нең утыз бишләп китап бастыруын беләалдык. Ләкин чын сан күбрәк булырга тиеш. Дөрес, ул китаплар югары сәнгать биеклегенә күтәрелә алмаганнар. Алар, күбесенчә, дидактик рухта, үгет-нәсихәттән торалар, укучыны мәгърифәткә, гадел, эшчән, риясыз, саф күңелле булырга өндиләр. Ул заманда Уфа, Казан нәшриятларында да мондый китаплар күп чыккан. «Каләм» дә дидактикадан башлаган. Бу — Стәрлетамактагы мәгърифәтчеләрнең балалык дәверен күрсәтеп тора.

Әмма Г. Ибраһимов әсәрен башка китаплар рәтенә куймыйбыз. Ул, кайбер гыйлләләре булса да, художестволы повесть. Без анда талант чаткыларын күрәбез. Ул әле дә «Каләм»не сәламләп, «Нур»ны нурлап тора.

Бәлки бу юлларны укучылар арасында «Нур», «Каләм», «Ашкадар»ның эшчәнлеге хакында хәбәрдар иптәшләр табылыр. Ил-халык диңгез генә түгел, океан бит ул. Бернәрсә дә анда эзсез югалмый. Моннан соң бәлки иске «Каләм» белән берәр яшь каләм кызыксыныр?

...«Стәрле» җыры белән башлаган идек, шуның белән үк бетерик тә:

> **Хуш, Стәрле кала, тау-манара!**
> **Без китәбез, килсен башкалар.**
> **Сагынганда берүк бик саргайтма,**
> **Чакырып ал, җаным Ашкадар!..**

**1969—1974.**

# ЕГЕТЛЕК ХАКЫНДА

Язучылар арасында берничә жанрда эшләүчеләр күп очрый. Драматург шигырь яки хикәя яза. Әдәбият галиме хикәя һәм пьесалар өстендә эшли. Кайбер каләм осталары шигырь дә, повесть һәм роман да, сәхнә әсәрләре дә иҗат итәләр. Ә менә каләмдәшләребездән берсе егерме елга якын фәкать бер генә жанрда эшли. Сүз Малик Хәмитов хакында бара. Ул — «коеп куйган» очеркчы, бары очерклар гына язучы.

Малик Хәмитов әдәбият мәйданына авыл темасына багышланган очерклары белән килеп керде. Бу бик табигый хәл иде. Чөнки ул авылда туып-үсә, сала җиренең табигатен, кешеләрен яхшы белә, аңа авыл кешеләренең характеры һәм гореф-гадәтләре, уй-фикерләре һәм теләк-омтылышлары таныш була. Авторның «Совхоз кешеләре», «Гүзәл җимешләр», «Активист» колхозында», «Эзләнү», «Ныклы ышаныч белән» кебек беренче очеркларында илленче еллар азагындагы колхоз тормышы сурәтләнә, авыл кешеләрен борчыган мәсьәләләр күтәрелә.

Еллар үтә тора, вакыт узу белән тормышыбызда күркәм үзгәрешләр барлыкка килә. КПСС Үзәк Комитетының 1965 елгы март Пленумыннан соң колхоз авылы текәүрләр яулый башлый. Иң оператив һәм сугышчан бер жанрда эшләүче кеше буларак, очеркчы каләмдәшебез дә заман белән бер аяктан барырга тырыша. Күпчелек очракларда шуңа ирешә дә. Нәтиҗәдә, 1959 елда дөньяга чыккан «Гүзәл җимешләр» җыентыгы янына «Ышану» һәм «Күтәрелештә» дигән яңа очерк китаплары өстәлә. Алардан тыш, Малик Хәмитов «Казан утлары» журналында һәм республика газеталарында дистәләгән очерклар бастыра.

Иҗади тәҗрибәсе арту, каләме шомару белән бергә, аның очеркларының тематик географиясе дә киңәя бара. Ул промышленность темасына караган очерклар яза, фән һәм техника кешеләре турында сүз әйтергә батырчылык итә. Автор үз очеркларының тематик диапазонын гына киңәйтеп калмый, катлаулырак мәсьәләләрне тирәннәнрәк күтәрергә дә өйрәнә.

Былтыр, фашистик Германияне җиңүнең утыз еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә, Татарстан китап нәшрияты аның «Егетлек» дип исемләнгән яңа җыентыгын бастырып чыгарды.

Җыентыкка дан орденнарының тулы кавалеры булган батырлар турындагы өч очерк тупланган.

Очеркларның төп персонажлары — Апас районының Чирмешән авыл Советы башкарма комитеты председателе Ислам Насыйбуллин («Солдат даны»), Алабуга дәүләт педагогия институтының өлкән укытучысы Рифкать Гайнуллин («Егет булып йөрер чаклар иде»), Чаллыдагы икенче автохуҗалыкның газ һәм электр белән эретеп ябыштыру остасы Зыятдин Арсланов («Кабат кайтты яшьлек КамАЗда») — халыкның йөз аклыгы булырдай ир-егетләр, батыр, тәвәккәл кешеләр. Аларның сугыш кырларында күрсәткән каһарманлыгы хакында күкрәкләрен тутырган орден һәм медальләре сөйли. Яу батырлары тыныч тормышта да алгы сызыкта калалар. Җиң сызганып эшлиләр, җәмәгать эшләрендә актив катнашалар, яшьләрне илсөярлек рухында тәрбияләргә булышалар.

Малик Хәмитов күз алдына җанлы образ бастыра, персонажларының эчке дөньясына үтеп керә, аларның ил азатлыгы хакына үз-үзләрен аямыйча көрәшүләрен сурәтли, егетләр күрсәткән батырлыкның чыганакларын ачып салырга тырыша. Автор әлеге чыганак-чишмәләрнең газиз Ватанга тирәнтен бирелгәнлектә булуын, социалистик җәмгыятьнең совет кешеләрендә сокландыгыч характер сызыклары тәрбияләвен зур ышандыру көче белән күрсәтеп бирә.

Өч очеркның да баш персонажы Бөек Ватан сугышын яшь егет булып каршылый. Аларның яшьлеге канлы сугыш, ут-ялкын эчендә чыныга. Алар үлем белән якага-яка

килгән сугыш кырында яшьлекләрен калдыралар. «...Яшьлек хыялларына, уен-көлкегә бирелеп һәм иң тәүге мәхәббәт хисләре белән исереп, егет булып йөрер чаклары иде бит». Мәгәр аларның берсе дә «моңа үкенми, киресенчә, горурлана гына. Яшьлек иртәсендә егет булып йөри алмасалар да, халыклар авыр сынау кичергәндә ватан каршында, туган җир каршында егетлек» күрсәтәләр.

Менә шушы фикер әсәрләрне бер циклга берләштерә, шушы фикер очеркларның буеннан-буена кызыл җеп булып сузыла.

Минем үземә әдәби эшләнеше ягыннан «Кабат кайтты яшьлек КамАЗда» дигән очерк аеруча нык ошады. Бу очеркта бер Зыятдин Арсланов кына түгел, аның хезмәттәше Виктор Зиновьев та, начальниклары Николай Федорович Янимов та гаять җанлы, тере итеп тасвирланган. Аларның сөйләү рәвешләре, йөрү-хәрәкәтләнү манералары, уй-фикер йөртү үзенчәлекләре бар. Бер сүз белән әйтсәк, очерк геройлары тормыштагыча булып күз алдына басалар. Зыятдинга кунакка килү күренеше, орденнар тагып карау эпизодлары осталарча язылган. Геройның сугыш истәлекләрен бәян итүе дә бик табигый башланып китә.

«...Орденнарны тагып кына карау да аларның икесендә дә үзенә күрә бер горурлык уятты.

— Бу орденнарның т-т-тарихын сөйләсәгез иде, — дип, Янимов карашын Зыятдинга төбәде.

— Анысы качмас, егетләр. Әйдәгез, утырышыйк».

Калган ике очеркта исә үткәннәргә кайту шактый таптанылган ысул белән, геройның искә төшерүләре аша бара. «Егет булып йөрер чаклар иде» дигән очеркта 18 яшьлек разведчик Рифкать Гайнуллинның сугыштагы маҗаралары мавыктыргыч итеп, бер тында укып чыгарлык итеп язылган. Әмма сугыш ветеранының бүгенгесе шактый тонык килеп чыккан. Бу урыннарда очерк газета мәкаләсенә тартым төс алган. Ашыкмаска, мәйдан кызганмаска, институт укытучысының мәшәкатьле дә, кызыклы да тормышын детальләбрәк күрсәтергә, бүгенге яшьләрдә батырлык тәрбияләвен бирергә, традицияләрнең дәвам итүенә басым ясарга кирәк иде. «Солдат даны» очеркы да өзек-төтегрәк килеп чыккан.

Күңелдә мәгълүм канәгатьсезлек тудырган тагын бер нәрсәне әйтми булмый. Ул да булса портретларның ярлылыгы: «Бөдрә чәчле, мөлаем матур чырайлы, тыйнак татар егете коммунист Ислам Насыйбуллин» (20 бит); «Зәңгәр күзле, әле малайлыгы да чыгып бетмәгән татар егете сержант Гайнуллин» (36 бит); «Беренче карашка кырыс чырайлы, үткен зәңгәр күзле, саргылт чәчләренә инде яртылаш бәс кунган бу илле яшьләрендәге кеше» (59 бит). Боларны чын әдәби портрет дип әйтүе бик читен.

Табигать күренешләрен язганда да Малик Хәмитов саранлык күрсәтә. Акланмаган саранлык. Хәлбуки, алар геройларның эчке дөньясын ачу өчен бик зарур, конкрет урынны чамалау өчен бик кирәк, эстетик ләззәт алу өчен дә нур өстенә нур булырлар иде. Сүз бит әдәби очерк, матур әдәбият әсәре турында бара. Әйтик, шыңгырдап торган нарат бүрәнәдән йорт җиткерделәр, ди. Ишеге уелган, тәрәзәсе куелган. Эчтә җылы да, якты да. Тик хуҗа моның белән генә канәгатьләнми. Ул тәрәзә йөзлекләрен, кәрнизләрне, капканы бизәкләргә дип оста чакыра, чөнки күңел дигәнең, ныклык, муллык өстенә, матурлык, нәфислек, бизәк тә тели. Сәнгать әсәрендә дә шуңа охшаш хәл ләбаса!

Тагын бер мәсьәлә. Малик Хәмитов очеркларына Бөек Ватан сугышы тарихыннан һәм генерал-майор Минзакир Әпсәләмов истәлекләреннән өзекләр кертә. Моңа аның тулы хакы бар. Ләкин шуны, ничектер, саграк, остарак эшләсен иде дигән теләк туа. Югыйсә, автор менә ничек ди бит: «Бу вакытта фронттагы хәлләр түбәндәгечә иде». Шуннан цитата китә. Бүтән чыганакларны үз әсәренә керткәндә такт сакламау да тешкә тигәндәй була.

Очеркларның теле һич ямanлардык түгел. Малик Хәмитов культуралы әдәби телдә яза, халык сөйләме аһәңен сизеп яза. Персонажлар телен хәл-хәленчә индивидуальләштерергә тырыша. Шулай да урыны-урыны белән эч пошыргыч төчелекләр яки копкоры җөмләләр очрый, кабатлаулар күренгәләп китә.

«...Ләкин... ләкин немец-фашист илбасарлар аның кизләү суы кебек саф хыялларын, кояштай якты өметләрен чәлпәрәмә китерде...» (9 бит). Бизәк хакына бизәк бит!

«Дулкын-дулкын булып җирдән су парлары күтәрелә (17 бит). Физика дәреслегендәгечә коры итмичә, «җирдән бу күтәрелә» дип тә булыр иде төсле.

Малик Хәмитов «пәйда булды»ны бик ярата: «Алда кечкенә бер хутор пәйда булды» (43 бит); «...юлда тагын бер машина пәйда булды» (45 бит); «Озак та үтмәде,

алар югалган урында тагын ике солдат пәйда булды» (81 бит) һ. б. Мондый җөмләләр күпкә киткәч, укып барган кешедә ризасызлык «пәйда булуы» да бик ихтимал бит.

Инде әйтергә теләгәннәрне йомгаклап куярга вакыт. Кайбер бертөрлелекләргә, кабатлауларга, аерым чатаклыкларга карамастан, «Егетлек» җыентыгы, тулаем алганда, Малик Хәмитовның алга бер адымы. Кирәкле, файдалы китап чыгарган. Әмма газета-журнал сәхифәләрендә аның байтак очерклары сибелеп ята бирә әле. Аларның иң әйбәт дигәннәрен яңа китапка туплап, укучыга тәкъдим итәргә кирәк. Әдәби кыйммәте булган язмалар көнлек матбугат кысасында калып, онытылмаска тиеш.

БАРЛАС КАМАЛОВ

# ТУГАН ЯККА МӘХӘББӘТ БЕЛӘН

Мөнир Мазунов — җыр өлкәсендә күп һәм актив эшләүче шагыйрьләрнең берсе. Узган ел Татарстан китап нәшрияты, «Туган як» дигән исем белән, аның өченче җыр китабын бастырып чыгарды. Китапка төрле елларда язылган һәм төрле композиторлар тарафыннан музыкага салынган утыздан артык җыр тупланган.

Җыр — ифрат авыр һәм үзенчәлекле бер жанр. Күп, бик күп таләпләр куела җыр алдына. Ул тирән эчтәлекле, шигъри матур яңгырашлы һәм образлы булырга, тигез, дөрес ритмик үлчәүле, югары поэтик сурәтле булырга тиеш. Әлбәттә, җырның сүзләренә ярашлы, шул сүзләрнең эчтәлеген ача, яңгырашын баета торган музыка язылырга тиеш. Шигъри сүз белән музыка бер-берсен тулыландыра, бер бөтен, бер җан, бер тән: булып яңгырый алганда гына чын җыр туа.

Яхшы җыр кеше күңелендә сафлык уятырга сәләтле рухи көч булып саклана. Андый җырлар яза алу — зур шатлык һәм бәхет. Китабына язган кереш сүзендә Мөнир Мазунов үзенең дә шундый шатлыклы, бәхетле минутлар кичерүе турында әйтә. Авторның ул сүзләренә ышанырга була, чөнки аның халык күңелен кузгатырлык яхшы җырлары бар.

Кеше күңеле төрле халәттә төрлечә була. Шуңа яраклы рәвештә җырлар да күп төрле. Тантаналы, пафослы, публицистик җырлар белән беррәттән, мәхәббәт, дуслык, җырлары да, шулай ук шаян, чәнечкеле җырлар, такмаклар да иҗат ителә. М. Мазунов җырлары да төрле характерда, төрле төсмердә, төрле кичерешләрне чагылдыра. Аның җырларында кеше тормышының төрле халәтләре тасвирлана. Эчтәлекләре ягыннан да төрле алар. Туган илгә, Ватанга мәхәббәт, тынычлыкны яклау, хезмәтне, хезмәт кешесен олылау турында, шулай ук бәхетле яшьлек, мәхәббәт, дуслык, тугрылык турында яза автор.

Дөрес, «Туган як» китабына кергән җырларның барысын да бер үк дәрәҗәдә сәнгатьчә эшләнгән, чын мәгънәсендә югары шигърият әсәрләре дип бәяләп булмый. Китапта «Таң йолдызым», «Бер тутырып карыйсың да», «Кыз бала һәм каз бәбкәсе», «Оча шарлар» кебек, эчтәлек ягыннан саерак, эстетик тәэсир итү көче зәгыйфьрәк, образлы сурәтләү чараларына ярлырак җырлар да урын алган. Шагыйрьнең дуэтлары, әйлән-бәйлән уеннарына язган җырлары да бик үк уңышлы түгел. «Таң йолдызым» җырының, мәсәлән, балкып торган шигъри табышлары, уңышлы сурәтләре юк. «Бер тутырып карыйсың да» җырында: «Мәхәббәтем кереп чумган», «Оча шарлар да», «Шул шарларга атланып менсәң иде һавага» кебек ямьсез юллар очрый. «Күзгә мәхәббәт кереп чуму» тәгъбирен күңел һич кабул итә алмый. «Шарга атланып һавага менүне» дә күз алдына китереп булмый.

Китапта кабатлаулар шактый. Мәсәлән, ике лирик җырда автор кеше күзен коега тиңли. «Хәлимә» җырында бу «кое» чагыштырмача уңышлы алынган. «Серләр коесы микән», дип фикерне киңәйтеп, автор бу очракта күзләрнең тирәнлеген, серлелеген куәтләү чарасы табарга омтыла. Ә менә «Бер тутырып карыйсың да» шигырендә ике күзне кое дип раслау уңышлы түгел, болай әйтү образлы сурәт тудыра алмый. Мондый уңышсыз сурәтләр һәм образлар, сыек буяулы тасвирлаулар, фикер тирәнлеге җитеп бетмәгән строфалар башка әсәрләрдә дә очрый.

Әмма ни генә булмасын, китап нигездә идея-эчтәлек ягыннан тотнаклы, әһәмиятле фикерләргә ия булган әсәрләре белән уңай тәэсир калдыра. Җыентыкның йөзен вакыт сынавын үткән әйбәт җырлар билгели. Ан-

дый җырлар китапта шактый: «Туган як», «Гөлкәем», «Бәйрәмнәр» (М. Мозаффаров), «Гасырлар кешесе — Ленинга», «Җырла, сеңелем», «Укытучыма», «Игенче җыры», «Әйдәгез, җырлыйбыз» (Б. Мулюков), «Яшьләр җыры» (Ә. Бакиров), «Канатлы яшьлек» (А. Ключарев), «Югалтмагыз дуслыкны» (Җ. Фәйзи), «Бишек җыры» (И. Якупов музыкасы) һ. б. Бу җырларның дүртесе төрле елларда үткәрелгән республика конкурсларында бүләк алган. Шуларның «Гасырлар кешесе — Ленинга» дигәне — даһи юлбашчыбыз образын бөтен бөеклеге белән ачарга омтылган киң масштаблы җыр. Хор һәм оркестр бу җырны революцион бәйрәмнәрдә, тантаналы концертларда еш башкара. Гади, тыйнак сүзләр белән язылган бу җыр, музыка белән матур ярашып, бер бөтен аһәң булып, В. И. Ленинга багышланган гимн шикелле яңгырый. «Туган як» җыры да үзенә бер ягымлы моң белән сугарылган. Бу җырны шагыйрь һәм композитор икесе дә туган илгә, туган якка зур мәхәббәт хисләре, ярсулы кичерешләр уята торган эпик планда иҗат иткәннәр. Фашизмга каршы барган авыр сугышларда катнашып, утны-суны кичкән шагыйрь күп юллар узган. Чит-ят илләрнең дә табигатен күргән, салкын чишмәләренең суын эчкән, чәчәк-гөлләренең хуш исен иснәгән, ләкин күңеле аның үзенең туган иленә ярсулы сагыш белән ашкынган. Туган якка, туган туфракка булган олы мәхәббәтен автор саран, ләкин күңелгә үтеп керерлек чаралар белән ачкан. Бу тиз генә онытыла торган җыр түгел, озын гомерле, матур гомерле җыр.

Кырыгынчы еллар ахырында республика конкурсында бүләк алган «Яшьлек җыры» берничә дистә ел буе хор коллективлары тарафыннан башкарылып килә. Бу җыр күңелгә яңа дәрт өсти, якты уйлар уйлата. Әнвәр Бакировның күтәренке рухлы, шат кичерешләргә бай, матур ритмлы музыкасы белән бу җыр комсомол темаларына багышланган башка әсәрләр арасында нык аерылып тора.

М. Мазунов җырларының күбесе—патриотик тойгылар уятырга сәләтле, аның иң яхшы җырлары эпик характерда. Авторның җыр өлкәсендәге хезмәтен шушы жанрда язылган җырлары билгели дә. Әлбәттә, мондый характердагы җырларыбызга хас уртак кимчелекләр — риторика, шомарып, шаблонга әйләнгән фразалар М. Мазунов җырларында да очрый. «Мул уңыш яулап алабыз...» «Дәртләнеп алга атлыйбыз...», «Тату семьяда яшибез...» («Тынычлык-дуслык иле» җыры), «Партия ялкыны сүрелми...» («Илһамчыбыз-юлбашчыбыз — партия» җыры) кебек тапталган юллар китапта шактый.

Гражданлык мотивлары белән сугарылган җырларның уңыш казануында, әлбәттә, композиторларның өлеше зур. Кайбер җырларыбыз безнең, чынлап та, музыкасы аркасында гына яши дә. М. Мазуновның бу жанрдагы уңышлы җырларының күбесе М. Мозаффаров, А. Ключарев, Ә. Бакиров кебек күренекле композиторлар белән күп еллык иҗат дуслыгы нәтиҗәсендә туган. Шагыйрь Б. Мулюков белән аерата күп эшли. Һәм, әйтергә кирәк, эпик пландагы җырлар иҗат итүдә алар бер-берсенә ярдәм итешәләр, бергәләп шактый уңышларга ирешәләр. М. Мазуновның Б. Мулюков белән иҗади дуслыкта туган җырларыннан «Җырла, сеңелем» әсәренә игътибар итик. Әсәрдә тигез ритмлы, салмак агылышлы матур музыкага кызыклы фикер салынган: «Җырың белән кешеләрне күркәм эшкә өндә, шатландыр, уйландыр, моңландыр... җансыз яткан ташлар гына уйланмыйлар...» Шулай ди шагыйрь. Бу кечкенә китап җыр сөючеләрне әнә шулай шатландырыр да, моңландырыр да, һәрхәлдә, битараф калдырмас дип ышанасы килә.

Китапта «Әйдәгез җырлыйбыз» (Б. Мулюков музыкасы), «Пионерлар маршы» (Р. Яхин музыкасы), әзербәйҗан теленнән бик матур тәрҗемә ителгән «Чебиләрем» кебек, мәктәп яшендәге балалар, пионерлар өчен язылган уңышлы җырлар да бар. Дөрес, боларының да кайберләре шигъри эшләнеш ягыннан поэзиянең югары таләпләренә җавап бирерлек дәрәҗәдә түгел. Шулай да ул җырлар башкару өчен уңайлы, хәтердә тиз калучан. Җыентыкта балалар җырларының өлкәннәр өчен язылган җырлар белән бергә бирелүенә дә каршы килеп булмый. Өлкәннәр өчен язылган җырларның күпчелеге патриотик рухлы әсәрләр, аларны өлкән яшьтәге балалар да башкарыр дип уйларга кирәк.

«Туган як» китабы җыр сөючеләргә кирәкле, кызыклы җыентык булыр дип ышаныйк. Шагыйрь М. Мазунов киләчәктә югарыда әйтелгән кимчелекләрне кабатламасын, җырларының шигъри эшләнешенә ныграк игътибар итсен, җырга хас образлар табу өстендә тагын да ныграк тырышып эшләсен иде.

**ГӨЛШАТ ЗӘЙНАШЕВА**



# СЕЗ ӘЛЕ ДӘ УҢ ФЛАНГТА

Без малай вакытларда — авыл мәктәбендә укып йөргәндә — «Сафа балалары» һәм «Безнең рапорт» дигән пьесаларны бик яратып мәктәп сәхнәсендә еш куйдык. Халык гөр килеп кул чаба иде. Димәк, тамашачы без уйнаган пьесаларны ошаткан. Балалар өчен язылган бу әсәрләрнең авторы Госман Бакиров иде. Ләкин без язучының үзен бер мәртәбә дә күрмәдек. Ул елларда тере язучыны күрү бик сирәк бәхет иде.

Еллар узды. Мин Кайбыч районы, Мөрәле мәктәбендә директор булып эшләгәндә, бик каты буранлы көннәрнең берсендә авылга райком хезмәткәре белән бергә бер язучы килде. Ул кап-кара чәчле, таза гына гәүдәле, ягымлы сөйләшә торган кеше — язучы Госман Бакиров булып чыкты. Госман ага мәктәптә балалар белән очрашты, үзенең хикәяләрен укыды. Балалар аның хикәяләрен бик яраттылар, мәктәп залын яңгыратып кул чаптылар. Очрашудан соң язучыга рәхмәтләр әйттек. Соңыннан мин аңа: «Сезнең пьесаларны без бала вакытта ук сәхнәгә куя идек», — дигәч, Госман Бакиров елмаеп куйды. Ул шатланып: «Кайсы гына районга барсам да, очрашу вакытында ата-аналар, укытучылар, партия, совет оешмалары хезмәткәрләре яшь вакытларында минем пьесаларда төп геройлар булып уйнауларын әйтәләр. Бу — язучы өчен бик куанычлы хәл!» — диде.

Бу вакытта язучыга алты дистә дә тулмаган иде әле. Хәзер аңа сиксән яшь! Бер уйлаганда моңа бик үк ышанасы да килми. Чөнки Госман ага әле яшьләрчә җиң сызганып эшләп йөри: яңадан-яңа әсәрләр иҗат итә, укучылар белән очраша, җәмәгать эшләренә актив катнаша.

Татар әдәбиятының олы буын язучысы Госман ага Бакировның тормыш һәм иҗат юлы кызыклы, бик күпләргә үрнәк булырлык.

Ул 1896 елның 12 мартында хәзерге Арча районының Югары Курса авылында туа. Дөньяга ир бала килгәч, әтисе Фәтхулла абзый куанып бетә алмый.

— Ир балага җир бирелә. Моннан соң без дә туйганчы ипи ашый башларбыз!..

Тик бу куаныч озакка бармый, җирдән җыеп алынган уңышның яртысыннан артыгын төрле налоглар түләү өчен сатарга туры килә. Семья кара ипигә дә туймый...

Госман башта мәдрәсәдә укый, аннары укытучы була. 1915 елда аны солдатка алып, фронтка — ут эченә озаталар. Сугыштан кайткач, яңадан укытучылык эшен дәвам иттерә. 1923 елны Г. Бакиров Казанга килә. Җир төзү техникумына укырга керә, бер үк вакытта балалар йортында уку-укыту бүлеге мөдире булып эшли. Менә шул елларда ул әдәбият белән кызыксына башлый, беренче хикәяләрен яза. Шуларның иң характерлысы «Иске мәдрәсәдә бер кич» дип атала. 1928—1930 елларда исә ул Казан дәүләт педагогия институтында укый.

1929—1937 елларда Г. Бакиров журналист буларак зур тырышлык белән эшли:

«Мәгариф» журналының җаваплы секретаре була, бер үк вакытта Татарстан китап нәшриятында дәреслекләр һәм методик китаплар редакцияли, аннан соң мөдир булә. Ике шундый җаваплы эш алып баруына карамастан, әдәби иҗат белән дә шөгыльләнә. Шул елларда «Беренче җиңү» дигән пьесасын дөньяга чыгара. «Яшәсен яшьләр», «Безнең рапорт», «Сафа балалары» дигән сәхнә әсәрләре иҗат итә. 1930 елда аның «Урак өсте» дигән хикәяләр җыентыгы басылып чыга.

Госман Бакиров мәктәп-педагогия темасына дистәләрчә очерк, мәкаләләр язды. Шулай ук ул күп кенә юмористик хикәяләр авторы да.

Бөек Ватан сугышы барганда, 1942 елны Госман Бакиров, олы яшьтә булуына карамастан, үзе теләп фронтка китә. Ул алгы сызыкта орудие командиры булып авыр сугышларда катнаша. Соңга таба «Ватан намусы өчен» фронт газетасында хәрби корреспондент була, хикәяләр, очерклар һәм мәкаләләр яза. Аның сугыш батырлары турындагы хикәяләрен һәм мәкаләләрен укып рухланган сугышчылар дошманга каршы дәһшәтле атакаларга күтәреләләр.

Госман Бакиров, подразделение парторгы, полк партия оешмасында бюро члены буларак, алгы сызыкта оештыру һәм аңлату эшләре алып бара, сугышчыларны дошманга каршы куркусыз көрәшергә өнди, үзе дә атакаларга керә. Сугыш кырында күрсәткән батырлыклары һәм хезмәтләре өчен ул Кызыл Йолдыз, Ватан сугышы орденнары һәм медальләр белән бүләкләнә.

Утлы елларда — окоп, блиндаж һәм землянкаларда Г. Бакиров әдәби әсәрләр дә иҗат итте. Фронт газеталарында аның «Партия члены», «Казан егете», «Биш баһадир», «Каенсарга кайту» һәм башка хикәяләре, очерклары басылганы билгеле.

Гитлер Германиясен тар-мар итеп, фашистларны үз оясында дөмектергәч, зур җиңү яулап илгә кайтучы сугышчылар арасында Госман Бакиров та бар иде. Ул — озак еллар кырыс солдат тормышын татыган олы сугышчы — Казанга кайту белән яңадан матбугат эшенә чумды. Фронтта язган «Сугышчы көндәлеге» китабын бик нык тәзәтеп, редакцияләп чыгарды һәм «Партизан малай» исемле повестен тәгәлләде. «Сиртмәле кое» дигән хикәяләр җыентыгын бастырды.

Сугыштан соң ул яңадан Татарстан китап нәшриятында укыту-педагогик әдәбият редакциясенең мөдире булып эшләде һәм мәктәпләр өчен дәреслекләр, методик кулланмалар бастырып чыгарды. Шул ук елларда аның «Башваткычлар», «Партизан малай», «Мыеклы бикә», «Классташлар», «Кадерле бүләк», «Минем укытучым», «Утлы тегермән» һ. б. яңа китаплары да чыкты. Кайбер әсәрләре рус һәм чуваш телләренә дә тәрҗемә ителде.

Г. Бакиров балалар психологиясен яхшы белә. Аның әсәрләре сәнгатьчә, балалар яратып укырлык итеп язылалар. Кыска җөмләләрдә ул күп кенә мәгънә бирергә тырыша. Тасвирлау, сурәтләү чаралары белән дә Г. Бакиров оста эш итә.

Язучының «Пьесалар» җыентыгы — мәктәп балаларының иң яраткан китабы. Укучылар аны мәктәп сәхнәләрендә куялар, мондый әйбәт пьесалар язганы өчен язучы Госман абыйларына рәхмәт әйтеп хатлар язалар.

Хатлар аңа бик күп килә. Сугыш елларында ул Украинаның Тернополь шәһәрен азат итүдә катнашкан. Бу турыда Г. Бакировның истәлек мәкаләсе Тернопольдә чыга торган «Вiльне життя» газетасында украин телендә басылгач, мәктәп балалары үзләренең туган шәһәрен фашистлардан азат итүдә катнашкан Госман абыйларын кунакка чакырып хат язалар, истәлек итеп бүләкләр җибәрәләр. Шунсы кызык: Госман Бакиров бу шәһәрне ике тапкыр — 1916 елны Австрия-Венгрия гаскәрләреннән, 1944 елны немец фашистларыннан азат итүдә катнаша. Шуның өчен шәһәр хезмәт ияләре аны Бөек Җиңүнең утыз еллыгына үзләренә кунакка чакырдылар.

1927 елдан КПСС члены Госман ага Бакиров — ике сугыш ветераны, тынгысыз иҗат кешесе. Ул күп кенә җәмәгать эшләренә катнаша, мәктәпләрдә, культура йортларында, клубларда очрашулар үткәрә, үзенең яңа язган әсәрләрен укый, эзләнә, иҗат итә. 70 яше тулу уңае белән аңа Татарстанның атказанган культура работнигы дигән мактаулы исем бирелде. СССР Культура министрлыгы язучыны «Культура работнигы отличнигы» дигән значок белән бүләкләде.

Сиксән яше тулу көнендә без олы әдипкә, сугыш һәм хезмәт ветеранына, тынгысыз дустыбызга тагын да зур уңышлар телибез.

САМАТ ШАКИР.

# ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

**Кояш Тимбикова**

## ДАРУЛЫ СӨТ

хикәя



Вафирә сөйгән егете белән очрашырга барырга җыена. Күзге каршына утырган да бизәнә. Күңел дигәне бер дә юкка гына бу кадәр ашкынмый торгандыр, кыз гомеренең соңгы сәгате суккандыр, мөгаен. Фатир хуҗасы: «Олыгаям дип бер дә кайгырма, балам! — дип, сабыр итәргә кушып тора торуын. — Кияүгә чыгуның бер ние дә юк аның, — ди. Күрмәгәннең генә күрәсе килә. Бер барып капсаң, качып котылыр җай таба алмый аптырыйсың әле аны! Ашыкма! Өлешеңә тигән «Насыйбулла» беркая да китми ул!..»

Җитте! Вафирә көтмәде түгел, шактый көтте инде. Тагын шул кадәр яшәсәң дә, чама чамадан узмас. Әлеге егет белән ул алдан ук, язмышны шуның кулына тапшырырга кирәк дип, олыдан кубып йөри башлады. Шулай да бераз сынаштырып карамый булмый. Гомерлек яр итеп сайлаган кешең күңел теләгәнгә туры киләме? Теләк дигәч тә, Вафирә әллә ниләр өмет итми ул. Акылы булсын да көн күрердәй һөнәр белсен. Кирәк чакта, усалланып та күрсәтсен. Ир-ат халкы юк кына эшне дә гайрәтләнеп тамак кырудан башлап җибәрә бит ул. «Ирлек» дип атала торган зурлык шуның ише вак-төяктән җыела да инде. Булсын, Вафирәгә дигәне дә гайрәтле булсын! Җаен табып, назлый-иркәли дә белсен, чамалап кына матур сүзләр дә сөйләсен! Менә шул. Вафирә аңа гомерме биш ел буе түкмичәчми саклап килгән сафлыгын-инсафлыгын баш-аягы белән тапшырырга әзер тора икән, егетнең үзенә мондый гына таләпләр куюбер дә күп түгел инде.

Кыз, күзен дә алмый, көзгедән үзен күзәтә. Кара, бөтенләй үк төшеп калганнардан түгел икән бит! Аксылт сары чәче дә, почык борыны да, яшькелт зур күзләре дә ап-алсу, мөп-мөлаем йөзенә килешеп кенә тора. Хәер, ул хәзер үзе дә кичен клубтан кайтканда авыл егетләреннән качып йөрүче авыл кызы түгел шул инде. Аның сурәте: «Үземнекен иттемме? Җимердемме киртәләрегезне?» дигәндәй, тегү фабрикасының Мактау тактасыннан бөтен дөньясына елмаеп утыра. Елмайса да урынында. Русчасы да такы-токы гына бул-

ган авыл кызына шәһәргә килеп урнашулар уенмыни? Фатир табу үзе генә ни тора?! Ә Вафирә шул четерекле мәсьәләне майлы табадан коймак алгандай җип-җиңел хәл итте дә куйды. Хәзер ул шәһәр үзәгендәге газлы, сулы, ванналы өйдә бер тиен түләмичә яшәп ята. Читкә китеп өйләнгән иреннән алимент алып, юк сырхавын бар итеп, үлмәсәм генә ярар иде дип сукранып яшәүче ялкау бер хатын, өен каратып торыр өчен, Вафирәне үз янына чакырды. Шәһәр өенең ниен карыйсың инде аның? Идән юуларын, келәм кагуларын кертеп исәпләсәң дә, Вафирәгә җыенысы бер сәгатьлек эш бит ул! Дөрес, хуҗа хатын бик вак сүзле кеше. Аның каравы, бик тәмле телле үзе. «Кызым» гына дип тә әйтми, «балам» яки «бәбкәм» дип эндәшә.

— Ба-ла-ам! Кая китеп бардың әле?

Вафирә, көзге каршыннан сикереп торып, йокы бүлмәсенә атылып керде, түшәк-ястыкка күмелеп яткан симез хатынның каршына килеп басты. Кызның йөзе ак: бүгенге көн мәшәкатьләренең хәстәрен ул алдан ук күреп куйган иде. Очрашуга үз вакытында чыгып китәрлек булсын дип чамалады.

Кыз ягыннан бөркелгән хуш исне сизеп алып, хуҗа:

— Һу-у-у! — дип сузды. — Кая җыендың болай, бәбкәм? Исле-майлар сөртенгәнсең түгелме?

— Ә-э... Киногa барыйм дигән идем, апа. Эштән культпоход оештырганнар иде. — Вафирә үз сүзләренә үзе гаҗәпләнде: бу кадәр килештереп ялганларга сүзләре каян табыла?! Менә нишләтә бит ул егет заты: ерактан торып та ялганларга өйрәтә!

Хуҗа хатын чыннан да аны-моны сизмәде, Вафирә сүзен ялгап алып китте:

— Ә-әй, ул кино дигәннәренең хәзер бер яме дә калмаган. Беркөннәре, күрше Мөсәббиха кыстагач, мин дә «Чаткы»га барган идем. «Таһир-Зөһрә»не күрсәтәләр дигәч, нәфесемне тыя алмадым. Без яшь чакта театрын куяларые аның. Җылый-җылый хәлләр бетәдер ие. Мәйтәм, барыйм әле, тагын бер җылап, эчләремне бушатып кайтыйм әле! Бардым. Ник барганыма әле дә үкенеп ятам. Юк икән, беткән икән Зөһрәнең рәте. Бер чибәрлеге дә калмаган. Йөзе тонык, тавышы зәгыйфь, гел ишетелми...

Вафирә хуҗасына елмаеп карап торды.

— Әле ник чакырган идең соң, апа?

— Ә-ә, юк, балам, болай гына, бар, бар, юлыңда була күр! Мин болай гына! Киткәнче, бу бүлмәнең идәнен юеш чүпрәк белән сөртеп алырсың әле, яме? Чәй куеп, берәр таба коймак чыжлатырсың аннары, менә бу батист яулыгымны чайкап куярсың: бераз керләнеп китте... Ефәк яулыгым бар да, яратмыйм, баштан шуа, батист әйбәт!..

Вафирә сәгатенә күз ташлады. Чәй кайнап утыра, йомыркалы камырдан коймак күпертеп алу — биш-ун минутлык эш, идәнне...

— Апа, идәннәрне иртән, эшкә киткәнче үк юган идем бит!

— Тагын да бер кат сөртеп ал инде, балам, авырсынма, юеш һаваны яратам, сулышка рәхәт була.

Вафирә җиңнәрен сызганды. Ничек тә өлгерергә кирәк. Салихны көттерергә ярамый. Ул да — эш кешесе. Сеңелесе Гандәлиф әйтә, безнең абый — Казанда бер уңган ди. Барына да өлгерә икән ул үзе. Хәтта сеңелесен төнге сменадан каршыларга да вакыт таба. Соң! Аларның танышлыклары да шуннан башланды инде. Хәзер менә сеңелесе ялда чакта да егет фабрика ишеген каравыллый, Вафирәне көтә. Смена азагына таба Вафирә үзе дә сабырсызлана башлый. Тизрәк урамга чыгасы, егетнең күзләрен күрәсе килә. Кызык: шул күз-

ләргә караса, Вафирә әллә кая, кайнар чоңгылга төшеп киткән кебек була. Дөньяда алар икәү генә торып калган төсле. Рәхәт.

— Ба-а-ла-м! — Бу юлы хуҗа хатынның тавышы аш-су бүлмәсеннән ишетелде. — Коймагың бик тәмле булган, балам, рәхмәт яусын! Бәхетле бул! Китәсеңме инде?

— Барырга кирәк шул, апам, кешедән аерылу килешмәс. — Вафирә соңгы тапкыр көзгегә күз салып алды. — Үзең дә шулай өйрәтәсең бит!

— Бар, бәбкәм, бар! Менә бу табынны гына җыеп ал да — йөгер! Мин, аякларымны җылы суга тыгып, бераз утырырмын да ятармын инде. Су кертеп куярга онытма әле! Бик кайнар итмә, җылымса гына булсын! Бераз ылыс оны сибеп җибәрерсең!

Хатын сөйли торды, кыз кушылган эшләрне үти барды. Ниһаять, Вафирә ишек катында туфли сайлый: күркәмрәген, килешлерәген, озак йөрергә җайлырагын кияргә тели.

— Бәб-кә-әм! — дип, хуҗа хатын тагын аваз салды.

— Ә-ә-әү, апа-җаным!

— Аягымны суга тыкканыем инде, авырсынма, даруымны гына кертеп бирче, зинһар! Сөтен җылыт, бераз сары май өстә, дүрт тамчы йуды тамыз.

Сабыр савыты тәмам тулган булса да, Вафирә сер бирмәде. Эчтән генә сукранды. «Бетмәде шул дарулары! Элек эчә торганнары да бихисап иде бит инде. Тагын яңаны уйлап тапкан: сөткә йод эремәсе тамызып эчә. Кан тамырына утырган ташны эретә, имеш! Башта бер кашык сөткә — бер, икенче көнне — ике, өченче көнне өч тамчы тамызып эчәләр, ди. Ун көн шулай дәвалангач, унберенче көнне киметә башлыйлар, бер кашык сөткә — тугыз, уникенче көнне — сигез, унөченче көнне — җиде... Уф!»

Болай да тавык чүпләп бетерә алмаслык вак-төяк йомышлардан башы әйләнеп беткән Вафирәгә шул гына җитмәгән иде тагы!

— Мә, апа-җаным, эчеп җибәр! — Вафирә яңа дару өчен билгеләнгән, сода белән ышкып-ышкып юсаң да агармый торган, саргаеп беткән таш касәне күтәреп бәрүдән көчкә тыелып калды. — Шифасы тисен!

— Рәхмәт яусын, балам, миңа күрсәткән изгелекләреңне ходай бише белән кайтарсын! Сабыр ит әле, аякларымны сыйпаштырыйм әле, торып тор!

Вафирә икенче кулы белән чөйдәге кофтасына үрелде. «Кичен салкынча була. Бакчада утырырга туры килсә, туңдырыр»...

— Бә-әбкәм!

— Нәрсә, апа?

— Карале, син моңа йудыны күбрәк җибәргәнсең, ахры, исе борынны яра, һу-у-у! Артыгы ярамый, ди, бит аның, эчне яндыра, ди, үтерә, ди!

— Дүртне тамыздым, апа, дүрт тамчы! — Вафирәнең озын-озак сөйләшеп торырлык чамасы юк иде. Ул, кухнядан саф сөт алып кереп, түшәккә яткан хатын янына килде. — Күңелеңдә шик калмасын, апа-җаным, — Шикләнеп эчкән даруның бер файдасы да юк аның. Менә карап тор: бер, ике, өч, дүрт! Дүрт тамчы, апа-җаным, мә, эч, терелергә язсын!..

Очрашу сәгате тулып узган иде инде. Тик сабыр егет бер кая да китмәгән, көткән, ачуланырга уйлап та карамаган. Кыз:

— Зинһар, кичерә күрегез! — дип кенә әйтә алды аңа. Башкасын сөйләп тормады. Бөтен нәсел-нәсәбе гомер-гомердән шәһәрдә яшәгән, Казан тәрбиясендә олыгайган инженер кеше синең бу хәлеңне аңлыймы соң? Озын бармаклы нәфис кулын селтәр дә:

«Карчыклар алар — узган гасыр, узган гасыр, — тузган гасыр», дияр. Үзе бит ул — замананың асыл заты! Вафирә, горурланып, егетнең шоп-шома итеп кырылган битенә карады. Карандаш белән сызып тигезләгәндәй калдырылган чигә чәчләренә, кершәндәй ак якасына, зур төенле галстугына күз йөгертеп алды. Синең идән юу хакына тапкан фатирларың, йодлы сөт эчеп ятучы карчыгың — барысы да чүп бит моның каршында, чүп! Илаһи зат, матурлыкның кеше сурәтендәге гәүдәләнеше бит бу! Сүзләре генә дә ни тора! Вафирә бүген аңардан гомер буе күңел түрендә сакланырга тиешле сихри сүзне ишетергә килде. Шул сүз барын да хәл итәчәк.

Алар бакчага керделәр. Егет кыз беләгенә сак кына кагылды. Тотар өчен түгел, болай гына, барыр юлга бер юнәлеш бирер өчен, кайсы урындык янында тукталырга кирәген аңлату өчен генә орынды ул. Утырдылар. Көндәлек хәлләр турында сөйләшкән булдылар. Тик икесе дә моның олы сүзгә кечкенә бер кереш икәнен сизә иде. Бер-береңне туган итеп беркетердәй сүз — алда. Менә Салих, сулышын ук башкача алып:

— Вафирә! — диде.

Кыз тоташ ут булып яна башлады, оялып, башын аска иде. Ул хәзер иң кадерле сүзне ишетәчәк. Башка бер кызга да әйтелмәгән, берәүгә дә болай бәхетле итә алмаган өр-яңа сүз яңгырачак хәзер.

— Вафирә! Син үзеңнең кем икәнеңне беләсеңме? Минем өчен кем булуыңны аңлыйсыңмы?..

Кыз аны-моны аңларлык хәлдә түгел иде, әлбәттә. Егет Вафирәгә сыенды, йөзен кызның күперенке чәчләренә тигезде дә:

— Йодалы сөтем минем! — дип пышылдады. — Врачлар миңа көн дә йод эремәсе тамызган сөт эчәргә кушалар иде. Сине очратканнан бирле мин шундый сәламәт, шундый нык — бернинди даруларның да кирәге юк. Йодылы сөтем минем!

Кыз өстенә гүя бозлы дәрья капланды. Ул бөрешеп, куырылып калды. Нәрсә инде бу? Сөтне йодысыз-нисез, саф килеш кенә эчә торган берәр кеше бармы соң бу Казан каласында?!.

Бугазына елата торган төер җыелуын тоеп, Вафирә урыныннан кузгалды. Соңгы кабат күреп калу өчен, кабынмас борын сүнеп баручы йолдызына борылды. Салих исә сүзләренең кызны хәсрәткә салуы турында башына да китерми. Туп-туры Вафирәсенә караган, күзләре мөлдерәмә, төпсез чоңгыл.

Кыз тетрәнеп китте. Зиһене чуалды, аның бөтен барлыгын серле чоңгыл ләззәте биләп алды. Бу рәхәтлек эчендә сүзләр дә, карчык-корчыклар да, дарулы сөтләр дә бик кечкенә нәрсә иде. «Исең киткән икән, сөткә йод тамызып эчә, имеш! Эчсен!..» Кыз сискәнеп куйды. Борылып, егетнең каршына ук иелде, куллары үзеннән-үзе Салихның иңбашына үрелде.

— Карале, — диде Вафирә. — Син ул йодны ничә тамчы тамызырга кирәген беләсеңме соң? Күпкә китсә, ярамый бит ул, яндыра!?.

*
* *

...Хәзер хуҗа хатын куша торган мең йомышның берсен Вафирә аеруча теләп, яратып башкара. Ялкау хатын вакыт-вакыт үзе дә гаҗәпләнеп карап тора. «Йудылы сөтемне бир әле, балам!» — дисәң, кыз күбәләккә әйләнә, даруны күз ачып йомганчы ясап китерә.

— Мә, апа-җаным! — ди. — Эчеп җибәр! Шифалы булсын!

## Гамил Афзал

### Иртә килгән көз

Ачуланган председатель
Ачынып вәгазь укый:
— Алланың рәте калмады,
Җәй белән көзне бутый.

Җәй буе яңгыр яумады,
Коя да коя көзен.
Түзәрлек хәлем калмады,
Тәгәрәп үлим үзем!

Миңа үч итеп ява ул,
Минем намуска ява, —
Игеннәр кырда кала да,
Абзагыз шелтә ала...

Агайлар кайта басудан,
Кирза итекләр — бер пот.
Мунча ягалар, ачудан
Әтәч суялар тотып.

Юеш тупыллар өстендә
Күгелҗем төтен төсе.
Яшәсен эссе ләүкәләр
Һәм дә себерке исе!

Бер туктый да, урап килеп,
Коя да коя һаман.
Яңадан яз килгән кебек
Яшәреп китте ялан.

Урамда казлар коена,
Уйлары — үлән генә.
Конторга ирләр җыела,
Чырайлар сүрән генә.

Борчулы-салынкы кашлар,
Борчулы йөзләре дә.
Мәшәкать күрәсе башлар,
Беләләр үзләре дә:

Яңгырлар күпме яумасын,
Озакка бармас әле.
Йөрәкләр күпме янмасын,
Гомергә янмас әле.

Игеннәр урылып бетәр,
Курмы да җитәр әле.
Көз керер, бәлешләр пешәр,
Киленнәр төшәр әле...

●

Апрель ае төсләргә бай, хисләргә бай,
Уйландыра ачык зәңгәр кичләрдә, һай;
Күк йөзеннән йөзеп бара ямансу ай,
Армиясез кайтып барган Наполеондай.

●

Директива килә, оклад килә,
Сукно җәйгән өстәл озынча.
Курчак иканеңне белә-белә,
Тиргәшәсең тәртип буенча.

●

Бер абзый халыкка әхлак өйрәтә,
бик тырыша, имди.
Ә аның үзен хатыны өйрәтә,—
бик орыша җиңги.

## Кашфел Задә

### Бер шагыйрьнең зары

Күңелемдә фикер туа минем! —
Шигъри фикер... утлы юллар туа...
Шапырыну түгел! — нәкъ Тукайча
(иң кимендә Гәрәй Рәхимгә тиң)
Җырлар туа.
Күңелемдә сурәт балкый минем!
Шигъри сурәт...
Шундый якты, нурлы!
Равил Фәйзуллинча оригиналь,
Дәрдмәнд
(яки Ренат Харис!) кебек... моңлы.
Күңелемдә шигырь туа минем!
Гүя яшен —
Ул ялт итеп тора.
—... Кем соң әйтә анда:
— Язганыңны
(«Сөйгән» шагыйрьләрен инде мактап беткән,
Чират, имеш, хәзер миңа җиткән!)
Тәлгать Галиуллин — үзе! — көтеп тора.
...Тиле шигырь! Ник аңламый шул бәхетне,
Оялчан кыз кук гел качып, өркеп тора?!.

# БЕРВАКЫТ ШУЛАЙ БУЛА...

## Хатка каршы хат

Бернард Шоу режиссерлардан үз пьесаларын беркайчан да һәм берничек тә кыскарттырмаган. Лондондагы бер театрның директоры, Шоу комедиясен куярга хәзерләнгәндә авторга түбәндәге хәбәрне җибәрә: «Пьесагызны әз генә кыскартырга рөхсәт итегез, юкса, читтән килгән тамашачылар соңгы поездга өлгерә алмыйлар».

Шоу аңа болай дип җавап бирә: «Кыскартырга ярамый, поездлар расписаниесен үзгәрттерегез».

## Юл бирү

Атаклы Джонатан Свифт бер чакны урамнан узганда ниндидер бер тәрбиясез егет аның алдына ук килеп туктый да: «Мин ахмак кешеләргә беркайчан да юл бирмим!» — ди.

— Ә мин исә ахмакларга да юл бирәм! — дип, читкә борыла «Гулливер сәяхәте» авторы.

## Гафу үтенү

Инглиз язучысы Оскар Уайльдны кулга алып төрмәгә утырталар. Аның белән күрешергә бер дусты килә. Шуның белән саубуллашканда язучы әйтә икән:

— Гафу ит инде, мин сине озатырга чыга алмыйм.

## Кем язганын әйтегез

Вольтерның укый-яза белми торган хезмәтчесе бервакыт аңардан үзенең авылдагы туганнарына хат язып бирүне үтенә. Язып бетергәч, Вольтер хатны кычкырып укып бирә дә:

— Тагын ни дә булса өстәргә кирәкмиме? — дип сорый.

— Кирәк, әфәндем, — ди хезмәтче. — Хатның шома язылмавы өчен гафу үтенергә һәм аны сез үзегез язган икәнен дә өстәп куярга кирәк.

## Икеләтә сәләтле автор

Ниндидер бер яшь язучы Конан-Дойлга үзенең детектив роман кулъязмасын китерә һәм шуның турында фикер әйтүен үтенә. Бераз вакыт үткәч, кулъязма авторына түбәндәге язу килә: «Китабыгыз бик әйбәт! Ул авторның җинаятьченең эчке дөньясына ни дәрәҗәдә тирән үтеп керә алганын аңлатып кына калмый, бәлки аның бүтәннәр сюжетын урларга гаять сәләтле талант иясе булуын да бик ачык раслый!»

## Искиткеч хәл

Бер вельможа бүлмәсендә Вольтер уннан артык парик күрә.
— Искиткеч хәл бит бу! — ди атаклы философ, чыннан да исе китеп. — Башы юк кешегә ничәмә парик эшләгәннәр.



## Ничек истә тотарга

Үткен генә бер хәбәрче Альберт Эйнштейннан интервью алыр өчен аңа үзенчә бик оригиналь сорау бирә:
— Истә тотар өчен, сез үз фикерләрегезне язып барасызмы? Әллә булышчыларыгыз күпме? Әллә картотекагыз бармы?
— Хөрмәтле дустым,— ди аңа бөек физик,— олы һәм зирәк уйлар кеше башына бик күп килми ул, аларны яттан белүе дә бик җиңел.

## Яңа профессия иясе

Инде бөтен Европага күптән танылган Виктор Гюго Пруссия буйлап сәяхәт кылырга була. Чик аша үткәндә жандарм әһелләреннән берәү, аңардан сорый-сорый, анкета тутыра:
— Нинди эш белән шөгыльләнәсез, мсье?
— Язам.
— Яшәр өчен кирәкле малны ничек табасыз дип сорыйм мин сездән?
— Каләм белән.
— Алайса, шулай дип язабыз да: «Каләм белән сату итә».

## Төзәтү кирәк

Бер драматург күренекле тәнкыйтьчегә сорау бирә икән:
— Ничек уйлыйсыз, пьесага нинди дә булса төзәтүләр кертү кирәк түгелме?
— Минемчә, кирәктер кебек, дустым. Әйтик, мәсәлән, сезнең героегыз асылынып түгел, ә атылып үлсен иде.
— Ә ни өчен алай?
— Мылтыктан аткан тавыш тамашачыны йокыдан уятачак.

## Куркырга урын юк

Әле бөтенләй яшь чагында Лев Толстой комедия яза һәм аны бөек рус драматургы Островский укып каравын тели. Островский исә, цензурада ашыгыч эшләрен ачыклау өчен Петербургка китүе сәбәпле, аны яңа елга кергәч кенә укый алачагын әйтә. «Ә иртәрәк мөмкин булмасмы?» — дип сорый комедия авторы. Островский аңа болай дип җавап бирә:
— Син комедияндә фашлаган бәндәләр беренче гыйнварга чаклы бетәрләр дә кешелек дөньясы кимчелекләрдән тәмам азат булыр дип куркасыңмы әллә син?

## Әйбәт кыланыш

Үзенең туган көне кичәсендә Чарли Чаплин кунакларның күңелен ачар өчен мәҗлестәгеләрнең барысына да таныш ирләр, хатыннар һәм балалар булып кылана икән. Хәтта бер операдан ария дә җырлап күрсәтә.

— Мин сезнең болай шәп җырлавыгызны әле белми идем, — ди табындагыларның берсе.

— Ә мин бит гомумән җырлый белмим, — ди аңа Чаплин. — Мин бит җырчы Карузо булып кыландым гына.

## Иң дөрес киңәш

— Яңа пьеса язып бетердем диярлек, тик азагын төгәлли алмыйм — героемны ничек үтерергә әмәл табуы кыен.

— Ә син аңа пьесаңның инде язылган хәтлесен укыт.

## Бүләкнең файдасы

— Туган көнемдә хатын миңа «Семья экономиясе буенча мең дә бер киңәш» дигән китап бүләк итте.

— Ә файдасы булдымы соң?

— Менә алты ай тәмәке тартмыйм инде.

## Сәбәбе бер генә

— Минем хикәянең ахыры сезгә ник ошамады икән соң?

— Чөнки ул башыннан бик еракка киткән.

## Җиңел хәл ителгән бәхәс

Берәү, аның үзе уйлавынча, бик кызыклы һәм оригиналь мәсьәләләрне күтәргән әсәр яза. Әмма кайберәүләр аның белән килешмиләр. Бәхәсне хәл итәр өчен галимгә мөрәҗәгать итү кирәк була. Галим, кульъязманы карагач, бәхәскә урын калдырмаслык итеп:

— Сезнең хезмәтегез бер үк вакытта кызыклы да һәм оригиналь да. Бәхетсезлеккә каршы, кызыклы өлешләре оригиналь түгелләр, ә оригиналь өлешләре кызыклы булып чыкмаган,— ди.

## Әле укымаган

— Сезнең китабыгызның азагы бик уңышлы.

— Ә аның беренче өч өлеше турында фикерегез ничек?

— Гафу итегез, мин аларына барып җитмәдем әле.

## Бүтәннәр әйткәнне әйтә

— Минем соңгы китабымны бер тәнкыйтьче ничек тетеп ташлаганын укыдыңмы?

— Ә-ә-ә... Бер дә исең китмәсен һәм игътибар да итмә. Ул бит, попугай шикелле, башкалар әйткәнне генә кабатлый.

## Илһам чыганагы

— Сезнең соңгы никахыгыз уңышлы булгандыр дип уйлыйм.
— Ярыйсы ук нәтиҗәле! Хатынымның үткән тормышыннан алып инде өч роман яздым.

## Кайсы да ярый

— Миңа нинди дә булса берәр китап сатсагыз иде!
— Сезгә тизрәк укыр өчен җиңелрәге кирәкме?
— Анысы барыбер, чөнки мин бирегә машина белән килдем.

## Йокы — зур фикер

Әсәрен яманлап язганы өчен, бер яшь драматург тәнкыйтьчегә бәйләнә икән:
— Әсәрнең яхшымы, начармы икәнен каян беләсез? Сез бит спектакль барганда йоклап утырдыгыз!
— Кайчакта йокы үзе дә зур фикер ул, — дип җавап биргән тәнкыйтьче.
Курыкма, син чирләмәссең.

Башлап язучы тәнкыйтьче белән сөйләшә:
— Гениаль булу үзе бер чир диләр, дөресме шул?
— Ул яктан тыныч булыгыз, сезгә ул чир йогар төсле күренми.

## Бүтән билге юк

— Профессор әфәнде, миңа әдәбият теориясеннән «начар» билге куюыгызны һич аңлый алмыйм.
— Нишлим соң, энем, аннан да түбән билге юк бит.

## Кем түләде икән дисәгез

— Ура! Минем «Сәлат» дигән хикәям өчен биш доллар акча кулга керде! — дип куана бер яшь язучы.
— Каян керде соң ул?
— Тимер юл компаниясеннән. Чөнки кулъязманы алар югалткан.

## Поэма юкка чыккач

— Кичә язган поэмамның кулъязмасын таба алмыйм, — ди бер шагыйрь, — аны бәләкәч Жан учакка ташламадымы икән?
— Юкны сөйләмә, Пьер — ди аңа хатыны, — бала бит әле хәреф тә таный белми.

## Ашка начар рецензия

— Кадерлем, бүгенге төшке аш сиңа ошадымы? Бу бит минем үз композициям.
— Киләчәктә, әнкәсе, элеккеге өлкән осталар язганнар буенча эш итсәң яхшырак булыр.

## Бердәнбер булганга күрә

— Бу кеше балаларны бик ярата: күргән бер малай кулына, бүләк итеп, рогатка тоттыра.
— Булыр-булыр! Ул бит безнең якта бердәнбер пыялачы!

## Ата белән улы сөйләшә

Яшь доктор атаклы профессор булып танылган әтисенә:
— Шатлыгым бар! Син ун ел рәттән дәвалаган бер өлкән абыстайны тәки аякка бастырдым бит! — ди.
— Бик яхшы булган һәм ул ханым аңа лаек та. Чөнки син укыган өчен түләгән акча — аның кесәсеннән иде.

## Хәтер иясе

Бер станциядә пассажир буфетка чыга. Утырганда ялгышмас өчен, вагон номерына күз сала:
— 1492. Хәтерләү өчен бик яхшы сан: Американы ачкан ел.
Ә берничә минут узуга поездга әйләнеп килгәч исә ул тимер юл хезмәткәреннән:
— Американы кайчан ачканнарын белмисезме? — дип сорый.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## РСФСР ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ IV СЪЕЗДЫ

*
* *

Узган елның 15—18 декабренда РСФСР язучыларының чираттагы IV съезды булып узды. Татарстан язучылары оешмасыннан анда 20 делегат (Г. Ахунов, Ә. Баянов, Ш. Бикчурин, Х. Вахит, Ш. Галиев, А. Гыйләҗев, М. Зарипов, М. Маликова, Ә. Маликов, Ш. Маннур, З. Нури, Ф. Миңнуллин, В. Нуруллин, М. Скороходов, Р. Фәйзуллин, С. Хәким, М. Хәбибуллин, Я. Халитов, М. Шабаев, И. Юзеев) катнашты. Съездның кунаклары итеп бездән тагын 15 әдип чакырылган иде.

*
* *

Россиядә 50 телдә китап чыгарган һәм 4 меңгә якын әдипне берләштергән зур иҗат коллективының бу съездында «Коммунизм төзүнең хәзерге чорында Россия әдәбияты» дигән темага доклад (Сергей Михалков), Союзның ревизия комиссиясе доклады (Евгений Пермяк) һәм съездның мандат комиссиясе председателе (Олег Шестинский) доклады тыңланды. Милли әдәбиятларны рус теленә тәрҗемә итеп пропагандалау турында Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов сөйләде. Әдәбиятның тегe яки бу проблемасын анализлауга багышланган иллеләп чыгыш булды.

*
* *

Съезд республика Язучылары союзының житәкче органнарын — 172 кешедән идарә составы һәм 67 кешедән ревизия комиссиясе — сайлады. Татарстан Язучылары оешмасыннан идарә составына Г. Ахунов, А. Расих, С. Хәким, Р. Фәйзуллин керде. Ревкомиссия члennары — Ә. Маликов һәм М. Шабаев.

*
* *

Съезд СССР Язучылары союзының 1976 елның июнь аенда уздырылачак VI съездына РСФСРдан 276 делегат сайлады. Татарстаннан делегатлар: Гариф Ахунов, Ләбибә Ихсанова, Рафаэль Мостафин, Туфан Миңнуллин, Зәки Нури, Геннадий Паушкин, Атилла Расих, Равил Фәйзуллин, Сибгат Хәким, Фатих Хөсни.

Съезд сайлаган яңа идарәнең беренче пленумында РСФСР Язучылар союзы идарәсенең председателе итеп Сергей Михалков, председатель урынбасары итеп Юрий Бондарев, идарә секретарьлары итеп 33 кеше (Татарстаннан Гариф Ахунов) сайланды.

*
* *

Мәскәүдә СССР халыклары әдәбиятлары әсәрләрен туплаган махсус китапханә бар. Ул — Николай Некрасов исемендәге китапханә. Татар укучылары белән шул китапханәдә очрашуда съездга килгән язучыларыбыз М. Садри, Ш. Маннур, С. Хәким, Ә. Маликов, Г. Ахунов, В. Нуруллин, С. Сөләйманова, М. Маликова, Ш. Галиев, И. Юзеев, Р. Батуллин катнаштылар.

*
* *

Мәскәүдәге электровакуум җиһазлары заводы цехларында съезд делегатларыннан Тельпугов (Мәскәү), Чепуров (Ленинград), Островой (Мәскәү), Смердов (Новосибирск), Ирошникова (Мәскәү), Зәки Нури (Казан) укучылар белән очраштылар.

## РӘССАМНАРЫБЫЗ ОТЧЕТЫ


РСФСР республикалары һәм өлкәләре рәссамнарының «Совет Россиясе» исемле бишенче күргәзмәсен илебез халыклары үткән ел азагында Мәскәүдәге Үзәк күргәзмә залында карадылар. Ул партиянең



*Татарстан алтыны. Х. Якупов.*

XXV съездына багышланган һәм «Безнең замандаш» дип аталган иде. «Күргәзмәгә кергәндә,— дип язылды ул көннәрдә,— ин

беренче сурәт буларак өсләренә сырма, халат, аякларына күн итекләр кигән кызлар күзгә ташлана... Ә күзләрендә аларның берьюлы арганлык та, җитдилек билгеләре дә чагыла... Тагын шундый контраст: читтәрәк электросварка утлары ялтырый, ә бер кызның кара бияләенә кунган ак күбәләк күренә...» Бу күргәзмәнең танылган рәссам Харис Якуповның «Чаллы гүзәлләре» дигән шушы картинасын караудан башлануында зур мәгънә бар: димәк, заман темасын, күтәренке хезмәт пафосын, тормыш гүзәллеген, кешеләр мөнәсәбәте матурлыгын якты буяулар белән оста сурәтли белергә кирәк. Өч меңнән артык рәсем, графика, плакат, скульптура, монументаль-декоратив һәм сәхнә әсәрләрен декорацияләгән хезмәтләр арасында шулай күренә белү ил тамашачыларының тирән хөрмәтенә лаек! Күргәзмәдә шулай ук хезмәт коллективлары, яңа төзелешләр, хәзерге колхоз һәм совхоз



*Кама акчарлаклары. В. Скобеев.*

кешеләре тормышының иҗади елъязмасын сурәтләгән әсәрләре белән Татарстаннан В. Скобеев («Кама акчарлаклары»), В. Попов («Чаллы яклары»), Р. Госманов («КамАЗ» сериясе акварельләре), М. Усманов («Камада яңа шәһәр»), Э. Ситдиков, И. Колмогорцева, Р. Имашев, В. Маликов, Х. Хәйдәров, И. Зарипов катнашты.

## КӨН ТӘРТИБЕНДӘ — ТЕЛ ҺӘМ ӘДӘБИЯТ УКЫТУ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

«Татар мәктәпләрендә укыту-тәрбия процессын камилләштерү» дигән темага фикер алышу өчен Казанда фәнни-практик конференция үткәрелде. Анда республикабызның мәгариф хезмәткәрләре, укытучылар һәм унике тугандаш республика һәм өлкәләрдән вәкилләр катнашты. Мәктәпләрдә туган телне, рус телен һәм әдәбият укыту проблемалары буенча үткәрелгән конференциядә дистәгә якын доклад һәм чыгыш тыңланды.

## КИТАПХАНӘЛӘР ҺӘМ ЯШЬЛӘР

Яшь буынны коммунистик рухта тәрбияләү эшендә китапханәләрнең роле темасына үткәрелгән фәнни-практик конференцияне республикабыз культура министры Ә. С. Миндубаев ачты. Комсомол оешмаларының соңгы еллардагы сугышчан эшчәнлеген анализлаган төп доклад белән ВЛКСМ өлкә комитеты секретаре З. Г. Бохараев чыкты. Ленин исемендәге республика фәнни китапханәсе директоры М. Х. Делешова яшьләр белән эшләү буенча китапханәләрнең бурычлары һәм практик чаралар турында сөйләде.

## ДҮРТ КӨН РӘТТӘН МУЗЫКА ЯҢГЫРАДЫ

Республикабызның Композиторлар союзы «Партиянең XXV съездын каршылап» дигән темага махсус багышлап үткәргән чираттагы пленумына (декабрь, 1975), гадәттәгечә, барча шагыйрьләрне һәм әдипләрне чакырды. Анда төрле темага күп төрле жанрда язылган яңа үрнәкләр башкарыласы билгеле иде: Нәҗип Җиһановның алтынчы симфониясе, Фасил Әхмәтов, Анатолий Луппов һ. б. ларның симфоник музыкасы, яңа шигырьләргә язылган яңа көйләр, инструменталь музыка... Аннары халык уен кораллары оркестры һәм хор музыкасы концерты, Казан дәүләт консерваториясе студентларының иҗат отчеты... Пленум көннәрендә барлыгы иллеләп яңа әсәр тыңланды һәм тикшерелде.

## 1976 ЕЛ ПЛАНЫ БУЕНЧА МӘСКӘҮДӘ ЧЫГАЛАР

Үзәк нәшриятларда татарчадан русчага тәрҗемә ителеп быел бастырыласы китаплар инде чыга башлады. Шәхси китапханәләр өчен һәм җәмәгать китапханәләренә, мәктәпләргә, культура һәм фән учакларына заказ биреп алдырырга теләгәннәр өчен аларның исемлеген кайбер кыскача аңлатмалар белән белдерәбез:

## «ХУДОЖЕСТВЕННАЯ ЛИТЕРАТУРА» НӘШРИЯТЫ

1. (114 [1]). Галимҗан Ибраһимов. Романнар һәм хикәяләр (Романы и рассказы): «Тирән тамырлар», «Казакъ кызы», «Карт ялчы», «Габдрахман Салихов». 22 табак.

2. (146). Муса Җәлил. Сайланма әсәрләр (Избранное). Рәсемнәр белән тулыландырылган басма. 7 табак.

## «СОВЕТСКИЙ ПИСАТЕЛЬ» НӘШРИЯТЫ

3. (284). Шәүкәт Галиев. Кыңгырау турында баллада (Баллада о колоколе). Шигырьләр. 3 табак.

4. (307). Зәки Нури. Күңел дусларга тарта (Навстречу дружбе). Яңа шигырьләр. 3 табак.

5. (318). Равил Фәйзуллин. Кайтыш мизгеле (Миг возвращения). Шигырьләр. 3 табак.

[1] Нәшриятларның тематик планнарында һәр китапның билгеләмәсе булган рәсми саннар.

## «СОВРЕМЕННИК» НӘШРИЯТЫ

6. (179). Гариф Ахунов. Хәзинә (Клад). Роман. 26 табак.
7. (191). Роберт Әхмәтҗанов. Июнь иле (Страна июнь). Шигырьләр. 3 табак.
8. (168). Гомәр Бәширов. Намус (Честь). («Россия романы» сериясе). 18 табак.
9. (161). Эдуард Касыймов. Чулман — оныклар елгасы (Чулман — река внуков). Повестьлар. 24 табак.
10. (219). Флүн Мусин. Тормыш координаталары буенча (По координатам жизни). Соңгы еллардагы татар прозасын тәнкыйть күзеннән үткәреп анализлы күзәтү. 8 табак.
11. (204). Муса Җәлил. Утлы тоткын (Узник огненный). Сайланма шигырьләр. 4 табак.
12. (194). Камил Мостафин. Йөздә беренче могҗиза (Сто первое чудо). Шигырьләр. 2 табак.

## «СОВЕТСКАЯ РОССИЯ» НӘШРИЯТЫ

13. (223). Габдулла Тукай. Шүрәле. А. Әминев рәсемнәре белән. 3 табак.
14. (170). Муса Җәлил. Йолдызлар (Звезды). 10 табак.

## «МОЛОДАЯ ГВАРДИЯ» НӘШРИЯТЫ

15. (291). Ибраһим Нуруллин. Тукай. «Атаклы кешеләр тормышы» сериясе. 14 табак.

## «ДЕТСКАЯ ЛИТЕРАТУРА» НӘШРИЯТЫ

16. (354). Ләбибә Ихсанова. Гөлләр кояшка карый (Цветы тянутся к солнцу). Повесть. 12,5 табак.
17. (106). Сандугач (Соловей). Татар халык әкияте. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен. 1 табак.
18. (337). Татар халык әкиятләре (Татарские народные сказки). Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен. 9,5 табак.

## «МАЛЫШ» НӘШРИЯТЫ

19. (29). Муса Җәлил. Иркле җилләр (Вольные ветры). Рәсемнәр белән бизәлгән катыргы тышлы китап. («Совет чоры классикасы» сериясе). 7 табак.

## БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫН КАЙГЫРТЫП

Үткән ел азагында РСФСР Язучылар союзы һәм РСФСР Министрлар Советының матбугат комитеты Астраханьда Идел буе өлкәләре һәм автономияле республикалары (Татарстан, Башкортстан, Чувашстан, Мордва, Мари, Удмурт, Калмык АССР), кара туфраклы Үзәк өлкәләрдән, Ростов, Краснодар, Ставрополь шәһәрләреннән, Төньяк Кавказдан Кабарда-балкар, Чечен-ингуш һәм Дагстан халыклары телендә балалар өчен китап язучы авторлар һәм алардагы нәшрият редакторларының зона семинарын үткәрделәр. Семинар яшь буынга хәрби-патриотик һәм әхлакый тәрбия бирү темасының әдәбиятта инде өлешчә чагылдырылган проблемаларына багышланды. Бу исә асылда балалар өчен китапларны күбрәк һәм яхшырак сыйфатлы итеп чыгару кирәклеге турында сөйләшү иде. Семинарда Татарстаннан язучы Габдрахман Минский һәм нәшрият редакторы Сания Сибгатуллина катнашты.

## НӘШРИЯТ КИЧӘСЕ, ДУСЛЫК КИЧӘСЕ

Казан химиклары белән «Нәшрият кичәсе» дип аталган әдәби кичә үткәрелде. Анда Татарстан китап нәшриятында зурлар һәм балалар өчен матур әдәбият чыгару буенча бүлек мөдирләре шагыйрь Шәүкәт Галиев һәм прозаик Шамил Рәкыйпов китап укучыларны 1976 елда нәшрият бастырып чыгарачак яңа әсәрләр планы белән таныштырдылар, үз иҗатларыннан кайбер яңа үрнәкләр укыдылар. Эшчеләр белән республикабыз язучылары арасындагы иҗади дуслык турында килешү дә шунда расланды.

* * *

Шул ук эшчеләрнең бер төркеме белән очрашуда шагыйрьләрдән Зәки Нури, Геннадий Паушкин һәм Рәдиф Гатауллин үзләренең соңгы елларда язган лирик шигырьләрен укыдылар, укучыларның күп санлы сорауларына җавап бирделәр.

## ПОВЕСТЬ: ХӘЗЕР УЛ НИНДИ ҺӘМ НИЧЕК БУЛЫРГА ТИЕШ

Союзыбызның проза һәм тәнкыйть секцияләренең берләштерелгән утырышында шул темага сөйләшү булды. Соңгы елларда басылып чыккан повестьларның геройлары, сюжет-композиция төзелеше, жанр һәм стиль өлкәсендәге эзләнүләр турында сүзне үз фикерләрен конкрет әсәрләр мисалында ачыклап тәнкыйтьче һәм әдәбият белгече Нур Гыйззәтуллин башлап киткәннән соң, заман тудырган яңа конфликтлар, яңа геройлар проблемасы, бүгенге алдынгы геройны сурәтләүнең төрле формалары буенча фикер алышуларда Ф. Хөсни, Х. Госман, Ф. Мусин, Ф. Хатипов катнашты.

## УКУЧЫЛАР КОНФЕРЕНЦИЯЛӘРЕНЕҢ БЕРСЕНДӘ

Шагыйрь һәм прозаик Әхсән Баянов иҗатына багышланган укучылар конференциясе Казан дәүләт педагогия институтында үткәрелде. Тарих-филология факультеты деканы Фәрит Хатипов һәм өлкән укытучы доцент М. Җәләлиева чыгышларыннан соң студентлардан Фәнил Фәйзертдинов «Яшьлегемне эзлим» повестенда кеше һәм аның таланты», Зәмәрә

Фәйзерахманова «Дүрт монолог» әсәрендә бәхет проблемасы», Мәмдүдә Садрия «Тау ягы» повестенда психологизм» дигән темаларга күзәтү ясадылар.

## «АКТИВ КЕШЕ ПОРТРЕТЫ» КИТАБЫННАН БЕРНИЧӘ СҮЗ

Мәскәүдәге «Прогресс» нәшриятында күптән түгел чыккан бу китапның авторы — Польшада чыга торган «Трибуна Люду» газетасының Советлар Союзында биш ел эшләгән журналисты Ежи Крашевский. Ул илебезнең бик күп якларында, завод-фабрикаларында булган, бик күп милләт кешеләре белән очрашкан һәм аларга хас бер сыйфатны күргән: «Минем бөтен әңгәмәдәшләрем дә белемгә һәм гыйлемгә аеруча көчле омтылалар».

Шундыйларның бер үрнәге итеп ул элекке тракторчы, хәзер Татарстан республикасының мәгариф министры, СССР Педагогия фәннәре академиясе член-корреспонденты Мирза Мәхмүдов турында да яза. Әлбәттә, башта ул Көнбатышта әле хәзер дә татарларны бары тик күчмә тормыш, кыргый далалар һәм тирмә-йортлар белән бәйләп кенә уйлаучылар булгалавын елмаеп әйтә. Чөнки бит революциягә кадәр атаклы Казан университетын нибары 6 татар тәмамлаган, ә элекке Казан губернасының 87 процент халкы укый-яза белмәгәнлеген аңа документлар расланган. «Ә хәзер,— ди журналист,— карты да, яше дә китап укымаган бер генә татар өе дә юк»,— һәм министрыбыз Мирза Мәхмүдов турында түбәндәгеләрне белдерә: «...ул укый-яза белмәүчелекне бетерү программасын эшли, ә аны исә «ЮНЕСКО бюллетены» үсә башлаган барлык илләргә тәкъдим итә. СССРда мәгариф эшенең казанышлары турында рус һәм татар телләрендә үз илендә, гарәп телендә — Көнчыгыш илләрендә, инглиз телендә — Бангкок университетында лекцияләр укый...»

## ШУНДЫЙ КЛУБЛАР КҮП ХӘЗЕР

«Без һәр айда совет шагыйрьләре һәм чит ил шагыйрьләренең яңа әсәрләрен бергәләп укырга, иҗат турында киңәшләшергә һәм бәхәсләшергә, белгәннәребез турында фикер алышырга җыелабыз. Әдәби экскурсияләр оештыру һәм күп милләтле әдәбиятыбызның аерым вәкилләре белән очрашулар да безгә бик ошый. Менә сезне дә, хөрмәтле иптәш, безнең белән шундый иҗади очрашуга чакырабыз...»

Кырымның Евпатория шәһәрендәге шигырь сөючеләр клубы чакыруы буенча бу очрашуга Белоруссиядән, Ленинградтан, Харьковтан, Калмык, Мордва, Якут АССРдан килгән шагыйрьләр белән бергә Татарстан вәкиле буларак Зәки Нури катнашты. Клуб советы аларның барысын а үзенең почетлы членнары итте.

## КОНКУРС ДӘВАМ ИТӘ

Шагыйрьнең шигырьләрен, шигырьләр циклын аерым башкаручылардан кем яхшырак укый? Ә культура йортларындагы, клублардагы һәм мәктәпләрдәге нәфис сүз түгәрәкләре 20—25 минутлык нинди иң яхшы әдәби-музыкаль композиция тәкъдим итә ала?

Шундый смотр-конкурсны Муса Җәлилнең 70 еллык юбилее хөрмәтенә Республика халык иҗаты йорты игълан итте. Зона смотрында үзен инде таныткан осталар һәм коллективларның кайберләре Муса Җәлилнең 70 еллык юбилее тантанасында катнаштылар.

## ӘЛМӘТТӘН КИЛГӘН ОТЧЕТ

Татарстан Язучылар союзының Әлмәт бүлеге үзенең соңгы айлардагы иҗади оештыру эшләре турында түбәндәгеләрне хәбәр итте:

— Урыссу эшчеләр поселогында башлап язучы авторлар семинары үткәрелде. Анда Заһит Хәкимовның «Сагыныр кешең булганда» исемле повестен, Факил Зәйнетдинов һәм Мөслим Газизов язган хикәяләр һәм очеркларны җентекләп өйрәнгән әдипләрдән Ю. Әминов, Г. Афзал, С. Сөләйманова, С. Кальметов, Э. Мөэминовалар яшьләргә киңәшләр, анализ сүзләре, теләкләр һәм иҗатка юллау сүзләре әйтеп чыгыш ясадылар.

— Техника йорты залында «Әлмәтнефть» идарәсендәге хезмәт бүлекчәләре һәм цехларның политинформаторлары өчен үткәрелгән чираттагы семинарда шагыйрә С. Сөләйманова «Татар поэзиясе — сугышчан поэзия» дигән темага, И. Винокуров Татарстандагы рус шагыйрьләре иҗаты турында сөйләделәр, үз әсәрләреннән яңа үрнәкләр укыдылар.

— «Илһамыбыз — хезмәт батырларына» дигән темага Татарстан радиосы тапшыруында бүлекнең җаваплы секретаре Ә. Маликов, язучылардан Г. Афзал, Р. Төхфәтуллин, Ш. Бикчурин, С. Сөләйманова, Э. Мөэминова, К. Булатова, яшь язучы Г. Кашапов катнашты.

— Казан телевидениесында Рөстәм Кутуй әзерләгән сценарий буенча С. Сөләйманова, Э. Мөэминова, К. Булатова шигырьләре рус телендә яңгырады.



**Яков Свердлов һәм Хөсәен Ямашев.**



**Хөсәен Ямашев «Урал» газетасы редакциясендә.**

**Хөсәен Ямашев Елга ьягы эшчеләре ара- нда.**



**Большевик-революционер әен Ямашевка багышлап**

**Мансур Рәхимов ясаган рәсемнәр.**

## *Хөрмәтле укучыбыз!*

Журналыбызның дүртенче саны Габдулла Тукайның тууына 90 ел тулуга багышланып чыга. Шул уңай белән Гали Халитның «Тукай. Лирик герой» дигән зур мәкаләсе, Тукай иҗатының казакъ, кумык әдәбиятларына йогынтысы турында фәнни хезмәтләр, Нәкый Исәнбәтнең «Г. Тукайның мәгълүм булмаган бер шигыре һәм Мәхмүт Дулат-Али хакында» дигән язмасы, Әхмәт Фәйзинең «Тукай» исемле киносценарие, Ибраһим Нуруллинның «Тукай» әсәреннән өзек, Илдар Юзеев, Рәдиф Гатауллин, казакъ шагыйрьләре Сырбай Мәуленов һәм Кадыр Мырзалиев, яшь шагыйрьләр Фәннур Сафин һәм Зиннур Насыйбуллиннарның Тукайга багышланган шигырьләре һ. б. материаллар урнаштырыла.

Бу санда сез Фатих Хөснинең «Язмышлар» дигән повестен, Равил Фәйзуллинның «Көн уртасында килгән уй...» исемле шигырьләр циклын укырсыз.

Шагыйрь Хисам Камаловка 50 яшь тула. Шул уңай белән журналыбыз аның иҗаты турында Рөстәм Мингалимов мәкаләсен һәм шагыйрьнең «Бу төбәктә истәлек» дигән шигырьләр циклын бирә.

Татар театрының 70 еллыгы якынлашып килә. Истәлекле бу көнгә әзерләнгәндә редакциябезгә театр тарихына караган хезмәтләр, артистларыбызның иҗат портретлары, истәлекләр һ. б. материаллар килде. Шулар арасыннан беренче артисткаларыбыздан берсе Сона ханым Сафиуллина турындагы язманы укырсыз.

Бу санда да республикабыз алдынгылары турында очерклар, публицистик мәкалә һәм яңа китапларга рецензияләр, нәниләр өчен шигырьләр, шаян шигырьләр һ. б. материалларны табарсыз.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210